# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлүсә БАТТАЛОВА. Тукай сандыгы. *Поэма*. ....3
Зөлфәт ХӘКИМ. Серле тәңкә. *Роман*. ....9
Ренат ХАРИС. Үлмәдек, торып бастык... *Шигырьләр*. ....83
Илдус ДИНДАРОВ. Ак төннәрнең кара көннәре. *Повесть*. ....88
Таһир ШӘМСУАРОВ. Җир арынган чакта кыштан... *Шигырьләр*. ....123
Наилә ХАРИСОВА. Мин кайтырга тиеш. *Хикәя*. ....127

ЯҢА ИСЕМНӘР

Фәнис ЗЫЯЛЫ. Ян син, ян, ярсу йөрәгем... *Шигырьләр*. ....139

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Лилия ФӘТТАХОВА. Гаярьнекеләр. *Хикәя*. ....142

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Дмитрий МОИСЕЕВ. Кеше бакчасыннан өзгән кура җиләге. *Хикәя. Ландыш ӘБҮДӘРОВА тәрҗемәсе*. ....148

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. «Бу бит безнең сукмак!..» ....154

*Шигъри хәтер:* Рашат НИЗАМИ. Ышанасы килә... *Шигырьләр*. *(Рафис КОРБАНның кереш сүзе белән)*. ....162

*Күңел җәүһәрләре:* Индус ТАҺИРОВ. Халкыбызның раушан көзгесе. ....166

*Китап күзәтү:* Флёра СӘЙФУЛЛИНА. Шәхси архив серләрен милләтебезгә ачып... *(«Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат», төзүче Зөфәр Мөхәммәтшин)*. ....171

*Милләттәшебез:* Хәйриячелекне якыннарыңнан башларга кирәк. *(Ильяс ГЫЙМАДОВ белән Алинә ХӘБИБУЛЛИНА әңгәмәсе)*. ....175

*Хатлар яздым утырып:* Әдип хатлары. *(Наҗар НӘҖМИнең Халисә МӨДӘРРИСОВАга язган хатлары)*. ....178

«Казан утлары» архивыннан. ....185

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Батырлык һәм матурлык җырчысы *(Самат ШАКИРның тууына – 100 ел)*. ....187
Оныкларым белән бергә язам *(Бикә РӘХИМОВАның тууына – 85 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара*. ....188

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде*. ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 4 (1218) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.03.2024, график буенча 28.03.2024, басылып чыгу вакыты 03.04.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-0665. Тираж 4550.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Гөлүсә
Батталова

# ТУКАЙ САНДЫГЫ

ПОЭМА

*Габдулла Тукайның кечкенә генә сандыгы булуы аның белән Җаек мәдрәсәсендә бергә укыган сабакташларының истәлекләрендә үк телгә алына. Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылындагы борынгы таш мәчеттә сакланган агач сандык – Тукайның замандашы, Җаектагы дусты Нәҗип Нигъмәтуллинныкы.*
*Сандык төбенә «Караван» фабрикасының чәй кабы кәгазе ябыштырылган. Ул капта Габдулла Тукайның «Тәүлек» шигыре дә басылган. Шигырь үзе 1908 елда «Бәянелхак» ширкәте заказы белән языла.*
*Нәҗип Нигъмәтуллин 1909 елда туган авылына – Әтнә районы Түбән Бәрәскәгә кайтышлый, Казанда, Тукай янында – «Болгар» номерында туктала. Бу аларның соңгы күрешүләре була.*
*Барлык мәгълүматларны да искә алып, әлеге сандыкның Габдулла Тукай сандыгы булуы ихтималын фараз кылырга җөрьәт итәм. Бу сандык тарихы әлегәчә галимнәр тарафыннан өйрәнелмәгән.*

**Автор**

Иң әүвәле кемнең кулы тигән,
Кайсы оста түккән күз нурын?
Хәтерләми тарих. Сәбәп итеп
Инде шактый вакыт узуын.

Хәтерләми тарих! Хәтерләми
Бу сандыкта яткан серләрне.
Башны салып бер тыңларга иде,
Күп ләбаса аның сөйләре.

Бу сандыкта ятим әрнүләре,
Өмет-ният таслап төрелгән.
Бу сандыкта аның хыяллары
Соңгы күмер кебек сүрелгән.

Өе дә юк, малы-мөлкәте дә,
Бар байлыгы – шул бер сандыгы.
Шунда сыйган бөтен тормыш йөге,
Сыйган анда бөтен барлыгы.

Сандык, гүя, гаиләсе дә аның,
Чын дусты да – инде сыналган.
Гади тактадан ул, тик шулай да
Тулы язмыш аңа сыялган.

Фаҗигасе, әллә бәхетеме,
Сандык белән үткән гомере.
Төпләрендә аның ята кебек
Шагыйрь йөрәгенең күмере.

Табиб куйган диагноз да монда
Яшерелгән якты дөньядан.
Шагыйрь, бәлки, шул сердәше барга
Язмагандыр җирдә кыйбладан.

---

Гөлүсә БАТТАЛОВА (1982) – *шагыйрә; «Бер йотым бәхет», «Кесә тулы – давыл!» исемле китаплар авторы. Әтнәдә яши.*

## Җаек шәкерте

*«Габдулла мәдрәсәдә дә шәкертләр сафсатасына күп кушылмый, үз урынында гына кечкенә генә бер сандыгыннан алып, әллә нәрсәләр генә укыган һәм язган булып утырганы күренгәли иде. Кайсы вакытларда моңланып кына тавышын чыгарыр-чыгармас бәетләр укыганы, озын көйләремезне матур гына иттереп көйләп җибәргәне дә ишетелә иде... Менә бервакытларда Габдулла әфәнде сандыгында төрле хикәят китаплары да күренгәлиләр...»*

Ярулла Муради,
Г.Тукайның Җаекта «Мотыйгия» мәдрәсәсендә
бергә укыган сабакташы истәлекләреннән.

Әйләник бер Җаек урамнарын,
«Мотыйгия»[1] тора чакырып.
Мәдрәсәдә Габдулла да укый,
Күләгәсе китә чагылып.

Бөтенләй үк күченгәндә беркөн
Агач сандык иде кулында.
Ә эчендә – китап. Ул – төп азык,
Хәзинәи тәгам югында.

Шәкертләргә Аллаһ шаянлыкны
Күмәртәләп бирә, тәгаен.
Пәри туе купса ялгыш кына,
Шайтан үзе качар, мөгаен.

Ә Габдулла – читтә. Сандыгыннан
Ала да ул китап-дәфтәрен
Исе китми дөнья гамьнәренә,
Күрә һаман уку хәстәрен.

Йә булмаса, озын көйләр суза,
Бәет әйтә шулай үзалды.
Кинәт кенә йөзе алсулана
Һәм яктырып китә күз алды.

Сандык шаһит күңел давылына,
Сандык шаһит тәүге ютәлгә.
Шагыйрь булып җитешкәндә шәкерт
Мәҗбүр икән ниләр үтәргә?

Халык гамен җан ярасы итеп,
Җан догасы итеп күтәреп,
Белгән микән Тукай яшен кебек
Яшьнәп кенә җирдән китәрен?
Белгән микән дөнья юшкыннары
Үпкәсенә беркөн туласын?
«Без китәбез, сез каласыз...» диеп,
Йөрәгенең әрнеп еласын.

***

«Казан» нумирының[2] тугызынчы
Бүлмәсенә күчә барлыгы.
Сандык янда, ул янәшә булгач
Сизелми дә дөнья тарлыгы.

Рух саклаучы изге җан кебек ул,
Төбәп карамасаң – күренми.
Искәрмәсәң, аның бәһасе дә,
Кадере дә бик үк беленми.

Җаектагы көннәр ага тора,
Төрлесе бар туган таңнарның.
Күңел дәфтәренә языла бара
Хәерхаһлылары җаннарның.

Буфетчы дус Нәҗип[3] булган чакта
Баш очында, түбә, ризык бар.
Кемдер кайчак тез астына суга,
Язмыш бармый туры сызыктан.

Миңлебай[4] да янда, Әхмәтша[5] да...
Җан сызлаткан сүзләр сөйләнә...
Мут елмаеп, дуслар сорап куя:
«Шагыйрь егет кайчан өйләнә?»

---

[1] «Мотыйгия» – XIX гасыр уртасында төзелгән Җаек шәһәрендәге дини уку йорты, җәдиди мәдрәсә, XIX гасырның танылган мөселман уку йортларының берсе.
[2] «Казан» нумиры – 1905 елның ноябрь аенда Җаек шәһәрендә ачылган «Казан» кунакханәсендәге бүлмә.
[3] Нәҗип – Нәҗип Зариф улы Нигъмәтуллин (1889-?) – Казан губернасы Казан өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Әтнә районы) Югары Бәрәскә авылы кешесе, Г.Тукайның замандашы, дусты. Ул – 1905–1914 елларда Җаекта яшәгән. «Казан» кунакханәсендә буфетчы булып эшләгән, Г.Тукайдан рус телен өйрәнү буенча дәресләр алган.
[4] Миңлебай – беренче татар профессиональ театр труппасына нигез салучыларның берсе Габдулла Кариевның чын исеме.
[5] Әхмәтша – Габдулла Тукайга рус телен өйрәтүче хәлфә – Әхмәтша учитель.

«Юк, туганнар, минем әле алда
Караласы була солдатка...
Аннан соң мин ошбу җир йөзенә
Килмәгәнмен кебек озакка...»

Пәйгамбәрлек әллә, шаярумы?
Кем аңласын шагыйрь тел-төбен.
Җан түренә кул сузучы булса,
Күзгә җибәрер ул төтенен.

Сандык кына шаһит: керфек какмый
Үткән төннәренең санына.
Мыштым гына, ютәл битлегендә
Үпкәләргә үлем сарыла.

Сандык кына шаһит, шагыйрь үзе
Искәрмәгән булып кылана.
Төннәр буе китап, ютәл, китап...
Ә иртәнгә күзләр кызара...

Ә иртәнгә... гәҗит-журнал эше,
Дөнья мәшәкате җитәрлек.
Ил-көн кайный, йөрәк кенә түзсен,
Уйлый калсаң, исең китәрлек.

Хәреф җыя[6] – кайсы дәвердә дә
Кургаш йота сулар һаваны.
Үпкәләргә тула, тынны буа –
Кайдан алсын егет дәваны?

Җаек – газиз, инде күнегелгән,
Монда дуслар, монда җандашлар.
Әмма Мәккә – Казан, ашкындыра
Туган туфрак, анда якташлар!

Үзе белән ниләр алсын шагыйрь?
Бәгырь тулы шигъри ут кына...
«Минсез кузгалма» дип иңри кебек
Агач сандык, бары ул гына.

Аннан башка юл хәерле булмас,
Сандык – сердәш, сандык – юлдашы.
Дуслар җыелышкан мая белән
Туган якка насыйп юл башы.

Моңсу калыр Җаек урамнары,
Гамьле яшьләр калыр сагышлы.
Китәр шагыйрь, офыкларга йотар
Габдулланы кояш баешы.

## Әтнә никруты

*«Кайвакыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем. Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман әтинең сабакташы йә дусты булгангамы, нидәндер миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде. Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда юл буе ашап кайта идем...»*

Габдулла Тукай «Исемдә калганнар».

*«1907 ел август айлары килеп җитү белән, Тукай Казан ягына – туган илгә кайтып, солдатка каралу мәсьәләсен башына китереп куйды... Тукай Казанга киткәндә, кулына хат язып биреп, минем туган илемә, Әтнә районы Югары Бәрәскә авылында торучы атам Зариф Нигъмәтуллинга тапшырырга һәм солдаттан каралып кайтышлый минем авылыма, минем өемә барып, кунак булуын үтендем.»*

Нәҗип Нигъмәтуллин,
Г.Тукайның замандашы, Җаектагы дусты истәлекләреннән.

*«Габдулла Каенсарга кайткач, апасы-җизнәсенең лапас бурабзар стеналарына аларга атап шигырьләр язып калдыра.»*

Фатыйма Габделкәримова –
Тукайны күреп белгән Зәйнәп Хәсәниянең сеңлесе истәлекләреннән.

Ку атларны, әйдә, ямщик дускай!
Сагындырган туган туфрагы.
Ширбәт төсле хәтта көз һавасы,
Үз җиреңнең көзге яфрагы.

Әтнә урамнары... Балачакның
Ак күмәчле базар чатлары.
Хатирәләр касәсенең чите
Бүген менә янә чатнады.

---

[6] 1905 елгы революция йогынтысында Җаек шәһәрендә демократик юнәлештәге «Фикер» газетасы, «Әлгасрел-Җәдит» журналы, соңрак «Уклар» исемле сатирик журнал чыга башлый. Г.Тукай әлеге басмаларда хәреф җыючы, корректор, мөхәррир, актив автор була.

Һәм түгелде күңел... Шатлык белән,
Әрнүләре бергә укмашкан.
Гүя тылсым тулы төшләр белән
Ачы чынбарлыгың тоташкан.

Волость идарәсе ишегалды
Тулып ташкан бүген халыктан.
Кемдер яңа килгән, ә берәүләр
Көтә-көтә инде ялыккан.

Үктәбрнең ахыры. Өстә – пальто,
Яхшы ботинкалар аякта.
«Кем булыр бу? – дип сөйләшә ир-ат –
Болай киенмиләр бу якта?»

Авыл никрутының[7] аягында
Тула оек белән чабата.
Өстендә – тун яки иске чикмән.
Ә бу егет сәер, чынлап та.

«Кушлавычның хәзрәт улы, диләр,
Бик гыйлемле егет, имештер.»
Дүрт волостьтән килгән никрутларның
Кайберләре шулай диеште.

Номер алды егет. Зур сан чыкты.
Озак әле, димәк, көтәсе.
Йөрәк ярсый чабышкы ат кебек,
Гүя алда сират үтәсе.

Никрут булу барча ир-егетнең
Кайчан да бер уза башыннан.
Нидер булыр төсле... Күңеле дә
Бәргәләнә сәер ташкыннан...

Олы Мәңгәр Габделвәлиләргә
Тукталып ул – чират көткәндә
Уйга калды, агач сандыгының
Юл тузанын ышкып сөрткәндә.

Нинди бетмәс ютәл булды соң бу?
Әллә куба дөнья юшкыны?
Әллә сулу кабып йөткерәмме –
Туган якка кайттым ашкынып?

Дәшми сандык. Дәшми тыңлый белә.
Йота белә шикле уйларны.
Аның белән шагыйрь бәхетен дә
Кайгысын да бергә урады.

Чират җитте. Волость идарәсе.
Көнбатышка карый ишеге.
Куллар салкын тоткасына тигәч,
Җан-бавыры кинәт өшеде.

Нидән курка? Солдат хезмәтеме,
Ни өркетә егет бәгырен?
Сизгер йөрәк күкрәк читлегендә
Көтәме соң тәкъдир әмерен?

«Солдатка дип, каралырга» диеп,
Юллар кайтты Казан артына.
Җаны уйный, чандыр бу гәүдәне
Әллә инде ул да тарсына?

Комиссия үтә. Иң дә, буй да җитми.
Бер күзенә әнә ак төшкән.
Шулай дияр, ак билетын тотып.
Шулай дияр таныш-белешкә.

Каенсарга кайтыр. Сәҗидәгә[8].
Шатландырыр сөйгән апасын.
Сандыгына бикләр көн күзеннән
Диагнозы белән ярасын.

Сандыгына бикләр. Белмәс җиһан
Хөкем карарының чыкканын.
«Үпкәндә – чир» дигән табиб сүзе
Аягыннан аны екканын.

Сандыгына яшерер дә шагыйрь
Сөенгәндәй итәр: «Котылдым!»
Үзе генә һәм сандыгы белер
Киләчәкнең шомлы котыбын.

Кем уйлаган, гомер шулай ансат
Бүленер дип бүген икегә.
Юллар ябык, капкалар да бикле,
Кайтып булмый инде кирегә!

Күпме калган? Аймы, әллә еллар?
Әнә тагын ютәл кузгалды.
Үпкәләрдә – шагыйрь үксезлеге,
Үпкәләрдә – тарих тузаны.

Каенсарда бура диварында
Кырып язган шигырь юллары.
«Истәлеккә!» – диде, ә чынында
Сулык-сулык җаны елады.

---

[7] Никрут – хәрби хезмәткә алынган кеше. Рекрут — татар теленә рус теле аша кергән француз сүзе. Татарлар арасында әлеге сүзнең «никрут» формасы киң таралган була.

[8] Сәҗидә – Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдәнең уртак атадан, әмма башка анадан туган сеңлесе – Бибисәҗидә Зиннәтулла кызы Хәбибуллина.

Бәрәскәгә килде. Нәҗип дусның
Хаты кайтты шагыйрь кулында.
Ата-ана өчен шатлык – Тукай үзе
Иптәш булган газиз улына!

Кунак булды. Җаек хәбәрләрен
Сөйләгәндә моңсу елмайды.
Таш мәчетле авыл хәтеренә
Уеп алып калды Тукайны.

Алда – Казан. Пар атларда кайтыр,
Сандыгына салып серләрен.
Язар, язар... «Өлгерергә» диеп,
«Агартырга дөнья керләрен».

Алда – Казан. Алда – яңа дуслар.
Янартаулы шигырь ялкыны.
Ни кичергән шагыйрь ак билетның
Сарылганда җанга салкыны?

Ни кичерде икән шагыйрь җаны?
Күзләренә карап сорарга...
Хөкем карарыннан кул пешкәндә
Никрут белән тулган урамда.

Сандык шаһит тә бит, ләкин дәшми,
Чишми сандык дусты серләрен.
Тик хәтерле булыр мең тугыз йөз
Җидедәге Әтнә көзләрен.

## Казан шагыйре

*«Бу вакытта йорт саен*
*Кайный самавыр һаман;*
*Чәйнекләрдә пешмәктә*
*Чәй — фирмасы «Караван»!*
*Өйдә хуш ис чәчелгән,*
*Һәркем күңле ачылган;*
*Нинди фирма чәе бу! —*
*«Караван»дыр, «Караван!»*
Габдулла Тукай «Тәүлек»

*«Мин – мөсафир... Номерларын «Болгар»*
*Ачар миңа, кайсын алсам да...*
*Яңгыратты коридорны кемдер:*
*– Ишеттеңме, Тукай Казанда!»*
Сибгат Хәким «Кырыгынчы бүлмә»

Казан. «Болгар».[9] Кырыгынчы нумир.
Керә-чыга дуслар-танышлар.
Шагыйрь йөрәгеннән үтә барлык
Гасыр башындагы тавышлар.

Шагыйрь каләменнән үтә бар да –
Ак кәгазьгә таслап түгелә.
Ютәл буа кайчак, күкрәк яна –
Егылмыйча тәмам түз генә.

Үз хәле хәл, ләкин милләт гаме
Өстен икән үпкә чиреннән.
Шигырь уты дөрләп кабынганда
Әҗәл үзе өркеп чигенә.

Көлә шагыйрь тәкъдиренә карап,
Көлеп аргач кинәт тын кала.
Дөнья белән алыш-биреш өзеп,
Сандыгына кереп югала.

Үз эчеңдә рәхәт – алдамыйлар,
Алданмыйсың – базар түгел лә!
Туры Тукайның да берәр заман
Күңел дәрьялары түгелә.

Истә һаман: элек торган бүлмә
Хуҗасына түли алмады.
«Хозяйка»га түләр өчен шагыйрь
Шигырь белән ертык ямады.

Җан биргәнгә юнен бирде Ходай:
«Бәянелхак»[10] шакый ишекне.
«Караван» чәй фабрикасын илдә
Җаны булган һәркем ишетте.

Егерме биш тәңкә – шигырь хакы –
Таралды да бетте тиз генә.
Акча юкта, ялган дусларның да
Кинәт кенә юлы өзелә.

[9] «Болгар» – XX гасыр башында Казанда эшләгән кунакханә. Габдулла Тукай 1907–1913 елларда биредә яшәгән.
[10] «Бәянелхак» – Казанда 1906–1914 елларда чыккан татар сәяси, икътисади һәм әдәби газетасы.

Сандык калыр. Бүлмә уртасында
Күпне күргән олпат карт сыман.
Елмаер да шагыйрь, келәм түшәр
Бушап калган чәе кабыннан.

Кич утырып, төсле чәй кәгазен
Ябыштырыр сандык төбенә.
Гарәп имлясында шигырьләре
Сибелерләр төннең күзенә.

Шигырь тамган бармаклары белән
Сандык такталары сыйпалды:
«Сиңа сыйган шатлык-хәсрәтләрем
Бар җиһанга кайчак сыймады...»

Ютәл буган мәлдә никтер һаман
Шул сандыгын жәлләп күрсенде.
Җан дустына үпкә-шөбһәләре,
Яшьле әрнүләре күп сеңде.

«Кемгә калыр? Затлы мөлкәт түгел.
Чыра итеп ватып ягарлар.
Заман чүбен тутырырга булса,
Башка савыт эзләп табарлар.

Васыять итсәм, бөтен Казан көләр!
Агач сандык әллә малмы соң?
Көфер почмагында көн күткәнгә
Җан кадере җирдә бармы соң?»

Кояш чыкса, кинәт чыга икән –
Җаек дусты Нәҗип сугылды.
Кара төннән якты таңга чаклы
Ерак түгел – бер кул сузымы.

Бәрәскәгә кайтып барыш дусның,
Тик беразга ташлап Җаекны.
Казан арты – туган туфрагына
Озатыр ул бүген сандыкны.

Шушы җирдә кендек каны тамды,
Шул туфракта ачы хәсрәте.
Шунда тойды ике куллап тотып,
Күмәч ашауларның рәхәтен...

Шагыйрь түгел Нәҗип. Түгел иде.
Тик аңлады аның йөрәген.
Үзе белән алып кайтып китте
Сандык тулы шагыйрь серләрен.

Буп-буш калды нумир. Шәһәре дә...
Берни дә юк. Бары ютәле.
Сандыгына сала алмас гамьне
Хәзер инде кәгазь күтәрде.

Шигырь сүрүенә йокты әрнү,
Тәкъдиренең чире-дәвасы.
Килде кайчак чыраларга телеп,
Дөнья ваклыкларын ягасы.

Янды. Язды. Яшьнәп яшәде дә
Фани әманәтен үтәде.
Үксез калды галәм. Үпкәләрдә
Калды кебек аның ютәле.

***

Таш мәчеттә[11] тып-тын. Сандык тора.
Эче тулы... шагыйрь җылысы.
Чәй кабында аның шигырьләре –
Күз салдыңмы, килә елыйсы.

Иске инде. Тупсалары иске.
Яшел буяулары борынгы.
Күзне йомсаң, шагыйрь чәй пешергән,
Хуш исләре назлый борынны.

Күзне йомсаң – яшь-яшь никрут егет.
Иңе җитми, буе тагын да...
Бүген аның халкын дөнья үзе
Шагыйрь сүзе аша таный да!

Таш мәчеттә тып-тын. Сизелми дә
Дөньяларда давыл барлыгы.
Аксакал күк түрдә вәкарь саклый,
Рухны саклый Тукай сандыгы.

[11] Таш мәчет – Түбән Бәрәскәдәге таш мәчет күздә тотыла — Татарстанның Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылында урнашкан ислам дине гыйбадәтханәсе. 1552 елдан соң төзелгән иң беренче таш мәчет кенә түгел, гомумән, Татарстанда авыл җирендә урнашкан иң борынгы таш мәчет тә. Мәчетне сәүдәгәр Ибраһим Борнаев 1769 елда үз акчасына төзетә. Агач сандык бүгенге көндә әлеге мәчеттә саклана.



Зөлфәт
Хәким

# СЕРЛЕ ТӘҢКӘ*

РОМАН

## 1

«Лаура сөеклем, хәерле көннәр сиңа!

Хатны нинди сүзләр белән башлыйм икән... Хисләремне, халәтемне ничекләр аңлатмак кирәк, минем бит әле моңарчы мондый хат язганым юк иде. Бер елдан артык вакыт үтеп китте, ышанырлык түгел, чөнки ул җәйге төн әле кичә генә булган кебек. Бер генә көнем дә сине искә алмыйча үтми. Яшькелт-зәңгәр күз карашың, куе-бөдрә кара чәчең, пешкән чиядәй иреннәрең һаман аермачык күз алдымда, алай гына да түгел, хәтта шул җитлеккән чияләрнең тәме әле дә иреннәремдә саклана, йөрәк тибешеңне, җылы сулышыңны һаман тоям, ишетәм шикелле. Күңелең түреннән чыккан хәтфә тавышыңны, назлы итеп миңа «Рауль» дип эндәшкәнеңне кайчан да булса тагын ишетергә насыйп булса иде.

Иманым камил, без синең белән озакка сузмыйча якын арада очрашырбыз. Танышып, якынаеп, бер-беребезгә гашыйк булырга язган икән, димәк, без синең белән һичшиксез кавышырга тиештер. Әйе, син – күчмә тормыш кешесе, хәтта төгәл адресың да юк, әмма бу безгә киртә була аламыни инде?! Ник без фәлән җирдә, фәлән вакытта очрашырбыз, дип сүз куешмадык икән? Безне бүтән беркайчан да очраштырмаслык дәрәҗәдә үк зур түгелдер бит инде Җир шары. Безнең кавышу котылгысыз булачак дип инанганга күрә, хушлашкан чагында бу хакта сүз катмаганмындыр, мөгаен. Ә син моны, бәлки, көткәнсеңдер...

Сине күрмичә, әмма күңелемдә синең белән бер ел узды да китте. Бу хатны кая җибәрергә, ничек сиңа тапшырырга – белмим. Әмма язам, язмый

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге үткәргән әдәби конкурста «Роман» номинациясендә икенче урынны алган әсәр.

Зөлфәт ХӘКИМ (1960) – *драматург, прозаик. Татарстанның халык язучысы. Дистәдән артык китап, иллегә якын пьеса һәм күпсанлы җырлар авторы. Казанда яши.*

булдыра алмыйм. Уй-хисләремне кәгазьгә төшергәндә, синең күзләреңә карап, үзеңә сөйләгәндәй булам.

Син бүләк иткән тәңкәне мин иң кадерле әйбер итеп саклыйм».

Хатны унсигез яшендә армиягә китәргә ике ай кала язды ул – бергә булган серле-могҗизалы төннән соң бер елдан артык вакыт узган иде. Аны почта аша да, башка төрле юл белән дә беркая җибәрмәде. Кайларга, нинди адрес буенча җибәрсен инде ул аны? Хатны, беркемгә күрсәтмичә, озак еллар саклады, ә инде армиягә китәр алдыннан, авылда, туып-үскән йортның чормасында, мәктәп елларыннан калган дәфтәрләр, уку әсбаплары төргәгендә яшереп калдырган иде.

Кызганыч, еллар узгач, хатны беренче хатыны Гөлнара тапты да ертып ташлады. Әмма Равил хатны һәр җөмләсенә, һәр сүзенә тиклем яттан белә – кирәк булса, ул язманы теләсә кайчан бер тында кәгазьгә төшерә ала. Хатны ул тугыз ел буе хәтерендә саклады, күңелендә язды да язды. Казанда очрашканчыга кадәр... Дөресрәге, Лаураның абыйсы, серле тәңкәне йолкып алып, сеңлесе белән бүтән очрашмаска кушканга кадәр.

Менә хәзер, егерме сигез елдан соң, бөтенләй көтмәгәндә, бу тәңкәнең, кинодагы кебек могҗизалы рәвештә кеше ышанмаслык юл белән кулына янә килеп эләгүе аны таң калдырды. Шул тәңкәме соң бу? Шул инде, шул! Нигә тагын килеп эләкте ул аңа? Ничек аңлатырга моны?

Беренче тапкыр 1977 елда ук очраштылар бит алар. Егерме сигез ел узды. Лаурага ничә яшь икән хәзер? Ничек инде, ничә... Аңа да илле биш. Икебезгә дә унҗидешәр иде бит. Үзгәргәндер инде. Кай тарафларда икән ул хәзер?..

Казанда соңгы очрашулары бик ямьсез килеп чыкса да, егерме сигез ел элек насыйп булган айлы төн, шул төндә дөрләгән якты, кайнар хисләр беркая югалмады. Ул төн аннан соң булган вакыйгалардан аерым яши, әйтерсең лә бөтенләй икенче дөньяда, башка яшәештә булды ул.

Лаураны төшләрендә еш күрә, гади төшләр сыман түгел, өн кебек алар. Уянгач та, кичә генә булды бу вакыйга, төштә түгел дигән тойгы кала. Серле төшләр тикмәгә керми. Алар бит бер дөньяда, бер планетада, бер күк астында яшиләр, бер һаваны сулыйлар. Алар бит, аралар ерак булса да, бер үк Кояш назын тоялар, төнлә бер үк Айга, шул ук йолдызларга карыйлар.

Бүген көтмәгәндә, «Хәтер дөнья»сы актарылып, болганып-тугланып алды да, аның иң якты тарафлары ачылып киткәндәй булды. Лаураның соңгы очрашудагы дорфалыгын да гафу итәрлек, акларлык лабаса.

Хәзер инде, очрашып, алга таба бергә булу хыялына күңелдә урын юк шикелле. «Очрашуның хәзер кирәге бар микән?..» дигән уй да килә.

Ә шулай да Равил тәңкәне учында кысып, хатирәләргә бирелеп утырганда, гомер буе күңеленең шул вакытка омтылганы белән бернинди карусыз килеште. Бәлки, үзенең унҗиде яшьлек чагын сагынудыр ул, әмма Лаурасыз, шул айлы төнсез яшьлеге юк бит аның.

Беренче мәхәббәт иң кадерлесе, диләр. Бу һичшиксез шулай.

Җиденче класста Сәвиягә гашыйк булуы да мәхәббәт түгел, тугызынчы класста Әлфинә белән чуалуын да мәхәббәт дип атарлык түгел иде. Аның чын беренче мәхәббәте унҗиде яшьтә Лаура белән булды. Ә бит ул мәхәббәт һаман исән, ул үлемсез лабаса.

Равил Казанда соңгы тапкыр очрашуларын исенә төшерде. Тынчу фатир,

канечкеч бандитлар, Лаураның нәфрәтле йөзе, аның абыйсы... Следователь кабинеты...

Әйе, инде хәзер кабат очрашу теләге бигүк көчле түгел. Очрашуның кирәге бармы икән хәзер, дигән сорау тынгылык бирми. Туктале, очрашу булырга тормый бит әле. Тәңкә дә яңадан аның кулына очраклы рәвештә генә килеп эләкте, әгәр телевизордан күрмәгән булса, белми дә калыр иде.

Инде күпме вакыт узды... Әллә Лаура Казанда микән? Барыбер күрәсе килә бит аны. Бәлки, бу юлысы очрашу ямьлерәк булыр иде.

Гомер кичкә авышып бара. Улына ундүрт яшь, кызына тиздән унике тула. Бик тиз ага икән гомер елгасы һәм олыгайган саен вакыт тизрәк чаба икән ул. Әмма тормыш дәрьясы ничек кенә кайнап акса да, синең иң якты хатирәләреңне үзе белән алып китә алмый икән.

Хәтер үз көенә яши. Нәрсәне югалтырга, нәрсәне барлап истә тотарга – Хәтер үзе белә.

Нишләп бу тәңкә тагын аның кулына килеп керде соң?..

Шул тәңкә бу, шул. Лаура бүләк иткән тылсымлы әйбер.

Нинди билге бу, нәрсәне аңлата? Тикмәгә түгелдер. Язмыш тагын нинди борылыш ясар икән? Лаураның сәламе шулай килеп җиткәнме? Башка төрле бер-бер хәбәрме, әллә көтелмәгән билгеме? Болай булырга мөмкин микәнни?! Шул тәңкә бу, шул инде!

**2**

Садри – базык гәүдәле, кызыл чырайлы, чепи күзле агай – кибет директорының бүлмәсенә кергәндә, анда дүрт хатын талашып утыралар иде. Ызгыша торгач, инде тирләп-бүртеп беткән дүрт кеше арасында кайсысы директор икәнне креслода утыруына карап түгел, төс-битеннән күреп тә аңларлык иде. Садри, талашның бетмәячәгенә төшенеп, аваз салды:

– Исәнмесез.

– Сезгә нәрсә кирәк? – диде креслода утыручы ханым, «исәнмесез» дигән сүзнең мондый шау-шуда бернинди әһәмияткә ия түгеллеген күрсәтеп.

Садри төймәгә охшаган медальчыкны пинжәгенең ян кесәсеннән чыгарып күрсәтте:

– Менә бу төймә ипи эченнән чыкты, – диде ул нәфрәтле тавыш белән.

Ипи эченнән әллә нәрсәләр чыгу гадәти күренешкә әйләнгәнгә күрә, талашудан туктаган хатыннарның исләре китмәде генә түгел, алар хәтта шундый пүчтәк йомыш белән кергән тар пинжәкле, мәңге үтүк күрмәгән чалбар кигән, башына иске салам эшләпәне кыңгыр салган агайга сәерсенеп карадылар.

Директор зарланып килүче клиентлардан гарык булса да, бу кешенең керүенә хәзер бераз сөенде. Чөнки сатучы хатыннарның талашуына чик куясы килеп утыра иде аның.

– Кызлар, аннары разберёмся, барыгыз. Әнә, покупатель зарланырга килгән, – диде ул, чыраен сытып.

Директор бүлмәсеннән чыгып киткәндә, сатучыларның һәркайсы берәр сүз әйтми калмады:

– Тапкан проблема!

– Үзенең кальсон төймәседер әле.

– Эше юктыр, буш вакыты күптер. Була бит шундый кешеләр, гел скандал кирәк...

Сатучылар ишекнең теге ягында юк булгач, директор зарланырга кергән кешенең кайда кем булып эшләгәнен чамалар өчен аны җентекләп күзәтте. Кыяфәтеннән күренеп тора – бу агай директор өчен һич кенә дә куркыныч кеше түгел иде.

– Тыңлыйм сезне, – диде ул, абзый ике бармагы белән җирәнеп кенә тоткан төймә кебек нәрсәгә текәлеп.

– Менә бу төймәме, монетамы... нәрсәдер бу, белмим... Бүген ашаганда ипи эченнән чыкты, – диде Садри.

– Сез кайда, кем булып эшлисез? – дип сорады директор.

– Кайда эшләсәм дә, барыбер түгелмени? – диде агай, аптырап. – Техобслуживание станциясендә механик булып эшлим. Илле ике яшь.

Директор, төймәне алып, әйләндергәләп карады:

– Нindидер борынгы монетага охшаган, – диде ул, күзләрен чекерәйтеп. – Тишеге дә бар. Муенга тагып йөри торган медальон сыман... Бизәкләре әллә нинди, аңлашылмый торган.

– Нәрсәгә охшаса да, ризыктан мондый әйбер чыгарга тиеш түгел! – диде Садри.

– Ник, сез ипине шулай олы кабып ашыйсызмыни? – дип гаҗәпләнде директор хатын. – Ипи телемен калын кисәсезмени?

– Ипине ничек ашавымда сезнең эшегез булмасын! – диде Садри, бер урында таптанып. – Нишләп ипидән мондый әйбер чыга? Бәлки анда зараза бардыр.

Директор ипи эченнән чыккан әйберне өстәлгә куйгач, Садри аны шунда ук, алып, чалбар кесәсенә тыкты.

– Ипине безнең кибеттә алдыгызмы?

– Әйе.

– Чек бармы?

– Юк, ташлаганмын.

– Бәлки сез ипине башка кибеттә алгансыздыр?

– Башка кибеттә алган булсам, шунда барган булыр идем.

– Бездән алган булсагыз да, ипине без пешермибез бит. Һәрбер буханканы ярып, тикшереп утырыйкмыни? Димәк, пекарняда фильтрлар тишек, раз мондый төймәләр сыя.

...Садри хәтта ипи заводының проходноеннан да керә алмады. Вахтада утыручы 40-45 яшьләрдәге ир-егетнең кыяфәтеннән дөньяны да, кешеләрне дә күп күргәнлеген чамаларга була иде.

Монда Садри кәчтүм-чалбар киеп, галстук тагып килде, әмма шуны әйтергә кирәк, завод проходноендагы сакчы Садриның муенындагы галстук белән артын сөртергә әзер, чөнки галстуклы кешеләрне аның җене сөйми иде. «Закон», «җавапка тарту» дигән сүзләрне охранник күрәлмый, чөнки аның ике тапкыр төрмәдә караклык өчен утырганы бар иде – бер тапкыр Брежнев исән чакта, икенче тапкыр Андропов килгәч. Перестройка башлангач, ул, караклыктан китте, сакчылар оешмасына эшкә урнашып, үзе каракларны тоту юлына баскан иде. Шулай да закон турында сүз катсалар, аның беләкләре, балтырлары кычытырга тотына иде.

– Завод директоры синең авызыңнан чыккан сәдәп турында разборка ясарга вакыт тапмас! – диде сакчы, Садриның ярты сәгать буе кулланучы хокуклары турында сөйләгәнен игътибарсыз гына тыңлаганнан соң.

– Ул минем авыздан түгел, ипи эченнән чыкты.

Сакчы Садриның ике бармак белән кысып тоткан медаленә күз кырые белән карап:

– Мондый шыксыз нәрсә ипидән чыкмас, синең ише кешенең авызыннан гына чыгарга может, – диде.

Садри аңа:

– Хам! – дигәч, вахтёр «ягымлы» гына иттереп, аны русчалап «өч хәрефкә» юнәлтте.

**3**

Равил Шәмсиев, телевизор карый-карый, чәй эчеп утырганда, «Эфир» телеканалыннан барган «Актуаль тема» дигән тапшыруда табак битле бер агай ду китереп, ипи пешерүчеләрне, шул ипине сатучыларны ачулана иде. Алып баручы аның сүзен куәтләп, ипи эченнән әлләниләр чыкканын мисалга китереп утырды. Бу юлысы ипидән чыккан медальонны зур планда күрсәттеләр. Равил чак кына тончыкмады, сикереп торды, кайнар чәен ботына түкте, әмма авырту тоймады. Ул телевизор экранына карап катып калды. Медальонны зурайтып күрсәткәч, андагы бизәкләр, тамгалар бик таныш булып күренде – бу тәңкә аныкы бит!

Ул тапшыру тәмамлану белән үк телевидениегә шалтыратып, эфирга чакырылган кунакның телефон номерын сорады.

Равил икенче көнне иртүк, әлеге дә баягы номерны җыеп үзенең кем икәнен әйткәч, Садри аптыраштa калып, беравык телсез торды. Данлы артистның аның белән очрашырга теләгәнен ишеткәч, ни уйларга да белмәде, хәтта бераз каушады. Равил аңа үзенең йомышын әйтте һәм тәңкәне югалтмаска, ташламаска кушты, аның бик истәлекле әйбер икәнен кат-кат аңлатты. «Ул тәңкә минеке!» – диде ул сүз ахырында.

Өйдә ремонт бара дигән сылтау белән Садри очрашу урынын театрда билгеләүне сорады. Актёр Равил Шәмсиев аңа шундук театрга, спектакль башланырга берәр сәгать кала килергә кушты.

– Сезнең ипи комбинатында берәр туганыгыз эшлиме әллә? – дип сорады Садри, Равил Шәмсиевнең грим бүлмәсенә кереп исәнләшкәннән соң.

– Юк.

– Бәлки, кибеттә берәр кемегез эшлидер?

– Юк ла. Мин белмим, ничек ипи эченә кергәндер бу тәңкә? Минеке бу, – дип, Равил тәңкәгә текәлде.

– Бәлки телевизордан берәр тарихчы күргәндер дә бик кыйммәтле әйбер икәнне сезгә әйткәндер, – диде Садри, күзләрен челәйтеп.

– Син мине кемгә саныйсың! – дип кайнарлана башлады Равил. (Бу кешене ул телевизордан күрү белән үк өнәмәгән иде.) – Кыйммәтле әйберләргә кызыгып, шулар артыннан йөрердәй кеше булсам, мин гомерем буе актёр булып эшләмәс идем. Моны миңа 1977 елда чегән кызы бүләк иткән иде. Шул медальон бу, шул. Ялгышмыйм.

– Сез бит моны исбатлый алмыйсыз, – диде теге, үҗәтләнеп.

– Син пычрак күңелле кешедер, мөгаен, – диде Равил тыныч кына, әмма усал һәм тәэсир итәрлек интонация белән.

Гаҗәпләнүдән Садри хәтта берничә адым артка чигенде:

– Нишләп сез миңа андый ямьсез сүз әйтәсез? – диде ул, тавышын калтыратып.

– Күңеле чиста булмаган кеше башка кешеләрдә гел кыңгырлык кына күрергә тырыша, – диде Равил, тәңкәне тумбочка тартмасына салып.

– Сез мине дөрес аңлагыз... Минем ипиемнән килеп чыкты... Сез, моны белеп, шундук шалтыраттыгыз...

Равил, тирән сулап:

– Минем өчен бик истәлекле әйбер бу, – дип куйды.

Садриның медальоннан болай гына колак кагасы килмәде:

– Ювелирга барып, бәясен белергә кирәк... – диде ул, тумбочка тартмасына карап.

– Ювелир нинди бәя бирсә дә, минем өчен бәһасез нәрсә ул. Ничек бәяләсәләр дә, синнән аны кем сатып алсын? Бу әйбер белән син чак кына да байый алмыйсың. Башкалар өчен кыршылган, таушалган, күгәргән төймә генә, ә миңа бик кадерле ул. Аны миңа моннан егерме сигез ел элек чегән кызы бүләк иткән иде.

Сатулаша торгач, Равил Садрига биш мең сум акча бирде. Садри, акчаны куен кесәсенә тыккач, Равилне хөрмәт иткәнгә күрә генә шулай арзан бәягә бирүен, татар театрын яратуын, аның уйнавын беркем беркайчан кабатлый алмаячагын, татар халкының театраль халык икәнен озын-озак итеп сөйләде.

Ул әле тагын сөйләр иде, әмма Равил аңа:

– Минем сәхнәгә чыгасым бар, әзерләнергә кирәк, – дип, Садрига арты белән борылып, көзге каршына утырды.

Ниһаять, бу җанбиздергеч кеше гримёркадан чыгып китте. Равил тартманы ачып, тәңкәне алды да учына салып, уйга чумды.

**4**

Үзләрен ромалэ дип атаган кавем Советлар Союзында беренче тапкыр рәсми рәвештә 1956 елда чегәннәр дип телгә алынды. Шул елның 5 октябрендә Утраклык турында Указга кул куелды һәм РСФСР Министрлар Советының 658 номерлы «Сукбайлыкта йөрүче чегәннәрне хезмәткә тарту» дип аталган карары чыкты.

Ирек яратучы, хөр күңелле бу халык белән дәүләтләр гомер бакый көрәштеләр. Россиянең үзендә дә чегәннәргә һәрвакыт гаять төрле вә капма-каршылыклы мөгамәлә булды. Алардан читләштеләр, шүрләделәр, өнәмәделәр, әмма барыбер халык аларны яратты, дошман итмәде. Чегәннәрнең яшәү рәвеше, мәдәнияте һәрвакыт кызык вә серле, затлы һәм шул ук вакытта шомлы-матур иде.

Революциядән соң аларны коллективлаштырып та карадылар, сәвит халкына кушып, коммунизм төзү эшендә дә катнаштырырга маташтылар. Әмма бу халыкны буйсындыру иң көчле хакимнәрнең дә хәленнән килә торган эш булмады.

1956 елгы карардан соң аларны урамнарда тоткарлый башладылар,

спекуляциядә, күрәзәлек итүдә, кәрт белән фал ачуда, сихерләүдә, караклыкта гаепләделәр. Аларны җәмгыять кулына күчерүне сәвит хөкүмәте үзенең мөһим бер бурычы дип санады. Чегәннәрне эшкә тарту башланды, күбесен, үзләренең яшәү мохитеннән аерып, заводларга урнаштырдылар, балалары өчен махсус мәктәпләр дә ачылды, хәтта махсус шартлар тудырылды. Буйсынмаганнарын сөргенгә җибәрделәр, кайберләрен төрмәгә утырттылар, алтын әйбер коючыларны исә «валюта махинацияләре» статьясы буенча хөкем иттеләр.

Әлеге дә баягы карарда аларны паспортлаштыру, прописькага кертү дә күздә тотыла иде. Бу гамәл, гәрчә ирексез рәвештә хәл ителсә дә, бик күп чегәннәргә файда китерде, чөнки паспортлы булып, кайдадыр пропискада торып, күчмә тормышны дәвам итү кайвакыт җиңелрәк тә иде әле. Кесәгә паспортны тыгып, алар әллә нинди хәйләле юллар белән җаннары теләгәнчә ирекле яшәү ысулларын табарга оста иде.

Чегән таборлары Татарстан җирендәге авыллар тирәсендә әле алтмышынчы-җитмешенче елларда, бигрәк тә җәй фасылында, еш күренәләр иде.

1977 елны Октябрь революциясенең 60 еллыгын билгеләргә җыенган илдә төбәкләрдәге җирле хакимиятләргә чегәннәрне җыеп бетерергә, күчмә тормышка киртәләр куярга, аларның сукбайлыгын бетерергә катгый фәрман бирелде. Бу юнәлештә эш актив барганлыктан, чегәннәр авыллар тирәсендә сирәгрәк күренделәр, әмма алар барыбер торымнан-торымга әле бер районда, әле икенчесендә бөтенләй көтелмәгән яктан килеп чыгалар да, урман тирәсендә, йә урманның үзендә урнашып, шул тарафтан авылдан авылга сәяхәт кылалар иде.

Равилгә унҗиде яшь иде. Быел ул туган авылы Аулаш урта мәктәбендә ун классны тәмамлады, алда якты киләчәккә илтә торган олы тормыш юлы көтә иде. Җәйге кояш һәр тарафка нурларын сибә, һәрьякка юллар ачык – үзең өчен карар кылып, юнәлешеңне билгеләп, максат куеп, хыялларыңны гамәлгә ашырыр өчен мөмкинлекләрне файдаланып, юлга чыгып китәсе генә кала иде.

Быел, Аулаш тирәсендә чегәннәр күренә башлагач, авыл халкы, гадәттәгечә, сак булырга тырышты – дозор торды, колхоз мал-туарын сакларга өстәмә каравылчылар куйдылар, авылдашлар үзләренең шәхси мал-туарына да күз-колак булуны көчәйтте.

Шулай да, гөнаһ шомлыгына каршы, двордан бер ат юкка чыкты. Әллә кемнәрдән, әллә ничекләр шикләнеп тормадылар, шул чегәннәр эше бу, диделәр. Чегәннәр өере башта урман авызында урнашкан иде, ат югалган көнне үк алар юкка чыктылар – урманның теге ягына күчтеләр, ахрысы.

Авыл сәвите рәисе Хәлил – алтмышка җитеп килүче коры сөякле агай, таушалып беткән салам эшләпәсен салып, битен җилләтеп алды да:

– Чегәннәр эше булса, атны да, башка әйберне дә табып, алар урлаганны исбатлыйм димә инде, – диде. – Алар әле синең белән сөйләшеп тә тормаячаклар, ялган гаеп тагарга маташасың дип, шау-шу куптарачаклар. Милициягә хәбәр итеп тә әле чегәннәр урлаган нәрсәне таба алганнары юк.

Әмма бу юлысы ат югалу вакыйгасы көтелмәгән юнәлеш алды. Урман буенда печән чабучы ирләр Аулашка таба баручы чегән кызын тотып, авылга алып кайтканнар.

– Кая барасың? – дип сораганнар кыздан.

– Авылга, – дигән кыз.

– Ник?

– Марля кирәк.

Чегән кызы яланаяк, яланбаш иде. Чибәр иде ул. Җил белән кояш каралткан йөзенә аның уңып, чәчәк төсен җуйган күлмәге дә, тузгыган озын чәче дә хуш килеп тора иде. Кыяфәте йончыган булса да, аның япь-яшь кыз икәне буй-сыныннан гына түгел, аз гына ясалган хәрәкәтләрендә чагылып күренә иде.

Яулыгын кулына тоткан, яулык очы җиргә тияр-тимәс салынып тора, куе бөдрә кара чәче биленә кадәр төшкән. Түшендәге куе кызыл төсле муенса, колакларында эленеп торган җиз төсендәге алкалар, күренеп тора, кыйммәтле түгел, гади, әмма алар бик килешеп тора иде үзенә. Кулындагы беләзеге дә муенсадагы кебек төймәләрдән җыелган иде. Кыз торымнан-торымга кул арты белән маңгай тирен сыпырып куя, чолгап алган авыл кешеләренә сак караш ташлый, әмма күзләрендә куркуның әсәре дә күренми.

Авылда гына түгел, якын-тирәдә мондый кызлар юк. Чегән кызына тиз арада авыл уртасына җыелган халык арасында кайберәүләр, бигрәк тә бала-чага гаҗәпләнеп, читтән килгән, хәтта күктән төшкән кешегә караган кебек карадылар.

Чегән кызының кыяфәтеннән тынычлык вә сабырлык аңкый. Ул чак кына ирен чите белән елмая, як-ягына борылып, авыл халкын күзәтә һәм сагышлы йөзеннән: «Ник мине тоткарладыгыз?» – дигән сорау укыла иде.

Селсәвит рәисе Хәлил кырыс, таләпчән тавыш белән:

– Исемең ничек? – дип сорагач, чегән кызының кипшенгән булса да, кып-кызыл иреннәре арасыннан:

– Лаура, – дигән аваз ишетелде.

– Хәлил, русча сөйләш, – диде кемдер.

– Мин татарча да аңлыйм, – диде чегән кызы.

– Безнең авылда нишләп йөрисең?

– Сезнең кешеләр тотып алып килделәр. Мин үзем дә монда бара идем... Медпунктка.

– Чирлисеңме әллә?

– Юк. Марля кирәк.

– Шушы көннәрдә, нәкъ сезнең табор урман буена урнашкач, безнең двордан бер ат югалды, – диде Хәлил. – Сине тоткарлыйбыз. Ат табылганчы бездә булачаксың.

Лаура моңсу кыяфәттә бер сүз дәшмичә басып тыңлап торды.

– Син аңладыңмы мин әйткәнне? – диде Хәлил, чегән кызына текәлеп.

– Русча әйтергә кирәк. Русча әйт, – дип киңәш бирде бер хатын.

– Татарча да әйбәт сөйләшә бит, – диде Хәлил.

– Безнекеләр бернинди ат урламадылар, – диде Лаура, горур кыяфәттә Хәлилгә туры карап.

– Менә участковый килер, без инде аңа хәбәр иттек, милиция ачыклар атыбызны кем урлаганны.

Лаура Хәлилгә көлемсерәп карады да яулыгын иңенә салды.

Аны үзәк урамдагы, кайчандыр Хисам байның келәте булган, хәзер исә колхозның каравыл йорты белән янгын сүндерү склады хезмәтен башкарган корылмага кертеп, өстеннән бикләп куйдылар.

Халык арасында Равил дә бар иде. Аңа нык тәэсир итте чегән кызы. Кызгану хисе күңелне биләп алды, ә яшь йөрәк үзенекен таләп итте – Равил чегән кызына гашыйк булды. Аны бит иртәгә милициягә озатачаклар. Берәр урлау ише җинаятьтә гаепләп, төрмәгә дә утыртып куюлары ихтимал. Коткарырга кирәк Лаураны, дип уйлады ул. Аның инде хәзер үк, чегән кызын җитәкләп, авылдан читкә алып китү теләге туды. Авыл халкын аңлап була, ләкин бу кыз ат урлый торганга охшамаган бит. Әйе, бәлки, атны абыйсы яки атасы урлагандыр, аның өчен бу япь-яшь гүзәл зат җавап тотарга тиеш түгел бит инде.

Төн уртасы таңга таба авышкач, Равил келәт яныннан әйләнеп килде. Авыл йоклый. Ишектәге амбар йозагын капшап карады – лом белән каерып ачарлык икәне аңлашылды. Каравылчы-мазар юк иде. Этләр генә каты өрә. Атны урлаганда өрергә кирәк иде, дип уйлап куйды Равил. Ул, тиз генә өйгә кайтып, лапастан лом алып чыкты да келәткә таба йөгерде. Йөрәк атылып чыгардай булып типте. Куллар калтырый, төн салкынча булуына карамастан, тәнгә тир бәреп чыкты. Равил йозак дугасына ломны кидерә алмый җәфаланды. Ниһаять, туры китереп, берничә тапкыр каергач, йозак ватылды. Ишек, тырнаулы ямьсез тавыш чыгарып, теләр-теләмәс кенә ачылды. Келәт эченең дөм караңгы түрендә салам кыштырдап куйды.

– Һәй! – дип эндәште Равил шул тарафка. – Чык тизрәк. Бар, чыгып кит. Качарга кирәк сиңа.

Чегән кызы әкрен генә ишек катына килде, Равилнең йөзен күрергә тырышып карап торды.

– Курыкма. Мин сине коткарырга килдем, – диде Равил. – Бар тизрәк, кеше-кара күргәнче. Югыйсә сине генә түгел, мине дә харап итәчәкләр.

Равил Лаураны келәттән җитәкләп алып чыкты һәм алар, як-якка карана-карана, Югары оч урамы буйлап атладылар – бу урамның юлы авылдан урман ягына таба сузылган иде.

Мортаза тыкрыгына җитәрәк алар туктап хәл алдылар. Шунда Равил Лаураның урманга үзе генә барырга курыкканын аңлады.

– Хәзер мин өйдән ипи белән сөт алып киләм, аннары сине озата барырмын, – диде ул.

Лаура тыкрык коймасы буенда яткан бүрәнәгә утырып калды. Равил, тиз генә өйгә кайтып, чоланда ике шешәгә сөт тутырды, шыпырт кына аш бүлмәсенә кереп, ярты ипи алды, шуларны рюкзагына салды да чегән кызы янына йөгерде.

Авылны чыкканчы алар бер сүз дәшмәделәр, тын гына бардылар. Авыл башындагы күперне чыгып, калкулыкка күтәрелгәч, икесе дә тирән сулыш алып, үзләре дә сизмәстән көлеп җибәрделәр.

– Минем исемем Равил.

– Мин – Лаура.

– Атны син урламагансыңдыр бит?

– Ат урлаган булсам, авылыгызга килер идеммени... – диде Лаура, көлеп.

Айлы сукмактан алар, сөйләшә-сөйләшә, юк кына сүздән дә рәхәтләнеп көлеп, ваемсыз төн үзәгенә юнәлделәр.

...Алар урман буенда шул көнне генә печәнчеләр өйгән хуш исле печән чүмәләсендә кундылар.

Лаураның тәне, тавышы, сулышы, татарча кызык сөйләшүе – барысы бергә Равилне таң калдырды, әсир итте, аның өчен бу минутларда чегән кызы гына бар иде. Ай яктысында тагын да гүзәлрәк, серлерәк иде ул.

Лаураның куе-хәтфә тавыш белән татарчалап-урысчалап, сыкы-быкы иттереп сөйләшүе матур, һәр әйткән сүзе җанга ятышлы, кызык һәм аны тыңлавы да рәхәт иде. Бу төндә Равил өчен колхозлар, коммунистлар, ә Лаура өчен чегәннәрне куралмаучы миллионлаган кешеләр юкка чыккан иде. Хуш исле печән чүмәләсен кочагына алган июль төне, күктән нурын мул койган алтынсу Ай яктысында ике йөрәкнең аваздаш тибеше генә бар иде.

Лаурадан кайнар дулкын килеп-килеп кага, ул тупырдап тора, терекөмеш кебек тиктормас, аның кулын тоту белән сиңа ниндидер энергия агып күчә сыман иде. Бу сихри төн Равилне бөтенләй ят, әкияти ләззәтле диңгездә тирбәтте. Әйтерсең лә бөек сер ачылды. Гүя бүген ул бөтенләй башка яссылыкка аяк басты.

Таң беленгәч, Равил аны таборга кадәр озатмакчы иде, Лаура:

– Кирәкми, – диде. – Табор моннан ерак түгел урнашты.

– Бүреләр очраса? – диде Равил, кызны җибәрәсе килмичә.

Лаура матур итеп елмайды:

– Миңа бүреләр очраганы бар, – диде ул. – Курыкмыйм мин алардан. Бүре кешегә тими. Бүре сезнең селсәвит рәисеннән дә явызрак түгел ул. Кешегә кешеләр куркыныч. Син кайт инде. Югалтырлар да үзеңне, мине син коткарганны аңларлар.

– Атны сезнекеләр урладымы?

– Юк, безнекеләр эше түгел. Берәр авыл янында күренсәк, барлык караклыкларны безгә сылтыйлар инде.

– Безнең авылга ник килгән идең соң син?

– Сине күрәсем килгән иде, – дип шаярды кыз.

– Дөресен әйт инде.

– Инде ничә тапкыр әйтергә була – медпунктыгыздан марля алмакчы идем.

– Сез бу тирәдә озак буласызмы?

– Ромалэга бер урында озак торырга ярамый. – Лаура Равилгә сыенды, аның башы егетнең йөрәк турысына терәлде. – Синең йөрәгең кызык тибә.

– Ничек ул кызык? – диде Равил.

– Бик тигез, дөрес тибә.

– Сәламәт булган һәр кешенең йөрәге тигез тибә инде ул.

– Синеке тигез генә түгел, дөрес тибә, – диде Лаура.

– Кая, ә синеке... – Равил кызның күкрәгенә колагын куеп тыңлады. – Синеке дә дөрес тибә. Төгәл күрсәтә торган сәгать кебек.

– Син нишләп мине коткарасы иттең?

– Бик ошадың син миңа... Мондый кызны әле моңарчы күргәнем юк иде.

– Гашыйк булдыңмы әллә, бичара? – диде Лаура, көлемсерәп.

– Әйе. Минем сине беркая да җибәрәсем килми.

– Авылдашларың да беркая җибәрәсе килмичә, келәткә бикләп куйганнар иде...

– Без тагын очрашабыздыр бит?

– Бәлки.

Равилнең чегән кызын беркая җибәрмичә, аның кулын тотып, күзләренә мәңге карап торасы килде, инде күптәннән бирле җанга якын бик кадерле кешесе белән хушлашкан сыман булды.

Лаура урман эченә кереп югалгач та әле, ул, авылга кайтасы килмичә, кырда бик озак басып торды.

Кайтыр юлга чыккач, еракта авылдан чыгып килүче печәнчеләрнең җигүле атлары күренде. Равил, сулга каерылып, ян тарафка китәргә ашыкты. Аның иртүк урманнан кайтып килүен күрсәләр, нишләп йөри бу монда дигән сорау тумый калмас. Әле келәт янында калган лом буенча Равил эше икәнне белмәгәйләре.

Ул инде аны авылдашлары танымаслык ара үтте һәм билдән тиң үскән куе үлән арасына сузылып ятып, йокыга киткәнен сизми дә калды.

Уянганда, кояш шактый югары күтәрелгән иде, ул ашыга-ашыга, авылга кайтып китте.

Авыл уртасында, келәт янына унлап кеше җыелган иде. Алар яныннан шыпырт кына үтеп китмәкче иде, әмма аны инде күреп алдылар һәм Равил, ни булса шул, дип, авылдашлары яныннан салмак кына атлады. Авыл советы рәисе Хәлил агай, ломны ике куллап тоткан килеш, әрле-бирле йөреп сөйләнеп калды:

– Үзебезнең авыл кешесе качырган аны... Менә участковый килер, ул уголовный розыск вәкиле белән килер дип уйлыйм... Табарбыз кем эше икәнне.

– Мужыт чегәннәр килеп ачканнардыр келәтне, – диде кемдер.

– Лом белән каерып ачканнар бит, – диде Хәлил

– Чегәннәрдә лом юк дисеңме әллә син, – дигән тавыш ишетелде.

– Чегәндә әллә ниләр бар ул. Аларда әле елан мөгезе дә бардыр... – диде берәү.

– Участковый кая, нишләп килми соң ул һаман? – диде кайсысыдыр.

– Бүлнискә киткән. Кадакка баскан, – диде Хәлил, чыраен сытып.

Тагын ниләр сөйләшкәннәрдер – Равил инде ишетмәде. Үзләренең турына җиткәч, капкадан керер алдыннан, ишегалдындагы тавышларга колак салып торды.

Әтисе Закир бу вакытта ишегалдын себерә иде. Шактый кырыс холыклы кеше, ул, Равил капкадан керүгә үк җикерде:

– Син, малай, кайда йөрдең?

Равил шундук үзен кулга алып, каушавын җиңде һәм:

– Аксар авылына барган идем. Дустым Зәбир үзләрендә кунарга күндерде, – дип ялганлады.

– Алдыйсың, – диде Закир, күзләрен чекерәйтеп.

– Алдамыйм.

– Теге чегән кызын, келәтне ачып, кемдер качырган. Лом белән каерып ватканнар йозакны.

– Чегәннәр үзләре килеп коткарганнардыр, – диде Равил, әтисенә туры карарга куркып.

– Безнең лом чегәннәр кулына ничек килеп эләксен икән?..

– Безнең лом белән ачканнармыни? – дигән булды Равил.

– Башыңны җүләргә салып тор әле менә! Әйләндереп җибәрермен! Кәнитилдә катнашасың килдемени?!

– Туктале, әти, авылда лом һәр йортта бар... Бәлки безнеке түгелдер...

– Үз әйберемне мин меңе арасыннан таныйм. Узган атнада гына җәйпәк башын игәүләгән идем, ялтырап тора. Силсәвит рәисе Хәлилнең келәт тирәли йөрүен күреп барган идем... Минем ломны тотып, кемнеке икән бу дип, үткән-сүткән кешедән сорап тора. Йөрәгем жу итте.

Закир кыжрап, себеркесен ике куллап кысты да лапаска кереп китте.

Әтисе сизгән, аңлаган Равил эше икәнне. Закир, лапастан чыгып, күршеләр ягына карап алды да чак кына ишетелерлек итеп:

– Участковый чакырып, ломны экспертизага җибәрсәләр? Анда синең бармак эзләре калгандыр... – диде.

– Мин җинаять кылмадым бит, – дип, борын төбенә мыгырдады Равил.

– Ат урлаучыларга ярдәм иткәнсең, дип гаепләсәләр?!

– Гаепләсеннәр, – диде Равил, бер дә исе китмичә.

– Нигә кирәк булды соң сиңа бетле чегән кызын коткару?!

– Бетле түгел ул! – дип әйткәнен Равил үзе дә сизми калды.

– Син кайда булдың соң таң атканчы?

Равил, тирән сулап:

– Су буенда йөрдем, – диде.

Закир, биленә таянып, тагын ни әйтергә белми торганнан соң:

– Лом шәп иде, җәлке, – дип куйды.

**5**

Лаура Равилнең уеннан чыкмады, төшләренә кереп йөдәтте.

Чын мәхәббәт инде бу! Классташ кызларга гашыйк булу бала-чага уены гына булган икән бит.

Әллә ничә көн рәттән иләс-миләс йөрде ул. Әйтерсең лә беркем белмәгән, һичкемгә таныш булмаган бөек серне үзе өчен ачты. Хәзер тирән ләззәт дөньясына керер өчен ул серле ачкыч тапты, аның Лаурасы бар хәзер, ул аны ярата, моның дәвамы кирәк, бу могҗиза бер төнлек кенә булырга тиеш түгел!

Равилдәге үзгәреш әнисе Нурияне борчуга салды:

– Нәрсә булды улыбызга? – дип, Закирга кат-кат әйтте ул.

– Улың артык хисле, кызганучан. Сиңа охшаган, – дип җавап бирде әтисе, ни булганын аңлап.

– Ул чегән кызын мин үзем дә кызгандым, – диде Нурия. – Ат югалды дип, япь-яшь кызны хөкемгә тартмыйлар инде.

– Атны кире кайтарсыннар өчен тоткарлаганнар иде ул кызны, – дип, силсәвит рәисен акламакчы булды Закир.

– Чегән булса да, тере кеше бит ул, аның да җаны бар, – диде Нурия. – Хайванга кыз баланы алмаштыру дөресме соң?

– Менә, менә, улың да синең кебек фикерли, – диде Закир ачулы тавыш белән.

Шул көннәрнең берсендә, беренче отпускысын алып, Равилнең апасы Илүсә кайтты. Медучилищены тәмамлап, ерак районгагы авылга фельдшер булып китәргә тиеш ул.

Туган авылын, әти-әнисен, туганнарны, күршеләрне сагынып кайткан апасы да сизде Равилдәге үзгәрешне.

Халык мәш килә. Авыл җирендә кышка җәй башыннан ук әзерләнергә тотыналар. Әтисе Закир – авылның абруйлы шоферы – көннәр буе ашыгып, машинасын ремонтлый, чөнки тиздән урып-җыю башланачак, эшнең бетәсе юк – колхозда да, йорт-җирдә дә.

Равил исә бу көннәрдә һаваларда очып йөри, аңарда башка төрле хисләр кайный – ул бәхетле дә кебек, әмма шул ук вакытта, Лаураны сагыну да җанга тынгылык бирми. Ниндидер татлы газап белән яши бу көннәрдә, аңлатып булмаслык халәт күңелне биләп алган, моңарчы дөньяның бик күп төсләрен күрми йөргән икән бит ул.

Ярый әле, аның «ат»ы бар – якын дусты, ерак араларны җилләнеп үтә торган мотоциклы. Бик озак ялынгач, әтисе аңа узган җәйне «М-107» матае алып бирде. Шуңа атланып, ул йорт мәшәкатьләреннән арынып торыр өчен офыкларга таба юнәлә ала.

Хәзер дә үзенә йөкләнгән йорт эшләрен тиз-тиз генә башкара да, матаена атланып, болынга чаба, Лаура белән кунган чүмәлә тирәсендә йөри, урман буйларын әйләнә. Туктап, озак итеп, урманга кереп киткән юлдан күзләрен алмый тора.

Беркөнне матайның артына апасы Илүсәне утыртып, урманга җиләк ашарга барырга вакыт таптылар. Аларның бу сәфәре җиләк җыю максаты белән дә түгел, тиздән Равил Казанга китәсе булгач, бергә бала чакларын искә төшереп, озаграк аралашып калырга теләүдән иде. Үзеннән өч яшькә олырак апасы Равил өчен бик кадерле кеше. Апа бит ул!

Кайтыр алдыннан, матайны кабызганчы, Равил апасыннан чегәннәр турында сораштырды.

– Апа, чегәннәрнең документлары буламы?

– Нинди документлары? – диде Илүсә, энесеннән сәер сорау ишетеп.

– Паспортлары, мәсәлән... – диде Равил.

– Белмим, – дип иңнәрен сикертте Илүсә. – Ник сорыйсың?

– Болай гына, – дигән булды Равил. – Кыш көне кайда яшиләр икән алар?

– Каян белим мин. Бәлки, кошлар кебек җылы якка китәләрдер. – Илүсә билен турайтып, кул арты белән маңгаен сыпырып куйды да Равилгә текәлеп карап торды: – Син ул чегән кызына гашыйк булдыңмы әллә?

– Нинди чегән кызына? – диде Равил, аңламаганга сабышып.

Илүсә энесенә апаларча кырыс караш ташлады:

– Теге, син олы җанлыланып коткарган чегән кызына.

– Кешегә ярдәм итәр өчен аңа имынны гашыйк булырга дигәнмени, – дип җавап бирде Равил.

– Син хәзер Казанга барып, театр училищесына керү турында уйла, чегән кызын башыңнан алып ат.

Һәй, бу Илүсә апа! Сизгер дә инде үзе. Кечкенә чакта да шундый иде. Равилнең уйларына кадәр укый ала бит ул. Равил берәр ширлек эшләр алдыннан ук апасы: малай, смотри, ди торган иде. Яшерерсең Илүсә ападан хисләреңне, уйларыңны!

Равил матайның кабызгычына типте. «Тимер дус» бер тибүдә кабынды һәм Равил, апасына чак кына ачулы тавыш белән:

– Утыр! – дип кычкырды.

Матай авылга чапты, ә Равилнең уйлары, каршы искән җилгә ияреп, чегәннәр таборы урнашкан тарафларга оча торды.

...Беркөнне югалган ат табылды – ул авылга үзе кайтты.

Сер булып калды – әллә Лаура таборга исән-сау кайткач, атны авылга китергәннәрме, әллә ат, үзе көтүдән калып, иректә йөргәннән соң, кайтыр юлны тапканмы...

Чегәннәр беркая да китмәгән, алар әле һаман бу тирәдә дигән хәбәр ишетелгәч, Равил бик сөенде. Тагын берничә көннән алар тагын урман буена чыгып урнаштылар – бу хәбәрне шул тирәдән кайткан печәнчеләр әйтте. Чегәннәр өчен ул урын бик җайлы – тирә-яктагы авылларның һәркайсына аларның ыстаныннан ара бер чама иде.

Лаура да Аулаш авылына сәгатьләр буе карап утыра торган булды, аның да Равилне күрәсе килә иде. Тиздән алар моннан башка тарафларга, еракка юл тотачаклар, киткәнче, Равил белән очрашырга тели иде ул.

Лаура урманнан авылга сузылган юлда җиләктән кайтып килүче 11-12 яшьлек малайны шәйләп алды һәм, ике дә уйлап тормыйча, шул тарафка йөгерде. Малай, чегәннәр таборыннан килүчене күреп, котсыз калды, үзенең дә йөгерергә, качарга исәбе бар иде, әмма көне буе урманда җиләк җыеп йөреп, ул бик арыган иде.

Лаура килеп җиткәч, малай беркөнне авыл келәтенә ябылган чегән кызын таныды һәм аның куркуы бермә-бер артты. Малай яланаяк, яланбаш, чәче кояштан саргайган, күлмәге уңган, чалбары тез турыннан ертылган, беләкләре, балтырлары агач ботакларыннан сыдырылган иде.

Лаура, малайның куркудан агарып китүен күреп, матур итеп елмайды:

– Курыктыңмы әллә миннән?

– Курыкмадым, нишләп куркыйм мин синнән, – диде малай, сер бирмичә.

– Исемең ничек?

– Сиңа нигә ул? – диде малай, качарга әзерләнеп.

– Бигрәк әдәпсез малай икәнсең. Минем сиңа бер йомышым бар. Минем исемем Лаура. Әйт инде исемеңне.

– Фаил.

– Җиләк күп җыйгансың икән, банкаң шыплап тулган.

– Булса ни, – диде Фаил. Ул инде курыкмый башлады. Аны чегән кызының йомышы нидән гыйбарәт икәне дә кызыксындыра башлады.

– Фаил, йомышымны үтәрсеңме?

Малай, беравык уйланып торганнан соң:

– Белмим. Нинди йомыш соң ул? – диде.

– Монда Равилне чакыр әле, зинһар. Лаура күрергә тели, дип әйт. Менә сиңа бер сум акча.

Лаура таушалып беткән бер сумлыкны малайга тоттырды.

– Кайсы Равилне? – диде малай, кесәсенә бер сум ачка кергәч, зур җаваплылык тоеп. – Безнең авылда өч Равил бар...

– Өчесе дә яшьләрме?

– Берсе дүртенче классны тәмамлады, бер класста укыйбыз. Икенчесе быел унынчыны тәмамлады, өченчесе яше буенча минем әти белән бер тирәдә бугай, мәктәп котельныенда кочегар булып эшли.

– Унынчы классны тәмамлаганын чакыр, – диде Лаура. – Мин аны әнә тегендә, урман авызында көтеп торырмын.

Фаил, арыганын да онытып, кызу-кызу адымнар белән авылга таба юнәлде.

Равил бүген иртәдән бирле утын яра иде. Биш кубометр утынны урталай кискәннән соң, әтисе фәрман бирде: Казанга укырга керергә киткәнче шушы утынны ярып өяргә!

– Равил абый! Сине болында бер чегән маржасы чакыра! – диде Фаил, капкадан кергән уңайга.

Равилнең кулыннан балта төшеп китте. Ул беравык аңышмыйча торды.

– Кычкырма! – дип җикерде ул. – Кем чакыра?

– Теге... Келәткә ябып бикләп куйганнарие бит... Шул, – диде малай, ешеш сулап. – Исемен әйтте... Муара дидеме шунда... Сине урман авызында көтәрмен, диде.

Бу вакытта Илүсә, мыш-мыш килеп, өйалды баскычын юып маташа иде. Малай кергәндә, ул инде ишек төбенә килеп җиткән иде. Илүсә, гәүдәсен турайтып, өйалды ишеген киеребрәк ачты да, чүпрәкле кулының беләге белән маңгай тирен сөртеп, малайга аптырап карады:

– Кем дисең?

– Теге...

Равил малайга әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

– Булды, бар, рәхмәт, бар, бар, – дип, аркасыннан этеп, капканы үзе ачып чыгарып җибәрде.

Илүсә, чүпрәген ташлап, ике куллап биленә таянды да усал тавыш белән:

– Свиданиегә чакырамыни? – диде.

– Анда синең ни эшең бар! – дип җикерде Равил.

– Апаң белән чамалап сөйләш! – диде Илүсә, олыларча усал итеп. – Бара күрмә!

Равил беравык нишләргә белмичә аптырап торганда, Илүсә тиз генә өйгә кереп китте.

Әти-әниләре өйдә юк иде. Равил, йөгереп барып, бакчадагы коедан су алды, билдән тиң аһ-ваһ килеп юынды, мунча өйалдында һәрвакыт эленеп торган тастымалларның берсен алып, ашык-пошык сөртенде. Күлмәген киярге дип өйгә кергәндә, аны апасы ишек катында каршы алды.

– Йөрмә! – диде апасы янаулы тавыш белән. – Әтигә әйтәм!

– Апа, нинди кеше соң син! – дип ыңгырашты Равил. – Гомергә әләкче булдың.

– Бәйләнмә ул чегәннәр белән. Юньлегә түгел бу. Ахыры начар тәмамланмагае.

– Кит әле, – дип, апасын читкә этеп, Равил олы яктагы шифоньердан кешелеккә кия торган күлмәген киде. Кече бүлмәдәге шкаф тартмасыннан мотоцикл ачкычын эзләгәндә, Илүсә һаман ишек катында энесен күзәтеп тора иде.

– Кая киткән минем матай ачкычы? – дип мыгырдады Равил, әле бер тартманы, әле икенчесен актарып. – Күрмәдеңме?

– Каян белим мин синең ачкычыңны!

– Син бит өй җыештырасың, – диде Равил һәм, шикләнеп, Илүсәгә текәлде. – Бир ачкычны!

– Аны әти алгандыр, – диде апасы, башын читкә борып.

– Нигә ул аңа, матай гаражда бит.

Илүсә кинәт:

– Әй, түтәлләргә су сибелмәгән бит, әни үтерә мине, – дигән сылтау белән өйдән чыгып китте.

Равил аңлады – апасы ачкычны яшергән, энесенең чегән кызы белән очрашуын теләми.

Равилнең йөрәге ярсып типте. Ярар! Илүсә белән талашып, тарткалашып торырга вакыт юк монда. Ул җәяү йөгерде, бу вакытта аңарда шулкадәр куәт уянды – иртә таңнан бирле утын ярган, димәссең. Бу минутларда Җир шарын әйләнеп чыгарлык дәрте-дәрманы бар иде аның. Лаура чакырган аны! Лаура үзе чакырган!

Равил авыл башындагы инеш аркылы күпердән чыгып, калкулыкка менде, үрле җирдән урманга кадәр җәйрәп яткан болынга күз йөгертте. Сул тарафта бер төркем чегәннәр урнашкан, уңдарак, юл урманга кереп киткән якта урман авызында берәү кул болгады. Лаура! Алар, әллә нинди ара булса да, бер-берсен танырлар иде. Лаура! Равил, томырылып, шунда йөгерде.

Туганнары күреп торырлар инде, дигән уй чыңлап үтте. Бу минутларда ул әле үзен ничек тотарга белми, әмма Лаураны күрергә теләве барлык каушау-куркуларны җиңәрлек иде. Аны берни, беркем туктата алмас,ниндидер сихри көч аны алып бара, ул көч аны урманнар артына, диңгезләрнең аръягына алып китәргә әзер иде.

Каршысына атлаган сурәтне абайлагач, аның йөрәге тагы да ныграк җилкенергә тотынды. Әле танырлык булмаса да, аның шиге юк иде – Лаура ул!

Кызны кочагына алып, аны беркем күрми торган тарафларга, икесе бергә калырлык аулак урынга алып китәр иде дә, әмма табор ягыннан күзәтеп торалардыр, шуңа күрә хисләрне тыярга кирәк булыр...

Ара утыз адым чамасы калгач, Лаура, табор ягына ымлап, бармагын иреннәренә тигезде. Бик хискә бирелмә дигәнне аңлатырга теләде ул – Равил шундук төшенде.

Лаура үзен коткарган егет белән очрашуга кардәшләреннән рөхсәт алган иде.

– Исәнме, Лаура, – диде Равил, еш-еш сулап.

– Исәнме, – дип елмайды Лаура.

Лаура бүген тагын да гүзәлрәк иде. Өстендә куе зәңгәр төстәге күлмәк, башында саргылт чәчәкле яулык, аягында бизәкле чүәк. Яулыксыз, бөдрә чәчләре салынып төшкән булса, тагын да әйбәтрәк булыр иде дип уйлап куйды Равил. Ул бүген күз явын алырлык чибәр, муенсаны башканы таккан, үзенең күз төсендәге яшькелт-зәңгәр төстәге төймәләрдән җыелганны, бу күлмәктә аның биле тагын да нечкә күренә иде.

– Сине уйламаган минутым юк, – диде Равил, кызны кочагына аласы килеп.

– Мин дә гел синең турында уйладым. Мине син коткарганны авылдашларың белмәделәрме?

– Өйдәгеләр беләләр. Авылдашлар белмиләр иде, теге малай сөйләп йөридер инде. – Равил кул селтәде: – Әй, белсеннәр. Лом һаман селсәвиттә ята, бармак эзләрен тикшерсәләр, мин икәнне исбатларлар инде. Теге ат табылды, үзе кайткан.

– Әйттем бит, безнекеләр урламады атыгызны дип.

Аларның бер-берсенә әйтер җылы сүзләре бихисап күп иде. Шуңа күрәдер, мөгаен, аларның һәр икесе күңел хисләрен ничек аңлатырга белмичә бер-берсенә карап торды. Хисләр кайнавы шулкадәр көчле иде ки, әйтәсе сүзләр гүя шул кайнауда үзләренең мөһимлеген җуялар иде. Аннары, табор еракта булса да, чегәннәр күреп торалар һәм сүзләрен ишетерләр сыман иде.

– Килер микән, мәйтәм... – дип елмайды Лаура.

– Ничек килмим ди инде, – диде Равил, кыздан күзләрен алмыйча.

– Рәхмәт сиңа, – диде Лаура.

– Ни өчен? – диде Равил. – Синең үзеңә рәхмәт!

– Ни өчен?

– Белмим.

Равил сүзләр таба алмады. Хисләр кайнар чакта аларны сүз белән аңлату мөмкинме соң!

– Без шушы көннәрдә китәбез, – диде Лаура моңсу тавыш белән.

– Ераккамы?

– Еракка. Таганрог тирәсенә бугай. Монда безгә көн күрсәтмиләр. Киткәнче, сине күрәсем килде.

– Миңа хат язарсың... – диде Равил.

Лаура дәшмәде. Ул табор ягына борылып карады да саклык белән генә күлмәгенең кесәсеннән егерме тиенлек акча зурлыгындагы медальчеккә охшаган әйбер чыгарды.

– Рауль, менә бу медаль бик борынгы, тылсымлы. Чегәннәрне гел саклый торган оберег ул.

Равил медальне алып әйләндергәләп карады.

– Кызыклы нәрсә бу, – диде Равил. – Бер ягында бөркет, тәре... Икенче ягында аждаһа... Авызы ачык, койрыгы бөҗраланып бөтерелгән... Бу ягында ярым ай да бар икән...

– Мин аны сиңа бүләк итәм.

– Нишләп аны миңа бирәсең? – дип гаҗәпләнде Равил.

– Бирәсем килә. Ал, безнең нәселне элек-электән михнәтләрдән саклап килгән ул, сиңа да уңыш китерәчәк, гомерең буе саклаячак бу тәңкә.

– Шулай ук тылсымлымыни?..

– Мондый якты күңелле кешегә ярдәм итәргә тиеш ул.

– Минем күңелем якты микәнни? – дип елмайды Равил, Лаурадан мондый сүзне ишетүенә куанып.

– Мин теге көнне синең йөрәк тибешеңне ишеттем, синең йөрәгең дөрес тибә.

Аларның хушлашуы ике кешенең бер-берсеннән төрле тарафларга киткәндәге саубуллашу түгел, ә асылда ниндидер бүтән мәңге кабатланмас нәрсә белән хушлашу кебек иде.

Лаура китәргә ашыкты:

– Хуш, Рауль!

– Сау бул, Лаура! – диде Равил. – Без тагын кайчан очрашырбыз икән?

Әмма җавап ишетелмәде, Лаура инде китеп барды.

Равилнең, йөгереп барып, кызны кочагына аласы, китмә, дип кычкырасы килде, ул шактый вакыт баскан урыныннан кымшанмыйча ерагаеп барган Лаурага карап торды.

Авылга кайтасы килми... Җәйге ыгы-зыгы, авыл эше инде тәмам туйдырды... Күңел хөрлек эсти. Әнә, чегәннәр – бәхетле халык, үз ирке белән гомер сөрәләр. Әмма кайтырга кирәк. Ул әкрен генә атлап авылга кайтып китте.

Шул көнне Равил якты, матур төш күрде: ул биек тауга менде – җиңел генә, бернинди арусыз. Тау башына менеп җиткәч, гаҗәеп җиңеллек тойды ул. Аста фирүзә төсендә диңгез җәйрәп ята, офык тарафыннан җылы җил исеп, җанга-тәнгә рәхәтлек бирә.

Икенче көнне Равил, матаена атланып, биш чакрым ераклыктагы күрше авылда яшәп яткан багучы, фал ачу белән маташучы Кадрия апа янына китте.

Кадрия карчыкның им-том, сихер-михер, күрәзәчелек белән шөгыльләнүе илнең коммунизм төзүенә һич кенә дә зыян китерми иде. Күптән түгел билгеләнгән яңа участковый милиционер аңа очраган саен бармак яный, әмма Кадрия апа андыйлардан һич кенә дә шүрли торган зат түгел иде. Берсендә хәтта шактый каты итеп җавап бирде.

Участковый:

– Кадрия апа, сәвит илендә мондый эш белән маташырга ярамый, – дигәч, Кадрия аңа:

– Син преступникларны тот. Һәм үзеңә бәла-каза килмәсен дип, Ходайдан сора, – диде.

– Мин атеист, – диде аңа яшь милиционер.

– Аллаһы Тәгалә синең атеистмы-матеистмы икәнеңне сорап тормый ул, китерә дә суга, – диде аңа Кадрия.

– Син үзең дә Аллага ышанмыйсыңдыр, мондый эш белән маташкач...

– Алла кушмыйча беркем берни эшли алмый.

Участковый, ямьсез елмаеп, багучыга карап торды:

– Димәк, мин сиңа протокол төзесәм, Алла кушуы буенча килеп чыга, шулаймы?

– Юк, анысы иблис котыртуы буенчарак килеп чыгачак, – дип җавап бирде Кадрия.

Кече лейтенант алтмыштан узган бу апаны коры кул белән алып булмаганны аңлап, башкарак тонда сөйләшә башлады:

– Кадрия апа, син үзеңнең төрле сыекчаларыңа, кибеп каткан сөякләреңә, төрле төймәләреңә ышанасыңмы соң?

– Ничек инде ышанмыйм, ди! Минем төймәләр, синең китель сәдәпләреңнән аермалы буларак, ерак буыннардан сакланып килгән төймәләр.

– Ярар, бәлки, синдәге чүп-чар борынгыдыр, әмма үзең кылган гамәлләрне ихластан ышанып башкарасыңмы соң син? – дип бәйләнүен дәвам итте участковый.

– Менә, энем, син милиция формасын киеп йөрисең... Берәр кайчан илдә тәртип урнаштырырмын дип ышанасыңмы син үзең?

Участковый шундук җитди кыяфәткә керде:

– Әлбәттә, ышанам. Килер шундый вакыт, җинаятьчеләр бетәр, синең ише сихерчеләр дә калмаячак.

Кадриянең бу сүзләргә һич кенә дә исе китмәде:

– Минем кебек багучылар Җир йөзендә кеше яралганнан бирле булган.

Ә сәвит милициясенә ничә ел? Коммунизмны төзеп бетергәч тә, хорафатка ышанучылар булачак, башкача мөмкин түгел. Минем яныма хәтта партком секретарьлары, хәтта прокурорлар да килә...

Шундыйрак әңгәмәләр, участковый белән Кадрия очрашкач, гел булып ала һәм тәртип саклаучы егет, аптырагач, гел кул селтәп китеп бара.

Равил килеп керүгә, Кадрия кырыс тавыш белән:

– Нишләп матаеңны рәшәткәгә якын куйдың? – диде.

– Ярамыймыни? – дип, Равил каушап калды.

– Ауса?..

– Нишләп аусын ул, – диде Равил. – Исәнме, Кадрия апа!

– Исән булмасам, сөйләшә алмас идем бит, – диде Кадрия. – Ник килдең?

Равил күрәзәче апа болай салкын каршы алыр дип көтмәгән иде.

– Мин күрше авылдан... – диде ул, никтер, үзен уңайсыз хис итеп.

– Шуннан?

– Равил минем исемем.

Кадрия күзләрен чекерәйтеп карап торды.

– Син теге шофёр Закир малае түгелме? – диде ул, тавышын бераз йомшартып.

Равилнең эченә җылы йөгерде:

– Әйе, шуның улы.

– Әниең Нурия бугай... укытучы.

– Әйе, әнием – Нурия. Шуларның улы мин.

Кадриянең караңгы чырае чак кына яктырып киткән сыман булды.

– Гашыйк булдыңмыни? – диде ул, егеткә күз карашын кадап.

– Кемгә? – дип, аптырап китте Равил.

– Кемгә икәнен төгәл үзең беләсең инде.

– Кадрия апа, мин менә нинди йомыш белән килдем... – Равил чалбар кесәсеннән Лаура бүләк иткән тәңкәне алып күрсәтте. – Бу акчамы, төймәме, медальме, әйтә алмыйсыңмы?

Чегән кызының бүләген шактый вакыт әйләндергәләп караганнан соң, Кадрия беравык күзләрен йомып утырды.

– Каян алдың моны? – диде ул, тәңкәне Равилгә кире биреп.

– Таптым, – дип алдады Равил.

– Кайда?

– Бәрәңге матиклаганда.

Кадрия тупас тавыш белән:

– Кайткач, әбиеңне алдарсың! – дип җикерде. – Кем бирде моны сиңа?

– Бер кыз.

– Әйе, күрәм, – диде Кадрия, читкә карап. – Кыз сезнең авылныкы түгел...

– Безнең авыл кызы түгел.

– Аңа да унҗиде яшь... – диде Кадрия.

Равил шаккатты:

– Әйе, аңа да унҗиде... Аны безнең авылда...

– Беләм, – диде Кадрия. – Атны урламаганнар, көтүдә йөргәннән соң, ат болын иркендә үзе калган. Атның үзе әйләнеп кайта торган гадәте бар аның. Ат – акыллы хайван.

– Әйе, ат табылды. Ат үзе кайткан, – диде Равил шат тавыш белән.

– Син ул кызны тоткынлыктан азат иткәнсең. Ул сукбай кыз рәхмәт йөзеннән биргән бу тәңкәне.

Равил шаккатты.

– Нәкъ шулай, Кадрия апа. Ничек, каян беләсең син барысын да?!

– Юк-бар сораулар бирмә, сүгендерәсең хәзер! – дип җикерде Кадрия.

– Тылсымлы әйберме бу? – дип сорады Равил.

– Шундыйга охшаган, – диде күрәзәче. – Әмма алмаска идең. Сиңа файда китерә торган нәрсә түгел ул.

– Булсын. Миңа бу тәңкәдән файда кирәкми. Бик затлы әйбергә охшаган бит.

– Бу дөньяда затлы әйбер дә, пүчтәк әйбер дә файдасын да, зыянын да китерә ала.

Равил башын чайкап:

– Бу тәңкә миңа зыян китерер дип ышанмыйм, – дип елмайды.

– Синең ышануың белән ышанмавың арасында минем өчен аерма юк. Мин сиңа күргәнемне, тойганымны әйтәм. Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк.

Равил үзенең иң мөһим соравын бирергә җөрьәт итте:

– Кадрия апа, мин ул кызны тагын берәр тапкыр очратырмын микән?

Кадриянең күзләрендә усаллык чагылды:

– Аның белән очрашу кирәкме соң сиңа? – диде ул.

– Кирәк! – дип катгый итеп әйтте Равил.

– Очрашуын очрашырсыз анысы... – дип мыгырдады Кадрия. – Очрашачаксыз.

– Кайчан? – дип сорады Равил, җанланып.

– Озакламый. Шушы айда ук.

– Мин тиздән укырга керергә Казанга китәм. Казанда очрашачакбыз микән әллә?

– Юктыр, Казанда түгелдер, – диде Кадрия. – Беренче очрашуыгыз шушы тирәдә булачак. Ә инде күпмедер вакыт узгач, ерактарак очрашачаксыз... Анысы, бәлки, Казанда булыр.

Равилнең башка сораулары юк иде, очрашачаксыз дигәч, муеннан җиткән инде. Аның иңнәренә гүя канатлар үсеп чыкты.

– Өч сум җитәме? – диде ул, кулын чалбар кесәсенә тыгып.

– Синең әти-әниең әйбәт кешеләр, шуңа күрә өч сумга риза, – диде Кадрия, кәкре бармаклары белән бөгәрләнгән «өчлек»не тигезләп.

Равил кат-кат рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Матае да менә-менә очып китәрдәй булып чапты. Равил юл буе мотоцикл тавышыннан да көчлерәк итеп кычкырып-акырып җырлап кайтты.

Өйдәгеләрдән качып, Равил серле тәңкәне, медальон итеп, җеп белән муенына тагып куйды.

**6**

Равил бала чактан ук артист булырга хыялланды. Өлкәннәр дә, җырга-биюгә оста, кыланырга ятратканга күрә, аңа кечкенә вакытта ук, мөгаен, артист булырсың син, диләр иде. Әмма инде хәзер, Казан театр училищесына керәм дигән теләген белдергәч, этисе дә, әнисе дә каршы

килә башладылар, кечкенә чакта мактау йөзеннән генә артист булырсың дигәннәр икән аңа. Җитди профессия түгел, шушы гәүдәң белән сәхнәдә кылтый-пылтый кыланып йөрерсең микәнни гомер буе, диделәр.

– Әле керергә кирәк бит анда, – диде Равил. – Әллә алалар, әллә юк...

– Йөрмә кеше көлдереп! – диде Закир.

Авыл хуҗалыгы институтына керергә әтисе аны җиденче-сигезенче классларда ук өнди башлаган иде. Нурия, Арча педучилищесын тәмамлаганнан соң, күп еллар мәктәптә башлангыч класс балаларын укыткан кеше, улының педагог булуын теләгән иде.

– Пединститут әйбәт. Алабугадагы институтка кер. Завуч булырсың, аннары мәктәп директоры итеп куярлар. Мәктәп директоры бик абруйлы эш, – диде ана, гәрчә улының барыбер үз сүзендә торачагын белсә дә.

Әмма Равил үзен механик итеп тә, педагог итеп тә күз алдына китермәде.

Ә менә Илүсә энесенең актёр булырга теләвенә бик сөенде. Апасы үзе дә моңлы тавышлы, матур җырлый, әмма мәктәптә энесе кебек үк әйбәт укымады, институтларга керү уенда да булмады, иптәш кызы белән медучилищега кереп укый башлагач, моңа һич кенә дә үкенмәде.

– Синнән шәп артист чыгар, – диде Илүсә. – Артистларны бөтен кеше таный, аларның тормышы кызык, безнеке шикелле төксе түгел.

– Ярый ла ул, данлыклы артист булып чыксаң. Халык яратмаса, синең артистлыгың пычагымамыни? – диде әнисе, борчылып.

Әтисе Равил сайлаган юлга бөтенләй каршы булды:

– Егетләрский һөнәр кирәк, – диде ул. – Авылларда агрономнар, зоотехниклар җитми. Иң яхшысы – механикка укырга керү. Чистайда авыл хуҗалыгы техникумы бар – менә дигән техникум, шунда укып кайтып, үзебезнең МТСта механик булып эшләр идең, аннары баш инженер итеп куярлар. Бәлки, тора-бара сельхозтехникага эшкә чакырырлар. Бик күп зур нәчәлникләр, абруйлы кешеләр башта Чистай техникумында белем алдылар.

Кыскасы, әнисе, укытучы буларак, улының мәктәп директоры булуы турында хыялланды, әтисе, шофёр буларак, улын үзе эшли торган паркта механик итеп күрергә теләде, әмма Равилнең үҗәтлеген җиңә алмагач, икесе дә күнеп, кул селтәделәр.

– Әле үзе дә ошатмас театрны, керә алса да, үзе ташлар, – дип фаразлады Закир. – Ну, артист нинди профессия инде ул! Җитди эш түгел бит инде.

– Күпме хезмәт хакы ала икән артист? – дип уйга калды Нурия. – Күп түгелдер... Узган елны авылыбызга спектакль белән килгәннәр иде бит. Клубка кергәндә, мин артистларның өс-башларын күрдем – бигрәк фәкыйрь.

– Юлда да затлы кием киеп йөрмәсләр бит инде, – диде Илүсә.

Нурия барыбер:

– Аттестатыңда бер генә өчле дә юк, юньлерәк вуз турында уйласаң, әйбәт булыр иде, – дип торымнан-торымга әйтә торды.

Равил үзе өчен карар кылган иде инде – Казанга, театр училищесына!

Менә инде башкалага барып, документларны тапшыру вакыты да җитте. Нәкъ менә шул көннәрдә аның каты итеп теше сызлый башлады, тешне дәваларга тиз генә Чистайга барып кайтырга кирәк иде. Элекке район үзәге булган Кызыл Таң якынрак, әлбәттә, анда теш дәвалау клиникасы бар, әмма

Чистайда әтисенең туганнан туган сеңлесе Зөлфирә апа теш врачы булып эшли, Равил аның янына барырга булды.

Вакыт тар, озакка сузарга ярамый, Равил попутка белән Кәрәкә бистәсенә китте. Пристаньда метеорны озак көтәргә туры килмәде, кечкенә «тимер аккош» аны Чистай шәһәренә алып китте.

Зөлфирә апа авызын киң итеп ачып утырган Равил белән бертуктаусыз сөйләште, үзе шул ук вакытта тешне дәвалап, ямап та куйды. Аннары апасы Равилне үзләрендә куна калырга өндәде, әмма Равилнең Казанга китәсе бар, тизрәк авылга кайтып, юлга әзерләнергә кирәк иде.

Ул пристаньга төшеп китәргә ашыкмады – метеорлар кичке эңгер-меңгергә кадәр йөреп тора, шактый вакыт бар иде әле.

Ипи кибетеннән ике клиндер алып чыгып ашагач, Чистай урамнарында бераз йөрисе килде.

Каяндыр дүрт яшүсмер килеп чыкканын ул сизми дә калды. Алар да Равил яшендә, кыяфәтләреннән күренеп тора – шпана малайлар иде. Боларның өчесе чандыр нәрсәләр, дүртенчесе тәбәнәк буйлы, киң җилкәле иде. Равил коелып иңмәде, каршы торырга әзерләнде – нык гәүдәле, егәрле авыл малае буларак, Равилнең боларга бирешергә исәбе юк иде.

– Әй, колхозник! Акчаң бармы? – диде берсе.

– Юк, – диде Равил, сугышырга әзерләнеп.

Икенчесе:

– Сал сәгатеңне, – дигәч, Равил аңа авылча сүгенеп җавап бирде.

Ышпаналар мондый дорфалыкны көтмәгәннәр иде. Берсе кизәнде, Равил читкә тайпылып калды, икенчесе арттан сикергәч кенә, Равилгә бер-ике йодрык килеп кунды, әмма зыян китерерлек сугу түгел иде ул. Равилнең кулларын каерырга маташтылар, эченә, касыгына суктылар, ләкин һич аяктан ега алмадылар. Әүмәкләшкәндә, күлмәк эченнән чыгып түштә асылынып торган тәңкәне берсе йолкып алды – моны Равил аермачык хәтерли.

Кибеттән чыккан бер хатын чәрелдәп:

– Нишлисез?! Сугышмагыз! Милиция! – дип кычкыргач, малайлар шундук юкка чыктылар.

Равилнең сәгате кулында, әмма түшендәге чегән тәңкәсен йолкып алганнар иде. Тәңкәдән мәхрүм калуы аны нык тетрәндерде. Сугышканда, сәгать каешы өзелә язган, ул чак кына эләгеп тора иде, Равил, сәгатен салып, кая барганын да белмичә атлады. Кулыннан сәгате ычкынып, юл ташына шыкылдап төшкәч кенә айнып китте ул.

Менә, медальонны югалткач, бәлаләр башланды – сәгатем төшеп ватылды дип уйлады ул. Сәгать йөрүен йөри, әмма пыяласы чатнаган иде. Тәңкәне алып качтылар! Лауранның бүләге бит ул, өстәвенә тылсымлы, борынгы әйбер иде. Әйтерсең лә аяклары махсус шул урамга алып барган – «милиция» дигән язуны укыгач, аны-моны уйлап тормады, туп-туры отделга кереп китте.

Равилнең нинди йомыш белән кергәнен ишеткәч, дежур милиционерның бер төге дә селкенмәде. Өлкән сержант битарафлыгын яшермичә:

– Аны хәзер ничек тапмак кирәк? – диде. – Гариза яз, эзләп карарлар.

Кайсыдыр ишектән кече лейтенант килеп керде. Өлкән сержант аңа Равилне талаганнарын әйткәч, кече лейтенант:

– Кайда, ничек таладылар? Нәрсәңне алдылар? – дип кызыксынды.

Равил барысын да сөйләп биргәч, кече лейтенант, күзләрен чекерәйтеп:

– Кичә төнлә музейны басканнар... – диде. – Синең медальоның борынгы дисең, син аны каян алган идең?

– Чегән кызы бүләк итте.

– Ник бүләк итте? Чегәннәр болай гына берни дә бүләк итмиләр...

Равил:

– Ярый, гафу итегез, – дип чыгып китмәкче булды, әмма әле генә кергән милиционер кычкырып:

– Стоять! – диде.

Ул шундук, телефоннан шалтыратып, чегән кызын алып килергә кушты. Дежур бүлмәнең арткы ишеге ачылды һәм... Лаура пәйда булды, Равил үз күзләренә ышанмыйча torаташ булып катып калды.

– Лаура!

– Рауль!

– Менә, менә, бер-берегезне тануыгыз бик әйбәт, – диде кече лейтенант, елмаеп. – Алайса монда, гадәттә, бер-берсен танымаган булып кыланалар.

– Шушы кыз бүләк иткән идеме? – дип сорады өлкән сержант.

– Әйе.

Кече лейтенант Лаураның каршысына килеп басты:

– Әнә, борынгы медальон бүләк иткәнсең икән бит. Каян алдың син аны?

– Әбиемнән калган медальон ул, – диде Лаура.

– Ялганлама. Кичә музейны басканнар. Ярар, тикшерербез. Әлегә камераңда ят.

Өлкән сержант Лauраны алып киткәч, Равил:

– Бу кыз музей баса торган түгел! – диде. – Җибәрегез аны.

– Үзеңне ябып куймаганга рәхмәт әйт тә авылыңа элдер инде син, – диде аңа «олы җанлы» кече лейтенант.

Милиция бүлегеннән саф һавага чыгып, нишләргә белми торганнан соң, Равил дежур частька кире керде. Кече лейтенант чыгып киткән иде, куе яшел төстәге кружкадан чәй эчеп утырган өлкән сержанттан бүлек начальнигының бүлмәсен сорады.

Бүлек начальнигы – юан капитан – бик авыр сулаучы урта яшьләрдәге кеше иде. Юанлыктанмы, үпкә чиреннәнме – аның һәр сулышы авырлык белән ясалганы күренеп тора, хәтта каршысында утырган әңгәмәдәш тә аңа карап, һава җитмәгәнне тоя иде.

Ул, Равилне тыңлагач:

– Син кайсы авылдан? – дип сорады.

– Аулаштан.

Капитанның йөзе караңгыланып китте:

– Аулаштан?!

– Ишеткәнегез бармы?

– Яшь чакта, Сабан туена баргач, мине анда кыйнаганнар иде, – диде капитан борын төбенә генә.

– Сез яшь чакта мин бәләкәй булганмындыр, – диде Равил. – Сезне кыйнауда катнашмадым мин.

– Музейны чегәннәр басмаган, әле генә шалтыратып әйттеләр. Шулай

да бу кызны әлегә чыгармыйм, – диде капитан, сүзләрен дә авырлык белән генә авызыннан чыгарып.

– Нишләгән соң ул? Нинди гаебе бар? – диде Равил хафалы тавыш белән.

– Чегән ул – гаеп шунда.

– Ул бик әйбәт кыз.

– Әйбәт? – дип чыраен сытты капитан. – Беркайда, беркайчан әйбәт чегәнне күргәнем юк.

– Лаура музейлар баса торган кыз түгел. Ул – табигать баласы. Ул – гадалка, карак түгел. Ул чибәр...

Капитан, мутлы елмаеп:

– Син аны ниме?.. – дип пышылдады.

Равил аңламады:

– Нәрсә, ниме?

– Аның белән тудым-судым итмәгәниеңме?

– Юк.

– Каян беләсең әйбәт икәнен?

Равил пыяласы чатнаган сәгатен чалбар кесәсеннән алып, начальникка бирде:

– Мәгез, шәп сәгать, бераз пыяласы гына чатнаган. Сезнең монда данлы сәгать заводы бар, пыяласын гына алыштыра алырсыз.

Начальник сәгатьне әйләндергәләп, селкетеп карагач, колагына куеп тыңлап карады да өстәл тартмасына тыгып куйды.

– Сәгатьне дә чегәннәр бүләк иткән идеме? – дип сорады ул.

– Юк, үземнеке, – диде Равил. – Былтыр җәйге каникулда ындыр табагында эшләдем, шул акчага алынган сәгать.

Капитан беравык уйланып утырды да:

– Бар, тышта көт, – диде.

Капитан алдамады микән дип борчылып, Равил әрле-бирле йөрде. Озак көтәргә туры килмәде, милиция бүлегенең ишегеннән Лаура чыкты, Равил хәтта бер мәлгә һушсыз калды.

Лауранын өстендә кайчандыр ачык зәңгәр чәчәкле булган, тора-бара төсе уңган күлмәк, әмма, кем әйтмешли, сылу кешегә солы капчыгы да килешә – аңа карап туймаслык иде. Лаура ни кисә дә, гүзәл булачак, йөзе генә бүген бераз агарган иде аның. Аягында инде Равилгә таныш чүәкләр, бүген ул яулыксыз иде, биргән бит Ходай чәчне – аның куе-кара бөдрә чәченә тарак та, Илүсә апасыныкы шикелле бигуди да кирәк түгел шул.

Лаура, караңгыдан чыккач, күзләре яктыга ияләшкәнне көтеп, бер урында басып торды.

– Лаура! – дип, аңа таба атлады Равил.

– Рауль?! – дип гаҗәпләнеп, моңсу елмайды кыз.

– Менә, тагын очраштык! – дип, шат аваз салды Равил, кайда ничек очрашуларын бөтенләй онытып.

Һәр икесе үз күзләренә ышанмыйча торды, әйтерсең лә бу очрашуны кемдер махсус оештырган.

– Рауль, ничек, каян килеп чыктың син?! – диде Лаура, шаккатып.

Равил кызны кочагына алды:

– Күрәсең, без, һичшиксез, очрашырга тиеш булганбыз, башкача мөмкин түгел иде.

Равилне шатлык белән бергә Лаураны кызгану хисе биләп алды. Шушындый гүзәл кызны гел тоткарлыйлар, ябып, бикләп куялар, ул гел кемнәрдәндер куркып, качып яшәргә мәҗбүр. Дөрес түгел бит бу! Шунысы гаҗәп – Лаура курыкмый, һәрвакыт тыныч, гел моңсу гына елмаеп тора. Ул курыкмый, чөнки гаепле түгел. Менә хәзер дә аңардан якты нур бөркелеп тора. Кереп чумарга иде аның күңел дөньясына – ямьле, якты дөньядыр ул.

Ни сәбәпле очрашсалар да, аларга очрашу үзе кыйммәт иде. Лаураның кайнар сулышы күлмәк аша тәнне өтеп-өтеп алды, алар шатлыктан бертуктаусыз көлделәр, һәр икесе нәрсәдер әйтә, ләкин әйткән сүзләрнең мәгънәсен аңларлык түгел иде.

– Сиңа һич кенә дә тыныч яшәргә бирмиләр, гел тоталар да ябып куялар, – диде Равил, моңсу елмаеп.

– Әйтмә дә, – диде Лаура бернинди аһ-зарсыз. Равил тизрәк кызны бу тирәдән алып китәргә ашыкты, кая барганнарын да белмичә, алар урам буйлап атладылар. Равил сөйләде дә сөйләде, Лаура елмаеп тыңлап барды.

Равил медальоннан колак какканын әйткәч, Лаураның сөмсере коелды.

– Яман билге бу... – диде ул, туктап.

– Алар бит дүртәү иде. Башта алар сәгатемне алмакчылар иде, сәгатьне алу хәлләреннән килмәде, муенымнан медальне йолкып качтылар.

– Сәгать ничә икән хәзер ? – диде Лаура, сәгать турында сүз чыккач.

– Белмим. Сине азат итсеннәр өчен сәгатемне милиционерга бирдем.

– Әрәм иткәнсең сәгатеңне.

– Аның барыбер пыяласы чатнаган иде. Сәгать кайгысымыни монда, аның караввы, син ирекктә. Сине ник тоткарладылар соң?

– Чегәннәргә облава ясадылар.

– Мондый гүзәл затны һәркемнең ябып, бикләп куясы килер инде ул, – дип шаярды Равил.

– Син бит мине менә бикләмисең, киресенчә, ике тапкыр инде коткардың.

– Дөресен әйткәндә, мин дә сине үземнең тоткыным итәр идем. Башка төрле тоткын итәр идем – сине иркәләр өчен, назлар өчен, яратыр өчен.

– Яраткан кешеңне тоткын итеп буламыни?

– Юктыр. Мин болай гына әйтәм инде. Карале, Лаура, син бүләк иткән медальон үзен урлауга каршы торалмыймыни? Бәлаләрдән саклый торган булгач, нишләп минем муенымнан үзен йолкытты ул?

Лаура Равилгә текәлеп карап торды да катгый итеп:

– Ул югалырга тиеш түгел! – диде.

Равил кинәт боегып китте – алга таба нишләргә? Алар тагын аерылышачаклар... Равил аны үзе белән алып кайтып китәр иде дә бит, беренчедән, ул аны авылга алып кайтса, өйгә кертмәячәкләр, икенчедән, авыл халкы алдында да әллә ничек... Аннары, Лаура үзе дә татар авылына кайтмаячак, ул барыбер үзенекеләр белән дөнья буйлап китәчәк.

– Нишлибез? – диде Равил, күрешү шаукымы бераз сүрелгәч.

– Миңа үземнекеләрне табарга кирәк.

– Кайда соң алар?

– Хәзерге вакытта Саратовта булырга тиешләр. Безнең монда шәһәр

читендә йорт бар, анда туганнарым яши, шунда үземне рәткә китерәм дә иртәгә пароход белән төшеп китәм. Ә син?

– Миңа авылга кайтырга кирәк. Вакыт бар әле, әйдә, берәр җирдә капкалап алыйк.

– Әйдә базарга, – диде Лаура.

Базар зур булмаса да, гөрләп тора иде.

Кайнар пәрәмәчләр ашаганнан соң, кәефләр тагын күтәрелеп китте. Алар, җитәкләшеп, базар рәтләре буйлап үттеләр. Бөтен нәрсә онытылды – Казанга барасы, авылга кайтасы, укырга керәсе... Мәңге шулай йөрергә иде Лаура белән. Әгәр хәзер аңа Лаура: әйдә минем белән таборга, дисә, һичшиксез ияргер иде, җәһәннәм тишегенә булса да, бу кыз белән китәр иде, мөгаен.

Кинәт Равил түшеннән төймәне йолкып алган хулиганны абайлады. Әйе, ул! Таныды аны Равил. Хулиган, үрелеп, вак-төяк сатучы карчыкның түрдәге товарын күзәтә иде.

– Әнә, күрәсеңме, кара картузлы, тәбәнәк буйлы малайны? – диде Равил.

Лаура ул күрсәткән якка карады:

– Кара пинжәклеме?

– Әйе. Әнә шул йолкып алды медальне.

Алар шактый вакыт шул малайны күзәтеп, артыннан ияреп йөрделәр. Карак малай берничә кешегә мөрәҗәгать итте, сүзләре ишетелмәде, берсенә ул куен кесәсеннән нәрсәдер чыгарып күрсәтте һәм шундук кире тыгып та куйды.

Лаура, Равилне читтәрәк калдырып, малай янына килде:

– Ни сатасың? – диде Лаура ясалма ягымлы тавыш белән.

Малай башта Лаурага сынаулы караш белән карап торды, аннары күзләрен елтыратып, зур кызыксыну белән чегән кызын җентекләп күзәтте. Шуннан соң, як-ягына каранып, куен кесәсеннән теге тәңкәне чыгарып, Лаурага күрсәтте:

– Илле сумга бирәм, – диде ул. – Затлы әйбер.

Лаура үзенең тәңкәсен ничек танымасын инде! Ул талисманның табылуына куанды, һәвәсләнеп китте:

– Һи, бу калай кисәген кем илле сумга алсын, – диде ул, елмаеп.

– Күпме бирәсең? – диде малай җитди кыяфәт белән.

Бу вакытта Равил арттан килеп:

– Хәзер маңгаеңа берне бирәм! – диде дә тәңкәне йолкып алды.

Малай үзе генә Равилгә каршы тора алмасын аңлады, дуслары шушы тирәдә иде, ахрысы, авызын кәмит формага китереп, сызгырырга тотынды.

Дуслары җыелгандырмы, юкмы, Равил белән Лаура базардан чыгып йөгерделәр, арттан куучылар күренмәде.

Табылды тәңкә! Ул тагын аңарда! Бәхет китерә торган медаль, ди, бит. Бәхет кирәк иде Равилгә! Бәхет Лаурага да кирәк иде. Бәхет һәркемгә кирәк бу дөньяда!

– Могҗиза бит бу, Лаура! Вакыйгалар бөтенләй көтмәгәнчә килеп чыга! – диде Равил тантаналы тавыш белән.

– Әйе, мин бәлагә тарыгач, гел син килеп чыгасың, – диде Лаура, Равилгә елышып.

– Бу тикмәгә түгел бит.

– Әлбәттә, тикмәгә түгел.

Равил кулларын як-якка җәйде:

– Нинди рәхәт һава, – диде ул, киерелеп. – Димәк, син Саратов якларына юл тотачаксың?

– Мин Чистай читендәге туганнарыма хәбәр җиткерергә тиеш, башта шунда барам.

– Анда ничек барасың?

– Җәяү.

– Хәбәреңне җиткер дә, аннары, әйдә, минем белән, – диде Равил.

– Кая? – диде Лаура, моңаеп.

Равил дәшмәде. Чыннан да, кая алып бара алсын ул аны?!

– Мине пристаньга кадәр озатасыңмы? – дип, кыюсыз гына сорады Равил.

– Озатам.

Су буенда һава тагын да рәхәтрәк иде.

Агымсу... Талгын агым җанга тынычлык бирә. Нишләп тормыш та шулай салмак кына акмый икән?..

– Шушы агымсуга ияреп, синең белән бер салда агып китәргә иде, – дип, хыялга бирелде Равил.

– Агымсу диңгезгә коя, анда ул инде агымсу булудан туктый. Менә без күзәтеп торган агым, мизгел саен үзгәреп тора, безгә генә мәңгелек илаһи бер күренеш сыман ул, без күргән хозурлык бер мизгелдә үзгәрә.

Равил, шаярып:

– Чегәннәр болай акыллы фикерлиләрдер дип уйламаган идем, – диде.

– Ни дигән сүз инде бу? – дип, иреннәрен турсайтты Лаура.

– Сезнең алфавит бармы ул?

– Юк.

– Китаплар укымыйсызмыни?

– Китап укучыларыбыз бар. Без гомер бакый үзебезнең тарихны, легендаларны буыннан-буынга телдән-телгә күчереп киләбез, безнең бөтен мәдәниятебез хәтердә саклана.

– Кызык. Алай кыйммәтрәктер дә әле ул, чөнки китапларга әллә ниләр язып калдырырга була, ә хәтердән хәтергә күчкән мәдәнияттә аның иң кирәкле үрнәкләре генә сакланадыр, алай кыйммәтрәктер ул.

Лаура ясалма җитдилек белән башын чайкады:

– Авыл малае болай акыллы фикерлидер дип һич уйламас идем.

Икесе дә көлеп җибәрделәр, кәефләр тагын күтәрелеп китте. Равил метеорның ничәдә киләсе белән кызыксынып та тормады, килгәч, тиз генә билет алып кереп утырырмын дип уйлады. Аның хәтта моннан беркая китәсе килми башлады – Лаура аның белән, алар янәшә, ул аның күзләрен күрә, тавышын ишетә, сулышын тоя.

Пристань янындагы ярга барып утыргач, Равил су өстеннән еракка карап:

– Тиздән Казанга китәм, театр училищесына керергә, – диде. – Алырлар микән?..

– Алырлар, – диде Лаура. – Син чибәр егет, буй-сының бар. Гомумән, шәп егет син.

Равил кызның бу сүзләреннән уңайсызланып китте, хәтта үзенең йөзенә кызыллык йөгергәнне тойды. Лаура аның өчен илаһи зат – келәтләргә бикләнеп, камераларда утырып, планета буйлап сукбайланып йөрүче бу кызның башка кешеләрдән нииндидер өстенлеге бар кебек иде.

– Ышанам, имтиханнар биргәндә, син бүләк иткән тәңкәнең ярдәме тияр, – диде Равил. – Тылсымлы ул, күңелем сизә. Менә бит, без синең белән хәзер тагын көтмәгәндә очраштык – киноларда гына була торган хәл. Тәңкәне талап алдылар, без аны яңадан үзебезгә кайтардык... Бу чынлап та тылсымлы тәңкә!

– Әйе, тирән тарихлы әйбер ул. Миңа аны әбием шундый матур итеп сөйләгән иде. Моннан биш йөз ел элек әле Россиядә ромалэ булмаган. Кайчандыр Индиядән чыккан кабиләләр Кече Азия аша Европа җирләренә барып җиткәннәр. Аннан тагын көнчыгышка күченүчеләре дә була. Безнең нәселнең ерак бабалары Кырымга китәләр, без, ромалэ, анда кырымлылар тарафыннан «чингеннәр» дип аталганбыз. Оста куллы һөнәрчеләребез, музыкантларыбыз, җырчыларыбыз җирле халыкны таң калдыра, шуңа күрә Кырым илендә чингеннәрне яхшы кабул итәләр, әмма багу, күрәзә итү кебек кәсепләре белән шөгыльләнергә рөхсәт бирмиләр. Минем Мирела исемле ерак әбиемне им-томлык, багучылык белән шөгыльләнгәне өчен Кырымда тотып, зинданга япмакчы булалар. Ул вакыттагы хан хатыны Нурсолтан бигемнең Гәүһәршад исемле кызы була. Гәүһәршад Миреланы, азат итеп, Казанга үзе белән алып китә, чөнки ул үзе дә им-томлык, күрәзәчелек белән бик кызыксынган була. Казан янындагы бер бистәдә Мирелага йорт-җир бирә, ул шунда яши.

– Мирела Казанда калганмы?

– Юк, качкан ул, кире Кырымга кайткан – балалары, туганнары янына.

– Күпне күргән әйбер икән бу, – дип, уйга калды Равил, уч төбендәге тәңкәгә карап.

– Мирела кайчан, нинди вакыйга буласын Гәүһәршадка алдан әйтеп торган, Казанның җиңелеп, буйсынасын да алдан күргән.

– Димәк, бу тәңкәгә 500 ел бар?

– Күбрәктер дә әле. Бу тәңкә элек-электән безнең нәселне михнәтләрдән саклап килгән.

– Ничек шундый затлы тәңкәне миңа бүләк итәргә булдың?!

Лаура башын Равилнең иңенә салды:

– Бүләк итәсем килде, – диде ул, күзләрен йомып. – Әллә кемнәрне очратканым бар, ә синең кебекне күргәнем юк иде.

– Ничек инде ул – минем кебекне? – диде Равил, кызны кочып.

– Ачык, ихлас, якты күңеллене.

– Син тагын минем белән очрашырга телисеңме соң?

– Әйе.

– Кайчан тагын очрашырбыз икән?

– Кем белгән инде аны. Бәлки, бүтән беркайчан да очрашмабыз.

Равилнең кинәт сөмсере коелды:

– Син моны шундый тыныч әйттең... – диде ул, тавышында шелтә белдереп.

– Бүтән очрашмабыз дип кайгырып утырыйммыни?

– Без синең белән һичшиксез очрашырга тиеш. Менә бит, бергә кунганнан соң, күп тә үтмәде, тагын очраштык – тикмәгә түгел бу.

Кыска гына вакыт эчендә аларга ике тапкыр очрашырга насыйп булды. Әйе, күңелсез хәлләр аркасында очраштылар, әмма аларның очрашуы үзе ямьле ләбаса! Киләчәк, һичшиксез, хәерхаһлы булачак дип уйлады Равил. Хәзер аңарда Лаураның ерак әбисе Миреладан бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән тылсымлы тәңкәсе бар!

Бу минутларда Равил бәхетле, аңа Лаурадан башка беркем, бернәрсә кирәк түгел иде. Равил өчен дөнья үзгәрде. Серле тәңкәдәме хикмәт? Дөньяда якты төсләр артты, элек балкымаган төсмерләр чагыла башлады, хәзер инде моңарчы таныш булмаган авазлар ишетелә кебек. Әллә үзе сихерле микән бу кыз? Аның нindидер магниты бар, ул үзенә тарта, ул гади кыз түгел.

Метеор һаман күренмәде, Равил исә моңа һич кенә дә борчылмады.

– Рауль, миңа кайтырга кирәк, – диде Лаура. – Туганнарым борчылып көтәләрдер. Кул болгап кала алмыйм инде сиңа, ачуланма.

– Лаура, менә шулай могҗизалы рәвештә очрашканбыз икән, нишләп аерылырга тиеш соң без?! – диде Равил, ни әйтергә белмәгәч.

– Нишлисең бит инде. Без хәзер ничек бергә калыйк, моны ничек күз алдыңа китерәсең?

Аның бу сүзенә Равил җавап таба алмады. Лаура, пристаньнан ерагаеп, борылышка җиткәч, туктап, Равилгә кул болгады һәм... күздән югалды.

Көткән метеор һаман килмәде. Хәер, Равил аны көтмәде дә инде, аның бөтен уйлары Лаура турында иде. Бергә кунган төн татлы төш кебек, бүген кыска гына вакытка очрашып алу да өндә булган сыман түгел иде.

Инде караңгы төште, ә метеор күренмәде, шулай итеп, Равилгә пристаньда кунарга туры килде. Пассажирлар залының кыршылган утыргычына сузылып яткач, татлы уйлар елгасы аны әллә кайларга алып китте.

Икенче көнне иртәнге алтыда гына кайтып китте ул.

Метеор елга агымына каршы кузгалганда, пристань янындагы ярдан гүзәл җан иясе, җанҗылымлы чегән кызы кул болгап калды, әмма бу күренеш өндә түгел, Равилнең хыялында гына иде.

Хуш, Лаура! Хуш!

Әмма без, һичшиксез, тагын очрашырга тиеш. Мин Казанда булачакмын, укырга керә алмасам да, шунда калачакмын. Ничек кенә булмасын, без котылгысыз бер-беребезне табарга тиеш, башкача мөмкин түгел!

Серле тәңкә үзенең могҗизалар тудыру сәләтенә ия икәнен күрсәтә башлады, алга таба да ярдәм итәргә тиеш ул, дип уйлады Равил.

Ул инде хәзер Лаура бүләк иткән тәңкәнең тылсымына тәгаен ышана иде.

## 7

Казан ханы Габдел-Латыйф сеңлесе Гәүһәршадны бик сагынган иде. Аларның бала чагы Кырымда бергә узды. Аны күбрәк калга-солтан Мөхәммәт карамагында тоттылар, ә калга-солтанның холкы бик үзенчәлекле иде. Габдел-Латыйф бик күп гадәтләрен Мөхәммәттән алган, тиз кызып китүчәнлеге дә, үзен тотышы да аныкына тартым иде.

Гәүһәршад Казанга килгәндә, Габдел-Латыйф ярты ел хан булып торган иде инде. Сеңлесен зарыгып көтте ул, ә инде күрешкәч, өч көн буена күптән көтелгән очрашу вакыйгасын аш-сулы мәҗлесләр белән, күңел ачып, тантана итте, кыскасы, сеңлесе янәшә булуга ул чиксез бәхетле иде.

Гәүһәршадка Казандагы һава торышы Кырымныкына караганда кырысрак тоелды, әмма, ни гаҗәп, монда сулавы җиңелрәк шикелле иде. Аңа казанлылар Кырым халкына караганда матуррак күренде. Аның күңеле иркенлек тойды – монда тегеләй эшләмә, болай ит дип тукып торучы әнкәсе Нурсолтан юк, гел төрттереп, чәнчүле сүзләр белән сөйләшүче калга-солтан Мөхәммәт юк, очрашканда, миңа ничек карар икән дип, куркырлык Кырым ханы – үги әтисе Мәңгли-Гәрәй юк. Монда аны ихластан яратучы абыйсы бар, ихтирам белән, ихластан сокланып караучы морзалар, бикәләр бар, ниһаять, аның үзе белән Кырымнан килгән – башкалар күрми торган нәрсәләрне абайлый торган – тирән акыллы Миреласы янәшә. Монда Гәүһәршадны үзе өчен ясыйсы бик күп ачышлар көтә, Казан ханлыгында тормыш башкача, яшәү рәвеше икенче, бу – башка дөнья иде.

Казанда соңгы вакытта гел нindидер көтелмәгән хәлләр килеп чыга, бер-бер артлы кискен вакыйгалар гөрләп тора, даны әллә кайларга таралган Казан-кала чын мәгънәсендә кайный. Мәскәүлеләргә яки ногайларга бәйле бaгланышлар тудырган астыртын вә мәкерле эшләр, төрле нәселләрнең үзара низаглары, әле моннан, әле тегеннән янаган дошманнарның кинәт килеп чыгуы – болар барысы да илне гел киеренкелектә тота, монда беркем дә эленке-салынкы яшәми, һәрчак киләсе көн сынауларына әзер тора иде. Бу болгавыр заманда кичәге дус кинәт дошманга әйләнә, бүгенге дошман, көтмәгәндә, иртәгә дустың булып куя. Дөрес, дөньяда һәркем үзенә файда китергәнне генә эшли, алдан күбрәк үзен кайгырта – бу исә Кырымда да, башка илләрдә дә шулай. Гәүһәршадның шушы кискен, тетрәндергеч вакыйгаларның эчендә кайныйсы килә. Аның абыйсы – хан, ул үзе дә Ибраһим хан кызы, үги әтисе дә – дан тотучы Кырым ханы. Ил-көн ыгы-зыгысын читтән күзәтеп торасы килми, ханның сеңлесе булу гына аны канәгатьләндерми, ил-көн тормышында гөрләтеп яшисе, яшьнәп катнашасы килә аның. Кырым ханбикәсе Нурсолтанның кызы дәүләт эшләренә тәэсир итәргә хаклы – Гәүһәршад шулай уйлады.

Сәер нәрсә беренче көннәрдән үк күзгә ташланды – Казанда кешеләр сөйләшкәндә, сүзләрен саклык белән генә әйтәләр, бер-берсеннән шикләнәләр, бер-берсенә бигүк ышанып җитмиләр шикелле тоелды. Казандагы бу күренешнең сәбәпләрен, яшь булуына карамастан, ул яхшы аңлый, ә инде нечкәлекләренә, тора-бара, бәлки, Мирела төшендерер. Чегән кызы башкалар күрмәгәнне күрә, алда ни буласын әйтә ала, кешенең уйларын укый, чит кешенең күңелендә ниләр барын чамалау сәләтенә ия.

Әле күптән түгел генә Кырымда иде бит ул. Казанга илткән юл, ни гаҗәп, авыр булмады.

Юлга кузгаласы көнне Гәүһәршад түземсезлек белән көткән иде. Мәңгли-Гәрәй төзегән Салачык соңгы вакытта Кырымның башкаласына әйләнде, мондагы Ашлама-сарай кебек зиннәтле корылма тагын кайда бар икән? Аның тирәсендә урнашкан мәчетләр, мәдрәсәләр, мунчалар, аксөякләрнең купшы-зиннәтле йортлары, һөнәрчеләрнең, сәүдәгәрләрнең

тораклары тиз арада барлыкка килде. Яшәү гөрли, әмма бөтен нәрсә таныш, кешеләре билгеле, шуңадыр ахры, барыбер ямансу иде. Күңел башка тарафларга омтылды, күңел яңалык эстәде, башка төрле киләчәкне таләп итте. Кырым ханы төзегән сарайларда Гәүһәршад үзенә ямь таба алмады, һәр адымын күзәтеп торучы әнкәсе Нурсолтан, бер кыек сүз әйтмәсә дә, кырын карый торган үги әтисе Мәнгли-Гәрәй, аның улы Мөхәммәтнең төрттереп сөйләшүләре һәм үзен генә Кырым ханының яраткан улы дип санавы – барысы да туйдырды, җанны биздерде. Озакламый китәчәк ул моннан, күңелнең яңа кичерешләргә ихтыяҗы бар. Уналты яшь бит инде аңа, тормыш гел кайнап тора, ә ул һаман әнкәсе Нурсолтан бигем куенында. Ана канаты астында җылы, әмма Гәүһәршадның чиксез күк гөмбәзе астындагы дөньяда яшисе килә иде.

Казанга китәргә берничә көн кала Гәүһәршад үзе яраткан урыннарга чыгып керергә булды.

Хан сараеннан ерак түгел урнашкан һөнәрчеләр бистәсе базарны хәтерләтә, көн саен ыгы-зыгы, көлке, шау-шу, ызгыш-талаш. Мондагы үзара сату-алу – үзе аерым бер тормыш булып кайный, ни генә һәм кем генә юк монда! Әмма Гәүһәршадка бу базардан берни кирәкми, чөнки Казанга алып барасы бүләкләр, күчтәнәчләр күптән әзерләнгән, алар арбаларга төяп куелган иде инде. Өсте күн белән ябылган көймә арбасыннан чыгып, ул тирә-яктагы күренешләр хозурында басып торды. Бала чакта бу тирәдә йөрергә ярата иде ул, ә аны өлкәннәр ачуланалар иде – хан кызына мондый җирләрдә күренү ярамый, килешми, имеш. Балачак артта калды, тиздән ул инде тәгаен үз иркендә булачак.

Кинәт тимерче алачыклары янындагы мәйданчыкта хәвефле хәрәкәт башланды, кычкырган тавышлар яңгырады. Кораллы кешеләр бер яшь хатынны кулларын каерып тотканнар, чәчләре тузган хатын, аякларын терәп, читлек урнаштырылган арбага алып баруларына каршы торырга маташа иде.

Гәүһәршад үз сакчыларының унбашына нәрсә булганын белеп килергә кушты. Унбашы тиз генә матавык купкан урынга барып килде һәм багучы чегән хатынын тотканнарын хәбәр итте. Кырымда фал ачу, багу, күрәзә итү кебек шөгыльләр җинаять санала, ханның хәтта махсус ярлыгы бар иде – ил буенча шуның ише барлык сихерчеләрне тотып хөкем итәргә!

Гәүһәршад Кырымда багучы, фал ачучы чегәннәр бар икәнен белә, аларның бу кәсебе белән ул үзе дә бик кызыксына иде. Күпме теләп, моңарчы аңа бер күрәзәчене дә очратырга туры килмәгән иде һәм менә, ниһаять, мөмкинлек туды.

Чегәннәр – сәләтле халык – оста куллы һөнәрчеләре, тимерчеләре, ат караучылары белән алар бу тирәдә дан тота, аючылар төркеме исә төрле тамашалары белән һәркемне таң калдыра, җыр-биюдә, уен коралларында уйнауда аларга тиңнәр юк иде. Дөрес, араларында караклар да күп, әмма башка халыкларда да алар җитәрлек түгелмени? Чегән хатыннарының иң серле кәсепләре – күрәзә итү, багу, фал ачу һәм моның өчен Кырымда аларны хәтта үлем җәзасына да хөкем итүләре ихтимал иде.

Унбашыннан нәрсә булганын белгәч, Гәүһәршад үзе барып, чегән хатынын азат итәргә боерды. Үткен күзле, киң күкрәкле яшь чегән хатыны

Гәүһәршадка нык тәэсир итте, багучы хатынның күз карашы кадала торган булса да, ул үзенә тартып тора, аның белән сөйләшсәң, бик күп нәрсәне белерсең, күп нәрсәгә күзең ачылыр шикелле иде.

– Сине ни өчен кулга алдылар? – дип сорады Гәүһәршад.

– Нахакка! Мин сихерче түгел! – дип еламсырады чегән хатыны. – Минем абыем – тимерче, монда ул алачык тота. Мин шуның янына килгән идем.

Гәүһәршад кул ишарәсе белән сакчыларга читкәрәк китәргә кушты.

– Хан фәрманы буенча, барлык им-томчыларны, багучыларны, күрәзәчеләрне тота башладылар. – Гәүһәршад як-ягына карап куйды. – Син миннән курыкма, миңа дөресен әйтсәң дә була. Син мине беләсеңме?

– Беләм. Син Нурсолтан ханбикәнең кызы.

– Әйе, дөрес. Исемең ничек?

– Мирела.

– Мин фал ачучы белән күптән танышырга йөрим. Сине коткарганым өчен миңа ярдәм ит. Ерак юлга чыгар алдыннан күрәзәче белән сөйләшәсем килгән иде.

Мирела, ышаныргамы-юкмы дип, беравык туп-туры карап торды:

– Сезнең дин буенча күрәзәлек итәргә ярамый, – диде ул, сагаеп.

Гәүһәршад көлемсерәп куйды:

– Мин башта күрәзәче белән сөйләшермен, аннары Ходайдан нәрсә сорарга икәнне үзем белермен, – диде ул, кинәт усалланып. – Курыкма, миңа күрәзә ит, шуннан соң мин сине җибәрәчәкмен, богаулап, зинданга ташламаслар.

Мирела текәлеп карады:

– Мин күрәм, сез алдамыйсыз... – диде ул.

– Син бит – багучы, тикмәгә эләктермәделәр сине, артыңнан күзәтеп йөргәннәрдер. Мин Казанга китәргә җыенам. Юлым уңачакмы минем?

Мирела читтәрәк торган сакчыларга карагач, Гәүһәршад аңа:

– Син болардан курыкма, алар миңа тугры кешеләр, – диде.

– Кулыңны бир, – диде Мирела. – Уч төбеңне күрсәт.

Гәүһәршад кулын сузды, Мирела озак итеп ханикәнең учын карады.

– Хәвеф-хәтәрсез барып җитәчәксең, – диде Мирела.

– Мине Казан җылы каршы алачакмы?

Мирела ханикәнең йөзе буйлап күз йөгертте, беравык, башын читкә борып, аңа карамый торды, аннары янә Гәүһәршадның йөзенә текәлде.

– Сине җылы каршы алучылар булыр, әмма дошманнарың да күп булачак анда, – диде чегән хатыны.

– Алар минем монда да җитәрлек, – дип кул селтәде Гәүһәршад. – Миңа Казанда кем булырга язган икән, әйтә аласыңмы?

Мирелaның йөзе кинәт тартылып китте, күзләрендә курку сыман нәрсә чагылды:

– Син Казанда күпмедер вакыт хакимлек итәчәксең... – диде ул. – Падишаһ исеменнән ил йөгәнен тотачаксың. Кайчан икәнен әйтә алмыйм. Анда хакимнәр бик еш алышынып торачак, ул илне өч тарафтан төрле көчләр үзенә тартырга тырышачак.

– Мине киләчәктә нинди кеше белән никах көтә?

– Синең никахың хакында әйтергә базмыйм, – диде Мирела, сагаеп. – Сине никах бәхетле итмәячәк дип кенә төгәл әйтә алам.

– Ничә балам була? – дип кызыксынды Гәүһәршад.

Мирела дәшмәде.

– Ник җавап бирмисең? – диде Гәүһәршад taләпчән тавыш белән.

Мирела, башын читкә борып:

– Ачуыңны китерүдән куркам, – диде.

– Курыкма, ничек күрәсең, шулай әйт.

– Балаларың булмаячак синең, – диде Мирела коры тавыш белән.

– Күрәзәче ялгыша да ала бит, – диде Гәүһәршад, кырысланып.

– Алайса ник сорыйсың? – дип, Мирела аңа туп-туры карады.

Мирeланың үткен күзләре тишеп керердәй булып карыйлар, бу күзләрдән бернәрсәне яшерү мөмкин түгел сыман иде. «Үтәли күрә, ахрысы, бу мине, дип уйлап куйды Гәүһәршад, хәтта хыял-ниятләремне дә чамалый бугай».

Гәүһәршадның сакчыларыннан берсе аваз салды:

– Ханикә, ул бик матур җырлый, ишеткәнем бар.

– Кайда ишеткәнең бар? – дип борылды аңа Мирела.

– Акмәчет базарында. Син идең бит ул?

– Әйе, мин идем, – диде Мирела горурлык белән.

– Бик шәп бии дә әле ул, – дип өстәп куйды сакчы.

Гәүһәршад күрәзәчене җентекләп күзәтте һәм бу хатынны юындырып, матур итеп киендерсәң, шундый затлы кыяфәттә булачак, дип уйлады.

– Әйдә минем белән Казанга, – диде Гәүһәршад. – Гел янымда булырсың, рәхәт яшәрсең. Күңелем сизә, син миңа бик кирәкле кеше.

– Минем ирем, балаларым бар, туганнарым, нәселем монда, – диде Мирела моңсу тавыш белән.

– Сине барыбер монда эләктерүләре ихтимал, мин монда булмагач, сине кем коткарыр? Сиңа барыбер, кичектермичә, һич югы күпмедер вакытка Кырымнан китеп тору мәслихәт, вакыт узгач, кире кайтырсың. Ә бит сине монда тотып хөкем итсәләр, ireңә дә, балаларыңа да, туганнарыңа да көн күрсәтмәячәкләр. Әйдә минем белән Казанга.

Мирела үзе дә аңлый – монда калу аңа хәзер куркыныч. Гәүһәршад асылда аны инде үлемнән коткарды, мондый затлы ханикә белән ерак сәфәргә чыгарга була, иренә, туганнарына бу адымын аңлата алачак ул.

Мирела муенына кызыл җеп белән таккан калайчыгын уч төбенә салып пышылдады.

– Нәрсә ул синең? – дип кызыксынды Гәүһәршад.

– Безнең нәселне саклый торган тәңкә, мин аның белән киңәшләштем.

– Сиңа ничек җавап бирә соң ул? – диде Гәүһәршад, гаҗәпләнеп.

– Ул миңа җавап бирми. Мин аннан сорыйм гына, аннары нишләргә икәнне үзем хәл итәм. Аның белән киңәшләшкәч, мин ялгышмыйм, дөрес адым ясыйм.

– Барасыңмы минем белән Казанга? – диде Гәүһәршад.

– Барам, – дип җавап бирде Мирела.

Гәүһәршад унбашына эндәште:

– Ике сакчы аны өенә озатып куйсыннар, юлга әзерләнсен, туганнары белән хушлашсын.

... Нурсолтан уналты яшьлек тиктормас кызын Казанга китмәскә үгетләп карады, әмма Гәүһәршад, үҗәтләнеп, үз киресен сукалады:

– Минем Казанга барасым килә! Абыем да мине зарыгып көтә, мин аны бик нык сагындым.

Нурсолтан кызына ачулы кыяфәттә карап торды.

– Сиңа ирек, хөрлек кирәк, – диде ул. – Әмма ирекле булып кына, кыз бала нишли ала? Хатын-кызның бәхете барыбер ирдән аның. Кемгә чыгарсың бит әле...

Нурсолтан Гәүһәршадны олы юлга зарлана-зарлана әзерләде, юлдашларның, сакчыларның көчлеләрен, чыдамнарын вә ышанычлыларын җыйды. Кызын ерак юлга озату хафаландыра, әмма бу көннәрдә Нурсолтанны куандырган вакыйгалар да булды – Мәңгли хан белән улы Мөхәммәт яудан табышлы җиңү белән кайттылар, шунысы җанны бераз тынычландырып торды.

Ханбикәгә Мирела хакында инде әләкләргә өлгерделәр. Әлбәттә, чинген хатыны турында хәбәрне Гәүһәршад өчен борчылып җиткерделәр аңа.

– Ник аласың син аны үзең белән? – диде Нурсолтан, күрәзәче турында төпченгәннән соң.

– Ул шундый матур җырлый, – диде Гәүһәршад, әнкәсе Миреланы хөкемгә тапшырырга боерык бирмәсә ярар иде дип борчылып.

– Аны күрәзәче диделәр, ул хатынны зинданга ташларга кирәк, ә син аны коткаргансың. Моны хан ишетсә, беләсеңме, нәрсә була...

Гәүһәршад, әнкәсенә кырыс караш ташлап:

– Тиздән Кырымдагы зинданнарда тоткыннар өчен урын калмаячак инде, – диде. – Ул күрәзәче түгел, аны башка кеше белән бутаганнар.

1499 елның җәй баш иде.

## 8

Казанга килгән көннәрдә Гәүһәршад үзен яшәештән чак кына өстәрәк, аяклары җиргә тияр-тимәс йөргән кебек хис итте. Хан, сеңлесе килгән уңайдан, өч көн бәйрәм ясады, әмма Гәүһәршадның кәефен кырган нәрсә шул булды – Габдел-Латыйф беренче көннән үк никах турында сүз башлады. Фәлән кешегә бирсәк, аның абруе ногайларда көчле, яисә тегенең улына бирсәк, Мәскәү кенәзе янында аның кешеләре бар, Казанда егетләр җитәрлек дип, фәлән карачының улы менә дигән егет, ул бик акыллы, көчле кеше, аның абруе Казанда бик зур, дигән иксез-чиксез тәкъдимнәр белән тәмам җелегенә үтте.

Нотык укыганнарын, һәрдаим киңәш биреп торуларын Гәүһәршад беркайчан кабул итә алмады. Менә абыйсы да, урнашып бетмәс борын ачуны китереп яшәргә өйрәтә башлады. Гәүһәршад, әле уналты яшьлек кыз гына булуына карамастан, барысын да үзем аңлыйм дип уйлый иде. Аның дөньяга, кешеләргә үз карашы бар, миннән дә күбрәк белә микәнни киңәш бирүчеләр дип аптырады ул. Аңламаган нәрсәләргә төшендерергә аның бит якын дусты, иптәше – гайре табигый сәләт иясе – Мирела бар.

Гәүһәршад белән Кырымнан килгән чибәр, җанҗылылы, шул ук вакытта, бераз сәеррәк яшь хатын үзенә игътибарны әллә каян җәлеп итеп торды. Үзенең хезмәтчесе дип тәкъдир ителеп, гел янәшәсендә йөргән Миреланың асылда кем икәнен белмәсеннәр өчен, Гәүһәршад барысын да эшләде. Гәүһәршад Казан хакимиятенең зур вазифадагы кешеләрен Мирелага

күрсәтеп, аннары аулакта алар турында аның фикерләрен тыңлады. Мирела кешене күреп, аның сөйләшүен тыңлап, хәрәкәтләрен күзәтеп, аның нинди шәхес икәнен, тәрҗемәи хәлен һәм алга таба нинди гамәлләр кыла алачагын әйтеп бирә иде.

Кырымнан Гәүһәршад белән килгән бу серле хатын турында тиз арада төрле имеш-мимешләр йөри башлады. Үзе чибәр, әмма күз карашы куркыныч, диделәр аның турында. Күпме яшерергә тырышмасын, әмма аның багу осталыгы бар икәнне, гайре табигый сәләткә ия булуын сизенделәр.

Гәүһәршад Мireланы җырлавы, биюе аркасында гына үз янында тотуын тәкрарласа да, абыйсы Габдел-Латыйф хан моңа ышанмады. Хан Мireланың җырлавын ишетте, әмма бигүк сокланмады, мөкиббән китмәде.

– Әйе, матур җырлый, – диде хан. – Әмма аның кебек җырлаучылар, хәтта аннан яхшырак җырлаучылар үзебездә дә җитәрлек.

– Үз халкының җырларын да җырлый бит ул. Ә андый җырларны монда кем җырлый ала? – дип акланды сеңлесе.

Гәүһәршад Мireланы яшәргә Кабан күле буена урнашкан зур йортка урнаштырды. Бу утар ханнар нәселе өчен махсус төзелгән йорт иде. Көяз йортта, сый-хөрмәттә яшәсә дә, Мирела барыбер монда үзен тоткындай хис итте. Аңа барысы да берьюлы күктән өелеп төште: мул тормыш, хезмәтчеләр, сакчылар (әйтерсең лә ул ханнар нәселеннән), әмма отыры мондый тормышны күңеле ятсына башлады. Кырыкка җитеп килсә дә, Мирела ир-егетләрнең һушын алырлык хатын иде, Гәүһәршад бүләк иткән киемнәрне кигәч, ул бөтенләй затлыланды. Әмма үзенә тартылучы ирләрне ул тиз өркетә, аның күз карашы гына да күпләрне хәлсезләндерә иде. Тиздән кырык тула моңа дип, һич кенә дә уйламассың – шома битле, озын керфекле, зур чем-кара күзле, туры-төз борынлы, кып-кызыл иренле килмешәк хатынга күпләр гашыйк булды. Куе бөдрә чәчен яулыксыз күрсәләр, мөгаен, бөтенләй һушсыз калырлар иде. Буй-сыны төз, атлап йөрешендә үк нindiдер сихри бөркелеш бар, озын нәзек бармаклары белән яулыгын төзәткәндә дә, аның хәрәкәтләре мәҗүси-күркәм иде.

Гәүһәршад аны татарча киенергә күндерде, үзе белән төрле мәҗлесләргә йөртте, кирәк чакта җырлатты, биетте, әмма Мireланың бу тарафта чит-ят зат икәне барыбер әллә каян «кычкырып» тора иде. Мирела аркасында чегән халкы турында Казанда белә башладылар. Гәүһәршадның аны мәҗлесләргә, киңәшмәләргә, очрашуларга йөртүенең төп сәбәбе – теге яки бу кешене күрсәтеп, соңыннан аның турында нинди кеше икәнен, алга таба нишләргә уйлаганын белү иде.

Тора-бара Мireладан шикләнә башладылар. Кем ул? Нишләп Гәүһәршад бу хатынны балда-майда йөздерә? Гәүһәршадның Мирела янына төнлә килеп йөрүе дә күпләрне пошаманга калдырды.

Беркөнне хезмәтче кыз Мireланың йокы бүлмәсендәге тартмаларда яткан серле ташларга игътибар итте – төрле төсләрдә, төрле бизәкләр белән иде алар... Чигүле җәймәнең төсе уңган, таушалып искергән, әмма Мирела аны бик кадерләп саклый... Хезмәтче кызны шул әйберләргә кагылганы өчен ачулана, чак кына сукмый кала... Хезмәтче кыз әллә ничә тапкыр Мireланың, ташларны шул җәймәгә салып, яртышар төн кымшанмыйча

утырганын да күрде. Кызны бигрәк тә ташлар янында яткан тәңкә аптырашта калдырды – тәңкәнең ике ягында да төрле тамгалар, сурәтләр һәм... тәресе бар. Иблис токымыннан микән әллә бу хатын дип, хезмәтче кыз хан сараенда эшләүче апасына әйтте.

Күп тә үтмәде, Гәүһәршадтан төпченергә үк тотындылар: «Кем ул? Нинди сәер әйберләр аңарда? Ник аны гел үзең белән йөртәсең?»

Гәүһәршад хафалана башлады – Мирелaның нәрсә белән шөгыльләнүен сизенделәр, ахрысы. Гәүһәршадка ул бик кадерле кеше, аны сакларга, якларга, беркемнән тел-теш, җил-яңгыр тидермәскә кирәк!

Мирела кемнең кем икәнен күрә белә, Гәүһәршадтан кемнәр шикләнгәнне, кемнәр аның хакында гайбәт сөйләгәнне дә әйтә. Кешенең хәрәкәтләреннән, күз карашыннан, атлап йөрүеннән, сөйләшкәндә, үзен ничек тотуыннан нинди кеше икәнен аңлый. Төрле төстәге йомры, шакмаклы, җәйпәк, озынча, колаша ташларын иске җәймәсенә салып, Казан ханлыгында тиздән ниләр буласын күрә. Гәүһәршад үзе дә кыска вакыт эчендә Миреладан кешеләрне аңлау, күрәзә итү, фал ачу дәресләрен алды.

Соңгы вакытта Габдел-Латыйфның шымчылары Миреланы җентекләп күзәтергә тотынганнар иде. Әмма шул вакытта башланган вакыйгалар – Казандагы үзара низаглар, ногайларның һөҗүм итүе, Мәскәү белән тарткалашу – Кырымнан килгән чегән хатыны турында берникадәр оныттырды.

Гәүһәршад үзен бәйсез тотты, абыйсына буйсынмады, карачылар, абруйлы морзалар белән телгә килеп яшәде. Абыйсы торымнан-торымга никах турында сүз ката торды, ир-егетләрне тәкъдим итте, ә Гәүһәршад барысыннан да йөз чөерде һәм абыйсына: «Син мине көчләп, иргә бирмәкче буласыңмы, юк, алай барып чыкмас!» – дип каршы килде. Габдел-Латыйф, сеңлесе нинди уйлар белән йөри икән, алга таба ничек яшәргә тели, нишләп аның холкы мондый дип, пошаманга калды. Ник килгән ул алайса Казанга? Дөрес, сеңлесен үзе дә сагынды, шат ул аның монда булуына, әмма үзен болай дорфа тотар дип уйламаган иде бит ул.

«Кырымнан үзе белән алып килгән Мирела атлы хатын бик шикле кеше. Сихер белән шөгыльләнүчегә охшаган...» Бу хакта инде аңа бик күп кеше әйтте. Тәре төшерелгән тәңкәләр, аңлашылмый торган тамгалар, ташлар... Кем ул? Нишләп монда ул? Ник Гәүһәршад аны монда үзе белән алып килгән? Бу уйлар ханны көннән-көн ныграк борчый башлады.

Ә Гәүһәршад Миреланы Казанга алып килгәненә сөенеп туймады. Мирела фаразлаган нәрсәләр барысы да чынга аша бара.

– Ханикә, син мине нык якын итәсең. Чөнки син үзең дә күрәзәлек сәләтенә ия, – диде аңа Мирела беркөнне.

– Минем Казанның киләчәген беләсем килә. Әмма алда ил-көн белән ни буласын күз алдыма китерә алмыйм, – дип уйга калды Гәүһәршад.

– Казан дусны дошманга әйләндерә торган урын, ә дошман монда дус була алмый, – диде Мирела. – Габдел-Латыйф белән синең мөнәсәбәтләр бозылачак, чөнки аңа буйсынырга теләмәячәксең. Син беркемгә буйсынырга теләмисең, сиңа ирек кирәк. Иргә чыгу сине һич кызыксындырмый, никахка синең үзегең каршы, шәригать кануннары буенча да яши алмаячаксың, ирекле тормыш, бәйсезлек тели күңелең, шуның белән бергә, астыртын,

мәкерле эшләр, матавыклар, көрәш сине канатландыра, илһамландыра, әле син фетнәләр оештырудан да чирканмаячаксың. Сиңа мәхәббәт кирәкми, син яратуларын түгел, алдыңда баш иеп, буйсынуларын телисең. Уйлап кара да үзең өчен үзең хәл ит – кешенең сине яратуы кыйммәтме, әллә сиңа буйсынуымы? Кайсысы күбрәк ләззәт бирә икән? Син – кире, үзсүзле. Син атаңа – мәрхүм Ибраһим ханга охшагансың.

– Мин гомер буе бәхетсез булырмын шикелле, – дип сыкрап куйды Гәүһәршад.

– Күрсәт миңа бәхетле кешене, – диде Мирела, көлемсерәп. – Бәхетсезлек чокыры тагы да тирәнәймәсен дип кенә телисе кала. Күңелең ничек тели, мөмкин булган кадәр шулай яшә.

Туганнарың белән аралар өзелер дип, үзеңне битәрләмә, син барыбер аларны яратмыйсың. Үзеңә каршы барма, үз асылыңа каршы барсаң, менә шул чагында беркайчан бәхетле булмаячаксың.

– Җан тыныч түгел, Мирела...

– Тере кешенең җаны тынгысыз булырга тиеш. Бу заманда җаның тыныч булса, димәк, син исән кеше түгел. Кызык кеше син, Гәүһәршад – үзең тыныч тормыштан качып, кискен вакыйгалар кайнаган җиргә, болгавыр тарафка омтылдың, үзең җан тыныч түгел, дип зарланасың...

– Зарлану түгел лә ул. Минем өлкән абыем Мөхәммәт-Әмин Казан тәхетенә утырырга тели. Аны руслар да яклаячак. Аның хатыны Фатыйма – ногай бикләрбәге Мусаның кызы. Мөхәммәт-Әмин аңа дала кешеләрен котыртырга куша, ә Габдел-Латыйф исә, ногайлар белән татулашып, Мәскәүгә каршы торырга өнди. Буталып бетте барысы да. Алар бит икесе дә – минем абыйларым...

– Син япь-яшь килеш ил-көн өчен кайгырып утырасың. Дөресен әйткәндә, илдә түгел синең хәбәрең, син барысыннан да өстен булырга телисең. Ничек инде җаның тыныч булсын?! Түз, сабыр ит, синең вакыт әле җитмәгән.

– Нинди вакыт? – дип ыңгырашты Гәүһәршад.

– Синең вакыт. Еллар узар, син әле бу ил белән хакимлек итәчәксең.

– Син моны Кырымда чакта әйткән идең инде, – диде Гәүһәршад, җанланып. – Кайчан җитәчәк ул вакыт?

– Тагын утыз елдан.

– Ул вакытта инде мин карт булырмын, – дип көлемсерәде Гәүһәршад.

– Син хәзер шулай уйлыйсың, – диде Мирела.

– Мин кем буларак идарә итәчәкмен Казан белән? Хан тәхетенә ир кеше генә утыра ала бит...

– Хан башка кеше булачак, әмма дәүләт белән син идарә итәчәксең. Озак түгел. Хәер, Казан ханлыгының да гомере озын булмаячак.

Гәүһәршад эчке сискәнү тойды:

– Мин хакимә булганда бетәчәкме Казан? – дип пышылдады ул.

– Юк, Казан син тәхеттән төшкәннән соң егерме ел узгач җиңеләчәк. Тынгысыз урын. Казан хәзер дә үзенә буйсынмый, җире, урыны шундый, бу урын – гел кемгәдер, бигрәк тә читтәгеләргә, буйсына торган җир. Хәзерге вакытта үзенең чиксез матавыкларына буйсына ул, тәкъдиренә шулай язылган.

– Аннан соң миңа нәрсәләр күрергә язган? – дип сорады Гәүһәршад шомлы тавыш белән.

– Анысын әлегә белмим.

– Казанны кем җиңәчәк? Ногайлармы?

– Ногайлар түгел.

– Габдел-Латыйф озак булачакмы тәхеттә?

– Тагын бер-ике ел гына калды.

Мирела куркыныч фаразлар әйтә, әмма аның алдан күреп сөйләгәннәре, күп тә үтми, чынга аша бара. Шуңа күрә, аны тыңлау гаять кызык та, шул ук вакытта бик куркыныч та.

Бу көннәрдә Мирeланың күзләрендә сагыш тирәнәйде – Кырымда калган ирен, балаларын, туганнарын сагына иде ул. Гәүһәршад аны кызганып куйды – соңгы вакытта күрәзәче хатынның тәм-томга да бик исе китми, затлы киемнәргә дә куанмый. Гәрчә затлы нәсел кешесе кебек яшәсә дә, күренеп тора, канәгать түгел, ә бит беренче көннәрдә яңа илдә аңа барысы да кызык иде, шат, көләч иде ул.

– Мирела, сиңа ир кирәк, – диде аңа Гәүһәршад сынаулы караш белән. – Әмма мин куркам, ир хатыны булгач, син миннән ерагаерсың шикелле. Мин синнән бик күп нәрсәгә өйрәндем, күп нәрсәгә күзләремне ачтың, мин кешеләрне аңлый башладым, башкалар күрмәгәнне абайларга өйрәндем, синең белән мин бөтенләй башкача уйлый башладым.

– Ханикә, мин бит әле иргә чыгам, димәдем. Минем ризалыгымнан башка никах укытырга җыенмыйсыңдыр бит? – диде Мирела, мыскыллы елмаеп.

– Юк, мин сине иргә ничек көчләп бирим? – Гәүһәршад уйга калды. – Ир бәхете башкадыр инде ул... – дип, авыр сулап куйды ул.

– Синең үзеңә ир бәхете насыйп булмаячак, син бу дөньяга башка эшләр өчен килгәнсең, язмышыңа күн һәм үзеңне битәрләмә, уфтанма, зарланма.

– Теләсәң, мин сиңа бер ир-егет табып бирәм, – дип, әлеге дә баягы сүзгә кайтты Гәүһәршад.

Мирела тыныч кына башын чайкады:

– Юк, ханикә, минем ирем, балаларым бар бит инде.

Гәүһәршад:

– Алар бит Кырымда калды, – дигәч, Мирела кинәт елап җибәрде.

Бу әңгәмәдән соң Мирела төн буе йокламады. Димәк, Гәүһәршад мине бөтенләйгә монда калдырмакчы була, дип уйлады ул. Аның бит әле Кырымга кире кайтырга өмет-хыялы бар иде. Кырымда ул үзенә кәсеп табар, күрәзә итмәячәк, анда хәзер кануннар каты, аның өчен иң мөһиме – ирен кочу, балаларын куенына алу.

Гәүһәршад сизенә башлады – хәзер Мирела Кырымны, анда калган туганнарын көннән-кын ныграк сагына. Берәр көнне ул бит качарга да мөмкин, дип уйлады Гәүһәршад һәм сакчыларны ныгытып кисәтеп куйды – тегендә-монда чыкканда, Мирела белән һәрвакыт янәшә булырга, һәр адымын күзәтергә! Күрәзәченең көнне ничек уздырганын белеп тору өчен дә махсус кыз-кыркын билгеләнде.

Гәүһәршадның башына тагын бер уй килде – Мирeланың серле тәңкәсен алып, үзенең сандыгында сакларга һәм бик кирәк чакта гына Мирелага биреп торырга.

Беркөнне ул Миреладан тәңкәне күрсәтүен сорады.

Гәүһәршад серле тәңкәне кулында әйләндергәләп караганнан соң:

– Бу тәңкә гел синдә генә булырга тиешме? – диде. – Бераз миндә дә торса ярамыйммы?

– Юк! – дип кырт кисте Мирела һәм тәңкәне Гәүһәршадка бирмәде.

Берничә көн узгач, Габдел-Латыйф сеңлесе белән Мирела хакында турыдан-туры сөйләшергә булды.

– Үзең ияртеп килгән чинген хатыны белән син еш аралашасың. Сезне нәрсә берләштерә? – диде хан.

Гәүһәршадның күңеленә шом йөгерде.

– Ул миңа борынгы риваятьләрне сөйли, тарихны бик яхшы белә, әби-бабаларының язмышын кызыклы бәян итә. Тыңлаганда исләрем китә, аның белән аралашу миңа шундый рәхәт.

– Аны сихерче, диләр. Янына барып кайткан саен син үзгәрәсең, үзеңә бикләнәсең.

Гәүһәршад белә: Мирела турында шымчылар ханга хәбәр ташый, морзалар, карачылар арасында инде чегән хатынының монда нишләвен ачыкларга кирәк диючеләр шактый. Абыема дөресен әйтсәм, Мирелага куркыныч янамас дип, Гәүһәршад беркөнне тәвәккәлләде.

– Ярар, мин сиңа дөресен әйтәм хәзер, – диде Гәүһәршад. – Ул күрәзә итә. Монда килгәнебезгә күп вакыт узмады, әмма соңгы вакыйгаларның буласын ул алдан фаразлады.

– Син нindидер сукбайлыктан күптән түгел арынган җен хатынының ихтыярына буйсынасың, шулаймы? Мин, хан, илдә андый кешеләрнең булуына юл куя алмыйм!

Гәүһәршад көтмәгәндә җан ачысы белән:

– Мирелага кагылма! – дип кычкырды.

Гәүһәршад җан тынычлыгын җуйды – Габдел-Латыйф Миреланы юк итәргә мөмкин. Ил-көндә тынычлык юк, тирә-якта дошманнар өере мыж килә, шуңа күрә соңгы вакытта Казанда шикле кешеләрдән тиз арыналар иде.

Күрәзәчене харап иттерергә Гәүһәршадның хакы юк, Мирела шулхәтле якын кеше, аны тизрәк Казаннан җибәрү мәслихәт дигән карарга килде ул. Кырымда аны коткарып, ул дөрес эшләде һәм рәхмәт йөзеннән Мирела монда килде, Гәүһәршадны күп нәрсәгә өйрәтте. «Хәзер Кырымга кайтарып җибәрсәм, без әле кайчан да бер очрашмый калмабыз, ул миңа әле кирәк булачак, – дип уйлады Гәүһәршад. – Гомерләр алда әле, ул аны кабат монда китерү юлын табар, бу хакта Мирелaның үзе белән килешергә кирәк...»

Шул ук көнне кичкырын Гәүһәршад Мирела яши торган Кабан күле буендагы йортка китте.

– Мирела, сиңа кичектермичә моннан китәргә кирәк, – диде ул килеп кергән уңайга. – Мин сине сәүдәгәрләр белән җибәрәм. Моннан өч көн элек Казаннан Кырымга кәрван чыгып киткән иде. Мин хат яздым, аны кәрванбашына күрсәтерсең.

Шуннан соң Гәүһәршад унбашына боерды: Миреланы алып, кәрванны куып җитәргә! Ә инде Мирела качты дигән хәбәр таратуны ул үз өстенә алды.

Шул ук төнне Мирела, атка атланып, кәрванны куа китте, аны ун җайдак озата чыкты, унысы да Гәүһәршадка тугры егетләр иде.

Гәүһәршадның Мирела язмышы өчен борчылуы юкка булмаган – берничә көннән хан Мирелане кулга алырга боерды, әмма бу вакытта күрәзәче инде, кәрванның ябулы арбасына утырып, Кырымга кайтып бара иде. Аны озатып куйган ун яугирне Гәүһәршад бүләкләде һәм серне сакларга кушты.

Миреладагы серле тәңкәне үзендә калдыра алмаганына гына эче пошты аның.

Мирелaның качуында беркемне дә гаепләмәделәр, эзләүне дә туктаттылар, чөнки Казанда тагын тетрәндергеч вакыйгалар кайный башлады.

Ел ярым дәвамында Габдел-Латыйф ханның тормышы киеренкелектә узды – ил-көн өстендә болытлар ныграк куерды һәм тиздән хәвеф-хәтәр булачагы аермачык сизелеп торды.

Ногай даласыннан яу килүдә абыйсы Мөхәммәт-Әминнең дә катнашы бар икәнне хан яхшы белә иде. Ногайлар Казан иленең көньяк тарафындагы авылларны талап, яндырып, үтереп үттеләр. Казанда сугышка әзерләнү, корылмаларны ныгыту, гаскәрне яңарту башланды. Озакламый ногайлар гаскәре Казан каласы янына ук килеп җитте, алар кат-кат һөҗүм ясап карадылар, әмма Казанны алуга ирешмәделәр. Бер ай чамасы вакыт узгач, ногайлар гаскәре, Казан җирен калдырып, далага кайтып китте.

Габдел-Латыйф бикләрбәк Мусага, ногай морзаларына: килешү төзик, бергәләп Мәскәүгә каршы торыйк, дип хатлар язды. Казанның үзендә бу сәясәт белән килешмәүче көчләр җитәрлек, Шириннәр һәм Олы карачы Коләхмәт җитәкчелегендәге төркем бу очракта үзләренең абруен илдә югалтачаклар иде.

Ханга каршы көчләр тик тормады. Коләхмәт, Иван Өченчегә берничә хат язганнан соң, үзе Мәскәүгә сәфәр кылды. Мәскәүдә ул, рус кенәзе белән сөйләшеп, Габдел-Латыйфны тәхеттән бәреп төшерергә күндерә алды һәм Казанга Иван Өченчедән мәкерле хат алып кайтты, әлеге хатта Габдел-Латыйфны ханлыктан алып ташларга дигән боерык бар иде.

1502 елның февраль башында Ширин казаклары белән рус ратниклары Габдел-Латыйфны тәхеттән төшерүгә ирештеләр.

Казанның яңа ханы Мөхәммәт-Әмин, сеңлесе Гәүһәршад белән очрашкач, башта аны танымый торды. Алар беренче көннәрдән үк уртак тел таптылар. Мөхәммәт-Әмин, олы карачы ярдәме белән тәхеткә менсә дә, абый белән сеңел өчен Коләхмәт барыбер дошман иде – олы карачы кайчандыр Мөхәммәт-Әминне сөргенгә җибәргән, хәзер исә Габдел-Латыйфны Мәскәү тарафларына тоткынлыкка озаткан кеше, аны гафу итәрлек түгел иде һәм абый белән сеңел тиздән аны юк итү җаен таптылар.

Өлкән абыйсы хан булгач, Гәүһәршад үзен тагын да иркенрәк тота башлады, әмма Казанның хәле авыр иде инде – ил өстендә болытлар елдан-ел ныграк куера торды.

Бу вакыйгаларның күбесен Мирела, фал ачып, алдан әйткән иде. Еллар узгач, нәкъ ул фаразлаганча, Гәүһәршад Казан иле белән хакимлек итүгә иреште. Мөхәммәт-Әмин вафатыннан соң, монда Шах-Гали хан булып торды, аннан соң кырымлы Сәхиб-Гәрәй тәхеткә менде, аны шулай ук

кырымлы Сафа Гәрәй алмаштырды. Ниһаять, 1531 елда Мәскәү кенәзе Василий Өченче үсмер яшендәге Җан-Алине Казан тәхетенә менгергәч, Гәүһәршад аның янәшәсендә булып, ханлык белән идарә итүче падишаһка әйләнде. Акыллы, хәйләкәр хатын, тиз арада Алтын Урда тарафыннан чыккан дүрт нәсел вәкилләрен үз ягына аудара алды, Гәүһәршад кырымлыларны да, мәскәүлеләрне дә, ногайларны да яратмады. Минминлекле, үзсүзле Гәүһәршад хакимияте чорында бер-бер артлы фетнәләр куба торды, ил-көн халәте тотрыксызланды, ханлыкта тәртипне каты кул белән генә тотарга мөмкин, әмма Гәүһәршадның хәйләкәр акылы гына Казан ханлыгына якынлашкан һәлакәтне тыя алырлык түгел иде.

Гәүһәршад хан киңәшмәләрендә кайчандыр Мирела әйткән сүзләрне еш кабатлый иде:

– Казан ханлыгына давыл киләчәк. Болай барса, безгә күп калмады, егерме ел чамасы гына. Моны булдырмас өчен нәрсә эшли алабыз?..

**9**

Равил Казан театр училищесына имтиханнарны уңышлы бирде. Конкурс шактый зур иде, алырлармы-юкмы дип, ай буе көткәннән соң, ул куанычлы хәбәр белән авылга хат язды: кабул иттеләр.

Казан мохите, яңа төрле тормыш-көнкүреш аның күңеленә бик хуш килде. Елга техникумының тулай торагында өч кеше бер бүлмәдә яшәделәр, утыз сум стипендиясе яшәргә җитеп барды, буш вакытта колхоз базарында капчык-капчык он ташып, Идел баржаларыннан товар бушатып эшләп алган акча да иш янына куш булып торды.

Бер ел уку сизелми дә калды – Казан каласындагы студент тормышы шундый тыгыз вә кызыклы вакыйгалар белән сугарылып кайнады.

Җәйге каникул, әлбәттә, авылда узды. Сагындырды авыл, хәзер инде авыр эш тә аның өчен ял кебек иде. Кызганыч, этисе мотоциклны саткан. Ярар инде, матайсыз да әллә кайларга барырлык, әллә нинди югары үрләрне алырлык дәрт-дәрман бар иде егеттә.

Быел чегәннәр бу тирәдә күренмәделәр.

Беркөнне Равил, болынга чыгып, узган елны Лаура белән булган урыннарны әйләнде, хәтерендә шул татлы мизгелләрне барлап йөрде.

Җәй шундый тиз үтеп китте, Казанга килеп, яңа көч белән икенче курста укый башлады, әмма военкоматтан повестка килгәч, тиздән армиягә аласылары билгеле булды.

...1978 елның ноябрь башында ул инде Татвоенкомат ишегалдында басып тора иде. Чүпрәк сумкада пешкән тавык, берничә күкәй, шешәгә тутырылган сөт, ипи, иске куртка кесәсендә – авыл кызлары бүләк иткән берничә кулъяулык иде. Лаура бүләк иткән тәңкәне алмады, армиядә югалырга мөмкин дип курыкты, ул аны авылда калдырды – мәктәп елларыннан калган китаплар, дәфтәрләр төргәгенә тыгып, өй түбәсенә алып менеп куйды.

Урал төбәгендә урнашкан ракета гаскәрләренең учебкасында хәрби тормыш башланды. Аның белән бер взводта Буадан Әнәс исемле егет бар иде. Ике татар егете тиз арада дуслашып киттеләр. Учебкадан соң Әнәсне замкомвзвода итеп шул ук дивизионда калдырдылар, Равилгә дә учебка

частенда калырга насыйп булды. Бер тапкыр дивизион командиры майор Проценконың фатирында ремонт ясарга дүрт курсантны билгеләделәр, шуларның берсе Равил иде. Оста куллы, балта эшен яратучы Равил бу эшкә бик теләп, хәтта илһамланып тотынды. Тырыш, көчле егет Проценконың күңеленә хуш килде һәм аңа «Дом офицеров»та ремонт остасы булып калырга тәкъдим ясады. Равил моңа сөенеп риза булды – әле алда ел ярым вакыт хезмәт срогы кала, белгән юк, нинди частьта, нинди шартларда хезмәт итәргә туры килер иде. Дусты Әнәс тә учебкада кала, аралашырга вакыт та, җай да табылыр, шәт.

Офицерлар йортында кызык, дәртле, җырлы-биюле тормыш кайнап тора иде. Хуҗалык ротасының казармасында йөз кеше, арада төрлесе бар. Хезмәт бигүк җиңел булмаса да, түзәрлек. Боевой частьларга караганда монда шартлар барыбер уңайрак иде. Равил төрле ремонт эшләрен башкарды, ел ярым вакытның күбесе «Офицерлар йорты»нда узды. Үз эшен яратып башкарды, күңел өчен дә буш вакыт күп кала иде, авылда ук гармунда, баянда уйный белә иде, монда исә гитарада да уйнарга өйрәнде.

1980 елның ноябрь уртасында армиядән кайткач, Равил авылда нибары берничә көн генә булды, Казанга килеп, укуын дәвам итәргә кирәк иде.

Казан үзәгендәге Тельман урамында яшәүче Нәфисә апаның иске агач йортында, аена ун сум түләп, бүлмә алып тора башлады. Кызык та, шул ук вакытта сәер дә – бөек каланың тарихи урыннарында урнашкан агач йортлар хәтта бераз авылны да хәтерләтәләр иде. Равил бик яратты Казанның бу урынын. Нәфисә апаның улы, күптән түгел өйләнеп, Восстание урамында яши, Нәфисә апа соңгы вакытта гел шуларда, бала карарга булыша иде. Равил апаның күңеленә хуш килде, ышанып, йортын шактый озакка бөтенләй аның карамагына калдыра башлады.

Казан бик сагындырган иде. Укуы да кызык, мавыктыргыч, Равил дәртләнеп, атлыгып, училищега йөрде. Казанда ике ел эчендә берни үзгәрмәгән диярлек – кешеләре, бигрәк тә кызлары, шулай ук матур, трамвайлар, троллейбуслар үз маршрутлары буенча, элекке номерлар белән тыз-быз йөреп тора иде. Равил юынырга йөри торган өченче номерлы мунча да үз урынында икән, Бауман урамы да шундый ук – монда, гадәттәгечә, бертуктаусыз рәхәт ыгы-зыгы кайный икән. Пушкин урамындагы «Блинная» дип язылган коймак ашханәсендә элеккечә тәмле коймак пешерәләр, ә Ленин урамының Спасс башнясы янындагы ашханәдә һаман тәмле итеп итле бәрәңге ашарга була...

Яңа ел алдыннан Равил Мамадыштан кулинария техникумында укучы Клара исемле кыз белән танышты. Яңа елны, Нәфисә ападан рөхсәт сорап, алар бергә каршыладылар. Аннары Клара каникул вакытында Мамадышка кайтып китте. Равил, Яңа ел шаукымыннан туеп, берничә көн беркая чыкмыйча, өйдә ятты.

Ул актёр булачак! Тизрәк укуны тәмамларга да театрда эшли башларга иде. Казанда танылган шәхесләр күп – җырчылар, композиторлар, артистлар, кайберләрен Равилнең инде күргәне дә бар. Аның үзенең дә билгеле вә данлы шәхес буласы килә, моны гамәлгә ашырырга мөмкин, монда аның өчен бөтен шартлар бар, барысы да фәкать үзеңнән тора. Казан – Казан инде ул!

Равил беркөнне Нәфисә апаның иске «Балтика-4» телевизорыннан «Табор уходит в небо» дигән фильм карады.

Лаура күз алдына килеп басты. Аның Лаураны онытканы да юк. Равил, чемоданнан чегән кызы бүләк иткән тәңкәне алып, муенына тагып куйды – армиядән соң тәңкәне ул үзе белән Казанга алып килгән иде. Лаура! Күрергә иде сине! Тагын кайнар сулышыңны тоярга иде, яшькелт-зәңгәр күзләреңә карап торасы иде. Лаура үзе мине онытмады микән? Онытмагандыр!

Күңелне якты сагыш биләп алды. Нишләп күңел кинәт боекты?.. Фильмны караганнан соң, тәңкәне тотып, моннан ике ел ярым элек чегән кызы белән кунган төнне мизгеленә кадәр хәтерендә барлап утырды ул.

Уку тәртибе бик тыгыз булу сәбәпле, Клара белән сирәгрәк очраша башладылар, тора-бара аралар өзелеп тә куйды. Очрашып йөргәндә, бергә гаилә кору турында хыялланмадылар алар. Вакытлыча гашыйк булу гына икәнне, гәрчә бу хакта бер сүз катмасалар да, икесе дә аңлыйлар, кыскасы, мөнәсәбәтләр, хәйран тирәнгә керүгә карамастан, бигүк җитди түгел иде. Соңгы тапкыр очрашкач, алар «Родина» кинотеатрына бардылар, кинодан соң Казан елгасы буенда йөрделәр. Равил аны тулай торакка кадәр озата барды, матур итеп хушлаштылар һәм шулчакны икесе дә сизенделәр – бу аларның соңгы очрашулары иде.

Клара янына бүтән бармады ул. Унынчы гыйнварда очрашырга сүз куешканнар иде, әмма Равилнең күңеле тартмады, соңрак барырмын янына, дип уйлады, вәләкин бүтән кыз тарафына аяк басмады. Клара да үзен горур тотты, Равилгә бүтән хәбәр бирмәде, шулай итеп, кинәт кабынган мәхәббәт тиз арада сүнде дә юкка чыкты.

## 10

Равил әллә каян кызлар күзенә ташлана торган, мәһабәт гәүдәле, коңгырт-кара күзле, кара чәчле, киң маңгайлы, «грекларча» озынча, төз борынлы, матур тавышлы егет иде. Армиядән соң ул мыек «җибәрде», аннары, мыегын кырып ташлагач, аңа барысы да, бигрәк тә кызлар: «Сиңа мыек шундый килешә, нигә кырдың?!» – диделәр. Аның төс-битен рус актёры Леонид Филатовныкына охшаталар иде. Бергә укучы кызлар аңа беренче көннәрдән үк гашыйк булды, гомумән, күңеленә хуш килгән кызны үзенә каратмый калганы булмады. Аның үзенә тартып торган нindidер сөйкемле сөяге бар иде. Кем әйтмешли, «кызларны пирчәткәдәй алмаштыру»дан ул һич кенә дә читенсенмәде, кызлар игътибары мул булган егетләргә хас: «Әле үземнең чын ярымны тапмаганмындыр...» дигән уй белән еш кына үзен хәтта эгоистларча тота иде.

Мәхәббәт, гыйшык-мыйшык мәсьәләләрендә үз-үзенә нык ышанса да, аның күңелендә гел сагыш уятып торган бер җәрәхәте бар иде – Лаура. Чегән кызының зиһен белән генә төшенеп булмаслык нindidер сихри тәэсире калды һәм менә инде еллар үтә торды, ә Лаураны сагыну сүнмәде вә сүрелмәде. Теге яки бу кыз белән күпмедер вакытка онытылып торса да, ул һаман чегән кызын сагынды, аны кайчан да булса очрату хыялы белән яшәде.

1981 елда КХТИда укучы Сания исемле студент кыз белән танышкач, менә, үз кешемне таптым, бу кызга өйләнермен, ахрысы, дип уйлаган иде. Алар өч елга якын очрашып йөрделәр, эшләр инде шактый тирәнгә керде,

әмма Сания институтны тәмамлап, юллама белән Новосибирскига киткәч, күпмедер вакыт хатлар язышып тордылар да, ара үзеннән-үзе өзелде. Моны да бик җиңел генә кичерде ул, һичнинди үкенү, уфтану, борчылу булмады.

Алда зур вакыйга булырга тора – укуны тәмамлап, диплом алып, театрга эшкә урнашасы бар иде, бу көннәрдә Равил, илһамланып, шул күтәренкелек белән яшәде. Саниядән хатлар килми башлагач, ул тагын Лаураны ешрак искә төшерде, төшләрендә аны күрде.

Инде өченче курста ук аңа театрның баш режиссёры игътибар итте, студент килеш инде өч спектакльдә катнашырга өлгерде ул. Өметле егет, бу актёрның киләчәге зур булачак, дигән сүзләрне ул даими ишетеп торды.

1984 елны Равилне театрга штаттагы актёр итеп эшкә алдылар. Театрда эшли башлагач, Равил сәнгать коллективының тормышында җанбиздергеч күренешләр бар икәнен беренче көннәрдән үк чамалады. Ул әле башта театрның «зәһәр еланнар оясы» икәнен белми иде. Анда бер генә затлы мәйданчык бар икән – сәхнә – ике сәгатькә чыгып, күңелеңне ачарга мөмкин урын, ләззәт ала торган, кешеләрнең рәхмәтен вә мәхәббәтен тоя торган биләмә. Әмма, ни кызганыч, театр сәхнәдән генә тормый шул.

Равил – ачык, ихлас күңелле егет, барлык хезмәттәшләренә дә җылы мөгамәләдә булырга тырышты, театрның һәр чагылышын яратып кабул итте, танылган, өлкән яшьтәге актёрларга сокланып, мәхәббәт белән карады, гәрчә араларында төрле холыклылары булса да. Әле ул үзара аралашканда, төрле кинаяләрне, төрттерү-чеметүләрне, кыек-мыек сүзләрне дә начар ният белән әйтелгәнен аңламый иде, үзе киң күңелле булгач, башкалардан да ихласлык көтте, сәнгать төркемнәрендә хөсетлек, сатлыкҗанлык көчле икәнне тора-бара гына аңлый башлады ул. «Талант гафу ителми», дигән сүзнең чын мәгънәсенә Равил әле еллар узгач кына төшенәчәк. Илдәге эшнәлек-кодалык, ялагайлык театрда аеруча анык, уч төбендәгедәй күренеп тора иде, инде беренче рольләреннән үк Равилгә кырын караучылар, аны пыш-пыш тәнкыйтьләүчеләр табылды. Тамашачы залыннан кызлар чәчәк бәйләмнәре белән сәхнәгә менеп, Равил янына йөгереп баруны күрүнең башка ир-егет артистларга ничек тәэсир итүе аңлашыла, әлбәттә.

Әмма тамашачыдан килгән җылылык сәхнә артындагы низаглардан, ямьсез күренешләрдән, ваклыклардан өстенрәк вә көчлерәк иде, халык мәхәббәте хакына ул күп нәрсәләрне кичерергә, аларга күз йомарга, игътибар итмәскә өйрәнде.

1985 елда Равил Гөлнара исемле төскә-биткә чибәр, ыспай киенгән, үзен ипле һәм горур тотучы кыз белән танышты. Тамашадан соң театр янында бер төркем кызлар Равилдән автограф алдылар, араларында бер үткен күзле, текәлеп карый торган кыз да бар иде, ул да нindидер открыткага Равилдән кул куйдырды.

Җиде-сигез кыз арасыннан Равилгә иң нык ошаганы Гөлнара булды – пөхтә, күренеп тора, үзен карый белә торган, бөтен нәрсәсе үз урынында, тәртип яратучы кызга охшаган, җитди, күзләре акыллы... Равилгә ул төче сүзләр, купшы мактаулар әйтмәде, мин сезнең уйнавыгызны яратам, димәде, хәтта бүгенге спектакль турында да шундый ошады, дип сүз катмады.

Гөлнараның, медучилищены тәмамлап, шәһәр хастаханәләренең берсендә медсестра булып эшләгәнен белгәч, Равил:

– Минем апам да, медсестра, – диде. – Димәк, бу – язмыш, – дип, шаярып өстәп куйды.

Алар очраша башладылар, әмма Гөлнара Равилгә профессиясеннән аерым гына гашыйк, аңа егетнең чибәрлеге, абруе кыйммәтрәк иде. Равил соңрак кына аңлады – Гөлнара театрны яратмый, дус кызлары Равилдән мөкиббән киткәнгә күрә, үземә каратам бу егетне дигән принциптан гына аның белән танышканы ачыкланды. Гөлнараның ул уйнаган спектакльләр турында хәтта ишеткәне дә булмаган, актёрларны белми, гомумән, татар сәнгатенә битараф вә илтифатсыз булып чыкты ул.

Күп тә үтмәде, Гөлнараның карьера ясау хыялы сизелә башлады, блат белән медицина институтына керергә омтылганы беленде, Равилнең популярлыгыннан файдаланып, берәр җитәкче белән сөйләшеп булмасмы дигән сүзләр әйтте. Ничек булса да, институтка керергә омтылып, баш врачка, аның урынбасарларына каш сикертүләре хакында Равил әле соңрак, бергә яши башлагач кына ишетәчәк. Гашыйк чакта бик күп нәрсәне күрмисең, аңламыйсың шул, бигрәк тә бер күрүдә гашыйк булганда, кешенең асылын аңларлык эчке сиземләү югалып тора, аның эчке дөньясын түгел, тышта чагылган сыйфатларын гына күрәсең.

**11**

1986 елның көзендә алар өйләнештеләр. Гөлнараның әти-әнисе бу никахка каршы булдылар – җитди профессия кешесе кирәк, диделәр. «Егет чибәр, сүз дә юк, талантлы актёр, әмма бүгенге көндә андый кешенең яшәештә тоткан урыны нинди булыр?» – дип кыбырсыды алар. Имеш, актёр халкы гаиләгә үзгә мөнәсәбәттә бит ул... Дөнья әллә нишләргә тора, «перестройка», тегесе-монысы, илдә кискен үзгәрешләр башланды, мондый чынбарлыкта аякта нык тору зарур, дип тукып тордылар. Мединститутка керәсең бар, язмышыңны хәлле кеше белән бәйләргә кирәк, имеш.

Әмма яшьләр гаилә корырга карар кылдылар.

Шул айда ук, театр ярдәме белән, Чуйкова урамында урнашкан медучилище тулай торагында аларга бер бүлмә бирделәр.

Равил инде актёр буларак танылды, аңа яңадан-яңа рольләр бирә тордылар, аның турында: өметле, киләчәктә татар театрының иң зур актёрларының берсе булачак, дип фараз кылдылар. Коллегалар арасында төрлесе бар – талантлылары бармак белән генә санарлык, ә сәләте җитенкерәмәгәннәре күбрәк иде. Нәкъ менә халык мәхәббәтен яулый алмаганнары гайбәт сөйләп, хөсетлекләрен яшерә алмыйча, мәкерле эшләр белән шөгыльләнеп йөриләр дә инде. Әмма халык мәхәббәте, театрга кирәк булуы һәм үз профессиясен яратуы андый ваклыклардан Равилне югарырак күтәрде, ул тора-бара театрдагы пычрак күренешләргә ригая бирмәскә өйрәнде.

Гөлнара исә хәтта үз эшен дә яратмый иде. Күп тә үтмәде, аның тарафыннан: «Профессиямне ялгыш сайладым, минем эш түгел бу, ялгыштым...» – кебек сүзләр ишетелә башлады, ә үзе шул ук вакытта мединститутка керергә хыялланып йөрде. Равил аңа: медицинаны яратмаган табибә булырга маташасыңмы, дигәч, ачуы кабара торган булды. Медицина белеме белән дә төрле урыннарда эшләп булырга мөмкин, дип акланырга тотына иде. Ә Равилне:

– Үзең популяр артист булып саналасың, ә мине мединститутка кертерлек әшнәләрең юк, – дип битәрләде.

– Блат буенча табибка укырга ярыймы соң?! – диде аңа Равил, ачуын яшермичә.

– Бигрәк намуслы кеше инде үзең, – диде Гөлнара. – Хәзерге заманда болай яшәргә ярамый!

Равил актёр буларак популярлаша барган саен, Гөлнара иренең эшен ныграк өнәмәде, ә инде театрны бөтенләй күрәлмый башлады. Үзен ире алдында ким-хур тоюдан, үзен бәләкәй кеше итеп хис итүдәнме бу? Әти-әнисе карьера ясарга котыртуданмы? Аның ир хатыны, хатын-кыз буласы гына килми иде, ничек тә булса танылу, югары үргә менү теләге көчәйгәннән-көчәя барды. Театрга тамашалар карарга йөрмәде, иренең сәхнәдәге уңышларына куанмады, өстәвенә, ул йөгәнсез рәвештә көнләшә башлады. Монда аны аңлап була иде – иренә хатын-кыз тарафыннан игътибар күп булу кайсы хатынга ошар икән?

Акча кытлыгына зарланып, юньле кием алып булмый, безнең белән эшләүче кызлар шуны кия, ире фәлән нәрсә бүләк иткән дип, Равилне ул гел йөдәтеп торды. Имеш, эштә аңа төрттерәләр – ирең шулай аз акча аламыни, диләр. Равил исә, жаны-тәне белән театрны яратучы буларак, бөтенләй түләмәсәләр дә, сәхнәгә чыгар иде, мөгаен.

Илдә үзгәртеп кору чоры башланды, төрле кооперативлар төзелгән, эшмәкәрләр барлыкка килгән, шәхси фирмалар ачылган заман икәнне телевизордан, радиодан гел тукып бардылар, Равилгә моны Гөлнара да гел искәртеп торды. «Баш врачның улы фәлән кооператив ачкан, инде машина алган. Минем белән эшләүче хатынның ире шәхси фирмасын булдырган...» кебек мисалларны Равил көн саен ишетә башлады.

– Әтисе партия горкомында инструктор, әнисе яшелчә базасында бухгалтер булып эшләгән кешеләрнең кызы шулай фикер йөртер инде ул, – диде аңа Равил беркөнне.

Әйе, Гөлнараның туганнары Равилне яратмадылар, ат хәтле гәүдәсе белән артист булып кыланып йөри дип, ачыктан-ачык әйткәннәре дә булгалады. Акча эшләү турында уйларга кирәк, диделәр алар. Равил театрда, төп эше өстенә монтировщик булып та урнашты, оялмыйча эшләде, акча күбрәк булыр дип уйлады.

Балага узгач та, Гөлнара тынычлана алмады. Равил исә, бала тугач, тормыш юлы яктырак юнәлеш алыр дип өметләнә башлаган иде.

...Әмма язмыш аларга зур сынау әзерләгән икән – Гөлнараның йөге төште.

– Тормыш шартлары шундый безнең, тикмәгә булмады бу выкидыш, – дип, Гөлнара елады да елады.

– Гаепне читтән эзләүдә ни мәгънә?! – диде аңа Равил. – Нервыларыңны дәваларга кирәк.

Гөлнараны ул хәленнән килгәнчә тынычландырырга тырышып карады, әмма хатынын игә китерерлек түгел иде инде.

– Әгәр тормышта популярлыгың гаиләгә ярдәм итми икән, пычагымамыни синең даның?! – диде аңа Гөлнара, янә элекке дәгъваларына кайтып.

Аның бу сүзләрен Равил җавапсыз калдырды, ә инде Гөлнара:

– Ирем актёр, ә тормышыбыз төксе, – дип, кат-кат кабатлагач:

– Актёрга чыккач, тормышыңда гел уен-көлке, җыр-бию булыр дип көткән идеңмени? – диде.

Равил үзе дә нык кайгырды ул көннәрдә – дөньяга килә алмаган балада үзенең дә бер өлеше югалгандай булды, ә менә Гөлнара белән көннән-көн аралар бозылганга һич кенә дә борчылмады.

Туганнарының, Казанга килгәч, бер спектакльне караганнары булды, спектакль ошады аларга, әмма театр турында, Равилнең эше хакында сөйләшкәндә аларның тел төбендә: «Шундый алкышларга күмелгән актёрның һаман фатиры юк...» дигән фикер ятканы аңлашылды.

Тора-бара Равил үзе дә Гөлнараны тәмам санга сукмый башлады. Кая китте кайчандыр балкып кабынган мәхәббәт?.. Никахка кадәр алар бер-берсен яраталар иде бит... Үзләренең төрле дөнья кешеләре икәнне бергә яши башлагач кына аңладылар шул алар.

Гашыйк булып йөргәндә, сөйгәнеңнең җитешсезлекләре, кимчелекләре күренми, яраткан кешеңнең кимчелеге дә хәтта сөйкемле булып тоелырга мөмкин. «Аңлаган нәрсәне генә яратып була» дигән сүз бар – кайдадыр укыдымы Равил, берәрсеннән ишеттеме... Әмма ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләрдә алай түгелдер инде ул, кешене алдан ук аңласаң, мәхәббәт шундук сүнәр иде, йә бөтенләй кабынмас иде...

**12**

Равил беркөнне, базарда йөреп, җилләнеп кайтырга булды. Илнең кинәт үзгәрүе базарда аермачык күренде. Горбачёв тарафыннан игълан ителгән «перестройка» тиз арада кешеләрнең дә аңын үзгәртә башлады. Кибетләрдә яхшы сыйфатлы ризык югалды, дефицит элек тә булды ул, әмма хәзер иң кирәкле товарны да табарлык түгел иде, алар урынына шикле сыйфатлы продукция чыга башлады, алыпсатарлар рәхәт чигә торган көннәр килде, бөтен җирдә күзгә карап алдау хөкем сөрде, оят дигән нәрсә юкка чыкты. Әхлак төшенчәсе мескенлекне аңлата торган сүзгә әйләнде, елгыр, хәйләкәр булмасаң, син булдыксызлар рәтенә керә идең. Ачылган кооперативлар халыкны иң кирәкле тормыш-көнкүреш әйберләре белән тәэмин итү ниятеннән түгел, халыктан, алдап-талап, акча җыеп, җиңел баю максатында эш итәләр иде.

Тормыш-көнкүрештәге әйберләрнең юкка чыгуы бер нәрсә... Кешеләр аңында кискен үзгәрешләр башлануы аермачык күренә башлады. Хәзер инде элек дәүләт тарафыннан җибәрелгән хаталар, ялгышулар булганны ачыктан-ачык сөйләргә тотындылар, күп нәрсәгә караш үзгәрде, әмма алга таба нәрсә буласы аңлашылмый иде, чынбарлыктагы проблемалар бер-бер артлы калкып чыга торды. Үзгәртеп кору, имеш... Ил болгана-туглана, гәҗит-журналларда берсеннән-берсе куркыныч мәкаләләр дөнья күрә, телевизордан кыю фикерләр яңгырый, котелмәгән фикерләр, элек әйтергә ярамаган сүзләр ишетелә, ә кешеләрнең ашыйсы, киенәсе, урамнарда җинаятьчеләрдән курыкмыйча йөрисе, кыскасы, иртәгәсе көннән курыкмыйча яшиселәре килә иде.

Тагын берничә елдан әле саклык кассаларында кешеләрнең акчалары «яначак», өметләр акланмаячак, ил таркалачак, тора-бара исән калу,

югалмау – иң мөһим максатка әйләнәчәк, ул кара көннәргә күп калмады инде. Әлегә халык, чынбарлыкны кабул итеп (кабул итми кая барасың?!), көн күрә иде.

Базар кайный. Равил сәүдә рәтләре буйлап китте. Ике куллап плащлар, пәлтәләр, свитерлар тоткан кешеләр арасыннан ул барды да барды. Берәү, килеп, тәмәке кирәк түгелме, дип сорады. Ярый әле Равил тәмәке тартмый, тәмәке дә юкка чыкты бит соңгы вакытта. Вак-төяк товар рәтләрендә хәтта чүплеккә ташланасы иске әйберләр дә сатуга чыккан иде. Иң тетрәндергәне – кешеләрнең күзләрендә, кыяфәтләрендә курку вә чарасызлык чагыла иде.

Сәүдә рәтләренең башында бер төркем чегән хатыннары күренде, алар, пакетлар, төргәкләр белән үзләренең әйберләрен тәкъдим итеп торалар, кайберләре үткән-сүткән кешеләргә фал ачарга маташа иде.

Равилнең аяклары үзеннән-үзе шул тарафка атлады. Ул аларны шактый вакыт читтән күзәтеп торды – чегән хатыннары мәш киләләр – үтеп баручыларга үзләренең әйберләрен тәкъдим итәләр, нәрсәдер кызу-кызу сөйлиләр. Үтеп баручыларның кайберләре туктап, уч төпләрен күрсәтә, кайсылары тыңлап кына тора. Таушалган киемле, йончыган кыяфәтле чегән хатыннары шулкадәр тере вә хәрәкәтчән, аларны күзәтеп торуы гаять кызык иде.

«Лаура башка төрле, ул болар кебек түгел, – дип уйлап куйды Равил. – Луара болар белән әйбер сатып йөрмәс. Лаура чегән кызына түгел, чит планета кешесенә охшаган».

Базардан кайткач, Равил унсигез яшендә Лаурага язган, әмма беркая да җибәрмәгән хатны чемодан төбеннән алып укыды.

**13**

Театрда тарихи әсәр куярга әзерләнеп яталар иде. Булачак тамашада Равилгә төп рольләрнең берсе эләкте. Шул уңайдан беркөнне актёрлар белән очрашуга, кыска гына лекция укырга танылган тарихчы-галим Гариф Сахипов килде. Ыспай киемле, чак кына агара башлаган сакал-мыегын тигез вә матур итеп кыркыган, башы алдан чак кына пеләшләнә башлаган, чигәләренә бераз чал кунган бу галимнең, таушалган кәчтүмле булса да, кыяфәте затлы иде. Аңардан җылы энергия бөркелеп тора, аның сөйләвен тыңлап туймаслык иде. Татар тарихының урта гасырларга кагылган һәм Казанның руслар тарафыннан җиңелгән чорга бәйле вакыйгаларны бернинди пафоссыз, купшы сүзләрсез бик кызыклы вә мавыктыргыч итеп сөйләде ул. Моңарчы ишетелмәгән тарихи фактлар да яңгырады, ерак гасырларда яшәгән шәхесләр дә телгә алынды. Күренеп тора, Гариф Сахипов – күп укыган, гыйлемле, акыллы, шул ук вакытта, үзе яшәгән заманнан калышмый торган зур галим һәм затлы шәхес иде.

Очрашудан соң, Равил аны урамда куып җитте.

– Гафу итегез, Гариф әфәнде, мин сезгә шәхсән рәхмәтемне дә белдерәсем килә.

Галим Равилне таныды:

– Ә-ә-ә, Равил Шәмсиев, – дип елмайды ул. – Ошадымыни?

– Бик тә. Калын бер китап укыгандай булдым.

– Мин бит шат. Син дә бу якка барасыңмы? – диде тарихчы, алга ишарәләп.

– Әйе.

– Әйдә, мин дә бер-ике тукталышны җәяү үтәм. Үзеңә рәхмәт җылы сүзең өчен. Җылы сүз ул һәрвакыт һәркемгә кирәк, хәтта югары дәрәҗәләргә ирешкән олпат кеше дә мактау сүзләренә мохтаҗ. Әллә кем булып күренсә дә, һәрбер кеше үзенең эшен югары бәяләүләрен көтә. Мин дә сиңа ихластан җылы сүз әйтәм: узган атнада син уйнаган спектакльне карадым, ролеңне искиткеч башкардың.

– Рәхмәт, Гариф абый.

Ленин бакчасы яныннан үткәндә, Гариф бакча эскәмиясендә бераз утырырга тәкъдим итте. Көзен сирәк була торган җылы, рәхәт көн иде.

– Син акыллы, уйчан актёр, – диде галим, эскәмиягә утыргач. –Укуыңны дәвам итәргә кирәктер, бәлки. Син режиссёр була алыр идең.

– Гариф абый, сез Кырым ханлыгы турында кызыклы нәрсәләр сөйләдегез, Гәүһәршад ханикә турында да бәяныгыз бик кызыклы булды. Аның әнкәсе Нурсолтан да зур шәхес булган икән. Мин бит, затлы хатын-кызлардан Сөембикәдән башка беркемне дә белми идем.

Равил курткасының куен кесәсеннән Лаура бүләк иткән тәңкәне чыгарды, аны ул тарихчыга күрсәтермен дип, театрга махсус алып килгән иде.

– Менә бу әйбер турында нәрсә әйтә аласыз? Бу бик борынгы монета, шулаймы?

Галим, тәңкәне алып, әйләндергәләп карады:

– О-о-о, бу бит Дракула монетасы,  – диде ул. – Каян алдың моны?

– Чегән кызы бүләк иткән иде. Күптән инде, армиягә хәтле үк, мәктәпне тәмамлаган елны. Тылсымлы дигән иде ул аны.

– Чегәннәр борынгы халык шул, – диде тарихчы, тәңкәне сокланып караганнан соң, кире Равилгә биреп.

– Дракула монетасы нәрсәне аңлата?

– Унбишенче гасырда хәзерге Румыния территориясендә Валахия дигән кенәзлек була, анда Влад Өченче Цепеш исемле кенәз хакимлек итә. Аның турында бик күп куркыныч легендалар сакланган – дөрестерме, юктырмы... Шул заманнарда сугылган акча булырга тиеш бу. Чегәннәр шул тарафтан киткәндә, бу тәңкә алар белән булган, күрәсең. Әле уналтынчы гасырда да без яши торган төбәкләрдә чегәннәр булмаган. Алар Византиядән Европа җирләренә үтәләр, кайсылары шуннан Кырымга китә. Россиягә чегәннәр Кырым аша кергәннәр, ахрысы. Сакла моны, бик борынгы, кызыклы әйбер. – Галим тирән сулап, беравык уйланып утырды. – Тарихка күз салсаң, шул ук ыгы-зыгы, – дип дәвам итте ул. – Кайгы-хәсрәт, бәхет-шатлык – барысы да бер көе, хисләр дә шул ук, аерым алган нәрсәләрнең генә кыйммәте үзгәреп килә. Менә бу тәңкә иң элек акча булгандыр, аннары гына тылсымлы санала башлагандыр, хәзер ул тарихи нәрсә, әмма аның тылсымы да, акча буларак бәясе дә юк. Борынгы әйбернең бәһасен аңлаучыга гына кыйммәт ул, аның үзбәясе югары һәм дә аны аңлаучылар гына бәяли ала.

– Бу тәңкә бәһасез! – диде Равил, дулкынланып. – Тылсымлы ул!

– Тылсымлы дип санасаң, тылсымлы инде алайса, – диде Гариф. – Теге яки бу әйберне кеше үзе генә бәяли ала, бер кеше өчен бәһасез булып саналган әйбер икенче берәүгә чүп булып күренергә мөмкин. Төшенчәләр белән дә шул ук хәл – бүген изге дип саналган нәрсә, еллар узгач,

бөтенләй башка бәядә булырга, хәтта бәясен югалтырга да мөмкин. Менә безнең ил революцияләр, сугышлар аша үтте, күпме символларга, күпме әйберләргә табынды халык, бөек дип аталган инкыйлаб хакына күпме кан коелды, күпме фаҗига булды. Ә хәзер менә перестройканы башладылар һәм җитмеш ел изге дип саналган символларга табынып яшәгәннән соң, күрәсеңме, кыска гына вакыт эчендә кешеләр ничек үзгәрде. Кешедәге тискәре сыйфатлар шундук аермачык күренә башлады, ә бит дистәләгән еллар буе дөрес сүзләр сөйләдек, кемнәргәдер, нәрсәләргәдер табындык. Бүген кешеләргә кара... Ышанмаганнар, табынмаганнар бит алар... Без барыбыз да бер үк Кояш астында тудык, бер үк шәхесләргә, кызыл байракка табындык, бер үк әлифбалар буенча укырга өйрәндек, бер үк мәктәптә укыдык, бер үк нәрсәләргә бил бөктек. Әмма йөгәнне җибәрүләре булды, төрле кеше төрлечә уйлаганны, дөньяга карашлар күптөрле булганны аңладык. Бүгенге гәҗит-журналларны укыгач, шаккатырлык бит – бер-ике ел эчендә күпме нәрсәгә күзләр ачылды! Син бүген, хәзер яшисең, үткән заманнарда яхшырак булгандыр дип ышанма һәм борынгыдан килгән һәр нәрсә изге була алмый. Теге яки бу нәрсәнең серен, тылсымын кеше үзе уйлап чыгара, ул әйбер элек кемнән кемгә күчкән, кем кулында булган, ул кеше нинди гамәлләр кылган, нинди уй-ниятләр белән яшәгән соң? Әнә, һәйкәл тора. Ул кеше исән чагында нинди булган, аның ниләр кылганын тәгаен кем әйтә ала? Кызыл йолдыз... Кызыл байрак... Сәвит илендә, йорт стеналарына хулиган малайлар фашист свастикасы ясап куялар, бу бит фашизмны хуплаудан түгел, кызыл йолдызга табынасы килмәгәннән, кызыл йолдызны изге әйбер дәрәҗәсенә күтәрүгә каршы протест ул... Символлар... Кеше үзе билгели – менә мондый символ-тамга әйбәт, мондые – начар. Имеш, свастика ясаучыларга тәрбия җитмәгән. Тәрбия җитәрлек булды, гел патриотик кинолар, патриотик җырлар, пионер лагерьлары... Нишләп соң, шулай була торып, демократия дию белән, вәхшилек өскә калкып чыкты?.. Тәрбия биргәндә, чынны ялганнан аерырга өйрәтү мәслихәт. Нәрсә дөрес, нәрсә фальшь – моны билгеләү җиңел түгел. Аннары, йорт стенасына әшәке сүзләрне язган малайны да кемдер хәреф танырга һәм язарга өйрәткән бит. Төшенчәләрне, әйберләрне, символларны идеаллаштыру, изгеләштерү, миңа калса, кешене үзе булудан тыядыр. Кеше бүген яшәргә комачаулый торган хатирәләрдән арынырга тиеш. Әйе, алардан тәгаен арыну мөмкин түгелдер, бәлки, алардан ваз кичәргә дә кирәкмидер, әмма аларга мөнәсәбәтне үзгәртү зарур – дөрес бәя биреп, аңлап, алга таба хаталанмас өчен.

Равил галимне таң калып тыңлап утырды, көннең калган өлеше дә тулаем Гариф Сахипов сөйләгәннәрнең тәэсирендә узды.

Йоклар алдыннан да әле галимнең кайбер сүзләре колакта яңгырап торды: «Син бүген генә, менә хәзер генә яшисең. Бүгенге көн тиз агып китә, ул тынгылыкны яратмый, ул сәгать саен, мизгел саен киләчәккә сусап тора. Син бүгенге көнең узган гомереңнән качмаслык итеп, бүгенге көнең кылган гамәлләрең өчен рәхмәтле булып калырлык итеп яшәргә тиеш. Ерак гасырлар безнең өчен – сер, уйланма, без инде аңа кагыла алмыйбыз, тарихны без ишетеп, укып кына беләбез. Үткәннәрдә, тарихи фактлар белән беррәттән, гамәлгә ашарга мөмкин булган, әмма булмый

калган вакыйгалар да саклана – шуңа бөек, тирән сер ята узган заманнарда. Тарих безгә яшәү мәгънәсе хакында бер җавап та бирми, җавапларны һәр буын үзе эзли, таба гына алмый. Язмыш нинди генә сынаулар әзерләп куйса да, безгә чынбарлыкны кабул итәсе генә кала. Бүген мине бер нәрсә бик борчый – узган еллардан начарлык, яманлык эзләү кирәк микән?.. Безгә кадәр яшәгән буыннар, ерак бабаларыбыз хәлләреннән килгәнчә, булдыра алганча яшәгәннәр. Узган заманнар инде беркая югалмыйлар, алар Җиһан хәтерендә мәңге сакланачак. Хәзерге заманны, йөз чөереп, инкарь итә алмыйсың, чөнки син бу заманда яшәргә дучар ителгәнсең. Бүгенге көнеңне, тарихтан дәрес алып, киләчәгеңне югалтмаслык итеп яшәргә генә кала. Алда – ап-ачык Кыр һәм яп-якты Күк. Анда әле пычрак та, кара болытлар да юк. Киләчәккә аяк басканда, үзең чиста булырга тиеш. Үзең якты күңелле булсаң, киләчәгең дә якты булачак. Шуны аңласын иде кеше».

Гариф абый искиткеч акыллы кеше, дип уйлады Равил. Әмма Лаура бүләк иткән тәңкә – серле, тылсымлы, затлы әйбер – моңа аның һич кенә дә шиге юк!

Влад Дракула заманыннан килгән тәңкә булганы өчен генә түгел!

**14**

Дракуланың атасы кенәз Влад Икенче «Дракул» (Шайтан) дигән кушаматны аждаһа сурәте төшерелгән акча суга башлагач ала. Көмеш тәңкәнең бер ягында аждаһа сурәте сугылган, ә аждаһа элек-электән һәрвакыт шайтан билгесе санала иде. Андый акча чыгара башлавы исә аның изге Георгий Ордены сафларына (Дракон орденына) керү белән бәйле иде.

Әлеге дә баягы орденның башлыгы – Рим империясенең хакиме Изге Сигизмунд Люксембургский – император таҗыннан тыш, Венгриянекенә дә ия була, ягъни Венгриянең дә короле булып тора.

Венгрия күп еллар дәвамында Валахия (Румыния) дәүләтенең сәясәтендә зур роль уйный, шуңа күрә Сигизмундның мөгамәләсе ул тарафларда гаять мөһим була. Ул вакытта Влад Дракул әле хаким түгел, әмма Валахия тәхетенә инде дәгъва кыла башлаган вакыты иде. Максатына ирешүдә ул Сигизмунд ярдәменә зур өметләр баглады, Орденның символы булып саналган драконлы акча сугуы да: «Миңа Сигизмунд һичшиксез ярдәм итәчәк!» дигәнне аңлатырга теләвенең бер мисалы иде.

1431 ел башында ул тәхеткә менеп утыруга ирешә. Аның улы Влад Өченче (Влад Цепеш) Трансильваниянең Сигишоара каласында шул ук 1431 елны туа. Әтисеннән күчкән Дракул исеме белән йөргән Влад Өченче, данлыклы воевод-кенәз булып танылгач, Валахия иле белән өч тапкыр идарә итә – 1448 елда, 1456 елдан 1462 елга кадәр һәм 1476 елда – төрекләр Балкан ярымутравын яулап ала башлаганга кадәр.

Ил башында Влад Цепеш торган вакытта Бухарест (Букурешти) 1459 елны Валахиянең башкаласына әйләнә.

Үсмер яшендә, Төркиядә булган чакта, Влад Цепеш «атцинганнар» дип аталган халык барлыгын мәгълүм кылган иде. Алар төскә-биткә кара халык булсалар да, киемнәре, үзләрен тотышлары, яшәү рәвешләре белән төрекләрдән нык аерылып торалар иде. Аннары ул белде: төрекләрдә «атцинганнар», «чингенләр» дип аталган кабиләләр кайчандыр Һиндстаннан

чыкканнар икән, аннан алар Әрмәнстан аша Персиягә, соңрак Византиягә үтеп кергәннәр, имеш.

Башка халыкларның кулыннан килмәгән һөнәрләргә ия булулары, җырга-биюгә осталыклары, төрле уен коралларында шәп уйнаулары белән дан казанган чегәннәр арасында багу, күрәзә итү, фал ачу белән шөгыльләнүчеләре дә күп була.

Ерак Һиндстаннан килгәннәрен белгәнгә күрә, аларны Византиядә аерым бер йомык төркемгә, үзгә бер кастага санылар. Ундүртенче гасыр азагында Византия хәлсезләнә, госманлы төрекләр исә көчәеп килә, шул вакыттан чегәннәр әкренләп, Европага тарала башлый.

Румын кенәзлекләрендә яшәүче җирле халык чегәннәргә уңай карый, аларның атаклы тимерчеләре, балта осталары, агач эше һөнәрчеләре, ат тотучылары, музыкантлары бу илләрдә үзләренә лаеклы урын табалар.

Тәхеткә утыргач, Влад Цепеш төрекләрдән 20 мең чегән сатып ала һәм аларны үз илендә урнаштыра, әмма алар тиз арада дәүләтнең, монастырьларның, боярларның колларына әйләнәләр. Ул вакытта аларны өч төркемгә бүлергә мөмкин була: беренчесе – кенәзгә буйсынучылар, икенчесе – монастырьга бәйлеләр, өченчесе – боярларга хезмәт итүчеләр. Кенәз чегәннәре, салымнарын түләп, үзләренең күчмә тормышын дәвам итәргә хокук алалар, монастырьга теркәлгәннәре һөнәрчелек белән көн күрә һәм авыл хуҗалыгындагы эшләрне башкарырга тиеш була. Чегәннәрнең күпчелеге, боярлар кулына эләгеп, барлык хокукларын югалталар – аларның милке, тормышлары, гомерләре хуҗаныкы булып исәпләнә башлый.

Илдәге тотрыксызлык каты кануннар таләп итә. Төрекләрнең торымнан-торымга һөҗүм итүләре, халыкның вакыт-вакыт баш күтәрүе, төрле фетнәләр тынгы бирми. Шуның өстенә, Дракуланың бертуган энесе төрекләр ыстанына чыга һәм бу, әлбәттә, кенәзне киеренкелектә тота, читтән килгән кешеләргә карата аның шиге арта, һәммәсендә шпионнар күрә башлый. Алманнар, мадьярлар, төрекләр аның ышанычыннан күптән чыккан була, соңгы вакытта исә кенәзнең нәфрәте чегәннәргә дә юнәлә – ни дисәң дә, алар бит чит-ят кавем, җитмәсә, араларында караклары, сихерчеләре күп.

Җир йөзенә 1460 елның җәе килә.

Беркөнне чегән малае нәрсәдер урлаган, аны тотканнар һәм хөкемгә тартырга җыеналар. Кануннар катыланган чор булганга, «малайны үлем җәзасына хөкем итәчәкләр» дигән хәбәр чегәннәр бистәсенә дә барып җитә.

Бу коточкыч хәбәрне атлар тотучы, затлы атларны боярларга сатучы Гозело да ишетә. Аның хатыны менә-менә бала табарга тиеш, бу көннәрдә мондый яман хәбәр алу аны хафага сала. Безнең балаларыбыз туа тора, әмма аларны, үсә төшкәч, гади шуклыклары өчен дә үтерә алачаклар бит, дип уйга бата ул.

Нәсел өчен, атцинганнар кавеме өчен борчылу аның җанын ашый – нәсел өчен Баро гына түгел, һәр ир-ат, Гозело үзе дә җаваплы иде. Әлбәттә, иң беренче чиратта, үз гаиләсе өчен кайгыра ул, әмма кан кардәше – теге карак малай кызганыч, бик кызганыч була аңа.

Беркөнне, Алланың рәхмәте белән, кенәз Влад Дракуладан чапкын килде.

– Гозело! – дип кычкыра чапкын, атыннан төшмичә генә.

Гозело йортыннан чыгып:

– Тыңлыйм, – дип җавап бирә.

– Синме Гозело?

– Мин.

– Син атлар дәвалыйсың дигән хәбәр бар... – ди чапкын, атын көчкә тыеп.

– Кулдан-хәлдән килгәнчә, – ди Гозело.

– Мин кенәз кушуы буенча килдем. Аның иң яраткан аты чирли, аягына баса алмый, ашамый. Син хәзер үк кенәзнең ат утарына барырга тиеш.

Гозело, төрле җиһазлар, сыекчалар, кара төстәге шакмаклы ат дарулары алып, кенәз сараена юл тота.

... Гозело кенәз утарында эшен тәмамлаганда инде караңгы төшеп килә.

– Бер-ике көннән аякка басарга тиеш, – ди Гозело үзен күзәтеп торган кенәз куштаннарына.

Баш атбагар усал караш белән Гозелога текәлә:

– Ат терелмәсә, нишләтергә сине? – ди ул.

– Теләсә нишләтерсез, – диде Гозело, утардан китәргә җыенып. – Минем хатын шушы көннәрдә бала табарга тиеш. Зинһар, хатыныма, балама гына тимәгез.

Өч көннән соң Гозелоның җыйнак кына йорты каршында зиннәтле кибитка килеп туктый – Валахия кенәзе Влад Өченче Дракула Гозело янына үзе килә.

– Минем яраткан атымны син дәваладыңмы?

Гозело котсыз кала.

– Мин, – ди ул.

Кинәт йорт эченнән җан ачысы белән кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелә.

– Нәрсә анда? – ди Дракула.

– Минем балам туа, – ди Гозело. – Кенәз монда чагында дөньяга килүен яхшыга юраргамы, начаргамы?

– Ай-яй, ачы телле икәнсең, – ди кенәз, көлемсерәп. – Син атны сихер белән дәваладыңмы, әллә табиблыгың шулай көчлеме?

– Ат савыктымы соң?

– Атым терелде, – ди кенәз. – Рәхмәт сиңа.

– Сихер белән дәваладыммы, дарулар беләнме – ат савыккач, сиңа барыбер түгелмени, кенәз?

– Әйе шул, – дип елмая Дракула. – Сине ничек бүләкләргә? Нәрсә телисең, әйт?

Өй эченнән яңа туган бала тавышы яңгырый. Ишегалдыннан бер хатынның чәрелдәвек тавышы ишетелә:

– Гозело! Кызың туды!

– Менә, миңа Ходай бүләкне бирде инде, – ди Гозело, тынычланып. – Әлбәттә, ир бала шәп булыр иде, әмма кыз баладан да гүзәлрәк кем бар?!

– Син минем соравыма җавап бирмәдең... Нинди теләгең бар? – ди Дракула.

Гозело авыр сулап куя да:

– Хәзер минем бер генә теләгем бар – бу илдә минем нәселемә тимәсеннәр, җәберләмәсеннәр иде, – ди ул.

Кенәз янында басып торган сакчыга нидер әйтә, теге шундук, кибитка эченнән нәрсәдер алып килеп, кенәзгә бирә.

– Менә моны күрсәтсәң, сиңа беркем тимәячәк, кыерсытмаячак, – ди Влад Дракула, Гозелога төрле тамгалар төшерелгән тәңкә биреп. – Бу гади акча түгел, аның бер ягында тәре янына ярым ай сугылган. Мондый билгене мин махсус эшләтеп, илнең абруйлы кешеләренә генә бирәм. Син – хәзер минем якын кешем.

Гозело, бил бөгеп, башын ия:

– Кенәз, тагын бер үтенечемне әйтим әле, – ди ул, кыюсыз гына.

– Тыңлыйм.

– Чегән малаен, караклыкта гаепләп, үлем җәзасына хөкем итмәкчеләр икән...

– Теге, бер боярның абзарыннан йөгән урлаган малайнымы?

– Әйе. Зинһар, җибәрсеннәр аны. Мин аңа үзем, атцинган кануннары буенча, җәза бирермен... Минем әле сиңа кирәк булуым ихтимал...

– Ярый, мин малайны азат итәргә боерырмын, – ди кенәз, кибиткасына утырганда.

Влад Дракуланың кибиткасы урам очындагы борылышта юк булгач, Гозело, ашыгып, өйгә керә.

Өйдәгеләр, тып-тын калып, Гозелоны көтә.

– Безгә Валахиядә беркем тимәячәк. Кызыма Мирела дип исем кушабыз. Кызым туганда, бу тәңкә кулыма килеп керде. Безне саклый торган тәңкә әле яңа гына дөньяга килгән кызым Миреланыкы булачак.

Гозеланың даны тиз арада бөтен Валахия буенча тарала, аның нәселенә җил-яңгыр тими, бернинди хилафлык килми.

Илнең үзендә исә бик болгавыр чор була. 1462 елда госманлылар гаскәре Валахиягә яу белән бәреп керә, Влад Өченче гаскәре, илне яклап, сугышка кузгала, әмма Дракуланың бертуган энесе – төрекләрдә озак еллар яшәгән Раду Өченче – госманлылар ягында сугыша һәм, өстәвенә, Валахиядәге боярларны абыйсына каршы фетнә күтәрергә котырта. Көчләр тигез булмый, Влад Дракула Венгриягә качарга мәҗбүр ителә, анда аны нахакка хыянәттә гаепләп, кулга алалар да, зинданга ташлыйлар. Озакламый госманлылар Валахиянең кенәзе итеп Владның энесе Радуны билгеләп куя. Озак еллар тынычлыкка ирешә алмаган илдән чегәннәр качу ягын карый, Гозело нәселе, Дракула бүләк иткән тәңкә ярдәме белән, Валахиядән чыгып китә һәм озакламый Кырым җиренә барып җитә. Аларга кадәр ярымутрауда чегәннәр шактый, аларны монда төрлечә – чингенләр, аючылар, татар чингенләре, Кырым чингенләре дип атыйлар.

Кырымга килгәндә Мирелага ике яшь була.

## 15

Казанны көз фасылы үзенең дымлы-салкын кочагына алды.

Гөлнараның эштән бирелгән бер айлык ялы шушы вакытка туры килде, ә театр хезмәткәрләре җәй көне генә ялга чыгалар, ягъни бергә ял итү турында уйлыйсы да юк иде. Гөлнарага зарланыр өчен тагын бик яхшы сәбәп булды, Равилне исә бергә отпуск уздыру-уздырмау мәсьәләсе һич кенә дә борчымады.

– Менә, отпускыга чыктым, мин нишләргә тиеш? – дип борсаланды Гөлнара.

– Кеше нишли соң? – диде Равил. – Кайдадыр курортларда ял итә торган заман түгел...

– Кешеләр бара бит әле.

– Минем ял җәй айларында гына мөмкин икәнне беләсең бит инде.

– Мин Әгерҗегә кайтам, – диде Гөлнара. – Әнине сагындым.

Равил моңа бик риза иде:

– Ярар, – диде ул. – Кайчан кире киләсең?

Җавап урынына Гөлнара:

– Театрның ял көннәрендә син дә килерсең бит Әгерҗегә? – диде.

– Юк, ара ерак, бер көн юлда үтәчәк. Син үзең анда озак булырга җыенасыңмы соң?

– Белмим әле.

Гөлнара бүген аеруча ачулы иде, моңа тагын бер сәбәп булган икән әле.

– Мин бер хат таптым, – диде ул, Равилнең йөзенә туры карап. – 1978 елны язылган.

– Шуннан?

– Нинди Лаура ул?

– Бер кыз инде шунда. Мәктәпне тәмамлаган елны танышкан идек. Кайда ул хат?

– Мин аны ертып ташладым.

– Ник?

– Бик кадерле идемени? – диде Гөлнара чәнчүле тавыш белән.

– Гөлнара, син бала-чага түгел бит инде. Миннән рөхсәтсез хатны ертырга ни хакың бар?!

Гөлнара кызып китте:

– Әйе, мин бала-чага түгел! Мин – хатын-кыз! Бәхетле булырга лаеклы кеше.

– Син бәхетсезмени?

Гөлнараның ияге дерелди башлады:

– Болай яшәп булмый бит инде, – дип еламсырады ул. – Күңелем сизә, без гомер буе, акчага туенмыйча, очны очка ялгап яшәячәкбез.

Мондый сүзләрдән Равил инде гарык булган иде.

– Булыр әле барысы да, – диде ул, үзен көчкә тыеп. – Алдан ук бөтен нәрсәне өеп, кемгә бирәләр?!

– Миңа өеп кирәкми. Минем кешечә яшисем килә. Синең популярлыгыңнан ни файда? Синең танылган артист булуың миңа газап кына өсти. Кызлар бүләк иткән чәчәкләреңнән, пинжәк иңбашындагы помадалардан да туйдым инде мин. Әйе, сине яраталар, ә мин – гади медсестра. Мине гомер буена ашарга пешерүчең, кер юучың, өй җыештыручың гына итеп тотарга уйлыйсыңмы әллә?!

– Имтиханнарга әзерлән, мединститутка кер. Блат белән керү турында хыялланып йөрмә, сиңа карьера ясатырлык әшнәләрем юк минем.

– Эгоист син, Равил, үзеңне генә яратасың. Актёрлар барысы да шундый микән?

Гөлнара елый-елый, юлга әзерләнде.

Хатынның үзен тотышы чамадан тыш пырдымсыз булганга, Равил аны вокзалга озата бармады, рольнең текстын тизрәк ятлыйсы бар дигән сылтау белән өйдә калды. Равил соңгы вакытта Лаура бүләк иткән тәңкәне көмеш чылбыр белән муенына тагып йөри башлаган иде. Гөлнарага бу тәңкә турында дөресен әйтмәде, район үзәге янындагы хәрабәләрдә таптым, дигән иде. Гөлнара: «Ник аны муеныңа тагып йөрисең» – дигәч, Равил: «Бер тарих галиме бу борынгы әйбернең Румыния якларыннан килгәнен әйтте», – дип җавап бирде.

Бүлмәдә үзе генә калгач, хәтер аны яшьлек елларына алып китте, Лаура белән тагын очраштырды, аннары шул вакыттан бүгенгәчә булган төрле вакыйгаларны барлап утырды.

Көз... Театрда сезон ачылган вакыт. Тиздән яңа спектакль сәхнәгә чыгачак, Равил анда төп рольне уйнаячак – шәп роль!

Аның игътибар иткәне бар – соңгы вакытта ЦУМ белән цирк бинасы арасындагы мәйданда вакыт-вакыт чегәннәр төркеме күренгәли. Төрле яшьтәге, төрле кыяфәттәге чегән хатыннары, шау-гөр килеп, анда вак-төяк әйбер, кием-салым саталар, күрәсең, алар бу урынны тимер юл вокзалы якын булганга сайлыйлардыр инде. Төркемнәре белән киләләр дә, үткән-сүткән кешеләргә кайбер нәрсәләрен сатып, бераздан тиз арада ул тарафтан юкка чыгалар иде.

Бүген Равил шунда барып кайтырга булды.

Вакытында килде ул анда – универмагның уң як тарафындагы мәйданчыкта чегән хатыннары мәш киләләр иде. Аларга монда озак булырга ярамый, хокук саклау органнарыннан шүрлиләр, шуңа күрә аларның хәрәкәтләрендә кабалану сизелә, кулдагы әйберләрен тиз генә сатып, кире вокзалга китү ягын карыйлар.

Равил, караңгы-чуар киемле хатыннар төркеме янына килеп, кырыйдарак басып торучыдан сорады:

– Сезнең арада Лаура исемле кыз юкмы?

– Кыз юк, хатын бар, – диде чегән хатыны һәм муенын сузып кычкырды: – Лаура!

Болар янына, әвеш-тәвеш килеп, беләгенә ниндидер чүпрәк-чапрак аскан олы яшьтәге юан хатын килде.

– Нәрсә? – диде ул, килгән уңайга.

– Сине сорый.

Равил башын чайкады:

– Юк, ул түгел.

Юан хатын Равилгә сигаретлар тәкъдим итте, сиңа ярашлы куртка бар, дип карады, әмма Равил аны игътибарсыз калдыргач, хатын, борын төбенә үз телендә мырлап, әкрен генә кире китеп барды.

Равил тагын берничә кешедән Лаураны атап сорау бирде, әмма җавап урынына аңа йә футболка тәкъдим иттеләр, йә олы сумкалардан төрле күлмәкләр чыгарып селкеделәр, ә берсе, киләчәгеңне әйтеп бирәм дип, уч төбен күрсәтүне сорады. Үзенең киләчәге кызыксындырса да, Равил, монда кулын ачып, алда ниләр күрәчәген ишетергә теләмәде.

Какча гәүдәле чегән хатыны, урталай бөкләнгән килеш, каерылып ачылган зәңгәр сумкасында футболкалар актарып тора иде, Равил аңардан

да сорап карарга теләде, әмма килүе булды, хатын аңа футболкалар тәкъдим итәргә тотынды. Футболкалар полиэтиленга төрелгән, нык итеп ябыштырылган, ачып карарга ярамый, упаковкасы бозыла, дигән сылтау белән, кеше шул килеш, тикшермичә генә алырга тиеш иде. Озын итәкле караңгы төстәге күлмәге өстеннән күн куртка кигән, башына төсе уңган яулык бәйләгән чегән хатынының яңак сөякләре чыккан, чем кара күзләре тирәнгә баткан иде. Бик нык кыстагач, Равил аңардан унике сумга футболка сатып алды. Ялтыравык төргәкле, затлы төймәләре шундук күзгә ташлана торган футболканы өйгә кайтып ачканнан соң гына Равил алданганын аңлады – матур упаковка эчендә, арзан бәяле ялтыравык төймәләр тагылган гап-гади триконың өсте булган икән ләбаса. Әле хәзер ул аны белми иде.

– Мин Лаура исемле кызны эзлим, – диде Равил. – Сез аны белмисезме?

– Безнекеме ул? – диде хатын.

– Әйе, – диде Равил, «безнеке» дигән сүзгә нинди мәгънә салынганны аңлап.

– Кайсы Лаураны эзлисең икән син? – дип, кашларын җыерып уйлап торды хатын.

– Ул бик чибәр.

– Чегәннәр барысы да чибәрләр, – диде хатын кырыс тавыш белән. – Безнең арада ямьсез кешене күргәнең бармы әллә?

– Юк, сезнең арада ямьсез кеше юк, – дип елмайды Равил. – Әмма Лаура күз явын алырлык чибәр. Без моннан тугыз ел элек очрашкан идек. Мин аны тоткынлыктан коткардым.

– Нинди тоткынлыктан? – дип сагайды хатын, «тоткынлык» сүзен ишеткәч, милициядән түгел микән бу егет дип уйлап.

– 1977 елны безнең авыл янында чегән таборы торган иде. Авылдан ат югалгач, шуларга сылтадылар. Лаура авыл медпунктына килгән, аны тотып, келәткә ябып куйганнар иде, мин төнлә келәтне ачып, аны качырдым. Ул миңа әбисеннән калган истәлекле акча бүләк итте, мин ул тәңкәне һаман саклыйм. Кайда икән ул кыз хәзер? Миңа аны күрергә кирәк.

– Ник?

– Сагындым.

– Кем соң син аны сагынырга? – диде хатын кырыс тавыш белән.

– Ник, таныш кешене сагыныр өчен махсус кемдер булырга кирәкмени? – диде Равил.

– Бездә Лаура берәү генә түгел бит?.. – дип, тагын уйга калды алыпсатар хатын.

– Аның ерак әбисе Мирела булган. Аңардан калып, буыннан-буынга күчкән һәм Лаурага килеп җиткән тәңкә бар – ул миндә хәзер.

– Ә-ә-ә, аңладым, – диде хатын. – Мин беләм ул Лаураны.

– Кайда ул? – диде Равил, җанланып.

– Бүген тегендә, иртәгә монда, берсекөнгә тагын тегендә.

– Ул миңа теге вакытта Таганрог якларына китәбез дигән иде. Шундамы ул?

Чегән хатыны, беравык Равилгә текәлеп карап торды да:

– Акчаң бармы? – диде.

– Бар. Егерме ике сум.

Равил шундук, бөтен булган акчасын чыгарып, чегән хатынына сузды:

– Бик күрәсем килә аны.

– Син Казанда яшисеңме? – диде хатын, Равил биргән акчаны курткасының куен кесәсенә тыгып.

– Әйе.

– Мин аңа әйтермен, теләге булса, ул үзе сине эзләп табар.

– Рәхмәт, – диде Равил, куанып, әмма шундук шиген белдерде: – Сез чынлап та шул Лаураны беләсезме икән?..

– Бу дөньяда мин белмәгән Лауралар юк. Акчаң шушы гынамы?

– Бөтен булган акчамны бирдем сезгә.

– Сине ничек табып була?

– Хәзер... язып бирәм.

Равил куртка кесәсеннән блокнот алып, бер битен ертты да гел үзе белән йөртә торган каләмен түш кесәсеннән алды. Кәгазьгә ул үзенең адресын, театрның кабул итү бүлмәсендәге, тулай торактагы телефоннарның номерларын язды.

– Монда минем адресым, театрның, яшәгән урынымның телефон номерлары, – диде Равил, икегә бөкләнгән кәгазьне чегән хатынына биреп.

– Ярар, тапшырырмын, – дип, хатын сумкасын күтәрде.

– Алдамыйсызмы?

– Үз гомеремдә минем беркайчан беркемне алдаганым юк. Исемең ничек?

– Равил. Мин анда яздым. Лаура миңа «Рауль» дип эндәшә иде.

Чегән хатыны, сумка авырлыгыннан бер якка чак кына янтаеп, төркем эчендә юк булды.

Равил әле шактый вакыт уйга чумып торды. Очрашып булыр микән дип дулкынланды ул. Чегән хатыны акча алыр өчен генә юри әйтмәде микән... Бу авыр көннәрдә очратырга иде Лаураны, ичмаса аның кай тарафларда икәнен белергә иде. Кайда икәнен белгәч, очрашуны оештырып була бит аны, дөнья кичеп чыккысыз ук зур түгел бит ул. Бер Җирдә яшибез ләбаса, бер илдә.

**16**

Равил инде театрда бик кирәкле, әйдәп баручы актёрларның берсе иде. Беренче рольләреннән үк популярлашып китте ул, режиссёрлар да, театр белгечләре дә киләчәге зур бу актёрның, диделәр. Тамашачы мәхәббәте Равилне канатландырды, гаилә тотрыксызлыгы, акча җитмәү, тормыш-көнкүреш мәсьәләләре әйтерсең лә бөтенләй юк, алар артка күчте, онытылды. Кайгыга бирешеп, Гөлнараның көен көйләп кенә яшәп булмый, дип уйлады Равил. Нишлисең бит, елгыр, хәйләкәр кешеләр заманы килде. Үземне үзгәртә алмыйм бит инде мин, Гөлнара аңламый мине һәм, сизелеп тора, аңламаячак та, аңларга теләми дә. Менә ничә көн инде ул өйдә юк, аңардан башка иркенрәк, тынычрак, хәтта рәхәтрәк икән ләбаса.

Чегәннәр еш күренә торган урыннарга Равил, мөмкинлек булган саен, баргалады, әмма, кызганыч, Лаура да очрамады, теге акча алган чегән хатыны да бүтән күренмәде.

Беркөнне көн уртасында, театрдан чыгып, ул тагын ЦУМ янына китте. Бүген дә анда чегәннәр төркеме бар иде, гадәттәгечә, чүпрәк-чапрак, вак-

төяк саталар, әмма Лаураны табарга вәгъдә биргән хатын күзгә чалынмады. Читтәрәк ике ир кеше кызып-кызып сөйләшеп торалар, күренеп тора – чегәннәр, берсе төптән юан, базык гәүдәле, күн курткадан, караңгы зәңгәр эшләпәдән, икенчесе озынча буйлы, соры плащтан, киң козырёклы кепкадан иде.

Равил алар янына барып исәнләште, тегеләр исә аның сәламен җавапсыз калдырдылар. Лаура турында кызыксынгач, ирләр чак кына ишетелерлек итеп үзара быр-быр килеп алдылар. Равил Лаура бүләк иткән тәңкә турында әйткәч, болар бу егет хокук саклау органнарыннан түгел микән, дип, шүрләделәр, ахрысы, озын гәүдәлесе:

– Нинди тәңкә? – дип, Равилгә текәлде.

Равил медальне тасвирлап биргәч, чегәннәр беравык бер-берсенә карап тордылар.

– Димәк, синең аны күргәнең бар? – диде базык гәүдәлесе.

– Кемне, Лауранымы?

– Тәңкәне! – дип җикерде озын гәүдәлесе.

Шунда Равил ник әйткәненә үкенә башлады.

– Миңа аның турында сөйләгәннәре бар... – дигән булды ул.

Чегәннәр тагын үзара сөйләшеп алдылар, шуннан соң базык гәүдәлесе кинәт яман усал итеп карады:

– Сиңа нәрсә кирәк? – диде ул, тавышында янау яңгыратып.

– Туктагыз әле, кызмагыз, мин бит сезгә бернинди начарлык эшләмәдем. Мин Лаура исемле кызны эзлим.

– Нигә сиңа рома кызы?! Күздән югал!

Равил болар белән сөйләшүдән мәгънә юклыгын аңлап:

– Гафу итегез, – диде дә тизрәк китеп барды.

Гөлнараның отпускысы тәмамланырга әле тагын бер атна вакыт бар иде. Хатынын аз гына да сагынмады ул. Гөлнара үзе дә, көнче була торып, һаман кайтмады. Ярар, отпускысы тәмамланыр, Казанга кайтыр, алга таба күз күрер, дип кул селтәде Равил. Аерылышу ихтималы аны аз гына да борчымады, барысын да үз агымына җибәрергә булды ул. Бүген ул, чираттагы спектакльдә уйнаганда, залда утырган тамашачылар арасында бик якын кешесен күргән кебек булды. Сәхнәдән кайвакыт аерым бер тамашачыга гел күз төшә, ул башкалардан аерылып торгандай була. Бу юлысы башта аны ниндидер сихри көч сәхнәдә илһамландырып йөртте, аннары бер мәлгә, никтер, сәхнәдән качасы килгәнен дә тойды, отыры залдан аны кемдер үзе янына чакырган кебек тә булды. Спектакль тәмамлангач, гадәттәгечә, артистларны алкышларга, чәчәкләргә күмделәр.

Гримнарны сөртеп, кием алыштырганда, бүген ниндидер көтелмәгән вакыйга булырга тиеш сыман тоелды Равилгә.

Театрдан чыккач, хезмәткәрләр йөри торган ишек янында аңа арттан берәү эндәште:

– Рауль!

Таныш тавыш аны шып туктатты. Равил түгел, Рауль дип эндәштеләр! Болай дип аңа бер генә кешенең эндәшкәне бар.

Борылып карады. Равил аны башта танымый торды, бу вакытта зифа буйлы кыз әкрен генә аңа таба атлады:

– Бу мин – Лаура.

– Лаура?!

Эчке сискәнү гәүдәне кинәт өскә күтәреп, кире җиргә төшереп куйгандай итте.

– Исәнме, Рауль!

Равилнең хәтта башы әйләнеп китте, аяк астында җир тирбәлеп алды.

– Лаура, синме бу?

– Мин.

– Лаура! Син?! Ниһаять... Өнемме бу, төшемме?!

Шуннан соң ул беркавым телсез калып торды. Спектакльдә паузаны уйнап була, бушлыкны тутыру мөмкин. Ә монда, чынбарлыкның бу мәлендә нишләргә?.. Бу бит уен түгел!

– Син спектакльне карадыңмы әллә? – диде Равил, аптыраганнан.

– Әйе, – дип елмайды Лаура.

– Ошадымы?

– Мондый егет уйнаган спектакль ничек ошамасын инде. Әлбәттә, ошады, аеруча син ошадың. Теге вакытта: сине театр училищесына алачаклар, дигән идем, хәтерлисеңдер. Театрга шалтыратып, нинди спектакль була дип сорагач, әйттеләр. Равил уйныймы дип сорагач, кайсысы – яшеме, картымы диделәр. Яше, дидем. Фамилияңне белмим бит. Бардым да билет алдым. Фамилияң ничек синең?

– Шәмсиев. Маладис, Лаура, минем бит сине уйламаган көнем юк. Мин бит тугыз ел инде сине күрәсем килеп яшим.

Күңел менә-менә түгелер сыман мөлдерәмә тулды, хисләр ташып чыкты. Равил каушады, аның башында: нишләргә, Лаураны кая алып барырга дигән уй сулкылдады.

– Мин һаман ышанып җитә алмыйм, – диде ул. – Әйдә әле яктыгарак. Җентекләп карыйм әле үзеңне, Лаура!

Соры плащ, плащыннан да озынрак күлмәк итәге, аягында көзге ботинка, башына матур итеп ураган кара-кызыл чәчәкле шәл – Лаураның киеме үзенә шулкадәр килешеп тора, сагышлы елмаюы исә күзнең тыныч киченә бик тәңгәл иде. Үзгәргән ул, унҗиде яшьтәге кебек түгел, олыгаю сизелә, әмма элеккечә чибәр, җан җылылы булып калган.

– Син Казанда яшисеңме әллә? – дип сорады Равил, кыздан күзләрен алмыйча.

Лаура башын чак кына кыңгыр салып елмайды:

– Беләсең бит инде, без Җир шарында яшибез, – диде ул. – Мин Казанда вакытлыча.

– Озак буласыңмы?

– Белмим әле.

– Кайда торасың?

– Шәһәр читендә.

– Шәһәр читендә... – дип кабатлады Равил, уйга калып.

– Борчылма, җылы урыным бар минем. Авыр булмаса, бераз урамда йөрик әле.

– Мин бик шат! Мин бәхетле! Мин бит һичшиксез очрашасыбызга шундый ышандым!

Алар әкрен генә тротуардан атладылар. Равил торымнан-торымга кызның каршысына чыгып текәлеп карап торды, Лаура моңа җавап итеп моңсу гына елмайды.

– Белсәң иде бу очрашуны ничек көткәнемне! – диде Равил, Лаураны иңеннән кочып.

Беркавым дәшми барганнан соң, Лаура:

– Үзгәргәнсең, – дип куйды. – Син хәзер элекке авыл малае түгел инде. Сәхнәдә дә хуҗа булып йөрисең.

– Сәхнә сәхнә инде ул, – дип, авыр сулап куйды Равил. – Тормышта хуҗа булырга иде.

– Гаиләң бардыр инде, балаларың...

Бу тема Равилнең кинәт кәефен кырды.

– Озак йөрдем инде мин өйләнмичә... – диде ул. – Сине оныта алмагангадыр, мөгаен. Гаилә хәлләре минем катлаулы шул әле. Хатын бала төшерде... Болай да мөнәсәбәтләр киеренке иде, выкидыштан соң тагын да катлауланды.

– Төшенкелеккә бирелмә. Син үз урыныңны тапкансың. Күрәсеңме, сине халык ничек ярата!

– Сиңа рәхмәт. Син бүләк иткән тәңкә мине саклап, яклап килә. Һаман гаҗәпләнеп туймыйм, шундый кадерле, затлы нәрсәне ничек миңа бүләк итәргә булдың?

– Рәхмәт йөзеннән. Мин синең бәхетле булуыңны ихластан теләдем.

– Үзеңнең тормышың ничек соң? Беләсем килә – ничек яшисең?

– Җиңел түгел, – дип авыр сулап куйды Лаура. – Дөньяга туганда, бер кешегә дә тормышың җиңел була дип вәгъдә ителми.

Кайчаннан бирле хыялланып көткән очрашу менә хәзер тормышка ашты, әмма нәрсәдер комачаулый кебек, гүя арада һаман әле вакыт белән ерак чакрымнар бар. Равилнең җаны җилкенә, Лаураны кочагына аласы килә, әмма Лаураның кыяфәте сагышлы, эчке киеренкелеге тышка чыккан иде.

Очрашсалар, Лаура да чиксез бәхетле булыр дип өметләнгән иде Равил. Бәлки, Лаура да бу очрашу котылгысыз булырга тиеш иде дип саныйдыр һәм, шул сәбәпле артык хискә бирелмидер. Бу уй Равилне бераз тынычландырды шикелле.

Равил, туктап, Лаураны кочагына алды:

– Мин теге төнне һич оныта алмыйм. Мин шундый сагындым сине, Лаура.

– Мин дә авыл келәтендә дер-дер калтыранып ятканымны аермачык хәтерлим, – диде Лаура.

Равилгә тагын күңелсез булып китте – Лаурага аның белән бергә чүмәләдә куну түгел, тоткынлыгы ныграк тәэсир ясаган микәнни?..

– Вакыт инде соң, рестораннар бикле... – диде Равил, уйга калып. – Минем өйдә вино бар...

– Синең анда хатының да бар бит, – дип елмайды Лаура.

– Ул Әгерҗегә кайтып китте. Отпускыда. Мин гомер буе сине уйлап, синең язмышыңны беләсем килеп яшәдем. Мин сине шундый сагындым, Лаура! Ә син?

– Күрәсең бит, мин дә сине онытмадым, – дип, моңсу тавыш белән җавап бирде Лаура.

Равил Лауранын җанлырак сөйләшүен теләде, аның турында күбрәк беләсе килде.

– Кайларда яшәдең, кайларда булдың? – диде ул, тавышына үтенү төсмере кертеп.

– Сөйләсәм, сиңа кызык булыр микән соң ул?

– Синең турында миңа бөтен нәрсә кызык булачак.

– Бер кеше дә барыбер дөресен сөйләми үзе турында.

Равил, беркавым дәшми торганнан соң:

– Син бик боек, Лаура... – диде.

Лауранын йөзенә газап төсе йөгерде:

– Минем абыем милициядә, аңа уголовный эш ачарлар, ахрысы, – диде ул.

– Җинаять кылганмыни?

– Милиционерлар белән сугышкан, пычак чыгарган, шуның өчен дә ике-өч ел бирүләре ихтимал икән.

Алар шактый вакыт култыклашып дәшми бардылар.

– Син минем белән буласыңмы бүген? – дип саклык белән генә сорады Равил.

– Сәгать ничә соң?

– Унберенче биш минут, – диде Равил, кул сәгатенә карап. – Әйдә минем белән.

– Кая?

– Минем өйгә... Өй дип... Мин яши торган тулай торакка. Безгә медучилищеның тулай торагыннан бүлмә бирделәр, шунда яшибез.

54 номерлы автобуска утырып, алар Чуйков урамына киттеләр. Автобуста барганда, Равил үзе турында кыскача сөйләде. Лаура, йөзендә моңсу елмаюын саклап, тыңлап утырды.

**17**

Шыгырдавык караватлы, фәкыйрь җиһазлы тулай торак бүлмәсе, әлбәттә, ачык кырдагы печән чүмәләсенә караганда да салкынрак иде.

Равил айлы җәйге төнне, печәннең хуш исен, Лауранын кайнар тәнен, аның сихри сулышын, Чистайдагы очрашуны – барысын да җентекләп, тәфсилләп искә алып сөйләде. Лаура, аның күкрәгенә башын салып, тып-тын гына тыңлап ятты. Равил аның бөдрә чәченә бармакларын батырып, унҗиде яшьтәге халәтне кайтарырга теләде. Нәрсә уйлый икән Лаура, нинди хисләр кичерә икән?..

– Синең ирең бармы? – дип сорарга батырчылык итте ул.

– Ирем булса, мин синең белән монда булыр идемме? – диде Лаура һәм, башын калкытып, терсәгенә таянды. – Чегән хатыннарыннан да тугрырак хатыннар юк.

– Иргә чыгарга теләгең бармы?

– Белмим. Бездә бер ирдә булган хатынга бик өйләнергә теләмиләр. – Лаура авыр сулап куйды. – Мине унөч яшемдә кияүгә бирделәр, ә аңа унбиш яшь иде. Туйдан соң ике ел узгач, суга батып үлде.

Равил телсез калды. Ул, шаккатып, торып утырды, Лаура шәрә тәнен каплар өчен одеялга төренде.

– Минем белән авылда очрашканда, син кияүгә чыккан идеңмени инде? – диде Равил, үз колакларына ышанмыйча.

– Әйе, ул вакытта иремнең батып үлгәненә бер ел узган иде. Синең белән очрашкан вакытта минем өч яшьлек кызым бар иде инде. – Лаура елмайды. – Синең белән чүмәләдә кунганда.

Равилне бу хәбәр бер мәлгә һушсыз калдырды, ләкин шул ук вакытта сөендерде дә шикелле – шундук аның күз алдына курчак кебек матур ике-өч яшьлек кыз килеп басты.

– Кызың хәзер үсеп җиткәндер инде... – диде ул, Лауранын кулын ике учы белән кысып.

Лаура, башын читкә борды, аннары чалкан ятып, газаплы тавыш белән:

– Ун яшендә аны машина таптады, – диде. – Ике ел элек.

Равил бу сүзләрдән тетрәнеп, эчке сискәнү тойды.

– Күпме бәла, күпме кайгы күргәнсең син! – диде ул җан ачысы белән.

– Кайгы минем башыма гына төшмәгән, – диде Лаура, сыктанып.

Алар шактый вакыт тып-тын гына караватта утырдылар.

– Нәрсә белән шөгыльләнүең турында сорау да әллә ничек инде... – дип куйды Равил.

– Мин әбиемнәрнең кәсебен дәвам итүче, күрәзәчелек белән шөгыльләнәм. Тагын бер вазифам бар – мине төрле переговорларга, очрашуларга, килешүләр төзергә йөртәләр, бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә ярдәмче итеп чакыралар.

Әйе, Лауранын кыяфәте дә, киенүе дә заманча һәм үзгә, аның чегән кызы икәнен чегәннәрне яхшы белүче генә аңлый алыр.

Лаура аякларын бөкләп, караватта утырганда, ярдәмгә мохтаҗ кошчыкка охшаган иде. Равил аны җиңел генә иңеннән кочып яткырды.

– Гаилә корырга теләсәң, син чегән кешесенә генә чыгарга тиешме? – диде ул, Лаура белән янәшә ятып.

– Әйе, – дип, күзләрен йомды Лаура.

Равил кызны битеннән, дымлы күзләреннән, иреннәреннән, күкрәкләреннән үпте.

Лаура, елмаеп, Равилгә сыенды:

– Рауль, син шундый әйбәт кеше, – дип пышылдады ул.

– Мин очрашуыбызны, ничектер, башкачарак күз алдыма китергән идем, – диде Равил сүренке тавыш белән.

– Очрашуыбыз үзе әйбәт.

– Мин сине бик сагындым, – дип, инде әллә ничәнче кат кабатлады Равил.

– Хатының бар килешме?

– Әйттем бит инде, мин күптән түгел өйләндем, – диде Равил, ни әйтергә белмәгәч. – Аерылырбыз, ахрысы. Чын гаилә кору хәлебездән килми, тормышны җайга сала алмыйбыз.

Равил кайчаннан бирле Лаурадан: «Мин дә сине сагындым!» дигәнен өметләнеп көтте, әмма Лаура алай дип бер тапкыр да әйтмәде. «Хәер, япь-яшь килеш шулхәтле фаҗигаләр кичергән бу сылудан үземнеке кебек хисләр таләп итеп буламы соң?» – дип уйлап куйды Равил.

– Хатыныңның фотосын күрсәт әле, – диде Лаура, көтмәгәндә.

Равил шәрәтән килеш торып, шкаф тартмасыннан альбом чыгарды,

аннан Гөлнара белән бергә төшкән фотоны алып килеп күрсәтте. Лаура фотоны кулына алмады, гәүдәсен чак кына калкытып карап торды.

– Чибәр, – диде ул, мендәргә башын салып. – Син аны югалтмаска тырыш инде.

Дөресен әйткәндә, Равил Лаураның бераз көнләшүен хәтта теләгән иде.

– Отпускысы тәмамланып килә, тиздән Казанга кайта инде, – дип, ул фотоны урынына илтеп салды. – Анда күз күрер.

Лаура чалкан яткан килеш башын борды да Равилгә текәлеп карады:

– Әмма барыбер аерылачаксыз.

Равил сикереп торып, тартмадан фотоны янә алып килеп, Лаурага бирде:

– Нинди кеше икәнен фотосыннан әйтә аласыңмы?

Лаура шактый вакыт Гөлнараның фотосурәтенә карап ятты.

– Син затлырак кызга өйләнә ала идең. Бик гади кызга өйләнгәнсең. Гади, әмма амбицияләре үзенең эчке мөмкинлекләренә тәңгәл түгел. Иркәләнеп үскән, әти-әнисе блатной урында. Мәктәптә начар укыган, шуңа күрә акылы институтка керерлек түгел. Эмоцияләрен тыя алмый, гаепне кешедән эзли. Чибәрлеге – салкын чибәрлек, юка ирен – усаллыгын күрсәтә. Көнче. Ачу итеп, үзе хыянәт итәргә дә мөмкин. Бернинди яңалык юк – бу сыйфатлар бик күпләргә хас, әмма мондыйлар белән дә гаилә корып яшиләр, түзәләр.

Алар шактый вакыт сөйләшмичә, тулай торак коридорында тыз-быз килеп йөргән студент кызларның тавышларына колак салып яттылар.

– Монда студентлар яшиме әллә? – диде Лаура, коридорда кызларның чырык-чырык көлгәннәрен ишетеп.

– Медучилище студенткалары.

– Сиңа барысы да гашыйк буладыр монда?

– Гашыйк булучылар бардыр. Алар бит минем хатыным бар икәнне беләләр.

– Тамашачының яратуын тою рәхәттер ул, – диде Лаура, елмаеп.

– Рәхәт, – диде Равил. – Чынбарлыкка кайтып, проблемаларга кабат чумуы читен.

– Теге вакытта мондый актёр булырсың дип, һич уйламас идем.

Равил тугыз ел очрашу турында хыялланып йөрүен кат-кат әйтте, кабат-кабат Лаураны кочаклады, үпте, Чистай пристаненда аерылышканнан соң күңел халәте нинди булганны ачынып сөйләде.

Хатирәләр Лаураны канатландырмады, үткәннәргә карата аның битарафлыгы аермачык күренеп торды. Йөзендә, күзләрендә, сөйләшүендә, хәтта хәрәкәтләрендә – салкынлык, илтифатсызлык сизелде. Теге төндәге җылылык кая? Нишләп болай?

– Лаура, минем беләсем килә, бу елларда кайларда булдың, ничек яшәдең, ниләр эшләдең?.. Сөйлә әле.

– Тормышымны, ниләр күргәнемне сөйләсәм, сиңа кызык булмас, мөгаен. Без бит синең белән төрле дөнья кешеләре.

Равил мондый сүзләрне ишетергә теләмәгән иде, сөмсере коелып, ул шактый вакыт дәшми утырды.

– Алга таба ничек яшәргә уйлыйсың? – дип сорады ул, шактый озын паузадан соң. – Нинди планнарың бар?

– Минем планнарым юк. Мин нәселебездә бәләкәй зат, ирләр ни куша, шуны эшлим. Ирләр белән Баро идарә итә, алар шуңа буйсыналар.

– Барон?..

– Барон дип ялгыш әйтәләр. Барон түгел, Баро – баш кеше дигән сүз.

– Аның сүзе чегәннәр өчен законмы?

– Баро баш кеше булса да, барысын да ул хәл итми, мөһим мәсьәләләрне крис хәл итә – ромалэ җыены. Крис карары – хәтта Баро өчен дә закон булып санала.

Равил күңелен тырнап торган сорауны тагын кузгатты:

– Иргә чыгарга уең бардыр бит?..

– Бездә икенче кат чыгу авыр. Чегәннәр кешедән калган хатынга бик өйләнмиләр.

– Син бит шундый чибәр...

Лаура көлемсерәп куйды.

– Шуңа күрә мин дипломатия белән шөгыльләнәм дә инде, разборкаларга, хәбәр илтергә, килешүләр төзергә йөртәләр.

Равил, кыюлыгын җыеп:

– Миңа чыгар идеңме? – дип сорады.

– Юк, – диде Лаура, кулын Равилнең күкрәгенә салып. – Минем чегән кешесенә генә чыгарга хакым бар.

Лаура тагын Равилнең кочагында эреде, аларны җылы агым чынбарлыктан вакытлыча каядыр алып китте. Әмма соңыннан Равилне бер шик-шөбһә җилтерәтеп алды – Лаура аның куенында рәхмәт йөзеннән генә ятадыр шикелле тоелды.

Лаура нык үзгәргән, ул инде элекке кыз түгел. Әмма нишләп соң ул һаман якын, үз кеше, сөеп туймаслык?.. Әйе, нәрсәдер югалган, кире кайтармаслык булып каядыр гаип булган. Тугыз ел шулай үзгәрткәч, күбрәк вакыт узгач, ни булыр?.. Абыйсы өчен шулай нык кайгыра микән? Унөч яшендә чыккан ирен сагына микән? Баласын югалту кайгыга батырганмы? Барысы бергәдер инде, тагын нинди булырга тиеш инде ул – күпне күрергә өлгергән яшь хатын?!

– Син зур югалтулар кичергәнсең, канатларың шуңа салынгандыр... – диде Равил, күңел сүренкелегенең сәбәбен, бәлки, Лаура үзе аңлатыр дип өметләнеп.

– Гомер буе кайгырудан мәгънә юк, – диде Лаура, сыктанып. – Кайгылар кичеп чыккысыз булып тоелса да, барыбер яшәргә кирәк. Гомер алда бит әле. Хәзер мин абыем өчен борчылам, миндә хәзер аның кайгысы. Бер риваять ишеткәнем бар. Имештер, бер хан күрше илне яулап алган, башкаланы җимергән, илне талаган. Шул илнең затлы яубашы һәм аның аркадашлары ханга әсир төшкән. Бер хатын хан янына килгән. «Бөек хан, – дигән хатын. – Син илебезне яулап алдың, иремне, улымны, абыемны әсир иттең. Аларның җанын кыю сиңа нәрсә бирә? Син бит инде болай да җиңдең, азат ит аларны, җибәр». Хан хатынга әйткән: «Алар миңа каршы сугыштылар, бик күп яугирләремне үтерделәр. Син кыю, чибәр хатын, курыкмыйча, минем янга килдең һәм миңа синең кыюлыгың ошый. Шуңа күрә өчесе арасыннан берсен азат итәргә мин әзер. Сайла, кайсысын азат итим, ireңнеме, улыңнымы, абыеңнымы?» Хатын, уйланып торганнан соң: «Алайса абыемны азат ит», – дигән. Хан, гаҗәпкә калып: «Ә нишләп улыңны яки ireңне коткару

турында уйламыйсың, ә абыеңны?» – дип сораган. Хатын әйткән: «Бөек хан! Мин әле яшь, мин тагын иргә чыга алам һәм минем ирем булачак. Мин әле сәламәт, мин тагын бала таба алам һәм минем улым булачак. Ә абыемны үтерсәң, абыем минем бүтән беркайчан булмаячак инде». Хатынның җавабы ханның күңеленә бик хуш килгән, хатынга ул сокланып карап торган да: «Җавабың шундый матур, син мине таң калдырдың, шуңа күрә мин өчесен дә азат итәм!» – дигән.

Равил уйга калды.

– Абыеңның исеме ничек?

– Харман.

– Армиядә бергә хезмәт иткән дустым угрозыскта эшли, мин аның белән сөйләшеп карыйм.

– Дөресен әйткәндә, ярдәм итә алмассыңмы дип килдем дә инде синең яныңа, – диде Лаура. – Актёр булгач, дуслары, поклонниклары, элемтәләре күптер, мәйтәм...

– Тырышырмын, тырышырмын, Лаура.

– Ул кем соң анда?

– Уголовный розыск инспекторы.

– Сөйләшеп кара, зинһар.

– Иртәгә үк сөйләшәм.

Лаура торып утырды:

– Тиздән таң ата башлый, – диде ул, тәрәзәгә карап. – Мин кайтыйм.

– Монда гына йокла. Иртәгә ресторанга барырбыз, күңел ачарбыз.

– Юк, миңа кайтырга кирәк, – дип, Лаура киенә үк башлады. – Йә такси, йә частник тотам.

– Мин сине озатып куям, – диде Равил, чалбарын киеп.

Юл кырыенда шактый вакыт торырга туры килде. Берән-сәрән үткән машиналарның, ниһаять, берсе туктады.

Иске «Жигули»нең йөртүчесе корык-корык ютәлли, машина эченә тәмәке, тир исе сеңгән. Равилнең эче поша башлады – димәк, Лаура яныма мине сагынып түгел, ярдәм эстәп килгән...

Казан читендәге шәхси йортлардан торган бистәгә җиткәч, машина хәйран гына көяз йорт янына җитәрәк туктады.

– Менә, тулай торакның вахтасындагы телефон номеры, – дип, Равил Лаурага алдан әзерләнгән блокнот кәгазен бирде.

– Машинадан чыгып торма, – диде Лаура, ишекне ачып. – Сау бул. Мин шалтыратырмын.

Машина кире борылып маташканда, Лаура тиз генә капкадан кереп китте. Равилнең тәмам кәефе кырылды.

– Чегән кызымы? – дип кызыксынды моңарчы бер сүз дәшмәгән шофёр.

– Әйе, – диде Равил. – Каян белдең?

– Мин бу йортта чегәннәр яшәгәнне беләм. – Шофёр мут елмайды. – Ну, ничек ул?.. Дәртледер...

– Юк, гап-гади, – диде Равил кырыс тавыш белән, пырдымсыз сорауга ачуы килгәнне яшермичә.

Моны аңлап, шофёр бүтән бер сорау да бирмәде.

«Очраштылар. Әмма очрашу мондый булырга тиеш идеме? – дип уйлады

Равил. – Ә ничек булырга тиеш иде соң тагын? Әйе, мин, хыялый уй-хисләр белән йөреп, очрашу зур тантана булыр дип өметләнгән идем. Ярар, иң мөһиме – без очраштык. Хәзер инде элемтә бар».

Әмма элемтә бер яклы, дөресрәге, бер яктан гына бар шикелле тоелды аңа.

**18**

Армиядә бергә хезмәт иткән Буа егете Әнәс, армиядән кайткач, милициягә эшкә керде, Алабугада милиция мәктәбен тәмамлады, хәзер ул лейтенант, уголовный розыск хезмәткәре иде. Равил шундук игътибар итте – түгәрәк чырайлы, хәйләкәр күзле «служак»ка милиция формасы килешеп тора, почык борынлы, тырпайган колаклы икәне дә хәзер күзгә ташланмый иде.

Кыршылып беткән өстәл яныннан кузгалып, Әнәс ихлас шатлык белән дустын кочаклап сәламләде.

– Минем бит әле синең эш урыныңда бер тапкыр да булганым юк иде, – диде Равил, инспекторның шыксыз бүлмәсенә күз йөгертеп.

– Уголовный эш буенча да булганың юк, – дип шаярды Әнәс.

– Алла сакласын.

– Гафу ит, премьерага килә алмадым, бу арада көн-төн эшләдем, югыйсә бик барасым килгән иде. Хатын барыйк инде дип, теңкәгә тиде, үзе генә барасы килмәде. Тегеләрен калдырмаган идем. Ярар, бераз бушагач, барып карарбыз әле. Ничек хәлләр? Театр – театр инде ул. Канәгатьме соң эшеңнән, сайлаган юлыңнан?

– Әлбәттә. Дөрес юл сайладым дип саныйм. Синең ничек? Эш әйбәт барамы?

– Әй, безнең монда үзебезнең драматургия. Төрлечә була. Әнә бит әле, илдә үзгәрешләр башланды – кая барып чыгарбыз, белгән юк. Перестройка игълан иттеләр, шундук җинаятьчелек арта башлады. Күрәселәр алдадыр әле. Ярар, зарлана башласаң, зарланырлык нәрсә күп инде ул. Армия сагындырамы соң?

– Аның нәрсәсен сагынасың инде, – дип, йөзен чытты Равил.

– Күңелле иде бит, – дип, авызын җәеп елмайды Әнәс.

– Мин һич кенә дә сагынмыйм армияне.

– Театрда ни хәлләр бар?

– Театр үзенчә эшләп ята инде ул. Театр читтән караганда гына, сәхнәдәге күренешләрне күзәткәндә генә, матур икән ул. Сәхнәдә ике сәгать ялтырар өчен кулисә артындагы чүплектә казынып ятарга туры килә. Әмма барыбер яратам мин эшемне, спектакльдә уйнаганда, күпмедер вакытка аерым дөнья белән яшәп аласың. Кайвакыт шул сәхнә тормышы бертуктамый дәвам итсен иде, дип уйлыйм. Чынбарлык китаплардагы, фильмнардагы, сәхнәдәге шикелле түгел инде ул, мәхәббәт драмалары да сәхнәдән мавыктыргыч күренә. Ә менә минем белән Гөлнара арасындагы мөнәсәбәтләрне сәхнәдән күрсәтсәң, җанбиздергеч күренеш булачак.

– Төшенкелеккә бирелмә. Выкидыш авыр нәрсә... Икенче яктан караганда, алай-болай аерылышсагыз, алимент мәсьәләсе булмаячак, бала ярымьятим үсә дип тә кайгырасы юк...

– Әнәс, мин сиңа бер йомыш белән килдем бит әле.

– Берәрсен төрмәгә утыртырга кирәкме әллә? – дип, авызын ерды Әнәс.

– Юк. Төрмәне иң яман дошманыңа да теләргә ярамыйдыр.

– Анысы шулай.

– Сездә Харман атлы чегән кешесен япканнар...

– Шуннан? – дип сагайды Әнәс.

– Нәрсә өчен тоткарладылар аны, нәрсә яный аңа?

Әнәс дустына беравык гаҗәпләнеп карап торды:

– Ә син аны каян беләсең?

– Сөйли башласам, озакка китә, – диде Равил.

– Туктале, туктале, ник кызыксындыра ул сине?

– Вакытың тар түгелме?

– Сөйлә, сөйлә, тыңлыйм.

Равил барысын да сөйләде. Әнәс йотлыгып тыңлады, чөнки дустының бәяне бик кызык вә мавыктыргыч булып чыкты.

Лаура турында, аның белән очрашу вакыйгаларын тәфсилләп җиткергәннән соң, Равил өметле күзләрен дустына төбәде. Әнәс беркавым уйга калып утырды да:

– Хәзер инде син шул чегән кызының абыйсы өчен хафаланасың, шулаймы? – диде. – Әй, сәер кеше дә инде үзең, Равил. Башка кайгың юкмыни?

– Аны коткарып булмыймы, азат итәргә берәр җай юкмы? Кеше үтермәгәндер бит инде ул?

– Нигә сиңа чегәннәр белән бәйләнешү?! – диде Әнәс, аптырап.

– Әнәс, без армиядә бик якын дуслар идек. Ярдәм ит, зинһар, – дип ялварды Равил.

– Унҗиде яшьтә гашыйк булган чегән кызының туганы өчен хафаланып йөрүең акылыма сыймый. Хәер, син шулай нык гашыйк була торган кеше шул. Армиядә учебный центрдагы буфетчының кызын күреп шашканыңны хәтерлим.

– Шәп иде бит ул, ә, –  дип елмайды Равил.

– Ул хәтле шәп түгел иде инде, – диде Әнәс, чыраен сытып. – Фигурасы ничава иде, ну төс-бите әллә ни түгел иде.

– Мөмкинме, ул чегәнне коткарырга?

Әнәс үтә җитди кыяфәткә керде:

– Аны Казанга наркотиклар алып килүдә гаеплиләр. С поличным алабыз дип, тоткарларга маташканда, ул каршылык күрсәткән. Наркотиклар үзе белән булмаган, аның каравы кулында пычак булган. Әлегә милиция хезмәткәрләрен кыйнаганы өчен генә эш башланды.

– Әнәс, мин Лаураны тугыз ел очратырга хыялланып йөрдем... Менә, ниһаять, очраштык. Ул бөтенләй боеккан, алай гына да түгел, кайгыга баткан.

– Чүмәләдә бер төн кунган кыз киләчәктә тагын ник кирәк инде ул сиңа? Хатының белән татулаш та тыныч кына яшәп ят.

– Белгән юк әле, алга таба бергә яшәрбезме хатын белән... – дип куйды Равил, авыр сулап.

– Ә мин сиңа әйттем, туган, хәтерлисеңме? Әле йөри башлаган чагыңда ук безгә кунакка алып килгән идең син аны... Мин сиңа әйттем: бу кыз

чибәр чибәрен, әмма дә ләкин бераз кылтый-пылтыйракка охшаган дигән идем. Хәтерлисеңме?

– Хәтерлим. Туганнары, никтер, мине өнәмәделәр. Алар гел файда гына эзләүче исәп-хисапчыл кешеләр булып чыкты.

– Меркантильный кешеләрме?

– Нәкъ шулай. Минем актёрлыгымны алар профессиягә дә санамыйлар.

Әнәс киерелеп утырды:

– Дөресен әйткәндә, артистларны мин үзем дә бездельниклар дип саныйм, – диде ул, чыраен сытып.

– Мине дәме?

Әнәс киң итеп елмайды:

– Юк, туган, син минем служагым. Син никак бездельник була алмыйсың. Әмма кызым үсеп җиткәч, артистка кияүгә чыгам дисә, «только через мой труп», диячәкмен.

– Ярар, Әнәс, шаярып утырыр чамам юк. Булыша аласыңмы?

– Уйлап карарга кирәк. Мин бер кеше белән сөйләшермен. Болай гына булмый инде ул... – Әнәс пышылдауга күчте. – Акча кирәк булачак. Ментлар белән сугышкан, пычак чыгарган кешене коткару җиңел түгел.

– Акча күпме кирәк булачак?

– Тс-с-с, кычкырып сөйләшмә. – Әнәс ишек ягына карап куйды. – Меңнән дә ким түгел, – дип пышылдады ул. – Шул мең тирәсе кирәк булыр дип уйлыйм.

– Мең?! – диде Равил, күз алмаларын киңәйтеп.

Равил әкрен генә урамнан атлаганда, шулкадәр акча кирәклеген Лаурага ничек әйтергә, дип кайгырды. Аның үзендә андый акчаның беркайчан булганы юк.

Лаура кайчан шалтыратыр икән? Бүгенме, иртәгәме, бер атнаданмы? Кайчан? Тагын элемтәгә керерме соң ул аның белән?..

Лаура шул ук кичне шалтыратты. Бер кыз, үтеп барышлый, Равил бүлмәсенең ишеген шакыды:

– Сезне телефонга чакыралар.

Равил баскычтан вахтага атылып төште. Вахтёр телефонының өстәлдә кырын яткан трубкасын алып колагына куйгач, элемтәнең теге очыннан Равил таныш, матур тавыш ишетте:

– Рауль!

– Әйе, Лаура, исәнме? – диде Равил, шатлыктан кычкырып диярлек.

– Син бардыңмы теге кеше янына? – дип кызыксынды Лаура.

– Бардым, сөйләштем.

Элемтә бер мәлгә өзелеп торды.

– Лаура... Алло. Ишетәсеңме?

– Ишетәм. Тыңлыйм.

– Лаура. Акча кирәк булачак.

– Күпме?

– Мең.

– Аңладым. Син бу арада беркая да китмисеңме?

– Юк, кая китим мин?

– Ярар, сау булып тор, – дип, Лаура трубканы куйды.

– Лаура! Алло! Лаура!

Әллә үпкәләде инде? Мең сум акча кирәк дигәч, өметен өзде микән әллә? Равил гаепле түгел бит инде монда. Хәер, шул хәтле акча кирәк дигәч, тагын нинди реакция булырга мөмкин.

Вахтёр хатынның гаҗәпләнеп карап утыруын күреп, Равил сискәнеп китте. Бу апа барысын да ишетеп торды бит, мең сум акча турында әйткәч, нәрсә уйлады икән ул?..

**19**

Көндезге репетиция тәмамланып, Равил гримёркада утырганда, ишек шакып, өлкән яшьтәге актриса Халидә Сабирова килеп керде.

– Равил энем, тышта бер кыз сине чакыра, – диде ул сынаулы караш вә серле тавыш белән. – Бар, чык. Әмма, бигайбә, хатыныңа әйтәм. Җенем сөйми хатыны бар килеш сөеш-мөеш ясап йөргән ирләрне.

– Ярар инде, Халидә апа, нинди кеше соң син! Бәлки, эш белән килгәндер ул, – диде Равил нотык укырга яратучы актрисага.

– Беләм мин нинди эш белән мавыгуыгызны, – дип калды Халидә аның артыннан.

Равил театрда эшли башлаганнан бирле Халидә Сабированы яратмый – һәр тишеккә тыгыла, гайбәт сөйли, яшьләрне бөтенләй урынсызга да ачуланырга, акыл өйрәтергә тотына торган гадәте бар. Үзен дөрес кеше дип саный, ә үзе... гап-гади гайбәтче.

Равил театрдан чыгып, як-ягына карады. Лаура күренмәде. Ниһаять, Равил аны абайлады – юлның икенче ягында көтеп торган икән. Лаура әкрен генә театрның каршы ягындагы йорт артына таба юнәлде, Равил, юлны аркылы чыгып, аңа иярде.

Равилнең кызны кочагына аласы килде, әмма Лаураның кыяфәтеннән хискә бирелергә теләмәгәне күренеп тора иде.

– Акча минем үзем белән, – диде Лаура. – Кемгә бирергә кирәк?

– Мин үзем илтеп бирәм, – диде Равил. Лаура акчаны бирергә ашыкмады.
– Ышанмыйсыңмы әллә миңа? – диде Равил, гаҗәпләнеп.

– Ышанам, – диде Лаура, аның йөзенә туры карап.

Лаура сумкасыннан пакетка төрелгән бер пачка акча бирде:

– Төп-төгәл мең сум. Егерме бишлекләр – кырык штук. Булышам, дидеме? Алдамасмы?

– Булышыр дип өметләнәм, – диде Равил, акчаны куен кесәсенә тыгып.

– Ярый, сау булып тор, – дип Лаура, плащын җилфердәтеп китеп тә барды.

Лаура бүген бөтенләй сулыгып калган, хәтта бер тапкыр да елмаймады. Күренеп тора, тугыз елдан соң очрашу куанычы аңарда бөтенләй юк иде.

Шунда Равилнең йөрәге жу итеп куйды. Акчаны алып, ярдәм итмәсәләр?.. Равил җавап тотмасмы бу акча өчен? Ярар, бу хакта Әнәс белән тагын әйбәтләп сөйләшергә кирәк булыр, дип уйлады ул.

Равил музыка бүлеге мөдире Вахит агай бүлмәсеннән шалтыратырга булды.

– Вахит абый, шалтыратып алыйм әле, – диде ул ишектән кергән уңайга.

Музыкант, ноталы кәгазен өстәл читенә куеп, күзлек өстеннән Равилгә карады:

– Кызларгадыр инде тагын?

– Бу юлысы юк, – диде Равил, көлемсерәп.

– Озак сөйләшмә түлке. Мәдәният министрлыгыннан шалтыратырга тиешләр, кемнеңдер кичәсе өчен оркестрга партитура язарга заказ бирмәкче булалар, ахрысы.

Равил, пианино янындагы тумбочка өстендәге телефон трубкасын колагына куеп, Әнәснең номерын җыйды:

– Алло, Әнәс! Сәлам!

Элемтәнең теге очыннан:

– О-о-о, татар халкының мәшһүр артистына легендар милициянең кечкенә бер хезмәткәреннән ялкынлы кайнар сәлам! – дигән шаярулы аваз яңгырады.

Әмма Равил хәзер шаяруга җавап бирерлек халәттә түгел иде.

– Миңа алып килделәр... – диде ул, Вахит абыйга шөбһәле караш ташлап.

– Бүтән бер сүз дә әйтмә, – дип кырт кисте Әнәс. – Кичке сигездән соң минем өйгә кил.

– Үзем белән алып килергәме?

– Әйе, – дип, Әнәс шундук телефон трубкасын куйды.

Равил кич җиткәнне түземсезлек белән көтте. Аның үзендә бу кадәр байлыкның беркайчан булганы юк, хәтта төшендә дә мондый зур акчаны күргәне юк. Бу кадәр күп акча белән урамда йөрү дә куркыныч бит әле – Казан бит бу. Удмуртлар әйтмешли: «Казань – город шумный».

Ниһаять, кич җитте, бер пачка акчаны куртканың куен кесәсенә тыгып, тыштан күкрәгеннән шул урыннан кулы белән кысып, Равил Әнәсләрнең адресы буенча китте.

Әнәс тә, аның хатыны Зилә дә Равилне, гадәттәгечә, җылы каршы алдылар. Театр сәнгатен ихластан яратучы Зилә ашыга-ашыга чәй әзерләргә җыенган иде, Әнәс аңа:

– Икебезне генә калдыр әле, – диде.

Хатыны:

– Колбасаны үзең тура инде алайса, – дип, кухнядан чыгып китте.

Равил акчаны өстәлгә куйды:

– Төп-төгәл мең сум.

– Үз акчаң түгелдер?.. – дип көлемсерәде Әнәс, Равилнең бу кадәр акчасы юклыгын белгән килеш.

– Каян килсен миңа бу хәтле акча?

– Үзеңнән өстәгәнсеңдер? – дип шаярып, күзләрен чекрәйтте Әнәс.

– Юк, төп-төгәл мең сум китерделәр, – диде Равил, бу минутларда дустының төрттереп сөйләшүенә бераз ачуы килеп. – Акчаны алып килделәр килүен дә, әмма мин уңайсыз хәлдә калмам микән?..

Әнәс аның әйтеп бетергәнен көтмәде:

– Син болай да бигүк уңай хәлдә түгел инде, – диде, гадәттәгечә, тупас ярымшаярып. – Бу акчаны мин кирәкле кешегә тапшырам, анысы өчен борчылма. Ә инде Харманның язмышын хәл итү – минем эш түгел.

...Өч көн вакыт үтте, ә Равил белән элемтәгә керүче әле һаман булмады.

Әнәстән дә хәбәр юк, Лаура да шалтыратмый. Йөрәк урынында түгел. Мең сум акча кая, кемгә киткәндер... Харманны чыгармасалар?.. Акчаны да кереп алып булмаса – бетте баш. Килеп, кая акча, дип, даулый башлаулары ихтимал. Шундый кәнител генә җитмәгән иде монда.

Өченче көннең кичендә ул түзмәде, тагын үзе Әнәсләргә юл тотты, бу юлысы телефоннан да шалтыратып тормады. Әнәс Әмирхан урамында яши, җәяү дә ерак түгел, ул йөгереп диярлек, кызу-кызу атлап, бик тиз барып җитте.

Аның килүенә Әнәс һич кенә дә аптырамады, хатыны Зилә дә һәрвакыттагыча мөлаем йөз белән каршы алды. Хатыны әллә ни чибәр дә түгел, әмма матур кеше, эчке гүзәллек тышка чыга бит ул. Өч яшьлек кызын инде йокларга яткырган булганнар, әмма ул уянып, йокы бүлмәсеннән кухняга чыкты.

– Әни, әкиятне укыйк инде, – дип шыңшыды тач әтисенә охшаган кызчык, яктылыктан күзләрен чекрәйтеп.

– Хәзер, кызым, хәзер, – диде Зилә, суыткычтан өстәлгә ризык куеп.

– Бар, бар, укы әкиятеңне, – диде Әнәс. – Чәйне үзем оештырам.

– Әнәс, гафу ит инде, сине бу арада борчыйм... – дип сүз башлады Равил, кухняда икесе генә калгач.

– Гафу итми кая барыйм инде, – диде Әнәс, чынаяктан чәй йотып. – Ник борчыласың син?

– Йөрәк урынында түгел.

Әнәс беравык җитди кыяфәт белән Равилгә текәлеп карап торды, аннары елмаеп:

– Харманны чыгардылар, – диде. – Гозереңне үтәдем.

– Чынлап чыгардылармы? – диде Равил, җанланып.

– Чыгармаган булсалар, чыгармадылар дияр идем бит инде. Эч чәеңне.

– Аны бөтенләйгә чыгардылармы соң?

– Уголовный эш әлегә туктатылды. Аны иреккә чыгардылар, ә инде алга таба ничек булыр – мин белмим, чөнки миннән тормый.

– Мин инде бик борчылган идем.

– Кеше үзенә гел михнәт, бәла-каза эзли инде ул. Тыныч кына яши башласа, аңа барыбер нинди дә булса бәла кирәк, кеше матавыкларсыз гына тора алмыйдыр инде, күрәсең. Син чегән кызын оныт! Тем более аның абыйсы сиңа ни пычагыма кирәк?! Гөлнараңның кылтый-пылтый килүенә дә төкер. Яраткан эшең бар, сине инде халык ярата, танылырга өлгердең, артың җылыда, хезмәт хакы аласың. Үз көеңә йөр, эшлә, яшә, үзеңә үзең маҗаралар эзләп йөрмә, беркайчан да артың сыймаган тишеккә башыңны тыкма. Эч чәеңне.

Әнәс алдамыйдыр инде, дип уйлады Равил өенә кайтканда, әмма миңа барысын да ачыктан-ачык әйтмәде бугай ул.

Әйе, Харманга җинаять эшен вакытлыча туктаттылар, иреккә чыгардылар. Угрозыскның планнары элек тә шундый иде – чыгарырга һәм аның артыннан тәүлек әйләнәсе күзәтү оештырырга. Моны Әнәс, әлбәттә, Равилдән яшерде.

## 20

Лаурага ярдәм итә алуына Равил башта бик сөенде, әмма шундук авыр уйлар башында чыңлый башлады. Туктале, алар мең сум акча түләгәч, минем тарафтан ярдәм дип атарга буламы соң моны? Менә бит әле Лаура

шалтыратмый, аңардан әлегә бер хәбәр дә юк. Мең сум түләшле булгач, Равилдән башка да коткарып була иде дип уйлыйдыр ул да, бәлки...

Лаура шалтыратмагач, Равилнең эче поша башлады. Тугыз ел элек булган очрашуның дәвамы бер дә күңелле түгел шул әле, ул бит хыялларында бер-берсен табуны бөтенләй башкача күзаллаган иде.

Бер көн үтте, ике көн...

Равил түзмәде, машина тотып, чегәннәр яшәгән тарафка китте.

Машинаны читтәрәк туктатып, ул теге көнне Лаура кереп киткән йортка таба сак адымнар белән атлады. Йорт каршындагы «Волга» машинасының арткы утыргычындагы берәү, ишек пыяласын төшереп, урта яшьләрдәге ир кеше белән сөйләшеп тора иде. «Волга» кинәт кузгалды да, тузан туздырып, китеп барды.

Машина артыннан ачулы кыяфәттә карап калган ир кеше, күренеп тора – чегән иде. Үтеп барышлый машинадагылар Равилгә текәлеп карап киттеләр. Алар белән сөйләшеп торган ир өйгә керергә ашыкмады, Равилне абайлап, шактый вакыт карап торды. Равил каушады һәм, теге өйгә кереп киткәнче, янәшәдәге төзелеп бетмәгән йорт белән кызыксынучыга сабышып, шул тирәдә әрле-бирле атлады. Ниһаять, чегән кереп китте. Күп тә үтмәде, Равил нишләргә икән дип уйланып торганда, капкадан, вилсәпит җитәкләп, ун-унбер яшьлек малай чыкты.

– Син шушы йортта яшисеңме? – дип сорады Равил.

– Әйе, – диде малай.

– Лаура өйдәме?

– Өйдә.

Равил аңа егерме тиен акча бирде:

– Лаураны чакыр әле.

Малай, акчаны чалбар кесәсенә тыгып, сәпитен коймага сөяде дә тиз генә өйгә кереп китте. Күп тә үмәде, малай, чыгып, сәпитенә атланды һәм Равил яныннан үткәндә:

– Хәзер чыга, – диде.

Капка ачылды, әмма аннан Лаура түгел, тагын теге ир кеше чыкты да шактый вакыт урыныннан кузгалмыйча, Равилне күзәтеп торды. Ниһаять, Лаура пәйда булды. Өстенә фуфайка гына салган, аягында резин итек, яулык урынына башына кулдан бәйләнгән башлык кигән. Аның бөтен вөҗүденнән шөбһәләнү аңкып тора иде. Лаура нәрсәдер әйткәч, теге ир, Равил ягына ачу катыш сынаулы караш ташлады да капкадан теләр-теләмәс кенә кереп китте.

Лаура Равилгә таба сүлпән адымнар белән килде.

– Исәнме, Лаура, – диде Равил, елмаерга тырышып.

– Исәнме.

– Бу кем?

– Харман абыем.

– Менә бит, чыгардылар абыеңны, – диде Равил, шатланып. – Аны азат иткәннәрен ник хәбәр итмәдең?

– Җай булмады.

– Нишләп син болай боек?

– Куркам мин, – диде Лаура, йорттан читкәрәк китеп. – Соңгы вакытта бик нык куркам.

– Нәрсәдән, кемнән? – дип, янәшә атлады Равил.

– Сиңа нигә инде ул? Ник төпченәсең... – диде Лаура, сыктанып.

– Сер итеп кенә әйтәм – абыеңны тыелган товар белән тотмакчы булганнар, – дип пышылдады Равил.

Лаура, туктап, Равилгә текәлде:

– Товар илтүчеләрне озатып баручы гына булган ул. Моңарчы андый эшләр белән беркайчан шөгыльләнмәде, андый юлга ялгыш басты. Аның бурычлары күп, шуңа гына бәйләнгән ул алар белән. – Лаура, тирән сулыш алып, Равилгә карады. – Соңгы вакытта бик куркам.

– Әйт инде, кемнән куркасың соң син?

– Бөтен нәрсәдән, барысыннан куркам – абыем чуалган кешеләрдән, безне моннан кысрыкларга тырышучы мафиядән, милициядән, тагын әллә кемнәрдән...

Равил, Лauraны кулыннан тотып:

– Әйдә минем белән, – диде.

– Кая? – дип көлемсерәде Лаура.

– Кая булса да. Мин яратам сине, Лаура.

– Мин монда, гаиләбез белән булырга тиеш. Облава булыр, ахрысы, күңелем сизә.

– Синең гаебең юктыр бит?

– Бу дөньяга туган кеше алдан ук гаепле инде ул. Хатының кайттымы?

– Юк әле. Әйдә, берәр җиргә барыйк, ресторангамы, театргамы...

– Бер җиргә дә күңел тартмый, бу арада йокым да туймый.

– Минем сине гел күрәсем килә.

– Күрешкәләп торабыз бит, – диде Лаура илтифатсыз тавыш белән. Ул кинәт матур итеп елмайды. – Син шундый затлы егет... Казанга күчкәч, бөтенләй күренеклегә әйләнгәнсең. Нигә сиңа рома кызы?

– Мин яратам сине! – диде Равил, Лаураның салкынайган кулына өреп.

Лаура көлеп җибәрде:

– Нинди ярату?! Тугыз ел очрашканыбыз булмады.

– Ә мин тугыз ел буе, кайда булсам да, нәрсә эшләсәм дә, очрашырбыз дип хыялланып, өметләнеп йөрдем.

– Мин сиңа инде әйттем: без синең белән төрле дөнья кешеләре.

– Юк, без бер үк дөньяда яшибез! – диде Равил, кинәт ачынып. – Дөнья бер үк!

Кинәт капка ямьсез шыгырдап ачылды һәм йорт алдында Харман пәйда булды.

– Лаура! – дип эндәште ул гөрселдек тавыш белән.


Лаура хәтта сискәнеп куйды.

– Ярый, Рауль, мин сиңа шалтыратырмын, – диде ул, абыйсы янына ашыгып.

Нишләп болай соң?! Лаураны очратырга күпме хыялланып йөрде бит ул һәм менә күрешү насыйп булды. Лаурада аңа карата җылы хисләр бөтенләй юк микәнни?.. Әллә үзе, гомумән, салкынайганмы... Тормышлары чамадан тыш катлаулымы?..

Кемнең тормышы җиңел соң бу дөньяда?!

*(Ахыры киләсе санда.)*



Ренат
Харис

# ҮЛМӘДЕК, ТОРЫП БАСТЫК...

## Сирәк кеше...

Ул Айны да, йөгән салып,
Җир тирәли үзе йөртә.
Кояшка да, сүрәнләнсә,
шырпы сызып, ялкын төртә.
Һәр йөрәккә йолдызларның
өмет булырдаен кертә;
яраланган Җир шарының
канын шигырь белән сөртә!

Ул диңгез белән сөйләшә
яңгыр тамчысы телендә,
елганы кан тамырына
ялгап куя күңелендә;
усак яфрагыдай сизгер
тибрәнә керфек җиленнән;
Адәм капкан алма булып,
алмагачларга эленә!

Ул яңадан яшел урман
итә учактагы көлне;
кирәгендә – кылыч була,
кирәгендә – ап-ак сөлге;
сөюеннән үлә ала,
мәхәббәттә яши белми;
өндәү билгесенә сыя,
җиһанга сыясы килми –

һәм шагыйрьгә әйләнә...

---

Ренат ХАРИС (1941) – *Татарстанның халык шагыйре; Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты; җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Уйлар тудыра алганда

Уйлар тудыра алганда,
мин әле монда кирәк!
Акылым әле йөрәктә,
йөрәгем әле зирәк.
Кемгәдер минем уйларым
үзенекедәй булсын –
җылы сер, бәлзәмле тылсым
булып җанына тулсын,
Ходай биргән, дип уйласын,
белмәсен дә мин барын...
Шулай булганда яшәргә,
язарга әле ярый...

## Канат чыгар алдыннан

Өч аяклап килеп җиттем
егерме дүртенчесенә...
Аякларыма, йөк булып,
сиксән һәм ике ел сеңгән.
Ә йөрәгемдә кимрәктер
күтәргән елларым саны –
сөйгән-сөелгәнен генә
гомер еллары дип таныйм.
Атлый алам әле тоеп
табан астындагы юлны...
Каурый каләм тотарга да
азат бит әле бер кулым.
Дүрт аяклы чакларыма
кайтасы килми кабаттан...
Калак сөякләр кычыта –
чыгачак, ахры, канатлар...

## Игелек бизе

Никтер, активлашып китте
минем игелек бизем –
яхшылык эшлисе килде
эшемне үзем сизеп,
рәхәтләнеп, тәмен табып,
ләззәтләнеп, шатланып...
Һәм үтәдем теләгемне –
мин үземне мактадым!..

* * *

*Кемдер Гоголь шинеленнән чыккан,*
*кайберләребез – Тукай бишмәтеннән...*

Мин Кандалый хөлләсенә
эләккәнмен ничектер...
Бәлки, әтиемнең китап
шкафларын кичептер?!
Анда күрдем Тукай эзен,
Җәлил, Кәрим эзен дә...
Аларның табындашлары
итеп тойдым үземне.
Алар табыныннан җыйдым
җаныма сихәтлесен.
Алда да кирәк булыр дип
алдым бернихәтлесен...
Кайдан чыгуга килгәндә –
хәзер инде сер тотмам –
Дәрдемәнд иңнәрендәге
затлы эчле сюртуктан!..

* * *

Казан урамнарын акбур белән
сызып-бозып, буран пыр туза.
Бакыр бабай бакчасында тыныч!
Каян монда сәер могҗиза?
Аллаһ белән әңгәмәдәш бабай
сүзен тапкан, ахры, Аңарга...
Һәм мин әзер бакыр Державинны
пәйгамбәрем итеп санарга.
Бакча уртасында кар бөртеген
телем белән аулап торамын...
Тынычландым бераз... Җан буранын
басты бугай Галәм бураны...

* * *

Дәрдемәнднең кабере юк...
Уфтанудан ни файда –
Сократның йә Әфләтунның,
Чыңгызханныкы кайда?!.
Кабер ташы булмаса да,
һәйкәле бар кайсының –
мәрмәре, җизе, бакыры
яки гранит-таш сыны!

Кабер ташларыннан кыйммәт
күңелдә баскан ташлар!..
Уфтану – мескеннәр эше,
горурлана бел башта...
Йөрәкләрдән йөрәкләргә
күчә торган горурлык
иң биек һәйкәлләрдән дә
биегәеп торырлык!

* * *

*Яздан аерып булмый Тукайны...*
Равил Фәйзуллин

Шәрәфләрдән[1] аерылгысыз Тукай –
беренче һәм соңгы китабы
шул Шәрәфләр басмаханәсендә
якты дөнья күргән бит аның!

Шигырьчене китап Шагыйрь итә!..
Китаплары әгәр чыкмаса,
Тукай чичән, ашуг, акын булып
калган булыр иде ләбаса...

Тукай аерылгысыз Шәрәфләрдән –
язмыш төенләгән бу төен
татар кешесенең муенына
дога итеп аскан бөтие!

* * *

Хәзер дә шулай бу... Шулай
булгандыр ул элек тә –
уңышлы әйтелгән Ялган
әйләнгән Дөреслеккә.

Без шуңарга ышанганбыз...
Һәм бүген дә яклыйбыз.
Акыл чикле, йөрәк сукыр
икәнлеген хаклыйбыз.

## Сәер төш

Күзләремә сүзләр тулган,
колакларым – сүз тутырук...
Сүзне тетеп болыт иттем,
очтым болытка утырып...
Аста үзәннәр, урманнар,
шәһәрләр, юллар, диңгезләр...
Очып барам Җир шарының
иң матур урынын эзләп.
Шунда төшеп, кыңгыр ятып,
җәннәт багыдай урында
илаһи бер зур мәдхия
языйм диеп Җир турында...

Һәм кинәт әллә ни булды –
болытны ракета тиште –
канаты сынган бөркеттәй
каты Җиргә егылып төштем...
Колагым балчык тутырук,
ком, тузан тутырук күзем,
борында ташкүмер исе,
авызда – сүгенү сүзе...
Сүгенүдән нинди файда?!.
Сүзләремне дога иттем,
һәм, кулыма корал алып,
аяныч, уянып киттем...

[1] Татар халкына галимнәр, мәгърифәтчеләр, наширләр биргән мәшһүр нәсел.

## Иделгә янәшә

*(Кемгәдер җавап)*

Иделгә янәшә, ләкин
каршы аккан Зөядә
гомерлеккә сабак алдым
мин җилкәнле көймәдән:
көймә каршы йөзә ала
җил җаен күрсә генә,
агымнан көчлерәк җилләр
җилкәнгә өрсә генә!

Көймәм җилкәне давылның
тугыз баллына түзем...
Мин диңгеземә юл ярам,
сазлыкка таба йөзмим...
Сасы сазда рух тончыга,
анда миңа ни хаҗәт?!
Бака туен яратмыймын,
китлар миңа дәрәҗә!

## Бездән тарих көлмәсен!

Татар халкы Феникс түгел,
Иисус Христос та...
Әкияттә батыр мең үлеп,
мең терелергә оста.
Йә, кем белә бер үлеп һәм
терелгән бер милләтне?!.
Үлеп терелүдән бигрәк
үлми яшәү кыйммәтле!

Мәеттән берни дә тумый,
тередән туа тере...
Теге дөньядан бусына
берни чыгалмый кире!
Йә, кайсыбыз туды икән
мәет ана-атадан?!.
Ходай безне үзе саклый
андый көлке хатадан...

Безне аударгалаганнар...
Үлмәдек, торып бастык...
Торып басуны хөрмәтли
хәтта ки түшәк, ястык!
«Мең үлдек,
мең тереллек», – дип,
юкка ышану – хәтәр.
«Без – бар, булган,
булачак!» – дип,
яшәргә тырыш, Татар!

Акылың ерактан күрсен
тозакны, тайгак бозны –
Чуд күлендәге[2] хәлләргә
төшермик үзебезне.
Күптәнмени, һаваланып,
батыраерга баздык –
тимер чылбырлы көпчәкләр
астында кала яздык..

Акыл тавышын ишеттек
хисләр давылы аша...
Без болай да туйган инде
үкенеч ашы ашап...
Үкенечтә яшәү авыр...
Алдагысын белмәссең...
Безне Тарих кызганмасын,
бездән Тарих көлмәсен!

***

Шатлыктан аккан күз яше
җаныбызны чистарта –
шатлык яше аккан саен
яшәүнең яме арта:
яман сүз керми колакка,
шакшы эш керми күзгә!
Күбрәк шатлыктан еларга
насыйп ит, Ходай, безгә, –
дибез!

Кайгыдан аккан күз яше
тагы да сихәтлерәк –
йөрәккә кергән суыкны
ул агызып бетерә.
Тормыш салулап ала да
яңадан төшә эзгә!
Кайгы белән дәвалауны
азрак бир, Ходай, безгә, –
дибез!

[2] 1242 елда кенәз Александр Невский, швед рыцарьларын Чуд күле бозына алдап кертеп, батырып үтерә.

Елау барыбер елау ул –
тозлы күз яше бизе...
Җан канатының каурыен
агызып китә өзеп,
күзләрдән агылган ташкын,
сиздерми генә безгә...
Шатлык күз яшен баллы ит –
Ходаем, җаен эзлә, –
димибез...

## Без барында

Без киткәчтен нәрсә булыр?!
Без бар чакта ул ямьле,
океан-диңгезләр – тозлы,
чишмә сулары – тәмле!

Без барында язлардан соң
һәрвакыт килә җәйләр,
көзнең алтын ятагына
кыш яба ап-ак җәймә.

Без барында ут яндыра,
сулар утны сүндерә,
комнан хәтта Кырыкалдар
ишә алмый киндерә.

Без барында һава төссез,
ә бөтен нәрсә төсле.
Без барында бар тереклек
ике генә җенесле.

Без барында ир-атлар – ир,
хатын-кызлар – хатын-кыз!
Яралгыны кеше иткән
айларның саны тугыз.

Без барында баш уйлады,
ә кул, аяк эшләде –
үзән тауларга менмәде,
тау үзәнгә төшмәде.

Без барында дүрт як иде
дөньяның иңе-буе,
тагы: ас-өс, каты-йомшак
һәм сыек белән куе.


Без барында мәхәббәтнең
оясы йөрәк иде.
Мәхәббәттә янган йөрәк
акылга кирәк иде!

Без барында шулай иде!..
Ни булыр без киткәчтен –
без Җирне үбеп яшәдәк,
безне дә Җир үпкәчтен...

* * *

Тәвәккәлләр батырлыгы
һәм батырларның көче
җитмәс татар инкыйразын
тәмам туктатыр өчен...
Фәкать акыл гакыйльлеге[3],
үҗәт, сабыр тырышлык
үлмәс итәр Россиядә
татар халкы тормышын...

[3] Гакыйльлек – зирәклек.



Илдус
Диндаров

# АК ТӨННӘРНЕҢ КАРА КӨННӘРЕ

ПОВЕСТЬ*

## 1. Шобага салмый гына

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан Кызыл Таң авылы кешеләре күңелендә гомерлеккә уелып калган шаккатмалы вакыйга булды. Авылдан дүрт-биш чакрымдагы Карамалы разъездына куе пар бөркеп, чыжлый-чыжлый, мал-мөлкәт ташый торган егермеләп кызгылт вагон сөйрәгән паровоз килеп туктады. Ул тирә-якны яңгыратып, кемнәрнедер кисәткәндәй гайрәт чәчеп, ачы тавыш белән сузып-сузып кычкыртты. Эшелонның бер вагоны кызылтаңнарга дип билгеләнгән иде.

* * *

Гафур, болдырда кармак җебенә каз канатыннан калкавыч рәтләп, хәйран матавыкланган мәлдә, әтисе Рамазан абзый кайтып керде. Җил капканы кәефле чагында гына бөтен киңлегенә каерып ачып керә ул. Аяк астында, ишек төбендә үк җәелеп утырган улына да әйбер әйтмәде. Аның шөгылен, беренче тапкыр күргәндәй, игътибар белән күзәтеп торды әле. Шул тирәдә тавык-чебешләргә җим сипкәләп мәш килгән хатыны Өммегөлсемгә нигәдер күз кыскалап, хәйләкәр елмаеп:

– Хи, улым! Ташла син бу иске-москыны! Кармакның мәскәүскиен генә алып бирермен үзеңә. Безнең күлдәге шыртлака да булдымы инде балык?! Озакламый керкә дигән асылын кына каптырып утырырсың рәхәтләнеп, – диде. Бераз икеләнебрәк торгач:

– ...Яңа җирдә, – дип тә өстәде. Аннары «яңа җир» дигәнен шул минутта

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган беренче әдәби бәйгедә «Үсмерләр өчен повесть» номинациясендә икенче урынга лаек булган әсәр.

Илдус ДИНДАРОВ (1949) – *язучы, журналист; «Гомер фасыллары», «Күңел яктысы», «Җәй кайда кышлый?» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Нурлатта яши.*

ук күрергә ымсынган төсле, беравык кичке шәфәкъ ягына карап торды. Үзе, яраткан гадәте буенча, чиста итеп кырынган ияген сыйпап, бармак очлары белән чеметкәләгән итте. Рәешкә генә кия торган соры кәчтүм кесәсеннән кулъяулык чыгарып, тирләгән башын-битен, калку борын тирәсен сөрткәләде. Бик тә тәҗел йомышы исенә төшепме, ымлап кына хатынын иялтеп, өйгә узды. Бераздан аларның мыдыр-мыдыр сөйләшүләре ачык тәрәзә аша өтек-төтек кенә колагына чалынды Гафурның.

Әнисе, еламсырап, үзенекен әйткәли, әмма әтисенең сабыр үгет-нәсыйхәт аралаш кырыс тавышы һәммәсен дә басып китә. Менә җитез хәрәкәтле әнисе ишегалдына караган тәрәзә буенарак килде булса кирәк, өстәлдәге савыт-сабаны әвеш-тәвеш кузгаткалап:

– Соң, бакчи, атасы, сөт-майдан, кара икмәктән өзелгәнебез юк бит хәзер... Анысына да ирештек, Аллага шөкер. Сиңа ни җитмәгән тагын? Ул чит-ят җирдә солтан булганчы, үз җиреңдә олтан булуың яхшырак, – дип, йомшарган борынын мышкылдатканы аермачык ишетелде. Ул инде соңгы вакытта ике арада барган бәхәстә ничек кенә тартышса да, ирен ниятеннән кире кайтара алмаячагын белә торып, җае чыккан саен гаҗизлектән, аптыраудан гына шулай каршы төшеп сөйләнә иде бугай. Кешегә ипле, йомшак телле, яшәү җаен яхшы белә торган, зиһенле ул үзе Гафурның әнисе. Аның ягымлы сүзләре җаныңа үтеп керә торган була. Зур якты күзләре белән гел елмаеп торган кебек. Тикмәгә генәмени, авыл хатыннары ул-бу чыга калса, киңәш-табыш итәргә аның янына килеп җитәләр.

Шулай да быел унөч яшен тутырып, бераз акны карадан аера башлаган малай күңеле белән әтисе яклы иде хәзерендә. Аны да кояш баешындагы тараф ничектер үзенә тартып, ашкындырып тора иде. Әйтерсең лә анда, офык артларында, кайдадыр дөнья читендә әкияти, тылсым белән өретелгән искиткеч матур, бай, ямьле ил көтеп тора. Әле бая гына Рамазан абзый әйтеп ташлаган кызыктыргыч вәгъдә сүзләре дә малайның омтылышын көчәйтеп, зәңгәр хыялын хуплагандай итте. Теге могҗизалы керкә балыгы нинди була икән соң ул? Аны каптыру өчен кармакның да әллә ниндие... чыны... корычы кирәктер... Каты тимерчыбыктан үзең әмәлләгән ише генә түгел инде... Аларның тубык тиңентен генә, сай инештә шыртлака белән еланбалыктан гайре бүтәне үрчеми шул. Ә тегендәге елгалар да диңгез хәтле диңгезнең үзенә үк барып кушыладыр. Аннан океанга... Ул анда пароходлар, кораблар, җилкәнле көймәләр!..

Үсмер чакта шулай инде ул. Башта ашкынулы күңел әти-әни канаты астыннан урамга, дус-иш янына каера; аннан соң салам түбәле ызбадан, фәкыйрь авылдан күз күрмәгән, шаулы, ямьле, бай чит-ят җирләргә китәсе килә башлый. Шулай итеп, туган нигезгә, ата-баба йортына тамырлану, җирсү хисенең бөреләнергә дә өлгермичә шиңүе, бетүе ихтимал. Хәер, әле бу яшьтә туган туфрак дигән мөкатдәс төшенчә, хис-тойгы сизелер-сизелмәс, зәгыйфь кенә булучан. Бәлки, бөтенләй бөреләнеп тә өлгермидер...

Чит җирләр турында татлы уй-хыялларга чумган Гафурның шуларны гамәлгә ашыру өчен иң алдан җан атып йөрүче әтисен эченнән генә яклавы табигый иде. Ни генә димә, авыл советында баш нәчәлник ул. Бу юлысы ерак сәфәргә чыгу уңаеннан соңгы мөһим яңалык-хәбәр ишетеп, шактый дәртләнеп кайтканга охшый. Ир белән хатын арасында ай буена нәкъ шул

хакта барган пышылдашу-юрашуларга соңгы нокта куела, димәк. Әнә, бер капчык сохари киптерүләренә дә бишбылтыр. Тикмәгә генә түгел, тәгаен озын юлга хәстәрләнү билгесе!

Малайның гамьле уйларын бүлеп, чолан ишеге ачылды һәм бераз сипкеллерәк аксыл, түгәрәк, мөлаем йөзенә күңелсезләнү, нык хафалану кыяфәте чыккан әнисе, алҗулы-басынкы тавыш белән бусага аркылы гына йомыш кушты:

– Бар, улым, Хәким абыеңны дәшеп кайт. Әти әйтте, диген.

Авылның аргы башында яши торган укытучы булып эшләүче җизнәсенең өенә тиклем барганчы, шактый вакыт узды. Юк, Гафурның эленке-салынкы йөрүеннән, йә булмаса ялкаулыгыннан түгел. Соң, урамга чыккач, төрле кызык-мызык, ахирәт дус-иш очрамый калмый бит инде, шулар тоткарлый, шулар юлга төшә. Аеруча җан дусты Сөббух ... Сумаладай чем-кара, кылдай каты калын чәчле, яшькелт күзле, сабыррак табигатьле Гафурның нәкъ киресе инде ул... Әнә, юри көтеп торган диярсең, уң як тыкрыктан аның өлгереп җиткән зур кыяр рәвешендәге озынча башы да күренде. Шуның өчен Кыярбаш дигән кушамат тактылар да инде аңа малайлар. Сап-сары чәчен кыркыткач, бу охшашлык әллә кайдан чәчрәп тора. Кыярбаш гел каядыр ашыга, тыкшынмый калган эше юк. Такыр баш түбәсе авылның әле бу очында, әле тегесендә ялтырып ала.

– Ниме, Гафур, малай?!. Теге, ниме, э-э-э, ак финнар ягына кайчан нитәсез... э-э-э... китәсез инде? ... – дип, холкына тач туры китереп, ашыга-кабалана такылдарга тотынган гына иде, сүзенең инәсен-җебен югалтып, буталып бетте. Һәр вакыттагыча алны-артны абайламыйча, әллә ниләр сөйләп ташлавы харап итә шул аны. – Киткәндә, миңа кармагыңны калдырып кит әле, яме!.. Мин әле Миннегаян җиңгиләргә барам... Аларда... теге... ни... әй ... исеме ничек соң әле... Аннан соң... бит ул...

Гафур дустының тиздән әллә кайларга, ушыңны алырлык мавыктыргыч, маҗаралы җирләргә китүеннән үлеп көнләшә, шуңа кызыга Сөббух. Эх, ул да куана-куана, җырлый-җырлый барыр иде дә... Юк шул! Биләмче Гайни әби әйтмешли, заманасына күрә, «бүресе улап торган» әтисе Сәлмән абзый ул тарафка ике аягының берсен дә атларга җыенмый. Завхоз булып эшләгән чорда колхоз малын, каз мамыгын йолкыгандай, берәмтекләп кенә үз куышына ташыган хәйләкәр агай бит ул. Инде менә аның телдәр улы, Гафурдан көнләшеп, гарьлегеннән үчегеп, «ак финнар» дип, өендә ишеткәнне тутый кош кебек кабатлый. Хәер, тасма телен шөпшә чаккыры, бу малай актыгы гына бер хәл, кемнәрдер ул күченүләр турындагы хәбәрне тагы да кабартып, күпертеп, төрле гайбәт, имеш-мимеш таратып өлгергән.

– Беренчедән, ак финнар ягына түгел, – дип, сүзләрен җизнәсе Хәким Сәлимовичныкына охшатып, салмак кына, йөзенә мөмкин кадәр зыялы төс салып, вәкарь белән җавап кайтарды Гафур. – Икенчедән, Финляндиягә дә түгел...

Ә кая икәнен анык кына әйтеп бетермәде Гафур, килгән юлыннан Сөббух-кыбырсыктан да җитезрәк чатыр чабып китте. Беренчедән, әллә ниткән Карел муентыгы дигәне генә колагына чалынганы бар, икенчедән, үзе дә ул карел затының кем, ни булуыннан юньле-башлы хәбәрдар түгел.

Хәким абыйларына барып керсә, монда да, әлеге дә баягы, «кесәлле

ярлар арасында сөт чишмәләре ага торган мәмләкәт» турында сөйләшеп туйганнар гына иде, ахры. Апасы Фираяның күзләре яшьле, елаудан иреннәр йомшап мимылдаган; җизнәсе, җенләнеп, ишекле-түрле йөренә... Каенесе йомышын әйткәч, ул зур бәладән котылгандай, җиңел сулап, чакырулы җиргә таю ягын карады.

Шул арада Рамазан абзыйларның ишегалдына чакырылган берничә кеше килеп тә өлгергән иде инде. Иң азактан йөгерә-атлый Кәпик Садыйк абзый белән Искәндәр карт килеп җитте. Барысы да нидәндер шикләнгән кебек, аллы-яллы каранып, тавышларын кыса төшеп гәп кора. Юк, болар бер дә гөрләп торган, күңелле аш мәҗлесенә дип килмәгәннәр. Рамазан абзый чыгып, кунакларны өйгә дәшүгә, кыстатып та тормадылар. «Ни сөйләшерләр икән?» дип түземсезләнүеннән шартлый язган малай да мич артына кереп шылды. Ул карел җире шулай да ни-нәмәрсә икән, ә? Кар баскан берәр котып иле түгелдер бит?! Әлсәм, кояш иңгән төштә нинди кар иле булсын, ди инде? Ул тарафка төшеп баеган эссе кояш кызуы бөтен кар-бозын эретеп бетерер иде, тиле!

Чәй эчәргә утырышкан агай-эне чәшкеләреннән берәр йотым уртлап алуга, Рамазан абзый, тамак кыргалап, сүз башлады:

– Җәмәгать, бүген ни өчен районга барганымны беләсездер инде. Әйе... Анда наканис соңгы решение принимать иттек... эһем... әйе... Тагын акурат бер атнадан юлга чыгасы... Һәм дә...

Мәҗлес башлануга, сабыры төкәнгән, кызгылт-җирән чәч-кашлары төсле үк бурлат битле Сәфәргали абзый, колхоз җыелышында утырмавын онытыпмы, уң кулын күтәргән көе хуҗаны бүлдерде:

– Туктале, син, Рамазан, табадагы бәрәңге түгел, алай бик кыздырма! Карел да карел дип, гел карылдап торудан узган юк соңгы арада.... Тәки башыма сыйдырып бетерәлмим әле мин: преселиние дигәннәренең условияләре ничегрәк соң аның? Безнең ише халыкны төпкә утыртмаслармы соңыннан?

Аның күршесендә өстәлгә таянып, йокымсыраган Гайфи дерт итеп калкынып куйды да кашын-күзен җимереп:

– Соң, вербовщиклар йорт саен тукып йөрделәр бит, Сәфәргали! Кай җирең белән тыңладың соң син? – диде. Аның сүзен Куян Самигы эләктереп алды:

– Һе, ул вербовщикларны тыңласаң, җәннәтнең үзенә ияртеп керәләр, дип белерсең...

Боларның һәрбер сүзен яулык почмагын авыз читендә тотып, тынын да алмый тыңлаган әнисенең артына яшеренгән малай Рамазан абзыйның ни дип җавап бирүен яхшырак ишетү өчен мич алдын бүлмәдән бүлеп торган чаршау янына ук елышты.

– Соң, җәмәгать, алтын таулары вәгъдә итүчеләр юк монда. Килешү буенча биргәне дә шөкер итәрлек. Вербовщиклар әйткәнчә, баруга, безнең тарафтан коры рәхмәт өчен генә бушлай һәйбәт йорт, шуңа өстәп сыер, сарык бирсәләр – начармыни?! Юлга чыкканда, кулыңа шактый гына тере акча да тоттыргач... Хи, сөйләп торасыз тагын! Ә җирләре безнеке ише генә түгел, вдовль, гупчим уңдырышлы, диләр бит анда! Шулай булгач, һич нигә карамый юлга кузгалырга әзер торыйк! – дип түгәрәкләде нотыгын Рамазан абзый ышанычлы, нык тавыш белән. Әмма бүтәннәрнең чыгарып селкисе сүзләре бетмәгән икән әле.

– Сәфәргалинеке дә дөрес... Әйе... Тора салып туган нигезеңне ташлап, җәһәннәм читенә китүләре ансат, дисезме әллә?! Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер инде ул ансы... Әгәренки уйлап карасаң... Әнә, урман астындагы Яңа Корган авылын гына алыйк! Әйе, әйе... әби-патша заманасында Иске Корганнан күченеп килгән авыл. Бирегә, яңа җиргә берничә гаиләне күчерергә дигәч, риза булмыйча, иң әүвәл шобага да тотканнар, жирәбә дә салганнар болар. Берсенең дә үзе теләп, тамырланган җирдән кендеген шартлатып өзеп күчәсе килмәгән! Чыгып төшкән ярлы-ябагай гына ризалашкан. Баераклар исә сыерын, бозавын биреп, кызыктырып, үз урынына бүтәннәрне яллап котылганнар. Менә шулай, әйе... кайдадыр урманга бай, суга мул ил бар дип, байлыкка кызыгып, туган җирен ташлап, кемнең генә китәсе килсен?! Налуг недоимкалары белән муеннан борып алмаган булсалар, әйләнеп тә карамас идем шул Финләндия якларына, – дип ачынып сөйләде козерёгы икегә ярык фуражка кигән Нурулла абзый.

Җәмәгать, кайсы якка кушылырга аптырагандай, бермәлгә тынып калды, мич арасындагы тишек-мишеккә яшеренгән тараканнарның шабырдаганы да ишетелгән кебек булды хәтта... Һәрберсе, «мескен бүреге белән киңәшләшкән» кебек башын аска салган. Эшләр комга терәлерлек хәлгә җитте бугай. Шунда Рамазан абзыйның кодасы Борыч Лотфи торды да күпне күргән киез эшләпәсен гайрәт белән аяк астына орды:

– Мать якасына! Кая барсаң да, кара сакалың үзең белән. Себердә дә бер кояш, Сембердә дә бер кояш, дигән борынгылар. Бер килешкәнбез икән барырга дип – барырга кирәк! Аннан килеп, аяк-кулларыбызны бәйләп салмаганнар бит. Еллар тыныч кына була күрсен, бераз түл җыеп, мал туплап, рәтләнгәч кайтырбыз. Бер-ике елданмы анда, иртәрәкме, карарбыз тагын, – диде.

Шуннан соң ничектер ир-атның шик-шөбһәсе үтәли җилдә тәмәке төтенедәй кинәт кенә эреп таралгандай булды, өсләреннән авыр тау-таш төшкән төсле, җиңеләеп калдылар. Үзара шаяртып сөйләшү-көлешү китте. Сәфәргали абзый гына һаман тынычланмаган иде әле. Тикмәгә генә кушаматы Тукран түгел бит аның. Томшыгы белән бер-ике тапкыр чукыгач, тирә-юньне озаклап шикләнеп тыңлаучы кошны хәтерләткән өчен инде. Җирән картның этисенә каршы төшеп, шул рәвешле өзми-куймый лыгырдавына ачудан куллары йодрыкланды хәтта урынлы-урынсыз тәэсирләнүчән Гафурның. Хәзер дә әнә күңелле әңгәмә шау-шуын кәҗәнекедәй калтыравык тавышы белән күмәргә, үзенекен бирмәскә маташты «Тукран – тукылдатып утырам»:

– Ниндидер бит әле ул сезнең мактаулы Карелия-марелия җирләре?! Бездәге сыман дала да даладыр әле... Елга-сулары ничек икән соң анда? – диде.

Рамазан абзый авызын ачканчы, Торна Сәлиме үзенекен кыстырырга өлгерде:

– Бакчи, бер ай элек кенә каениш Айдар хат язган иде: «Теге кышкы сугыштан соң финнар җиңелеп качып киткән җирләрдә тоташ күл-су», дип. Печәннәре дә котырып үсә икән. Туфрагы ипигә ягып ашарлык булгач...

Моңа каршы сүз катучы табылмады. Хуҗа кешегә «Итәк-чабуларны

җыештыра торыгыз, әле тагын сөйләшербез», дип, шуның белән бу хактагы әңгәмәне очларга гына калды.

Карел-фин җиренә күчеп китәргә үзләре теләк белдергән «бәхетле» халык, җанланып сөйләшә-сөйләшә, урамга чыгып китте. Өстәл яныннан Гафурның Хәким җизнәсе генә торып китәргә ашыкмады. Гөнҗәлә кебек күпереп торган кара чәчләренә кулларын батырып, уйга бирелебрәк утыруын белде. Әлбәттә, Гафур да поскан җиреннән чыгып, өстәл янына кунаклады. Чөнки ашыйсы килү теләге бөтен оялу-тартынуны аста калдырды. Рамазан абзыйның Гафурны күргәннән соң гына тагын нидер исенә төште бугай. Кулы белән ияген кармаштыргалап, бимазалаган уен әйтеп салды:

– Кияү, син дә кузгалырга булдыңмыни тәки? Яшь бала белән кыенга туры килер бит сезгә. Юл газабы – гүр газабы инде ул, – диде. Өммегөлсем апа да нәкъ шул сәбәп аркасында нык борчылуын яшермичә, аны җөпләп:

– Ие, ие, шулай шул, чистый! – диде дә, киявенең ни әйтәсен көтеп, аңардан күзен алмыйча, эше бетмәгәндәй, өстәл катында кайнашты. Кызлары Фирая күптән түгел генә икенчегә бәбәйләгән иде. Шуннан килә иде әби белән бабайның тирән борчылып уфтанулары.

– Соң, бабай, үзегез беләсез бит, өстәгеләр һич тынгы бирми, гел бәйләнәләр дә бәйләнәләр бит. Былтыр районга чакыртып сыкымны алдылар. Милләтче-фәлән дип, гел теңкәмә тиеп торалар. Хет шулардан котылырмын, колагым тынар ичмасам. Анда бергә-бергә яшәве дә начар булмас, – дип, нык итеп, ирләрчә өзеп әйтте кияү. Шуннан соң өлкәннәр аның белән килешмичә булдыра алмадылар.

– Ярый, Аллага тапшырдык, дигәндәй! Безнең силсәвиткә сигез гаиләне вербовать итү йөкләмәсе бирелгән иде. Әле тагын берсен үгетлисе була. Сез дә төшеп калсагыз, һаман алты семья гына списокта ярылып ята, өстән төшерелгән план үтәлми калачак, димәк ки. Аның өчен баштан сыйпамаслар, – диде Рамазан абзый, пошына биреп. Аннары, тискәре уйлардан арынгандай башын селкеп, киң итеп елмайды да, көтмәгәндә дивардагы календарьның «1940 елның 26 мае» дигән битен ертып:

– Менә тагын бер көнне сыер ялады! Шулай итеп, төп-төгәл бер атнадан, ягъни мәсәлән, акурат икенче июньдә сәфәргә кузгалабыз! – дип шаярта төшеп, рәсми төстә игълан итте.

## 2.«Утырып вагон читенә»

Кешегә баш чүмечен, арт тагарагын кашырга да җай калдырмый торган мең төрле борчу-мәшәкать, ыбыр-чыбыр эшләр, туктаусыз ыгы-зыгы, баш әйләнмәле хәстәрлек-әзерлек күрү белән тулы бер атна сиздермичә дә узып китте. 1939-1940 елларда Финляндия белән кыска вакытлы кышкы сугыштан соң, трофей-ганимәт сыйфатында СССР биләмәсенә кертелгән Карел муентыгындагы буш җирләрне үзләштерү, халык белән тутыру өчен Кызыл Таң авылына да райком ирештергән ирекле күчеп китүчеләр заданиесе үтәлде. Дөрес, аны сигез гаиләгә тутыру максатыннан, һичкем агитламаса да, үзе теләп, яман эшерелеп йөргән хөрәсән ялкавы Халикъны да хатыны белән исемлеккә кертергә мәҗбүр булдылар. Боларның

нәрсә, үзләре дә күзләре, дигәндәй, алып барасы мал-мөлкәт тә чуртмурт салынган фанер чумаданнан һәм иске толыптан гына гыйбарәт. Бүтәннәрнең исә әрҗә-әрҗә төрле әйбер-мазар, сандык тулы кием-салым, «Зингер» тегү машинасы, сепаратор кебек җиһаз, көрәк-сәнәк ише көндәлек хезмәт коралы. Вак-төяк кирәк-яракның сыңар таягы да кадерле, тансык шул. Бердәнбер гармун Гайфи абзыйның Галиулла исемле улыныкы иде. Кайсылары, ызбаларын сатып китсәләр дә, рөхсәт ителгәч, сыер-сарыгына кадәр үзләреннән калдырмадылар.

Сәфәргә ачы таңнан торып кузгалдылар. Биш чакрымдагы Карамалы разъездында тукталган «переселенецлар» эшелонына кадәр терлек-туарны куып, әйберләре белән арбаларга төялеп барганчы, малларны махсус вагоннарга кертеп япканчы, ялыгудан шыңшый-елый башлаган эрелеваклы бала-чаганы юата-юата үгетләп, орышып, тиргәп, кайчакта арт якларына бәргәләп, вагоннарга кереп урнашканчы кояш күк йөзенең нәкъ түбәсенә менеп утырды. Эшелон тирәсендә ул халык, ул ыгы-зыгы, ул чыр-чу! Үзе бер тамаша инде! Тирә-юньдәге барча авыл купканмыни да, озата килгәннәрмени! Кызыл таңнардан тыш, юмратлылар, карачишмәләр, кәчеләр, каенлылар... Боларның шул рәвешле кабыл-кобыл мәшәләнүен моңа кадәр элегрәк зур стансада ук вагоннарда үз урыннарын алып өлгергән бүтән район переселенецлары кызыксынып тамаша кыла... Күпләрнең күңелен билгесез ерак сәфәргә кузгалучы һәм аларны озатучы кешеләрдә генә була торган сагыш, моңсулык, аерылышу газабы биләп алган иде.

Артык йөккә санап, рәте беткән кармагын Кыярбашка биреп калдырган Гафурның үз кайгысы кайгы. Иртән аяк астында чуалган күндәм эте Акмаңгай, үч иткән төсле, кирәгендә күз уңыннан суга чумгандай юкка чыкты. Малай әбисенең хөрмә төшләрен тезеп ясалган дисбесен хәтерләткән галәмәт озын эшелонны башыннан азагына чаклы тасыр-тосыр чабып әйләнде, агач-куак асларын караштыргалады. Сөббух-Кыярбаш вокзал эчен дә тикшереп чыкты. Юк кына бит, эзе дә шәйләнми шайтан токымының!

Менә, «Кузгалабыз! По местам!» дип, корт чаккандай каушап, өтәләнеп, вербовщик йөгереп узды, түрә-кара, нәчәлниклар ары-бире йөгереште, тыз-быз килде.

Менә җыелган халыкның гөжләвен бүлеп, хәйран каты сискәндереп, сузып-сузып, паровоз кычкыртты, ә Акмаңгай күренми дә күренми. Гафур, үзен-үзе белештермичә, калын, куе посадкалар артында калган туган авылы ягына карап, «Акмаңгай! Маһ-маһ-маһ» дип, этне төрлечә чакыру авазларын әйтеп, елый-елый сөрән салды.

Менә берзаман поезд дисбесе буйлап гөлдерәгән тавыш дулкыны йөгереп узды; паровоз, тәгәрмәчләрен бер урында кызу-кызу әйләндереп алды да пошкыра-пошкыра кузгалып китте! Мал-товар ташый торган вагонның авыр, киң ишегеннән малайның чандыр, коштай җиңел гәүдәсен тартып алырлык кискен җил бәреп керде. Әтисе малайны җәтрәк үзенең артына алды. Паровоз гудок бирә-бирә, торбасыннан ургылган дегет төсле куе кара төтенен ат ялыдай уңлы-суллы җилпи-җилпи хут алып, тизлеген ишәйткәннән-ишәйтә бара. Тәгәрмәчләр, рельслар ялганган урыннарда сикергәләп, такы-тыкы итеп чакрымнарны санарга кереште. Шулчак әтисенең артыннан башын сузып, күзен каплаган яшь пәрдәсе аша шәйләп

алды малай: куаклар арасыннан кара йомгактай нидер тәгәрәп чыкты да җан-фәрман эшелон артыннан калмаска тырышып, чәңгелдәп-чинап өрә-өрә чаба башлады. Бу бит Акмаңгай! Гафур бер талпыну белән ишек катына килде, үзе дә сизмәстән, үрсәләнеп, сикергәләп «Акмаңга-а-й!» – дип акырды. Поезд тизлеген арттыра, бичара маэмай исә аның саен арып-алҗып калыша барды. Бераздан эшелон текә борылышка кисәк кереп киткәч, ул да, озатып калучылар да тәмам күздән югалдылар...

Кеше-кара алдында бәрәңге кәлҗемәседәй мәлҗерәп төшүдән ничек кенә тыелмасын, булдыра алмады малай, вагон буйлап ике якта сугылган сәндерәләрнең берсенә үрмәләде дә, мендәргә капланып, тавышсыз гына елады. Унөч яшьлек малай имчәк баласыдай балавыз сыгып ятсын инде, җә! «И, бала, бала», дип көрсенеп, аның тын гына үксүдән тартышкан гәүдәсен сыйпап юатты әнисе. Әллә маэмайны кызганып, әллә туган авылны ташлап китүдән йөрәкләре әрнеп, янәшәдәге хатын-кызлар да күзләрен сөрткәләп, лыш-лыш борын тарткалап утырдылар... Пошмас ир-ат халкы исә ачык ишек янында махра пыскытырга тотынды. Алар тиздән барып җитәсе җирләрне күзаллап, төрле гамьгә, уй-нияткә бирешкән иде.

Ә менә Гафур өчен бер дә хәерле-юньле башланмады әле бу сәфәр-сәяхәт. Алданиләр көтәдер бит? Акмаңгай кебек тугры, карусыз җан дусты табылырмы анда? Ә малайлар ниндирәк булыр икән? Тагын әллә ниткән уйлар, бер-берсе өстенә өелеп буталды, бөтерелде дә, башы тубал кебек булды малайның. Күңелен авыр юшкындай юксыну-сагыш басты... Әмма яңа җирләрдә керкә төсле гаҗәеп серле балыклар каптырасы зәңгәр күлләрне, киң елгаларны күз алдына китерде дә ул поезд барган көйгә, ишек уемы аша бер-бер артлы йөгерешеп калган манзараларны тамаша кылып, тынычлана төште... Соңгы тапкыр тирән сулыш алып сулкылдап куйды: хи, нигә юк-барга кайгырып торырга соң әле! Акмаңгайны Сөббух дусты да карап, асрап торала бит. Тиздән, бик тиздән Гафур кунакка кайтканчы гына! Шушындый уйлар дулкынында Гафур тәмам йокымсырады. Могҗизалы, серле керкә балыклары керде аның төшенә...

Уянып киткәч, Гафур вагон эченә дә җентекләп, тәфсилле күз төшерде. Як-якта өч катлы агач сәндерәләр. Ишек катындарак аш-су пешерү, чәй кайнату өчен тимердән эшләнгән, бик белдеклеләр ни өчендер «буржуйка» дип атый торган мич кәмәше. Әнә, тынгысыз хатыннар күпсанлы азык-төлек төенчекләрен чишеп, чәй кую, ризык хәстәрләү чарасына керештеләр дә инде. Мич өстендә эреле-ваклы чәйнекләр тезелде. Әби-апаларның кайсылары самавырын алырга да онытмаган. Үзләре белән эләктергән кара күмерен салгач, күңелле генә көйли-җырлый да башлады бәләкәй паровозлар. Иртә таңнан авызга локма да капмаган килеш әрле-бирле чаба торгач, кинәттән һәммәсенең ачykканнары исләренә төште.

Вагондагылар карыннарын туйдыргач, кайсы кая таралышып, черем иткән, үз мәшәкате белән әвәрә килгән бер вакытта җаен туры китереп, әтисенә әле генә күңелендә калкып чыккан соравын җиткерде Гафур:

– Әти, әти, безнең Ислам абый очрамас микән анда? – диде. 1917 елдагы революциягә кадәр үк Финляндиягә күченеп киткән туган абыйсы турында әти-әнисенең пышылдап кына сөйләшкәннәре бер колагына кереп калган иде аның...

Полевой сумкасындагы кәгазьләрен актарып, караштырып утырган Рамазан абзый башта аның сүзләренә әллә ни игътибар бирмәстән:

– Белмим шул, улым. Ул бит... ни... – диде. Аннары гына, бөтенләй айнып киткәндәй, уңлы-суллы каранып: – Каян исеңә төште соң әле ул? Кара аны, бүтән лыгырдап йөрмә, исеме белән авыз чайкап, – диде дә, шул кагыйдәне малайның башына ныграк кертергә теләгәндәй, тегенең маңгаена шәп кенә чиртеп алды. Малай шуннан шым булды. И-и, ничек хәтереннән чыккан, этисенең ул абыйсы хәзерендә капиталистлар илендә яши ләса. Моны озата баручы түрә-кара белеп алса, әллә кая өтермәнгә олактырырлар үзеңне!

...Тәгәрмәчле ызбаларга охшаган вагоннарда эчпошыргыч тормыш дәвам итә барды. Июнь кояшы кыздырган көннәрдә ифрат бөркү, тынчу; һава тын кысылырлык авыр. Вагон ишеген бар киңлегенә ачып куйганда, аның янында бераз җиләс тә бит, әмма өлкәннәр, агач йомычкасыдай очып кына калырсыз дип, бала-чаганы ул тирәгә якын да китермиләр. Ишек уемына аркылы беркетелгән борыска таянып, тәмәке төтәтеп, кәеф-сафа чигә үзләре! Ул төшкә кәефе килгәндә, тальян гармунын тотып, Галиулла да килеп утыргалый. Каратут йөзле, туры борынлы, коңгырт күзле боек егетнең сөйгәне авылда калган, әле дә һаман шул аерылышу хәсрәтен кичерә алмый җәфалана иде. Аның «Утырдым вагон читенә» җырының сүзләрен, хәзерге кызганыч, төшенке халәтенә туры китереп, үз җаена авыштырып, «Утырдым вагон читенә, киттем туган илемнән...» дип, берникадәр үзгәртеп җырлавы беркемнең дә күңелен юатмый, ә бәлки йөрәкне ачы сагышка батырып, каты пошаманга сала гына башлады... Җан әрнеткеч шул авыр көй, йөрәккә төшә торган бала елавы сыман, олы-караның тәмам теңкәсенә тиеп бетте бугай. Гафур, киресенчә, ирексездән ул ялгыз гармун тавышына тартыла, моңнары күңел түренә үтеп керә дә рәхәт дулкыннарда тибрәтә кебек иде. Гармунда уйнаучыларга да үзен белә башлаганнан бирле мөкиббән шул малай.

Әле дә хәтерендә, дүрт-биш яшьлек сабый чагында, әнисенең итәгенә ябышып, Хәйбул абзыйларның чишмә тибеп яткан коесына суга баргач, үзеннән өлкәнрәк Һадиның ишегалдында гармун тартып утыруына ничекләр тетрәнгән, кызыккан иде ул. Их, чәчәкле күрегеннән күн исе бөркелеп торган, матур итеп бизәлгән, укалы-чукалы шул тартманың ялтыравык шома телләренә, ичмасам, чәнти бармак белән генә булса да баскалап карарга!

«Әнием, сорап тор әле шул гармунны үзебезгә!» – дип, күпме ялынган-ялварган иде ул шунда. Карун Хәйбулларны ризалата алмагандыр инде... Алай да булмагач, «Миңа да Һадиныкы төслене сатып алыгыз!» – дип, елап куркытып та карады. Бу хәйлә дә үтмәде... Фәкыйрьлектән андый асыл малга акча арттыра алмады эти-әнисе. Кайдан килеп мал җыелсын, ди?! Рамазан абзый гомер буе Сафа байда батраклыкта гомер кичергән. Йөзе белән җир сөрсә дә, һич кенә дә бөтәя, мантый алмаган. Яңа тормыш башлангач кына, бераз хәл кергән үзләренә. Аяклары буразнадан чыкмаган ярлы кристиән дип, ярым-йорты белеме белән авыл советына куйганнар үзен, әле ярый. Авызлары кара икмәккә тиенгәч кенә, инде менә җәһәннәм сәфәре... Ә гармун, көмеш телле тальян гармун буй җитмәс балачак хыялы булып кына калды Гафурның...

Баксаң, Хәйбул абзый һич кенә дә авыз-борынын җыештыра белмәгән маңка Һади өчен сатып алмаган икән ул кыйбатлы гармунны. Моны авылда мәзәк итеп сөйләп тә йөрделәр...

Кичкырын, көтүдән кайткан мал-туарны җылы күз карашы белән барлап үткәргәндә, Челемче Гайсә, ата казың күкәй саламы, кодагый, дигәндәй, сорап куйган Хәйбулдан:

– Карале, күрше, теге, бер күзенә ак төшкән бә-ә-к симез сарыгың күренми... Саттыгыз мәллә, диюем...

Тегесе ачы көлемсерәп, киная белән:

– Кая китсен, ди ул?! Ишетмисеңмени, әнә ич акырып та бакырып утыра, – дип, башы белән генә өй ягына ишарәли. Әңгәмәдәше сагаеп колак салса, дөрестән дә, ул яктан әллә ниткән бәэлдәгән, мекердәгән, бакылдаган, такылдаган авазлар «тотып» алгандай була. Хәйбул ага, күршесенең әле һаман аңышып бетермәвенә эче пошып, кул селтәп, тагы да кәефсезләнеп әйтеп ташлый:

– Соң, безнең быел армиягә китәсе малайга, Һавилга соң... шул һәйбәт сарыгымны суеп, гармун сатып алган булган идем лә... Ай була инде, тәки уйнарга өйрәнә алмыйча, шуны тартып, акыртып утырудан башы чыкмый, пешмәгәннең!.. Күпме акча тыктым... Бер сарык бәясенә төшереп бит.

Дөрестән дә, өлкән улы Һавилдан да, Һадидан да, кыскасы, гаиләдәге һичкемнән дә гармунчы чыкмады. Сәләт булмаса, теләк кенә җитми, күрәсең.

...Кызганыч, хәзер вагон эчендә дә музыка аһәңнәре тора-бара сирәгрәк ишетелеп, бөтенләй тынып калды. Галиулла-гармунчы, мәхәббәт сагышына тәмам йомылып, гармунына кул селтәп, ул шөгыленнән дә гарык булды, ахры. Гафур аны еш кына сәндерәдә дөньясына битараф карашын түшәмгә текәп яткан хәлдә күргәли иде. Үз эченә бикләнгән кеше янына күңел һич кенә дә тартмый иде. Үзенең бик тә мөһим гозерен аңа җиткерә алмый калды шул Гафур.

Галиулла абыйсыннан йоктымы, соңгы арада Гафурны да шулайрак күңел тынычсызлыгы биләп алды бит әле. Юктан гына пошына, көяләнә. Күптән түгел генә монда танышкан, күрше Кәче авылы малае, искиткеч җете күзле, үткер, елдам холыклы яшьти Шәриф белән әллә кайчангы дуслар кебек пыр тузып качышлы уйнау да, шашка белән домино сугу да туйдырды аны. Азакта зерә дә җайлы урынны иң югарыдагы сәндерәдә тапты ике дус. Монда аулак. Бу биеклеккә олы-кара менәргә атлыгып тормый. Артык очынып, тузан куптарып сугыша, көрәшә башлагач кына, муеннарын югарыга сузып, кисәтү-янау белән чикләнәләр. Куллары кыска чөнки. Авыл баласы барыбер тотнаклы, тәүфыйклы, тәртип бозып, азынып, ата-анасын бик тинтерәтми. Шулай да үз почмакларын чаршау белән бүлеп өлгергән хуҗабикәләрнең әле монда, әле тегендә тыңлаусыз «тәмуг кисәүләрен», биеклектән төшкәч, чышын-пышын үгетләүләре, әрләүләре ишетелгәли иде. Артыгын һич узындырмыйлар. Гафур ак канатлы фәрештә түгел, ул да кимен куймый, аңа да шул ук чара, шишара эләгә.

Кичкә таба вагон ишеге тарсылдап ябылгач, ярым караңгыда аеруча ямансу. Көн узып, йокларга вакыт җитүен искәртә иде шул ишекнең шыксыз шырылдавы. Көндезләрен ничек күңелсез, моңсу булса, караңгыда, ялгыз лампаның зәгыйфь яктысында бөтенләй ямь калмый. Ул ут шәүләсе шом

булып, пәри күзе булып күренә иде... Сөйләшәсе сүзләр сөйләшенеп беткән, әйтәсе сүзләр түкәнгән... Юлчы сәфәрнең беренче яртысында туган ягында бәхилләшеп калган кардәшләре, дус-ишләре турында моңаеп, уйланып барса, икенчесендә исә тәкъдиренә язган барасы җирләр хакындагы гамьлеваемлы уйларга дучар... Алар исә гел күңелне җилкетеп, дәрт кенә өстәп тормый... Билгесезлек халәте һәрчакта да шик-шөбһә уята, куркыта, эчтән кимереп, бөтен җаныңны суырып тора. Әмма мондый рухи басынкылык, күңел төшенкелеге, җан сүлпәнлеге һич кемгә зыян-зәвер салмады. Эшелонда бер генә авыру да, чирле дә табылмады, шөкер. Тәм-томны чама белми суырганга, эч китүдән зарланган берничә баланы санамаганда, билгеле. Андыйларны карау яхшы, күзәтү уяу. Санитар хезмәткәрләр, табиблар вагоннар буйлап хәл-әхвәл белешеп йөреп кенә тора. Ә менә күңел бушлыгыннан, рухи төшенкелектән җанны дәвалый белми шул алар...

Олы-кара бер хәл. Алар үз шөгылен барыбер таба. Малайларның, кызчыкларның, эшсезлектән ирегеп, нишләргә белмичә, арлы-бирле бәрелеп, сугылып йөрүләре Хәким абыйларының күптән эчен пошырып, тынгысызлап торган икән. Укытучы кеше, тәҗрибәле педагог шул, өлкәннәр белән киңәш-табыш итеп, балаларның барысын да бер почмакка җыйнады да:

– Ягез әле, вакытны әрәмгә үткәргәнче, кайбер дәрес темаларын искә төшереп алыйк. Башта танышабыз! – дип, исемнәрен сорашып, куен дәфтәренә теркәде. Чын мәгънәсендә дәрес түгел иде әле бу, төрле фәннәр буенча кызыклы әңгәмә генә иде. Укытучы барасы җирләр, Карел муентыгы турында сөйләде. Географиягә кагылгач, андагы шәһәр-калаларны да искә төшереп, укучыларның белем ягын тарткалап карады. Кайсыдыр шул төбәктә быел булып узган «кышкы» сугышны телгә алган иде дә, «Ул хакта башка вакытта сөйләшербез», – дип, җәһәт кенә дикъкатьне бүтәнгә юнәлтте. Аннары математикадан җиңелчә генә бер мисал эшләтте. Мәктәптә үткән программаны хәтерләү дәресләре шул рәвешле барды.

Әлбәттә, кояшлы, эссе көннәрдә тыгыз, бөркү вагонда китап-дәфтәргә чекерәеп утыру да балалар өчен бик читенгә туры килә иде. Гәрчә эшелон каядыр сәгатьләр буе туктап торган арада да ачык ишектән борчак булып шабыр-шобыр коелырга юл бирми өлкәннәр. Берәр кайда тупыйктагы тәүлеклек тукталышларда гына вагон шыр бушап кала. Гаиләләр, тимер юл читендә аерым-аерым учак тергезеп, аш пешереп кинәнә. Җиңел кулдан гына каткан, керләнгән кием-салымны, имчәк баласы искеләрен юыпсыгып алалар. Чирәмлектә табын корган арада сатарга ашамлык-мазар, тозлы кыяр-помидор, бәйләгән оекбаш, свитер-фәлән күтәреп, җирле халык килеп җитә. Эшелон тирәсе чегән таборына әверелә бер мәлне. Станса кешеләренең, алыш-биреш белән мәшәләнгәндә, ник гаҗәпләнеп: «Сез ничек туган җирегезне ташлап китә аласыз?» – дип, җанны кыйнавын гына ошатмый иде Гафур. Ул чакларда әниләренең ничек итеп төсе-кыяфәте үзгәреп, йөзләре караңгылануын, боегып калуларын күрмәскә маңгаенда ботак тишегемени аның?!

Ул шуңа Шәриф белән вокзал тирәсендә әйләнеп-тулганып йөрүне кулайрак саный. Анда станса малайлары белән пәке, рогатка, сыбызгы, ватык будильник ише вак-төяк әйбер алмашырга да мөмкин. Әмма ләкин

уен белән мавыгып, эшелонны күз уңыннан ычкындырмыйлар. Юкса, паровозның теләсә кайсы мизгелдә кисәтми-нитми кузгалып китүе бар.

Рәт-рәт булып, корыч рельслар өстендә тынып калган, аркандай сузылган эшелоннар арасына балаларны төшереп йөртү дә куркыныч иде. Поезд койрыгындагы махсус вагоннарга урнаштырылган мал-туарны ашаткан-сугарган сурәттә дә аларга йомыш кушылмый. Поезд тупыйкта озакка сеңеп, терлек-туар вагоннары ишеген шудырып ачуга, аннан сыер мөгрәгән, сарык мәэлдәгән, каз-тавык каңгылдаган-кыткылдаган яңгыравык тавышлар тирә-юньгә тарала. Гафур Миләш атлы (чөнки бакча артындагы миләш агачы төбенә чыгып бозаулаган иде) аклы-каралы сыерларына азык салып төшәргә талпына талпынуын. Әтисе: «Анда олы-кара гына йөрергә тиеш», – дип, шундук каш җыерып, арты белән борыла. Ата-аналар үзләре дә мал-туарны күрергә тансыклаган. Иренмичә, мәш килеп, кәефләнеп, сыерларын савып-нитеп, сарыгын-мазарын, кош-кортын ашатып, асларын тазартып өлгерәләр иде.

Ә көч-дәрт ташып торган кыбырсык, чая малай-шалайга, алар яшендәге кыз-кыркынга ни кала? Ишек аркылы анда-санда күренгәләгән табигать күренешләрен тамаша итү белән канәгатьләнергә дә, ул да булмаса, кызыгын-мызыгын стена ярыклары аша гына күзләп бару белән чикләнергә! Монысы паровозның кайбер җирләрдә хәле беткәндәй, туктар-туктамас килеш, ташбака адымы белән үрмәләгәндә генә мөмкин эш. Шул вакытларда үзенең авыр, озын койрыгын ничек уфылдап-көчәнеп тартып бара ул! Борылышларда боргалана-сыргалана шуышканда, еланга да охшап куя үзе. Калкулык-тау буйлатып аска таба тәгәрәгәндә генә поезд, ниһаять, дәртләнеп, дәрман алып, гүелди-гүелди, бар көченә элдертә икән. Ул чакларда пар-төтенне шул кадәр мул, куе итеп бөрки дә инде үзе! Паровоздан таралган ул кара-кучкыл төтен исе үзенә бертөрле әчкелтем-төчкелтем. Гафур аннан аңкыган үзенчәлекле исне әле карел-фин җирләренә барып җиткәннән соң да озак вакытлар борын төбендә тоеп йөрде. Ул төтеннең кара корымы каршыдан искән көчле җил белән битләргә ягылып, морҗа чистартучы кыяфәтенә кертүе дә онытырлык түгел. Хәер, бу искә дә тиз ияләнәсең икән! Туган яклар тарафына искән ягымлы җиләс җил китергән, күңелгә якын ис бит ул!

Инде матур-төзек шәһәрләр, зур-зур авыллар, стансалар барчасы артта калды булса кирәк. Вакыт кимәлен бөтенләй чуттан чыгарып, атна-ун көн дәвамында барган хәлдә, ачык ишектән ниндидер иләмсез хәрабәләр, түбәсе каерып ташланган, җимерек, тәрәзәләре ватык-чытык килбәтсез йортлар күзгә чалынгалый башлады. Анысына шаклар катып, күзләрен шарландырып, авызларын ябарга өлгермәделәр, тора-бара бик тә сәер нәрсәгә игътибар иттеләр.

Юк икән, дөресрәге, аны барсыннан да элегрәк Кәпик Садыйк абзыйның хатыны Фатыйма түти сизенеп алган. Кеше-карадан яшереп булса да, биш тапкыр намаз-ниязын калдырмаган динле карчык, будильник сәгате буенча ястү вакыты җитә дип, камзул кесәсендәге дисбесен капшап, барлап куйганнан соң да шактый вакыт үтте бер кичне. Вагонда исә һаман да көндезге кебек яп-якты, әкәмәт! Ишектән ялт-йолт күренеп-күренеп киткән тышта да шулай, эңгер-меңгер дә төшмәгән хәтта, гөнаһ шомлыгы! Бу

хәлгә аптыраудан башкайлары түнгән Фатыйма түти гомерлек күршесе Өммегөлсем апаның сак кына колагына үрелде:

– Өммегөлсем, карале, күрше, ястү вакыты үтеп бара бит инде... Кояш баемый да баемый димен... Ахырзаман җиткән кебек, Ходаем кәрим, тәүбә, тәүбә, мең тәүбә, нишләп бу алай, ә?

Гафурның әнисе үзе дә аптыраште иде. Бүтәннәр дә, ниһаять, бу табышмакка таң калып, дәшми-нитми генә бер-берсенә карашалар, шиккә бирелеп, эчтән генә нидер укыштыралар. Якташларына табигатьнең бу шаукымын берничә сүз белән генә аңлатты да бирде Хәким абыйлары:

– Ак төннәр дигәне шушы була инде... Карел җирләренә кереп киләбез бит!

Чыннан да, әлеге шөкатьсез, шыксыз йорт-сарайларның, янгыннан соң сураеп-калгаеп торган өй-ызба калдыкларының, морҗаларның бу җирләрдән өермәдәй давыллап үткән кышкы сугыш кәсафәте икәнен чамаларга мөмкин иде. Ул да түгел, күңелгә ятышсыз, иләмсез күренешләрне тайга урманнары сыман, дивардай тоташ биек агачлар, уйчан, тымызык күлләр, исәпсез-сансыз бүрәнә әрдәнәләре, тәбәнәк куак-суак кына тырпаеп торган сазлыклар манзарасы алыштырды. Мәгърур имәннәр, төз, калын наратлар, зифа каеннар әледән-әле гудок биреп барган паровоз тавышына йокымсырап утырган җирдән капылт кына сискәнеп, калкынып куйгандай булалар. Юл биргән төсле артка чигенеп калган ул агачлардан соң, биек, текә комлы калкулыклар, кыя-ташлар, берәм-сәрәм терлек утлап йөргән көтүлекләр, яшел болыннар чагылып-чагылып үтте. Җәйге кояшның иркә нурларында анда-санда оеп утырган сирәк-мирәк авыл ызбалары туган якларны, дус-ишне, кан-кардәшләрне сагындырып, юксындырып искә төшерә, күңелләрне йомшарта иде...

Бу төбәкнең матур, җете, бай табигатенә соклaнудан тел шарлатып барган халык, үзләрен бөтенләй үзгә, һичнинди җиргә охшамаган чит-ят ил мохитенә эләгүләрен хәзер генә бөтен барлыгы белән аңлагандай тынып калды. Таныш булмаган Карел җирләре беренче карашка, күңелләрне тылсым белән урагандай хушландырып кызыктырса да, үзенең әби-чәбиләр әкиятендәге кебек хәтәр серлелеге, могҗизалы сихере белән әллә ничек кенә шикләндерә, шомландыра, хәвефләндерә иде.

## 3. Гафур исемен үзгәртмәскә булды

Ниһаять, поезд кичкырын романтик сәяхәтчеләрне Карел муентыгының үзәге – Выборг дигән искиткеч матур шәһәргә китереп җиткерде. Дөньяның һич башка җирендә булмый торган, фәкать биредәге «ак төннәр» дигән гаҗәеп табигать могҗизасын вагон тишегеннән аннан-моннан гына күреп калу бер хәл, ә менә аны ачык урында, киң мәйданда ашыкмый тамаша кылуы бөтенләй бүтәнчә икән ул. Һәрхәлдә, күпләр кичке эңгер-меңгердәге кебек гел караңгыланып торган вагон эченнән перронга чыгып басуга, әйле-шәйле көйгә, шәһәр өстендәге офыкка карап таң калдылар...

Ә анда кичке ал шәфәкъ бөтен күк йөзен камап, биләп алган. Менә-менә төнге караңгылык иңеп, җир өстен кап-кара пәрдә капларга тиеш иде кебек. Юк бит! Көн яктысы һаман сүнми, сүрелми генә! Шәфәкъ кызыллыгы

дөрләп янмый, ул инде юашланган. Һавасы да эссе түгел, яндырып, көйдереп алмый. «Бу ак төн үзе кояшлы, якты көннең күләгәсе кебегрәк икән ул», дигән фикергә килде Гафур. Туган авылында җәйге челләдә кояш нурларыннан качып, бакчадагы сәрби куагы ышыгында китап укып ятулары келт итеп сагындырып искә төште дә. Кара, хәзер дә, төн булуга да карамастан, ак кәгазьдәге һәрбер хәрефне аермачык күрергә, танырга мөмкин икән ләбаса!

Гафур, бүтәннәр кебек үк, ак төннәр күренешен шулай гаҗәпсенә биреп, кәефләнеп тамаша кылган мәлдә, очкын күзле Шәриф перронда каршылаучы халыкның башлыча хәрби киемле кешеләрдән генә торуын эләктереп алган. «Ворошилов та монда микән, малай?» – дип, чын-чыннан дулкынланып пышылдаганда кайнар сулышы белән колагын пешерә язды ул дустының. Җитди чырайлы, кискен хәрәкәтле, нык адымлы гаскәриләрнең сынаулы, үткен карашлары әллә ничек кенә тәннәрне чемердәтеп, эчтән калтыратып куя иде. Әйтерсең лә күчеп килүчеләрне никрутлар кебек, биредәге нindидер «ваенный чәсткә» чакыртып китерделәр. Мәгәр яңа гына инә-җептән төшкәндәй, үтүк эзләрен саклаган ыспай киемле бу кешеләр бик еракtan килгән кунакларга үзләре бик яхшы мөгамәләле кыланалар. Алай да кырыс итагатьлек белән эш итәләр.

Кызыл Таңнан һәм шуның шикелле Татарстанның бүтән авылларыннан килүчеләрне хәрби йөк машиналарына утырткач, станциядән биш-алты чакрымдагы зур гына утарга таба кузгалдылар. Кеше өстеннән командалык итмичә, боерык-әмер бирмичә бер генә минут та түзәлми, тынгы белми, ахрысы, бу хәрбиләр. Әллә нинди мөгез чыгармасалар, ашлары тамактан үтми, күрәсең... Иң алгы машинага ни өчендер яшьрәк ир-атны урнаштырды болар әүвәл. Аерылмас юлдашы гармунын иңенә аскан Галиуллага исә машина әрҗәсенең иң түренә менеп утырырга куштылар. Озата баручы көяз, кәттә яшь командир:

– Как фамилия?..

– Мухтаров.

– Ну-ка, Мухтаров, изобрази музыку! Песню «Если завтра война» знаешь? – диде дә, соравына җавап та көтмичә, көчле тавышы белән былтыр гына халык арасында киң таралган җырны башлап та җибәрде. Галиулла да сәләтле, задур[1] егет икән: аның артыннан ул көйне чамалап, башын гармуны өстенә салып, аның белән киңәшләшкәндәй, күреген акрын гына тырт та пырт шыңгырдатып тартып торганнан соң, көйне бер мәлне ару гына уйнап алып китте! Шуңа кәефе килгән хәрби кеше гармунчыга, хуплагандай, елмаеп күз сирпеп алды да:

– Барыбыз да кушылабыз! – дип, җыр уңаена кулларын селтәштергәләп, янә әмер бирде. Ул көйне сирәк кенә радиодан-мазардан ишетеп кенә белгән сала кешеләре авыз эчләреннән генә мөңгерәшеп, күтәреп алгандай иттеләр. Аларга бүтән машинадагылар да кушылды. Бер генә тантаналы чара да җыр-музыкасыз узмый торган замана, нишләтәсең?! Биредәге гаскәриләр дә яңа җиргә күченеп килүчеләрнең җиңүгә омтылучан көчле рухын шулай алдан ук билгеле бер күтәренке, утлы-ялкынлы дулкынга көйләп, тигезләп куярга дигән мәгълүм күрсәтмәне үтәделәр булса кирәк.

[1] Задур – диал. русларның задорный дигән сүзеннән.

Ике катлы, галәмәт зур йорт янына (Финляндиягә качкан эре алпавытныкы, диделәр) килеп төшүгә, тирә-юньне күзләп, иснәп дигәндәй, танышып, озын-озак юаныргa ирек бирмәделәр мосафирларга. Хәер, кара урман эчендә күз карашы дивар булып күккә ашкан биек, төз, зифа агачлардан ары узалмый иде. Шулай тәшвишләнеп, зарыккан күк басып торганда, әлеге дә баягы, күпне күрүчән Шәриф кабат төртте Гафурның янтыгына. Күчеп килүчеләрдән дә, каршы алучылардан да читтәрәк куе сакал-мыекка чумган карт кешегә һәм үз яшьләрендәге малайга ымлап күрсәтүе иде Шәрифнең. Болар аталы-уллы бугай. Шунысы сәер, икесе дә чабатадан. Өсләрендә туган якта чуваш авылындагыларныкы кебегрәк кызыллы-аклы бизәкләр белән чуарланган киндер күлмәкләр. Малайның җитүле саргылт чәчләре зәңгәр күзләренә үк төшеп аптырата. Кайдан икән соң болар?

Менә халык күче алдына гимнастёрка кигән, ялтыр-йолтыр күн итекләре баскан саен шыгырдап торган, искиткеч, эшлекле, һавалы гаскәриләр чыгып, өзек-өзек фәрманнар бирә дә башлады. Исемлек буенча гаилә башлыкларының исемнәрен атап, төркемнәргә бүлеп, хутор дигәннәренә билгеләп таратулары икән. Бер-берсеннән, апасы сеңлесеннән, кодасы кодасыннан, җизнисе кайнешеннән аерылып калмаска, бер үк командага эләгергә тырышып, өзгәләнеп каушаудан бәхәс, ыгы-зыгы, тавыш-гауга булып алды. Рамазан абзый белән тагын берничә гаилә өлешенә Выборгтан берничә чакрымдагы Марасельга дигән дүрт-биш йортлы авыл кәмәше туры килде. Шәриф дустын әти-әнисе белән башка хуторга аерып җибәрүләренә бик күңелсезләнде Гафур. Бүтәннәрдән исә кем кая эләккәндер: анысын хәтерләп, күңелгә бикләп өлгермәде. Хәер, эшелоннан төшүгә, өлкәннәрнең әңгәмәсен колак артларына гына озатты бала-чага. Почык борыннарның аларда эше юк, күңелләрен татлы төшләргә генә керә торган яңа җирләрне күрү тәэссораты, шатлыгы басып алган иде. Тоташ ак төннәр яктысында вакытны әрәм-шәрәм итеп, йокы-мокы белән әллә ни мәшәкатьләнеп торасы юк икән бит монда! Ура! Төне буе уйнарга, тагы әллә ниләр эшләргә була зурлар йоклап киткәч...

Марасельга дигән авылга махсус йөк машинасына салып җибәрмәгән вак-төяк букчаларын күтәреп, тирләп-пешеп барып җиткәннән соң, янә аталы-уллы теге икәүне очраткач, гаҗәпләнүеннән сызгырып куйды Гафур. Ничек алданрак килеп ирешкәннәр диген? Үзләренә генә мәгълүм урман сукмаклары белән, күрәсең. Шушында ук алачык сыман алама гына ызбада яшәп яталар, диме... Ә Рамазан абзый белән Садыйк абзыйларның, тагын кемнәрнең дә бәхетенә хуҗалары әле генә ташлап чыккандай төзек, һәйбәт йортлар насыйп булды. Каралты-курасына хәтле сугыш шаукымыннан ни могҗиза беләндер исән-имин калган. Абзарга Миләшне кертеп япкач, бер дә ятсынып тормады хайванкай, гүя бу шәп араннан беркая да китмәгәндәй, алдына куелган печәнне тәмләп кенә күши дә башлады.

Рамазан абзыйныкылар, шаулашып, өйгә үттеләр, әмма чит йортка бәреп кергән күк уңайсызланып, бусага төбендә үк кыяр-кыймас туктап калдылар. Чын хуҗалар менә-менә үзләре килеп керерләр кебек иде. Шулай булмыйни?! Зур өстәл, киң эскәмияләр, сандыклар анда-санда таралып ятмый, һәркайсы үз урынында, пөхтә килеш тора; киштәләрдәге пыяла савыт-саба чип-чиста, тузан да кунып өлгермәгән. Болын кадәр киң, биек

түшәмле йорт иде бу... Ишекнең сул ягында зур мич, өстендә ике-өч кеше рәхәтләнеп йоклый ала. Бердәнбер бүлмәнең иркенлеге тагы!.. Бүлсәң, тагын шундый ике-өч бүлмә чыгарлык. Яңа хуторда, инде үзебезчә авылда дисәң дә була, Рамазан абзый, тәүге тәҗел эш итеп, шуның чарасын күрүдән башлады да.

– Сөбханалла, эх тә итми тагын йөз ел торырлык ызба бу! Нинди алтын куллар салган моны? – диештеләр авылдашлары, тел шартлатып.

– Тагын ике йөз ел диген! Венецларын карагыз сез аның, венецларын! – диде куанычтан авызын җыя алмыйча, бу мактаулардан күңеле булган Рамазан абзый. – Колач җитмәс, түм-түгәрәк нарат бүрәнәләре бит!

Инде урамга чыгып, нигезен дә җентекләп карасалар, отыры хәйран калдылар: турыдан-туры җир өстенә, фундамент-нидер казып мәшәкатьләнмичә, почмакларына гына зур валуннар салып һәм вак таш тутырып, утыртып кына куялар икән бураны. Кышын ничек яшиләр икән соң мондый йортта? Астан суык җилләр керми микәнни?

Зур мичен ягып җибәргәч, өй эче май кебек җылы була, дип тынычландырдылар каршы алучылар. Баз капкачын ачып, идән такталарының калынлыгын юри шырпы кабын куеп үлчәгәннәр иде, алар шул тартмадан да ике тапкыр киңрәк булып чыкты. Һич тә җил-мазар үтәрлек түгел! Аннары инде качкын халыктан калган биналар канәгатьләндермәгән очракта, үзегез теләгәнчә яңасын төзеп керү мөмкинлеге бар; әнә, урман өстегезгә авып тора, дип тә өстәделәр җирле түрәләр.

Иң әүвәле эшне яңа җирдә яңа колхоз оештырып җибәрүдән башладылар. Беренче җыелышта олысы-кечесе катнашты. Балаларга да файдасы тисен, бөтенесен күреп-белеп үссеннәр, гыйбрәт, үрнәк алсыннар дигән изге максат белән эшләнде инде монысы. Рәисен, идарәсен сайлау шома гына үтте, каршылык-киртә булмады. Ә менә колхозга исем кушканда, һич көтмәгәндә, маңгайга-маңгай килүчеләр табылды. Берәүләре туган якларындагы колхозның элекке атамасын калдырыйк дип бара, икенчеләре бүтәнне тәкъдим итә, өченчеләре... Колхоз составына әүвәлге күрше авылныкылар да кергәч, фикер аермалыгы булмыймыни соң? Каты кызган бәхәсне, утка су сипкән күк, «пышт» итеп сүндерергә «Кырт» Нурулла абзыйның бер-ике кәлимә сүзе җитә калды:

– Күрегез әле, авылдашлар, якташлар, нинди матур көннәр, якты төннәр каршылады безне! – дип елмаеп, ерактан башлады ул сүзен, гаҗәеп якты ак төннәргә дә ишарәләп. – Безнең өчен үтереп биргән бит бу! Әгәренки, әйтик, эшеңне көндез, якты күздә төгәлләп бетермәсәң, кырт итеп төнлә очларга була, ә? Тирә-ягыбыз ничек балкып тора, тоташтан яктылык эчендә яшибез ләса. Шуның өчен, колхозыбызга «Балкыш» дигән исем кушыйк, дим!

Аның тәкъдимен бертавыштан кабул иттеләр. Дөрес, авыз еручылар да күренде. Алары Нурулла абзыйның сүз сөрешендә җае килгән саен «кырт итеп»не яратып, еш куллануын мәзәк итүләре инде. Күмәк хуҗалык оешып, турыдан-туры нәчәлникләр, җаваплы хезмәткәрләр ачыклангач, һәркем ныклап урнашу, тамыр җәю чарасына кереште.

Татар халкында шулай гадәтләнгән инде, китте шуннан соң өмәләр чакырып, бер-берсе белән ярыша-ярыша ызба күтәрүләр, каралты-кура салулар. Тегендә-монда өелә башлаган буралардан ап-ак йомычкалар очып

кына тора да, тирә-юньгә нарат сагызының хуш исе тарала. Менә дигән таза йортлар өлгертте Татарстан тумалары. Авыл советы әлеге алпавыт сараенда, МТС идарәсе белән янәшә урнашты. Аның тирәсенә – колхоз идарәсе, клуб, кибет укмашты. Мәктәп биналарын яңабаштан төзеп куйдылар. Чөнки вакытлары җитәрлек, әлегә «Балкыш» исемле яңа колхозда әллә ни зур эш күренми. Язгы чәчү тәмамланган чакка тып итеп килеп төштеләр бит. Аның каравы, яшелчәчелектә, урманчылыкта эш ел әйләнәсе бетәсе түгел.

Мондый вакытлы «хөррият» ат арбасының бишенче тәгәрмәче булып Кызыл Таңнан ияреп килгән Халикъка җитә калды булса кирәк. Үз мәнфәгатен генә алга сөрүе килүгә әчегән камыр куәсе кебек кабарып бәреп чыкты ата ялкауның. Уртача гына, җыйнак йортка әзергә бәзер булып кереп утырдылар да хатыны белән, өненә яшеренгән әрлән төсле, кешегә күзен-кашын күрсәтми генә өендә эшсез ята бирә бу, юл чыгымына бирелгән акчага кәеф-сафа корып. Ә бит нәрәт буенча, яңа ызба салучылар өчен өмәдә хәл кадәри һәркем катнашырга бурычлы. Халикъ исә: «Ник тыңкыш Гайфи өчен чиләним, ди, мин? Үзе соң авылда чакта миңа булыштымы?!» – дип тартыша, «Ничек ял итәргә – минем пырава!» – дип күкрәк кага... Идарә утырышында кара тиргә батырганчы пешерделәр үзен.

– Безнең йөзгә кызыллык китерүгә юл куймабыз! Монда син генә түгел, безнең, бөтен татарларның кем икәнлеге сынала. Кара аны, соңгысы булсын! – диделәр, эшсез селкенеп йөрүенә, «яшел елан» белән дуслыгына ишарәләп. Шуннан соң майланган кебек булды Халигың.

Бу күңелсез вакыйга биредәге ак төннәрдән тыш, тормышның караңгы, кара яклары барлыгын да искәртте колхоз җитәкчеләренә. Андыйлар белән итәк-чабуны җыебрак, катгыйрак сөйләшергә кирәк икән. Бала-чага түгел, аңламасалар – кискен чаралар күрергә. Ник дисәң, район җитәкчелеге дә, күрше хуҗалыклар да бер-берсен күз уңында тоталар, план-заданиеләрнең үтәлешенә җаваплылык көчле. Берәр чатаклык килеп туса, кайсы яктан, кайсы төбәктән килгәннәрен телгә алып, искә төшерәләр иң әүвәл.

Уңган, тырыш, булдыклы халыкны биредә дә хөрмәтли, ихтирам итә беләләр икән үзе. Андый кешеләрнең абруе зур. Әнә Гайфи абзыйның улы гармунчы Галиулла килеп төшкән көнне үк хәрбиләр каршында үзен шәп кенә күрсәтеп өлгерде. Шуңа күрә клубка мөдир итеп кемне куйсыннар инде? Үзе музыкант, үзе җырчы егетне, әлбәттә! Асылда ачык-уйнак йөзле егет инде сөйгәненнән аерылу хәсрәтеннән айный төшкән кебек күренә. Әллә инде үзенә тапшырылган мәдәни-агарту эшенә кайгыдан арыныйм бераз, онытып торыйм, дип чатыр ябышты?! Кай ара үзешчәннәрне табып, үз янына туплап өлгергән диген. Концерт-мазарын хәтта Выборгның үзенә барып та куйгаладылар. Һәвәскәр гармунчылар смотрында һич көтмәгәндә беренчелекне Гайфи улы Галиулла Мохтаров яулап куймасынмы! Бик мактадылар, күтәреп кенә йөртмәделәр үзен.

Күз җиткәч, кем әйтмешли, лаеклы егетнең армия сафларына алынуы күпләр өчен аяз көндә яшен суккандай булды. Түрә-караны да ике кулсыз калдырды ул. Хәер, Галиулла, шәхсән үзе, быел көзен армиягә китәчәген авылдан ук чамалап килгән булган икән. Ә нәрсәсе гаҗәп? Яше җиткән, буе-сыны белән гөрнадир! Дөньялар бозылып торганда, Ватанны Галиулла кебекләр дә якламагач, кем якласын?..

Шулай да Галиулла абыйсы гаскәри хезмәткә киткәч, күңеленең бер чите кителде сыман Гафурның. Ул бит аның вакыты бераз иркенәя төшкәч, үзен гармун уйнарга өйрәтүен үтенергә дип ниятләп кенә йөргән иде. Алданрак серен чишәргә базмады. Эх, туры килмәсә дә килми икән! Галиулла абый да китте, гармун да китте. Мактау нотыклары сөйләп, зурлап озаттылар шөһрәт казанган музыкантны! Якты эз калдырып, татарлар данын ишәйтеп китте бу ят җирдә. Гафур күләч, чибәр егетнең сынын-сурәтен, саубуллашканда, поезд тамбурында елмаеп басып торган, башына уртасында тимер төймәле, әллә ничә ялгаулы рус кипкәсе, аягына теш порошогы белән агартып торган брезент ботинкалар кигән, яшел гармунын иңенә аскан килеш кенә искә төшерә торган булды... Бүтән бала-чага да «Галиулла абый» дип өзелеп тора иде шул.

Балалар дигәннән, хәзергә иркенлектә, хозурлыкта, болын, урман итәгендә рәхәт чигә алар. Аякларына тышау салырга, яисә эш-хезмәт тәртәсенә кертергә иртәрәк иде әле... Гафур үзләре килеп урнашкан торак пунктының һәр почмагын беренче көнне үк айкап чыкты. Теге сәләмә ызбада гомер кичерүче кешеләрнең кемнәр икәне дә ачыкланды. Рамазан абзый сөйләп торды: карел дигән җирле халык кешеләре, ата белән аның улы икән болар. Өлкәне Блади исемле, русларның Владимирына тартым. Алар икесе дә әлеге фин баеның утарында батрак хөкемендә торганнар. Безнекеләр килә башлагач, җирле власть халыкны, кем булуына карамастан, Финляндиягә күчләп күчергәндә, урманда качып калганнар, ди. Чөнки Блади аганың олы улы кызылармеец икән. Шуны чишкән булсалар, финнар асып кына куялар иде үзләрен.

Беркөнне Гафур әлеге карел малаен урманнан кайтканда очратты. Кулында озын чыбык. Кармак таяклары?! Әллә инде балыкка хәстәрләнүе моның?.. Бу хәл юл сәфәрендә йокымсыраган балыкчы дәртен кыздырып, котыртып җибәрергә сәбәп булды. Гафур һич икеләнеп тормады, тегенең каршына ук килеп басты. Ул да барган җиреннән шып туктады. Бер дә йомыкыйга охшамаган озынча йөзле карел малае. Кызыксынулы, тере зәңгәрсу күзләре белән кирәгендә кешегә туп-туры карап торучан икән. Аларда ниндидер эчке көч-куәт, үҗәтлек талпынуы сиземләнә... Икесе дә, күзне-күзгә төбәп, көлемсерәгәндәй, тик басып тора бирәләр. Ә нишләргә ди тагын? Нинди телдә аңлашырга соң? Гафурның русчасы ипи-тозлык кына. Тегесе аны бөтенләй белмидер. Ярый әле, Блади абзый ярдәмгә ашыкты. Ул русча аз-маз гына сукалый иде.

– Как тебя зовут? – дип сорады ул. Малай «Гафур» диюгә, моңарчы ишетелмәгән татар исемен теле белән әйләндереп әйтергә кыенсынды, ахры, карт, шул исемнең руслардагы якынча аваздашын исенә төшерепме, «Гриша, значит?» – диде. Әйтергә җайсыз дигән булып, үзенең атын шул рәвешле бозып үзгәртүдән баш тартты Гафур. Тел сындырырлык түгел бит инде аның исеме алай да. Аннары «Гриша» дип кушарга аның хәтле үк бәләкәчмени Гафур?! «Нит!» – диде ул, – я – татар, я – Гафур! «Безнең татарча шулай», – дип тә өстәде. Моны ишеткәч, Блади абзый елмаеп килеште тагын. Улының атын исә сузып кына «Ваассила», – диде. Бу бит русларның Василий дигәненә охшап тора! Кызык икән!..

Малайлар икәүдән-икәү генә калгач, киеренкелек йомшарып, үзара

мөнәсәбәттә җиңеллек тойгач, бер-берсенең күкрәгенә төртешеп, көлешә-көлешә исемнәрен кабатлап әйтештеләр. «Га-а-ф-фур,» – дип, авырлык белән генә ермачлады карел өммәте. «Ва-а-силы-ы,» – дип сузып әйтергә тырышты да Гафур, алай килеп чыкмагач, көтмәгәндә саф татарча: «Васыйл», – дип чатнатып әйтте. Монда һичнинди дә хилафлык юк: карелның Ваассила дигәне безнеңчә Васыйл кебегрәк яңгырый икән бит! «Васыйл», – дип, үзе дә сынап карагач, ризалыгын белдереп, елмаеп, баш какты ачык йөзле, эчкерсез табигатьле карел баласы.

Һәрхәлдә Гафур ничектер бик тиз ошатты, үз итте авыр исемле ул малайны. Исеме дә безнең «Васыйл»га аваздаш, тәңгәл килгәч, күңеленә аеруча якын булып китте ул. Үзе өчен генә Васыйл дип атарга күнекте хәтта. Ваассила-Васыйлларның тәбәнәк кенә өйләренә тартына-тартына гына кереп чыккач, инде кунак ашы – кара-каршы, дигәнне шартына китереп, «әйдә» дип кул изәп, үзләренә чакырды. Өйдә әнисе белән Фирая апасының тиктормас сөйкемле кызы Ләйлә генә иде. Биш-алты яшьлек кызчык таныш булмаган малай килеп кергәч, алдына килеп басты да, алсу күлмәк итәген бөтерә-бөтерә, ятсынмыйча, аңа текәлеп карап тора башлады.

– Кызым, кунакны табынга чакыр! Бергәләп чәй эчәрбез, – диде Өммегөлсем апа ачык йөз белән. Ләйлә малайның кулыннан тотып, өстәлгә таба тарта башлады. Тегесе карыша. Күмәкләшеп, кыстый-кыстый, көчкә утырттылар аны чәйгә. Элеккеге батрак баласы үткән тормыш кануннарыннан арынып бетмәгән иде әле. Аның белән таныштырганда, ана белән улы арасында җиңелчә генә аңлашылмаучанлык та булып алды.

– Улым, туктале, ник син аны Васыйл дип атыйсы-ы-ң ул? – дип гаҗәпсенде әнисе, җиңелчә шелтәләгәндәй.

– Әй, әни, исеме әйтү өчен авыррак бит аның. Аннары Васыйл исеменә үзе дә ризалашты... – дип котылмакчы булды Гафур. Әмма Өммегөлсем апа Гафурның хатасын үзвакытында төзәтүне кирәк тапты һәм самавырдан чынаякларга хуш исле чәй агыза-агыза, кешеләр белән үзара мөгамәләдә тормышның язылмаган кагыйдәләрен телгә алды:

– Адәм баласының исеме-аты бер генә була ул, улым! Әйтергә җайсыз, миңа ошамый дип, үзең теләгәнчә боргалап, бозып атарга ярыймы соң кеше исемен?! Телең әйләнәме, юкмы, чын исеме белән әйтергә тырыш син аны... Әнәтерәк, безнең күрше Михайловка авылындагы ...этиеңнең дусты – тегермәнченең исеме м-м... кем әле... әйе... Бронислав иде. Атаң аны бер дә телгә җиңел булсынга, татарча «Барый» дип йөртмәде. Ул да этиеңнең исемен Роман, яисә Микулай димәде, үзгәртмичә «Рамазан» дип, авызын тутырып әйтә торган иде мәрхүм... Төрле халыкның бер-берсенә хөрмәте, ихтирамы шулай була ул ...

Бу вакытта Ваассила ана белән бала арасында ни турында сүз барганын аңлаган кебек, кирәге чыгар дигәндәй, чит телдә сөйләшүне күңел биреп тыңлап утырды, бер дә уңайсызлык кичермәде бугай. Шулай ук үзенә дикъкать йомшарудан файдаланып, мыштым гына ашамлыкларга да затсызланып үрелмәде, кагылмады. «Ятим бала икәнлеге әллә кайдан күренеп тора», – дип бәгыре киселде Өммегөлсем апаның, Ваассила әнисенең сугыш вакытында үлгәнен исенә төшереп. Аннары:

– Кара, балакаем, бигрәк арык. Әнисе булмагач, ашау ягы да рәтле

түгелдер, – диде дә тиктомалдан гына бәреп чыккан күз яшьләрен, самавыр артына яшеренә төшеп, сиздерми генә, сөртеп алды. Үзе табын сыен әледән-әле кунак каршынарак күчереп куюдан бушамады...

– Син, улым, сорап кара әле, «әни» сүзе ничек була икән аларда? – дип, балаларча беркатлылык белән улына дәште ул утыра торгач. Әйтерсең лә Гафур күп тел белә дә, әйтерсең лә аңа, тылмач сыман үзебезчәгә аудару – ике акча – бер тиен. Үзе үк хатасын абайлап, өйне яңгыратып көлеп җибәрде Өммегөлсем апа. Аңа бәләкәй Ләйлә белән Гафур да кушылды. Ваассила да ихлас елмайды. Һәм һич көтмәгәндә, Өммегөлсем апа ягына борылып, үз телендә «моама» (безнеңчә «әни» була инде) диде дә тавышы калтыранып, җәтрәк башын түбән иде.

– И мескен, мама, диме? Газиз әнисен исенә төшерде бугай. Без дә инде... күңеленә тиеп, әллә ниләр сорап торабыз, – диде Өммегөлсем апа, уңайсызлануыннан нишләргә белмичә, кунакны янә кыстарга кереште.

Бераздан пырдымсыз Гафур, әле генә әнисе кисәткәнне исеннән чыгарып, «Сезнеңчә ничек була?» – дип, Ваассилага ипи телемен тотып күрсәтте. Ваассила, сорауның мәгънәсен шундук эләктереп алып: «Лейбэе» – дип җавап кайтарды.

– Әни, карале, ул сүз дә безнеңчә яңгырый икән ич! Лейбә! Безнең «Ләйлә» төсле ишетелә, – дип бик шатланды Гафур. Аннары, шуның шикелле яңалык ачу дәртенә бирешеп, кызулык белән:

– «Сәлам» ничек була? – диде. Аңлаешлы булсын өчен, сәламләгәндәй уң кулын күтәреп, болгап торды хәтта. Моны инде Мәнди анасы да аңларлык иде. Ваассила, киң елмаеп: «Сялам?!» – дип кайтарып сорады һәм аның карел телендәгесен: «Тербех!» – дип җаваплады. Күрәсең, татарча, интернациональ сәламләү сүзен каядыр ишетеп калган зиһенле малай. «Тербех»не исә ана белән ике татар баласы күңелләрендә бикләргә тырышып, үзалларына еш-еш кабатлап тордылар. «Тормыш»ның аларча «Эло» дигәне ятлауга аеруча ансат булып чыкты.

Үз өендәгедәй самими җылылыкны тоеп, бөтенләй үк үзләшеп, кыюлана төшкән кечкенә карел үз чиратында «Куибо он синун ними?» («Синең исемең ничек?») – дип, бәләкәй Ләйләгә иелә төшеп, аның аркасына кагылып алды. Бу сүзләрнең кызчыкның исеменә бәйләнешле булуы сизелә иде. Сабый, авызыннан тәмле кәнфитен алып торып, үз исемен шартлатып әйткәч, уртак сөенечтән тагы көлешеп алдылар.

Менә шулай гөрләшеп утырганда, Рамазан абзыйның да кайтып керүе табынны бөтенләй ямьләндереп җибәрде. Аның җыйнак мыек астыннан нидер әйтергә теләве сизелә, иреннәре читендә елмаю кунган иде. Чыннан да, кулларын юып килеп утыруга:

– Быел яңа мәктәп ачыла! Үзебезчә, татарча укыячаксыз. Җәй буена тырай тибеп ялыккансыздыр, – дип, берникадәр Гафурга төрттереп, куанычлы хәбәр җиткерде. Аны ишетүгә, яраткан абыйсыннан һич тә калышмаска тырышкан Ләйлә:

– Минем дә мәктәпкә барасым килә! – дип көйсезләнде, уртак игътибарны үзенә яулап. Рамазан абый аны итәгенә алды:

– Сиңа анда барырга иртәрәк шул әле. Әлегә балалар бакчасына йөрерсең, яме, кызым! Тагын биш-алты көннән ул да эшли башлый, – диде.

Бу Ләйләнең кулларын чәбәкли-чәбәкли, шатланып-көлеп, идәндә тыпырдып биюенә сәбәп булды.

Шау-гөр килү, күңелле чыр-чу, уен-көлке моның белән генә бетмәде әле. Гафур Ваассила дустының гел чабатадан йөрүен әнисенең колагына пышылдап өлгергән икән. Әнисе сандыгыннан шундук ялтыр-йолтыр килеп торган, кызыл эчле өр-яңа галошлар тартып чыгарды һәм аларны, Ваассиланың ай-ваена карамыйча, чебиләнеп беткән аякларына үзе кидереп карады. Таман гына иде ул карел малаена. Бу табигать баласы, һәммәсеннән дә кадерлерәк әйбер тоткандай, бүләкне күкрәгенә кысты да, үзләренчә рәхмәт әйтеп, тизрәк өйләренә чапты. Әтисеннән сөенеч алу өчендер инде. Аның артыннан Гафур белән Ләйлә дә тышка атылдылар. Ата белән ана бәхетләре ташыган балаларга елмаешып карап калды.

### 4. Монда да шул шыртлака

Тагын бер ифрат әһәмиятле яңалык-әмер алып кайткан Рамазан абзый Выборгтагы күчеп килүчеләр белән эш итүче комитеттан. Менә шул боерыкны, төрле хуторлардан барча гаилә башлыкларын җыеп, ягъни мәсәлән, «Балкыш» колхозының рәисе буларак җиткерде дә... Бала-чаганың урман-күл буйларында эшсезлектән селкенеп, кәеф-сафа корып йөрүе тыела икән. Берничә ай элек кенә каты сугыш ялкыны көйдереп, яндырып узган җирләр ләбаса бу: атыш-үтереш кораллары, шартламый калган снаряд-бомба адым саен булмаса да сагалап тора. Әнә, хәрби санитар отрядының әле һаман да үлек, мәет сөяк-санагын, җәсәден, сугыш чүп-чарын, калдык-постыгын җыеп, урман-кырларны чистартып йөргән көне. Әлегә адәм кулы житешеп өлгермәгән ниндидер шикле чокыр-чакыр Рамазан абзыйлар яши торган авылның читендә үк караеп тора ич. Бәладән башаяк, сугыш калдырган куркыныч афәткә юлыгудан Алла сакласын!

Бу хакта аны-моны уйлаганчы, кыбырсык, башсыз, гамьсез малайларны моның ише тыю-кисәтүләрнең файдасыннан зарары күбрәк булучан. Сугыш-орыш коралы, мина, автомат, пистолет дигәндә шушы ташбашларның күзләре уттай янып тора. Тыелган җимеш татлы була, хәтәр эш үзенә тарта, дигәндәй, мондый коры куркытулар отыры котыртты гына аларны. Тирә-яктагы һәрбер куакны, һәрбер түмгәкне теләсә кемнән дә шәбрәк белгән Блади аганың урманда ниндирәк куркыныч янавы хакында үзе белгәнчә русчалатып кисәткән үгет-нәсыйхәт сүзләре дә бер колактан керде, икенчесеннән чыкты боларның. Яңа җирләрдә инде тәмам ияләнеп беткән, гаярь, кыю татар балалары бит!

Яңа дусты Ваассила урман ягын онытылганда бер генә караштыргаласа, Гафур ул тарафтан ике күзен дә алмый иде. Килгән көннән бирле таныш булмаган тоташ яшеллек, сихри тылсым дөньясына сәяхәт кылырга, күленә кармак салырга хыялланудан арына алмый ул. Биредә әтисе колхоз өчен урман кисү, кырчылыкны җайга салу белән мәшгуль булганга, йорттагы барча вак-төяк эшләрне «Син инде егет кеше, икенче хуҗа», итенгәләп, шыттырып, үсендереп, аның өстенә өйделәр. Алар исә тавык чүпләп бетермәслек булса да, чынлыкта дилбегә кактырмый, үзе белеп эшли торган зур үскән малай ул Гафур. Үзе генә дә мунча шае, зур авызлы

мич өчен, әнисе белән кышлык утын кисте-ярды, аранны, каралты-кураны төрле чүп-чардан чистартты, болыннан әтисе чабып кайтарган печәнне киптереп төз лапас өстенә өеп куйды, тагын әллә ниләр эшләп ыргытты. Инде менә бераз бушандым, урманга сәхрәгә чыгам дигәндә генә... менә сиңа! ...сәйран сукмагын кистеләр, юлга аркылы төштеләр бит әле.

Әмма шаян, шук, акыллы малай башваткыч мәсьәләне бүтән яктан кереп чишәргә кереште. Белмәмешкә салышып, беркөнне элегрәк яңа кармаклар вәгъдә итүен исенә төшерде атасының. Рамазан абзый күңеленә киртләп куйган икән аны, әмма ләкин теге кисәтү-тыюлардан соң, ул балык тоту кирәк-ярагын кайтаруны кичектеребрәк торырга карар иткән. «Ярый, ярый», диюдән артыгын әйтмәде. Ашыкмасын әле җәһәннәм оясына, янәсе.

Гафур, үзсүзле малай, аптырап калмады, бер күрешкәч, Ваассиланың кармак таягын кулына алып, авыл очындагы күлгә таба ымлады. Янәсе, әйдә, балыкка! Ваассиланың йөзе шуны гына көткәндәй яктырып китте. «Була ул!», дигәнне аңлатып, җәлт-җәлт баш какты. Сарай читеннән кармак сабы алып килде дә елмаеп, дустына сузды. Ул да түгел, өеннән тегәрҗеп кебек, нәзек кенә бау алып чыкты. Гафур аңа аптырап карады: «Нәрсәгә инде бу?» – Ваассила озак нитеп тормады, шул җебен чыбыкның бер очына бәйләп, кармак та тагып бирде. Үзенеке дә шуның ише гади тегәрҗептән аның. Күрәсең, боларда балык чирттергәндә, гап-гади җепле кармак куллану гадәткә кергән. Ә ничек кенә аңлатырга соң карел дустына, без бары тик кибеттән сатып алынган капрун җепне, ахыр чиктә, ат кылын эшкә җигәбез дип?

Моны аңлату өчен тышаулап җибәрелгән Зирәк дигән ат үзе «ярдәмгә килде». Куе саргылт төстәге бияне Садыйк абзый Кызыл Таңнан ияртеп килгән иде. Аты, дирбиясе бар, ә менә якын-тирәдә арба-чана ише нәрсәнең әсәре дә юк. Кайдан килсен, ди, алар?! «Кышкы» сугыштан соң дошман бөтен халыкны үзе белән куып алып киткәч. Әнә шуңа Зирәк җәй буе эшсез, авыл тирәсендә утлап, корсак тутырып йөри дә. Хуҗасы, колхоз эшеннән бушангач, шәп кенә арба ясамакчы була булуын. Колыны да туа калса, аңарга да ясыйм, дип, сөйләнеп торганын Гафурның ишеткәне бар. Үзе сәүдәгәрлек итәргә хирыс иде ул агай. Мал җанлы, сумга сум каерырга ярата... Ә үзеннән әҗәткә сукыр тиен дә сорап тора алмыйсың. «Кәпик акчам да юк бит, олан», – ди, күзен дә йоммыйча. Шуңа күрә Кәпик дигән кушамат килешеп кенә тора аңа, саран кешегә... Ә менә хәзер үзенеке булмаса, атының файдасы тисен әле. Койрыгындагы кыллар кармак җебе өчен менә дигән.

Садыйк абзыйлар эштә, авылда бер җан кисәге дә калмаганга охшый. Гафур, Ваассиланы җиңеннән тотып, үзе белән алып барды Зирәк янына. Тегеңә ат башыннан тотарга ишарәләп, җәһәт кенә койрыктан кармалап, берничә кыл өзеп тә алды. Аны-моны сиздеме юаш ат, юкмы, арт аякларын гына алмаш-тилмәш күчергәләп куйды. Калганы инде, кем әйтмешли, пүчтәк. Бер метрдан озынрак икешәр кылны бер-берсенә ялгап ныгытканнан соң, кибетнекеннән дә шәбрәк килеп чыкты әле кармак дигән балык тоту коралы. Ваассила гына үз кармагын алай кыландырудан баш тартты. Яшь балыкчылар сабырсызланып күл буена чаптылар.

Иң элек, хуҗа буларак, яшел камышлар арасына Ваассила кереп утырды.

Үз телендә нидер такмаклап, кармагын суга салды. Гафур исә, үзенекен: «Балык кап, балык кап, яр өстендә ялтырап ят!» дигән теләк белән көйләп җибәрде. Икесе дә бер-берсенә сынаулы караш ташлап алгаладылар. Кем беренче булып балык эләктерер икән, янәсе... Ваассиланың инде әнә калкавычы калкына, талпына, бата-чума да башлады. Гафур моны күреп:

– Күтәр инде кармагыңны, ычкына бит! – дип шәрран ярып, кычкырып салды. Әмма аңа карап кына кабаланмады Гафурны чиктән тыш гаҗәпләндергән карел малае, калкавыч шактый уйнаклый башлагач кына тартып алды кояш нурларында ахактай ялтыраган балыкны. «Болар үз балыкларының җаен-көен беләләрдер шул», дип көнләшә төште Гафур. Аннан нинди балык эләгүе турында сорашырга да өлгермәде, бәхетле Ваассила әле генә тоткан балыгын иреннәренә китереп, нидер пышылдады да, назлап үбеп алгач, кире суга җибәрде, тиле! Аның бу гамәленнән таңга калган иптәшенә карап, көлемсерәгән килеш кулларын җәеп, иңбашларын җыергалап, «Бездә беренче балыкны шулай ireккә җибәрәләр», димәкче иде бугай карел малае...

Бераздан Гафурга да чиртте. Уртача зурлыктагы әрсез шыртлаканы тартып чыгаргач, башы күккә тиде инде абзаңның! Бу уңышка Ваассила да аның үзеннән ким куанмагандыр, шәт. Әлбәттә, Гафур, «мая төбенә!» дип, аны кире суга җибәрергә җыенмады да. Ваассиланың аптыраулы карашына җавап итеп, нәкъ үзе сыман җилкәсен генә сикерткәләде. «Юк бит, дустым, бездә андый ырым, йола», диюе инде. Хәер, алай вакланып торыр чакмыни, балык шул хәтле еш чиртергә тотынды, малай, тартып кына өлгер! Бу тирәгә ни гомер адәми зат килеп басмагач, тын почмакта шактый симергәннәр дә балыкчылар белән көрешергә тилмергәннәр, диярсең. Нindiләре генә юк араларында. Корбан, шамбы, яисә җилембалык кирәкме, бәртәсме!.. Алабуга белән чабагына хәтле күлдәге суларны кайнатып, өере белән йөзеп үтә яр астыннан... Балык та каба, вакыт та сиздермичә алга чаба. Каядыр әнисенең: «Гафу-у-ур!» – дигән тавышы яңгырады. Димәк, төшке аш, әбәт вакыты җиткән.

Үз табышын сыгылмалы зирек ботагына ипле генә элеп, тезеп өлгергән Ваассила күзләрен юлдашына төбәде: «Бу малны хәзер кая куябыз инде?» Әлбәттә, Гафурларга, хатын-кыз кулына тапшырырга.

Көтмәгәндә генә ярты чиләк чамасы балык алып кайтуларын күргәч, кулларын тез башына суккалап, шаклар катты Өммегөлсем апа. Озын-озакка сузмыйча чистартып, «Сөбханалла, тансык ризык ашыйсы да бар икән әле, рәхмәт төшкереләре!» – дип, малайларның башларыннан сыйпап узды. Рамазан абзый да тәкатьсез булып, кыздырылган тәмле балык исенә турылап кайтып керде кебек. Блади абзыйны чакырып килергә дә онытмадылар. Ул кашыгын күтәреп килгәч, табын түгәрәкләнде. Китте гөрләшү. Гафур һәрбер балыкның ни рәвешле эләгүенә кадәр, кулларын буташтырып, йотлыга-йотлыга сөйләде. Әтиле-уллы кареллар элеккечә тыйнаклык саклап утырдылар. Шунда, җаен туры китереп, Гафур Ваассиланың тәүге балыктан соң ни әйтеп такмаклавын сорады Блади агайдан. Беренче капкан балыкны боларда: «Әниеңне алып кил, әбиеңне дә калдырма!» – дип такмаза әйтеп кире җибәрәләр икән суга! Күбрәк, мулрак капсын өченгә шулай итәләр инде. Моны ишеткәч, Өммегөлсем апа: «Әстәгъфирулла», – дип, үзалдына нигәдер сәер генә әйтеп куйды. Әби-әни

кебек изге затларны тиктомалдан гына телгә алып, шул рәвешле корбан чакыруны башына сыйдыра алмады бугай ул. Нишләтәсең, һәр халыкның үз гореф-гадәте. Аннан соң шаярту гына бит бу. Ә менә күп балык тоту белән масаеп-мактанып йөрү гадәте бөтенләй юк икән карелларда. Андый балыкчыны адәм мәсхәрәсенә генә калдыралар, ди Блади агай.

Бөтенләй үз кешегә әверелеп, якынаеп киткәч, карт карелның ни өчен кунакка кашык тотып килүе дә ачыкланды. Монысы да элеккеге йола икән. «Кашыкларны төрле бизәкләр белән сырлау да борынгыдан килә бездә», – дип җанланып сөйләп китте карел кешесе. Гаиләдә һәркемнең шәхси, үз кашыгы бар, һичкемнеке белән дә бутарга ярамый. Кунакка да үз кашыгың белән генә йөрешле, ди.

...Бер-ике көннән әллә ниткән төрле матур сыр-бизәкләр төшереп ясап та бирде әле ул Рамазан абзыйларның һәркайсына агач кашыкларны. Аның белән аш тәмлерәк була кебек, авыз да пешми дип, игелекле карелны мактап, бүләк кашыкларга тиз күнектеләр... Шулай берсендә Ваассила үзләренә дәшкәч, Гафур агач кашыгын эләктерде дә ишеккә таба юнәлде. Бусагада гына әнисе чабуыннан тотып туктатты:

– Кая шулай күзең тондырып чабасың, кашык тотып?

– Блади абзыйларга кунакка барам, – диде малай, тизрәк ычкынырга чамалап.

– Аларда да кашык белән кунакка йөрешү туган-тумача арасында гына таралгандыр ул. Бездә дә бит кунакка бару ашау өчен генә түгел, улым. Хуҗаларны хөрмәт йөзеннән, бары белән сыйланып, күңелле генә сөйләшеп утырырга дип... Корсак тутырыр өчен генә ымсынып, ашау турында кайгыртып йөрү затсызлык галәмәте, – дип үгет-нәсыйхәт бирде әнисе. Шуның белән Өммегөлсем апа тагы: «Аларның гел-гел ризык пешереп торырга әниләре дә юк! Блади абзаңны ничу мәшәкатьләргә!» – дип әйтергә дә теләде бугай кунакка нык ашкынган Гафурга. Хәер, монысы малайның да миенә тиз барып җитте. Бизәкле, тәти кашыгын иплә кенә киштәгә, үз урынына куйганнан соң гына, Ваассилаларга таба чыгып чапты.

### 5.Лимонка һәм медальон

Җәй урталарында җирле органнар тарафыннан санитар тыюлар чикләнә, йомшара төшкәч, балалар урманга сибелде. Ә монда үзенә күрә үзгә бер дөнья! Урман дигәч тә, ул Карел муентыгындагы яшел хәзинә безнең урманнардан шактый гына аерыла. Эченә барып кергәч, нарат кына үсә икән биредә дип уйлыйсың башта. Һәр җирдә күккә үрелгән нарат та нарат. Биш йөз елдан артык гомер кичергәннәре бар, диләр. Каеннар да бездәге ише генә түгел, егерме метрга тиклем буй сузганнары очрый хәтта. Арырак киткәч, каенның ботаклары борыла-сарыла кәкрәеп үскән бүтән төрлесе күзгә ташлана. Бусының кәүсәсе кутыр, сөяль белән капланган сыман, карап торырга бер дә күңелгә ятышлы түгел. Исеме дә аның «Бородавчатый», ягъни мәсәлән, «Сөяльле каен». Карел каены дип икенче исеме белән дә атап йөртәләр аны. Юкә, зирек, фин чыршысы, усак, карама, өрәңге агачлары да күренгәли...

Гафур беренче тапкыр урманга килеп кергәндә, үзләрендәге төсле яшел

юрган булып яткан болынга тап булгандай хис итте үзен. Әмма ул хатасы ике-өч адым атлауга ук сабак бирде үзенә. Ястык сыман күпереп торган ямь-яшел уйдыкка саксыз кыланып басуга, ике аягы да аска убылып, егылып китә язды. Юк, бу – бездәге кебек куе яшел чирәм үләне түгел, өсте кабарып, күпереп торган, асты буш мүк кәмәше генә икән. Алдавыч тозак итеп махсус ясап куйган шикелле бу каләм. Гафурлар авылындагы кебек төрле рәвештәге үлән-үсемлек биредә сирәк-мирәк кенә очрый. Аның каравы, җир астыннан гөмбә төсле калкып чыккандай яшелсу, кызгылт гранит-мәрмәр, тагын әллә ниткән чуар ташлар анда-санда кукраеп утыра. Мунча шаелары җәелеп ята хәтта. Борынгы дәвердә янартаулар атып чыгарган зур-зур каты токым кыерчыклары, ком-ташлар мүк белән чорналып беткәннәр. Валун дигәннәре дә байтак, кырларны, сөрү җирләрен басып алган.

Хәер, балалар, гөмбә вакыты үтүгә, урманда сирәк кунак. Татлы, сутлы җиләк-җимеш белән сыйланасың килсә, сазлыкка бар икән! Анда бата-чума йөрүе куркыныч, әлбәттә; әмма мүк җиләге, саз җиләге, сазанак , күк җиләге ише мимылдап, кызарып, каралып торганнарын кайдан табасың тагы?! Шул шомлы, хәтәр баткаклыкта гына. Шуңа күрә бала-чага, бер күнеккәч, җәй буена шуннан кайтып керми. Билгеле, өлкәннәр үзләреннән башка, ялгыз гына йөрергә рөхсәт итмиләр сазлык тарафларында. Аягыңнан суырып кына алыр ул төпсез сазлыкларның җен-пәриләре.

Гафурның эше җайлы: алдавыч урыннарның һәрберсе, һәр адымы белән яхшы таныш, ышанычлы юлдашы Ваассила бар... Тәүге тапкыр карурманны аркылыга-буйга айкап чыгулары да хәтердә нык сеңеп калды. Хәзер Ваассила этисе белән эштә. Блади абзый күчеп килүчеләрнең өйләренә мич чыгарудан бушамый. Балта белән эш итәргә дә осталыгы бар. Хутордан-хуторга йөртәләр аны шулай. Гафур бүген урманга иптәш итеп күрше хутордан килгән ахире Шәрифне ияртте.

Урман урман инде... Як-якка карана-карана, беренче аланга аяк басуга ук, тирә-юньдәге зеңләп торган тынлык шомландыра, әсәрләндерә. Шылт иткән тавыш та ишетелми ләбаса: колаклар чыңлавы гына. Гафур, шактый ук тәшвишләнә калса да, аны-моны сизмәгән атлы булып, игътибарны башкага күчерергә тырышты.

– Күрәсеңме, менә бу юкәне? Кармак сабына менә дигән бит, малай, ә? – диде дә, үткен пәкесе белән бер чыбыкны кисеп тә алды. Шәриф тә, кызыгып, үзенә дә бер саплык ясап бирүен үтенде. Биредә җиләк, чикләвек ише нәрсәгә юлыгуың икеле, аны-моны эзләнеп, туктап торырлык сәбәп юк, шуңа күрә малайлар урман эченәрәк үтәргә булдылар. Тора-бара әле генә куе чатыр булып, кояш нурларыннан ышыклап торган төз, зифа агачлар сирәгәеп, урман күзгә күренеп үзгәрде; як-ягы шыр ачык зур гына аланга, дөресрәге, агач төпләре генә тырпаеп калган алагаем киң кырга әверелде.

Теге нәрсә икән ул, бусы, дип ымсына-ымсына, үрә катып, карашны алга төбәп, аяк астын чамаламый гына кабаланып бара торгач, Гафур көтмәгәндә тирә-ягын мүк сарган тирән чокырга мәтәлеп төшмәсенме! Төште дә, кечтек кенә шүрләвен күрсәтмәс өчен берни булмагандай, ваемсыз гына арлы-бирле каранып торган итте. Черек-мерек агач кисәкләре тырпайган, киноларда гына күргән окоп сыман, озынча баз иде бу. Үткән сугыш хатирәсе! Кайсы гаскәрнең ут сызыгы булуы да әлегә нәмәгълүм.

Андый-мондый куркыныч шәйләнмәгәч, Шәриф тә дусты янына сикерде. Чокырның бер читендә, туфрагы убылып торган төшендә ишек сымак нәрсәне дә иң элек ул күреп алды, очлы күз.

– Анда блиндаж дигәне.. ну инде, солдатлар кереп ята, йоклый торган урын түгел микән, – дип гөман кылды ул.

– Кая әле! – дип, атаманлыкны үз кулына алырга ашыкты Гафур һәм аяк астында аунап тутыккан тимер кисәге белән шул култыкны чокып казырга тотынды. Ел буена җилләнеп, кибеп, көпшәкләнеп беткән туфрак тиз биреште һәм казылган урында сынык-җимерек бүрәнә, черек такта калдыклары астыннан ниндидер тимер кап ялтырап күренде. Өргәләп-сөрткәләп чистарта торгач, аның аккургаш йөгертелгән дүртпочмаклы калай булуы беленде. Портсигар калдыгы гынадыр, дип ачып карасалар, эчендә – ниндидер сүзләр язылган кәгазь кисәге. Язуы тонык, беленер-беленмәс кенә, шуңа күрә артык юанмадылар аның белән. Кайткач яхшылап карарбыз, дип, кесәгә тыккач, янә туфракны актарырга керештеләр. Телдән әйтмәсәләр дә, уйларында ни булганын чамалавы читен түгел иде батыр малайларның. Бер-бер кызыклы әйбер, пистолет-мазар килеп чыкмасмы, дип өтәләнүләре.

Шактый казыну бушка китмәде, ниһаять, каз йомыркасыннан аз гына зуррак, очлы түгәрәк тимер кисәге аяк асларына тәгәрәде. Чиратлашып кулга алып, учта сикерткәләп карадылар, кечкенә булса да әллә ниткән авыр, саллы гына, кабыргалы чуен ише булып чыкты бу әйбер. Шартлата торган граната-мазар түгел микән? Шундый сыек уй йөгереп үтте дә Гафурның башыннан, шуның белән каядыр ми почмагында адашып, тынып та калды. Табылдыкка кесәләрне тагын бер уч патрон гильзасы белән тутыргач, сугыш базының кирәге-кызыгы калмады. Малай-шалайга табышларын күрсәтеп мактану нияте белән артларына ут капкандай ашыгып, авылга җилдертте ике дус.

Алты-җиде йортлы авылны авыл дип атавы да әллә ничек кенә. Кызылтаңнар икешәр-өчәр гаилә булып бүтән хуторларга таралган. Кайсылары фин карелларыннан калган ызбаларга кереп урнашкан. Икенчеләре шыгырдап торган эре-эре нарат бүрәнәләреннән йорт, каралты-кура сала. «Балкыш» колхозы идарәсе карары белән бүтәннәр аларга ярдәм күрсәтә. Колхоз составындагы карачишмәләр, йомратлылар, кәчеләр колхоз үзәгендәге медпункт бинасын төзүне бетереп киләләр. Рамазан абзый көнозын бер төзелештән икенчесенә күчеп йөри, әле бакчачылар янына барып чыга, әле күпьеллык үлән чәчелгән көтүлектән әйләнеп кайта. Выборгка да өч-дүрт көн саен киңәш-мигәшләргә чакыртып торалар. Өй хәлләрен белешергә дә җай тапмый кайчагында. Бүген дә шунда, түрәләр катында.

Бу вакытта исә аның акыллыбаш, эшлекле, уңган ише саналган улы Гафур кунакка күрше хуторда яшәүче Шәрифне һәм дә шартламый калган Ф-1 дигән, солдатлар телендә « лимонка» дип аталган граната тотып кайтты. Авылда бүтән бала-чага заты күренмәгәч, ул өйгә керә-керешкә үк:

– Әни, карале, без нәрсә таптык. Лимонка! – дип шәрран ярды, асыл кош тоткан кебек, кәпрәеп. Өммегөлсем апа камыр күәсе белән мәш килгән җиреннән аның ни әйткәнен ишетеп бетермәдеме, аннары гына тегенең сүзен аңлады:

– Ни дисең, балам, нинди лимон ул булмаганны?! – дип, колакларын торгызды.

Шәриф белән бер-берсенә карашып, горурланып елмаештылар да Өммегөлсем апа алдына теге карасу төстәге гранатаны китереп тә куйдылар.

– Тәүбә, әстәгъфирулла! – диде әнисе, дары исе, сугыш исе килеп торгандай тоелган чиркангыч тимер кисәген күргәч. – Зарарлы, зыян китерерлек әйбер түгелме соң бу? Кайдан алдыгыз моны?

– Шул урманнан инде, окоптан. Граната дип атала бу, белдеңме?! – диде Гафур, исе китмичә генә, дусты белән кул юарга дип, урамга чыгып барганда.

Ананың хәрбиләр, армия чутыннан бернинди мәгълүматы булмаса да, сугыш ярчыгыннан ниндидер бәла-каза янавын күңеле белән сизенде. Ни генә булмасын, ашыкмавың хәерле. Эченнән генә «Атасы кайткач нишләтергә белер!» – дип, камырлы кулын сөрткәч, теге лимонканы алъяпкыч итәгенә иплэп кенә тәгәрәтеп төшерде һәм, як-ягына каранып торганнан соң, су чиләгенә куеп, идән астына ук яшерде. Чыгып кача күрмәсен, дигән күк, баз капкачы өстенә авыр комодны сөйрәп бастырды.

Кичен кияве белән кызы килгәч, Өммегөлсем апа табында хуш исле чәй ясаганда, иренә ишарәләп, шаяртка биреп:

– Әнә, улың Шәриф белән... лимон диме... алып кайтканнар монда, чәегезгә турасагыз шәп булыр, – диде. Аннары, идән астын ачып, чиләк төбен күрсәтте:

– Менә шушы була инде лимон!

Ир-атларның күзләре маңгайларына сикерде. Әтисе аптыраудан чәшкәсен чамадан тыш чыкылдатып, тәлинкәсенә куйды. Хәким абыйның йөзе бөтенләй агарып катты. Ни икәнен һәйбәт белә иде ул аны, хәрби сборларда чиләнгән запастагы кызылармеец.

– Бәтәч! – дип куйды ул үзе дә көтмәгәндә, – бу бит граната! Каяле... уф, божрасы урынында икән... Кайдан, ничек тапканнар аны, менә шул божрасын тартсаң, көлләре күккә оча иде ләбаса. Ярый, бәхеткә, анысына тимәгәннәр. Уф...

– Тизрәк ваенныйларга җәвить итәргә кирәк! – Куркуы аныкыннан ким булмаган йорт хуҗасының беренче сүзе шул булды.

– Тукта, бабай, сабыр ит! Уйлашыйк әле. Бу заманда корал белән уйнарга ярамый. Хәрби комендатурага хәбәр итеп, башыбызга бәла генә алмабызмы диюем?! Дөрес аңламаслар безне, сугыш кырында нидер казынып йөриләр, дип допрослый башласалар? Заманасы шундый, һәр нәрсәдән шикләнеп, дошманлык билгесе табарга гына торалар. Минем белән булган хәлләрне үзегез дә беләсез , – диде кияү, каушавыннан тирләп чыккан муенын сөртә-сөртә.

Бабай шым булды. Кияvенең сүзләрендәге хаклык аның миен яндырып үткәндәй итте.

– Әлсәм, нишләтәбез? – дип, аңа бердәнбер өмете-ышанычы итеп бакты ул. Әбисе дә, ни үле, ни тере, дигәндәй, киеренкелектән ялварулы карашын әле берсенә, әле икенчесенә күчерде.

– Беркая да нитмибез... хәбәр итмибез! – дип нокта куйды кияү. – Сазламык-баткаклыкларның очы-кырые күренми монда... Иң ерак, аулак почмагына олактырырмын ул лимонканы! Бетте-китте! Ә

малайларның колагына каты итеп киртләргә! Бу турыда һичкемгә – ни-ни, ...ычкындырмасыннар!

Урман тишегенә үк кереп, сәбәпсез-нисез сәйран кылып йөргән ике сәяхәтче малайны, бу нәрсәдән нинди куркыныч янавын колакларына тукып, орышып, җелекләренә үттеләр. Туган авылларына кайтарып җибәрү белән дә куркыттылар хәтта. Боларның эчләренә пожым керде. Алар өчен нык сабак булды бу хәл. Теләсә кайчан, теләсә кайда авыз ачып, теләсә кайда тыкшынып йөрмәскә ант иттеләр. Шуның белән бергә, олыкараның үзләрен инде дәү үскән кешеләргә, үзләренә тиң санап, урмандагы вакыйганы уртак сер итеп сакларга кушулары бер карышка үсендергәндәй булды малайларны. Һәм шундый ышанычны аклау өчен, дөрестән дә, һичкайчан артык-портык сүз чыкмады алар авызыннан. Әмма ләкин нәкъ шул вакыйгадан соң өлкәннәр күңеленә гөберле бака кебек нидәндер курку, шом иялӘште.

Гафур теге портсигар кабын да чыгарып күрсәтмичә булдыра алмады. Хәким абый аны кулында әйләндереп-тулгандырып карады да:

– Юк, портсигарга охшамаган бу. Сугышчылар муенга тага торган бөти кебегрәк медальон түгел микән?! – диде. Эчендәге кәгазь сәләмәсен өстәлгә салып, сыпырып тигезләгәч, озак маташты, әвәрә килде ул аның белән. Ниһаять, аннан ниндидер сүзләрне хәрефләп-берәмтекләп укып чыгуга иреште. Дерт итеп куйды да тирә-ягындагыларга күз йөртеп алды. Беравык аларга ни әйтергә дә белмичә тынып торды. Үлем медальонындагы кәгазьгә танылыр-танылмас хәрефләр белән русчалатып «Кызыларммеец Баязитов Вәли Азатович, ТАССР, Чишмәле районы Җиләкле авылы» дип язылган иде. Ә ул исә Хәкимнең ахирәт дусты, якын сердәше иде.

## 6. Мордва кызы Гелия һәм башкалар

Күчеп килүчеләрнең карел җирендәге беренче җәе дә үтеп бара. Урман чолганышында яшәгән бала-чаганың, йортлы-йортлы уенындагы сыман, билгеле бер сызык аркылы атлап узарга ярамаган кебек, хутор биләмәсеннән ары һичкая борын тыкканы, анда-монда чыкканы юк әлегә. Кече гражданнарны тышкы дөнья белән таныштырырга вакыт икәне авыл советында эшләүчеләргә дә барып җитте бугай, ниһаять. Хәким абый, каенесе Гафур, Шәриф, Морат, Нәсимә кебек өлкәнрәк малай-кызлар ярдәме белән урман сукмакларын таптап, төрле авыл-хуторлардан мәктәп яшендәгеләрне колхоз үзәгенә җыйды. Кечкенә автобуска кертеп утыртканда, ул:

– Балалар, хәзер Выборг каласына экскурсиягә барабыз. Тыныч гына, тәртипле йөрегез, бер-берегездән аерылмагыз, – дигәч, һәммәсе дә дәррәү ура кычкырдылар. Үзара очрашуларга тансыклаганнары, өр-яңа тәэссоратка сусаганнары әллә кайдан беленеп тора иде...

Автобус Выборгның үзәк мәйданына килеп туктады. Балалар өчен иң мавыктыргыч мизгелләр төбәк музеенда булгандыр, шәт. Алар монда Выборгның Виипури дигән атамасы да барлыгын исләре китеп тыңладылар. Фин телендә шулай йөртелә икән бу шәһәр. Аннары балалар өчен иң күркәме – урамда, сәйранда дәвам итте. Шәһәрнең символы – 17 гасырда ук төзелгән өч катлы Иске Ратуша бинасын, Базар мәйданындагы «Юан

Катерина» исемле Түгәрәк манараны карадылар. Ташпулат ише нәрсәләр, гадәттә, бала-чаганы әллә ни үзенә җәлеп итми. Алар атаклы шәхесләрнең купшы итеп тимердән йә мәрмәрдән коелган һәйкәлләрен карарга ярата. Пётр Беренче хөрмәтенә куелганын зерә дә ошаттылар. Швед маршалы Торгильс Кнутссон һәйкәле тирәсен исә Гафур белән Шәриф кат-кат йөреп әйләнделәр, югарыга карый-карый, башлары муеннан өзелеп төшә язды. Шәриф экскурсоводтан «Чин буенча кайсы зуррак: Ворошиловмы, әллә шушымы?» дип сорарга бик каударланган иде дә, Гафур аның итәгеннән тартып өлгерде. Советлар Союзы маршалы Ворошилов образын үзе өчен үрнәк иткән, шуның белән тәмам саташа бит дусты...

Хәер, вакыты шундый иде, әле монда, әле тегендә сугыш уты кабынгалап тора, һавада дары исе сиземләнә, һәр дивардан полководецлар, сугыш батырларының сурәтләре елмаеп карап тора. Ә бу көләч, шаян малайларның, кызларның нибары берничә айдан сугыш романтикасы корбаннарына, төгәлрәге, дәһшәтле сугыш балаларына әвереләчәкләре төшләренә дә керми иде әле...

Башта, «Яктылык рәтләп йокы бирми», дип, ак төннәргә күнә алмыйча җәфаланганнар иде дә, инде әнә караңгы, пычрак көз дә килеп җитте. Төрле хуторларга, вак торак пунктларына чәчелеп яшәгән кызылтаңнарның, тагын берничә авылның балалары мәктәпкә җыйналган 1940 елның 1 сентябре көне аеруча истәлекле булды. Үзәктәге берничә бүлмәле, күркәм генә агач бина татар мәктәбе өчен тәгаенләнгән иде.

Рамазан абзыйлар, ата-аналар, олы-кара сөенә-сөенә балаларга нотык укыштыргалап, колакларына тукыштыргалап, линейка сыман тантана үткәргәннән соң, элек бу җирләрдә һичкайчан да яңгырамаган кыңгырау тавышы укучыларны парта артларына өндәде.

Укытучылары – күченеп килүчеләрнең үз араларыннан ук. Хәким абый тарих, география, биология дәресләрен алып бара. Аның хатыны Фирая апа – Гафурның бертуган апасы була инде ул – башлангыч классларга керә. Физика белән математиканы Юмратлыдан Зыя абый Кәбиров укытырга алынды... Керәшен татары Николай Смирнов исә мәктәп директоры вазифасы белән бергә, рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнде. Пионервожатый Кәче авылыннан Әхсәнә атлы сары чәчле кыз иде.

Күчеп килүчеләр арасында күпчелеге руслар иде, әлбәттә. Шуңа күрә дә аларның балалары өчен уку бинасы да зуррак. Өстәвенә, җаны теләгәненең Выборгның үзенә үк йөреп укырга мөмкинлеге бар. Биш-алты бөртек чуваш, мордва баласына аерым мәктәп ачып тормадылар, аларга да шулар белән белем эстәргә тәкъдим ителде. Кызыл Таң татарларыннан торган «Балкыш» колхозында тимерче һөнәрен үзләштергән чуваш Андрей пиччәнең Костя дигән малаен, тагын умартачы мордва кызы Гелияне татар мәктәбенә үзләре теләп яздырдылар ата-аналары һәм моны табигый итеп санадылар. Икесе дә татарчаны су урынына эчә, җәй буе татар балалары белән аралашкач, безнекеләрдән аерып та булмый башлады үзләрен.

Сыйныфларга бүлгәндә, кызык кына хәлләр дә чыккалады. Гафур яше буенча җиденче сыйныф программасын «кимерергә» тиеш. Исемлектә ул, Кудашева Гелияне исәпләмәгәндә, берүзе генә. Юк икән әле, партага кереп кенә утырды, аның янына Шәриф килеп сырышты.

– Мин дә синең белән... Тегендә җыен ыбыр-чыбыр, – дип җирәнгәндәй, кул селтәп, күрше бүлмәгә ишарәләде һәм киндер букчасын парта астына ук тыгып куйды. Тик Хәким абыйсы эшне боза язды. Беренче дәрес башланыр алдыннан аңа сәерсенеп карап алды да:

– Син нәрсә, Заһитов, сыйныфыңны буташтырдыңмы әллә? Синең алтынчы сыйныф теге бүлмәдә, дүртенчеләр белән бергә ләбаса... Хәер, син анда берьялгызың буласың икән бит... Һм... Кызык. Дустың Гафур да биредә синнән башка япа-ялгыз калачак, – дип көлемсерәп, тубал чәчен артка сыпыра-сыпыра уйга талды. Шәриф, ялваргандай, күзләрен зур ачып, укытучыга мөлдерәтеп карап торды. Гафурга әллә ничек кенә җәл булып китте ахирие. Кулын күтәрде дә:

– Калсын ул безнең класста, Хәким Сабирович! Дәресләрен әзерләгәндә, үзем ярдәм итешермен, – диде.

Директор белән Хәким абый, исәпли торгач, уртак карарга килделәр: Заһитов Шәрифне 7 нче сыйныфка күчерергә. Бәширов Гафур исә аңа уку барышында даими рәвештә булышлык итәчәк. Шулай итеп, Шәриф ярты ел эчендә 7 нчеләрнең уку программасын куып тотарга тиеш була.

Әле бит шул ук бүлмәдә кечерәк яшьтәге тагын ике-өч бала утыра. Болар – бишенче сыйныф укучылары. Бер яктагы ике парта җиденче сыйныфныкы, ягъни Гафур, Шәриф һәм Кудашева Гелиянеке. Каршы якта – бишенчеләр, ике кыз да бер малай өчен ике парта куелган.

Хәким Сабирович беренче, танышу дәресен уртак темага үткәрде. Аннары инде берьюлы ике сыйныф дәресен дә алмаш-тилмәш алып барды. Бишенчеләр белән эшне көйләгәч, җиденчедәге тәүге география дәресендә өчесенә дә бер үк эш бирде ул. Союздаш республикаларның оешу елларын һәм башкалаларының исемнәрен язып бирергә кушты. Хәйләкәр үзе, сыйныфның старостасы итеп бик тә тәртипле, йөкләнгән эшне үтәргә дигәндә борылгаларга урын калдырмый торган, таләпчән Гелияне билгеләп куйды. Менә бүгенге дәрес темасы буенча язма эшне дә ул җыеп бирергә тиеш була, димәк.

– Йәле, егетләр, – диде педагог, – сез алгы партага күчеп утырыгыз! Арткысында Гелия утырыр.

Шук, шаян малайларның арттагы урыннарда, «Камчаткада» шаярып-уйнап утыруларына юл куймас өчен һәм күз алдында торсыннар өчен шулай эшләде ул моны. Малайлар яраткан урыннарын теләр-теләмәс кенә бушаттылар. Озын чәч толымнары уртасында күбәләк төсле алсу тасмалы, куе, кара уктай керфекләре гел шул күбәләк канатлары кебек тибрәнеп торган, үзе дә күбәләктәй җиңел гәүдәле кызчык тыныч кына артка күчеп утырды... Четерекле вакытларда кирәге чыкса, Гелия язганны арттан шыпырт кына күчереп алулар малайлар өчен шымытыр хәзер, димәк.

Гафур да чегән арбасыннан төшеп калмаган, белеме шактый гына. Хәзер дә Белоруссия ССР, Украина ССР кебекләрен бик тиз хәтерләп, дәфтәренә теркәде ул. Ә менә Карелиягә, тагы берничә союздаш республикага бәйләнешле белешмәләрне искә төшерү чишелмәс төен булып чыкты. Ул хакта мәгълүматы искергән иде. Җитмәсә, үзе батыраеп шефлыкка алган Шәриф тә өзми-куймый: «Әйт инде, әйт инде», дип сорап ялына, бәйләнә. Ә Гелия байтактан инде эшен бетергән дә тәүфыйклы песи кебек алдына карап

утыра бирә. Бераздан ул итагатьле генә итеп, малайлардан язма эшләрен бирүләрен үтенде. Сыкранып кына тапшырырга мәҗбүр булдылар Гафур белән Шәриф. Чөнки алларына укытучы үзе килеп баскан иде. Ул, җитез генә дәфтәрләргә күз йөртеп чыкты да Гелиягә елмаеп карады.

– Булдыргансың, Гелия! Эшеңә – «биш»ле! – диде. – Ә сезнекенә, сердәшләр, «өч» ледән артык куялмыйм. Ник дисәгез, СССРда союздаш республикалар саны бүгенге көнгә 16 га җитте. Ә сезнең җавапта алар 11дән артмаган күренә. Быел март аенда оешкан Карел-Фин союздаш республикасын һәм күптән түгел генә, августта Советлар Союзы составына союздаш республика сыйфатында яңа кабул ителгән тагы 4 республиканы онытып калдыргансыз. Гелиядә исә төп-төгәл, аңардан үрнәк алыгыз әнә. Җәйге ял вакытын бер дә заяга үткәрмәгән ул.

Менә бит Хәким абыйсы нишләтә: беренче карашка ансат булып күренгән, әмма башватмалы нинди хәтәр сорау биргән, ә? Ике малай да ал тасмалы чибәр кызчыкка ихтыярсыздан хөрмәт белән карап куйдылар. Бүтән дәресләрдә дә малайлардан өстен икәнен күрсәтте тыйнак кына мордва кызы. Чыннан да, җәйне уйнап-көлеп, шаярып кына йөрмәгәнгә охшый бу кызчык. Мәктәпкә хәстәрләнгән, укыганын искә төшергән, яңа мәгълүматлар туплаган. Ә малайлар малайлар инде алар, уен-муен белән мавыгып, икесенең дә дөнья хәлләре белән кызыксынырга вакытлары калмаган. Югыйсә республика, район газеталарын хат ташучылар түләүсез тараталар. Гафурның әтисе, болардан тыш, бүтән матбугат басмаларын колхоз идарәсеннән үзе белән дә алып кайткалый иде...

Мәктәптән чыккач, юллары бер юнәлешкә туры килде Гафур белән Гелиянең. Шәриф исә бүтән якта яши... Әллә ничек кенә тәртипсез-рәтсез урнашкан бу тирәдәге хуторлар. Берсеннән чыгып, урман эченнән бара торгач, көтмәгәндә генә икенчесе, аннары өченчесе пәйда була. Һәркайсы күп булса ике-өч йортлы. Күченеп килгәч кенә өйләр саны күбәйде, яшәүчеләре дә ишәйде. Гафур үзләренә керә торган сукмак янына җиткәч тә, шунда таба борылырга аяклары тартмыйча, кисәк кенә туктап калды. Бүген күңелен тетрәндереп, бөтенләе белән яулап алган акыллы, зиһенле, чибәр мордва кызы белән аерылыша алмый изалана ул. Аның кулындагы букчасын үзенә алып, кызны өенә кадәр озата барырга булды. Гелия каршы килмәде.

Башта дәшми генә бардылар. Шуннан соң гына Гафур, сүз урынына сүз булсын дигән кебек:

– Ә бит синең исемең татарча икән! «Гөлия» безнең кызлар исеме бит ул. Фамилияң Кудашева да безнеке, – дип, үзенчә ачыш ясады.

– Алай ук түгел. Исемемдә «г» хәрефеннән соң «е» хәрефе куела, ә сезнең Гөлиягездә түгәрәкләнеп «ө» хәрефе тора. Фамилиябезгә килгәндә, ул да борынгыдан ук безнең нәселнеке, – дип, йомшак кына әйтеп, татар грамматикасы буенча да, тарих буенча да хәзерлекле булуы белән таң калдырды кызчык. Аның тавышы да матур: үзенә бер төрле җылы төсмер, басынкылык бөркелеп тора иде. Гафурга тагын телен тешләргә туры килде килүен, һе, тез астына сугып егарсың чая егетне тиз генә!

– «Сәлам» сүзе ничек була сездә, мордва телендә? – дип, янә әңгәмәне ялгап җибәрде ул.

– Шумбрат! – дип, эчкерсез, матур итеп елмайды Гелия.

– Ә менә «Хәлләр ничек?» дисәң, сезнеңчә ничек була?

– «Кода тефне?» була... Йә, ярый, бүгенгә җитеп торыр грамматика дәресе, – диде Гелия әдәпле генә, юлдашының хәтерен калдырмаслык итеп. Бу вакытта алар юл читендә кыяташ булып калыккан иләмсез биек валун турысына килеп җиткәннәр иде инде. Монда да Гафурга егетлеген күрсәтергә җай чыгып тора бит әле. Ул букчаларны җиргә куйды да мәче тизлеге белән үрмәләп, шактый шома валун түбәсенә менеп тә китте. Валунның иң очында кулларын баһадирдай биленә куеп, һәйкәл кебек басып торуын гына күр син аның! Бу юлы инде Гелия малайга карап сокланмый булдыра алмады.

– Аннан niләр күренә, Гафур?! – дип кызыгып та, көнләшеп тә сорады ул. Малай, урман эченә текәлгән килеш дәшми торды. Ул нindидер серле-сәер нәрсә күргәндәй, бер урында кадаклаган кебек катып калган. Аннары кемнәндер башын яшерергә ниятләгәндәй бөгелә төште. Бу тикмәгә түгел иде. Тегендә, урман сирәкләнгән аланлык күк ачык урында чуар киемле нindидер чит ир-атның гәүдәсе шәйләнде. Әледән-әле тукталып, алан-йолан карануы, астыртын гына нидер күзәтүе белән үк шиккә калдыра иде ул... Аркасында биштәр, аягында сазлыкта йөри торган озын кунычлы резин итекләр дә бу яклардагы кешеләргә хас түгел иде. Гафур җәһәт кенә таш тавыннан төште дә дәшми-тынмый букчаларны кулына алды һәм шуннан соң гына:

– Китик без моннан, – дип, кызны алга әйдәкләде. Гелияләр яшәгән урынга кадәр ерак калмаган иде инде. Аларның йортына барып кергәч тә, үзенең шик-шөбһәсен Гелиянең әтисе белән уртаклашты малай. Янәсе, граница, чик буе якында гына, берәр диверсант-мазар түгелме теге сәер кыланышлы адәм? Гелиянең әтисе – күсә битле, көләч агай елмаеп кына кулын селтәде. «Берәр аучы-фәләндер». Гафур да куактан да өреккән мәгълүм карга кебек адәм көлкесенә калмас өчен бәхәс куертып тормады, бу хакта сүзен түгәрәкләргә ашыкты. Чәй эчкәннән соң, кунакчыл хуҗаларга алар телендә «Сугыпрә» дип, ягъни рәхмәт әйтеп, кайту җаен карады.

## 7. Туган җир җирсетә шул

Көзгә кергәч, әбиләр чуагыдай коры, җылы көннәрдә тагы бер күңелле мәшәкать өстәлде Гафурга. Өммегөлсем апа, бүтән дус-ахирәтләре белән берләшеп, якшәмбе көннәрендә Выборг базарына сөт-катык илтергә күнегеп китте. Сыерлары сөт-майдан, катык-каймактан яздырмый, хуҗаларыннан артып та кала әле, рәхмәт төшкере. Ә Гафур иртән әнисен йөге белән олы юлга кадәр озатып куя торган булды. Ул, йокысы бүленсә дә, моны бик теләп башкара. Чөнки шул рәвешле үз әнисен озата килгән Гелия белән күрешергә җай чыга бит. Мәктәптә генә аралашу җитми башлады кебек, аның белән гел икәүдән-икәү калып сөйләшәсе генә килеп тора. Мәктәптә Шәриф тә комачаулый аннары...

Олы юл читеннән апа-сеңелләр китә бер мәлне шәһәргә таба аккошлар кебек тезелеп. Көянтәле чиләкләр асып, яисә болай гына ике кулга ике кәрҗин, букча тотып. Яше буенча өлкәнрәк булса да, Өммегөлсем апа

башкалардан бер карыш та калышмый. Зифа гәүдәсен яратып карап кала торган иде аның артыннан Гафур: көянтәгә эленгән ике чиләк мал авырлыгын белми дә, әнә ничек җилгер элдертә әнисе! Ә бит бәхетләренә машина туры килсә генә утырып баргалыйлар, күбесенчә – тәпи-тәпи. Кайтканда, җиңеләеп, буш куллар белән диярлек кайталар үзләре. Базарда сөтен дә, помидор-кыярын да бишкуллап алалар икән. Шуңа да базарга йөрүдән һич гайрәтләре кайтмый апаларның, яшь киленнәрнең.

Бүген дә шулай булды. Бер-бер артлы тезелеп китә башлагач та, Өммегөлсем апа әле генә келт итеп исенә төшкән ашыгыч йомышын, борылып, кат-кат әйтмичә булдыралмый. Әлбәттә, Гелиянең әнисенең дә ашыгыч гозере табыла. Гелия үз телендә, көлә-көлә, кул болгап нидер җаваплый. Күңелле, кызык аның белән. Бу юлы Гафур аңардан «Озатканда, әниең нинди йомыш кушты?» – дип сорады.

– И аның сүзе бетәмени соң! – дип яратып көлде кыз. – Сеңлеңне садикка илтергә соңга калма, дигән була. Калырсың аның белән. Мин кайтканчы ук торып утырган була инде ул... Әйдә, кызурак атлыйк әле, Гафур! Елап ятмасын тагы бичаракай.

Гелия шундый инде ул, эшлекле, уңган кыз. Ашыкканда да, кичә өйгә тапшырылган эшнең үтәлеше турында сорашырга онытмый. Мәзәк кенә килеп чыга бит әле: Гафур Шәрифне шефлыкка алса, Гелия икесенә дә тынгылык бирми, барлык фәннәр буенча да сораулар яудырып, аптыратып бетерә. Ә бит шулай укый-тукый торгач, белем буенча Шәриф булып Шәриф тә тигезләшә башлады үзләре белән.

Үз хуторына җиткәч, гадәтенчә матур елмаеп, саубуллашып, сукмак буйлап каерылып кереп китте классташы Гелия. Күңелен ниндидер татлы юксыну хисе били башлаган малай исә шундук «Иртәгәсен мәктәптә очрашабыз бит», дип үзен-үзе юатты.

Япа-ялгыз кайтканда, Гафур мәгълүм валун яныннан җәтрәк үтәргә тырыша. Мәктәптә беренче кыңгырау көнендә урманда поскан теге чит кеше сурәте һаман хәтереннән китми, бимазалап тора иде. Ә башкалар берни дә булмаган кебек тыныч кына яши бирәләр. Әллә Гафурның күзенә генә күренде микән ул ят адәм актыгы?

Көннәрдән бер көнне гадәтенчә кичкә таба базардан кайтып төшкән әнисе каладагы яңалыклар турында сөйләде. Сүз базардагы бәяләргә кереп китте. Шәһәр халкы сөт, май, эремчекне бик теләп ала дип, куанычын уртаклашты. Шуннан соң кешедән ишеткән гадәттән тыш хәлләрне әсәрләнеп бәян итте Өммегөлсем апа:

– Беләсеңме, атасы, базарда безнең кебек Тамбов якларыннан күчеп килгән бер марҗа сөйләп торды. Моның килененә үзе белән бүлнистә бергә яткан бер тол хатын сөйләгән...

– Теге хатынга фәлән сөйләгән, фәләне төгәнгә... – дип көлеп бүлдерде аны Рамазан абзый. – Куян шулпасының шулпасының шулпасы килеп чыга инде азактан... Ну, сөйләргә оста да инде сез, җыен кыз-хатын, тузга язмаганны, булыр-булмастайны, имеш-мимешне!

– Туктале, син, авызыңны иләктәй җырырга ашыкма! Сөйләп бетергәнне көт баштан! – дип, ачуы кузгалып алды ни сабыр Өммегөлсем апаның. Тынычлана төшкәч, хикәятен дәвам иттерде:

– Шул, әлеге тол хатынга кара төндә әллә финмы, әллә карелмы килеп кергән, ди. «Курыкма, сиңа тамчы да кагылмыйм! Син минем өйдә яшисең. Моның өчен гаеп итмим, йортымны дауларга дип тә килмәдем. Сүзем юк. Син дә мине тыңла, зинһар... Мин теге яктан, чик аша, сазлык буйлап чыктым. Юк, юк, ниндидер зыян-зәвер китерү өчен түгел. Мине хәзер һичнәрсә кызыксындырмый, дөньясыннан гарык! Изге туфрагымда үләргә кайттым мин монда. Үземнең туган нигеземдә җан бирәсем килә... Менә сиңа бер төргәк акча, шикләнмә, бу сезнеке, сәвит акчасы. Бөтен гомереңә җитәрлек! Тик син мине үлгәч, әнә, бакчада чит кеше-кара күзе төшмәс аулак урында торган пар каен төбенә күмеп куй. Гәүдәмне иртән сарай эченнән табарсың!» – дигән. Нишләсен инде ялгызак хатын?! Җәвить итәр иде, теге адәм үзен хәл итүе бар. Акчасы да кызыктыра бит әле аның. Кыскасы, иртән чыгып караса, теге кеше асылынып үлгән, ди. Теге хатын мәетне элмәктән төшереп, күзләрен йомдырып, кабер казып күмеп куйган... Шул...

Өйдә киеренке тынлык урнашты. Бераздан гына:

– Мәрхүмне ул хатын мосафир теләгән урынга күмгәнме соң? – дип сорады үтә дә җитдиләнеп киткән әтисе, ияк очын кармалап, чеметкәләп.

– Соң! Әлеге аулактагы пар каен астына инде, – диде әнисе. Бераз тынып, башын чайкый-чайкый уйланып торгач, күзләрен сөрткәләп:

– Балачагы, бөтен гомере шунда үткән бит, ул мескенкәйнең. Ә теге якта беркеме дә калмагандыр. Туган җирем дип җирсегән инде ул... Туган туфрак һәркемгә дә якын, кадерле шул ул. Үз җиреңдә яшәүгә ни җитә! Безгә дә гыйбрәт... – дип сүзен очлады да, авыр гына атлап, чиләк тотып, аранга чыгып китте. Аның артыннан ни гамьсез Рамазан абзый да уйлана калды.

Гадәттән тыш мондый вакыйга булганмы, юкмы, анда түгел иде хикмәт. Өммегөлсем апа туган нигезен, туган туфрагын сагынып, җирсеп кайткан ул чит кешенең хәленә керә белә, хәзерендә үзенең халәте дә шул адәмнең хис-тойгыларына аваздаш иде. Туган җирне һичнинди дә байлык, мал-мөлкәт алыштыра алмый икән. Әтисе дә шуны тоя, сизә башлаган бугай, чит җирдә гомер иткәч...

Әнисенең өй җыештырганда, яисә керләр элгәндә, моңаеп китеп, үзалдына акрын гына ниндидер җыр көйләвен ишеткәләгәне бар Гафурның.

Сандугач күкәй салмасын,
Бала да чыгармасын;
Ризык читкә язса язсын,
Туфрак читкә язмасын.

Әнә шул сүзләрне еш кабатлый әнисе җырлаганда. Бер тапкыр кәефе килеп, улына «Ризык читкә язган»ның мәгънәсен аңлатып бирде. Кешене чит җиргә ашыйсы ризыгы тартса да, гомере читтә өзелмәсен, туган иленә кайтырга насыйп булсын, дигән изге теләкне белдерә икән ул тирән мәгънәле җыр.

Әнисенең шул рәвешле авыз эченнән генә көйләгәнен ишеткәндә, яисә туган илен бер күрергә тилмергәннәр турындагы хикәятен тыңлаганда, Гафур авылдагы таныш сукмакларны, балык тоткан инеш буйларын, печән җыйган җиләкле болыннарны, дус-ишләрен, Акмаңгайны исенә төшерә торган булды. Нихәл икән ул Акмаңгай? Нихәл икән Кыярбаш...

юк, Кыярбаш түгел, ә дусты Сөббух? Әкияттәге кебек күз ачып йомганчы өенә кайтып төшсәң икән ул дип, хыял диңгезенә дә бата торган иде... Урманда күргән теге кешенең дә шул кадәрле өзелеп сагынудан түзмичә туган нигезенә кайтып егылуы ихтимал бит. Хәзер ул аңа алай ук усал, явыз, шпиун-мазар булып тоелмый иде. Гафур йөрәгенең кайсыдыр кырыенда ул мескенне кызгану хисе кымырҗып куюын да сизде хәтта. Алар да безнең кебек бер башлы, ике куллы кешеләр лә!

Рус мәктәбенең бишенче сыйныфында укып йөрүче Ваассиланың ни өчен вакыт-вакыт күңелсезләнеп, моңсуланып, үз эченә йомылып калуын да төшенә, хәленә керә башлады кебек ул. Күрәсең, үз телендә сөйләшүче яшьтәшләре белән аралашу җитми аңа. Гафур белән күңелле дә бит, әмма барыбер телләрнең төрлелеге комачаулый җәелеп китеп серләшергә. Ваассиланың русчасы һаман сыек, аннары күңел биреп өйрәнми дә төсле ул аны. Ә менә кайчагында татарча сүзләрне чибәр генә әйтеп куйгалый! Чөнки очрашкан саен куллары тигән, күзләре күргән һәр нәрсәнең карелча, татарча исемен бер-берсенә әйтеп бирергә күнектеләр Гафур белән Ваассила. Кыш җитеп, чаңгыда шуарга чыккач, Гафур бар көченә татарча җыр сузганда, Ваассила аны игътибар белән тыңлып кына калмый, шул чакларда үзе дә иреннәрен кыймылдатып, тавышсыз гына кушылып киткәндәй була иде. «Сезнең озын җырларыгыз безнекенә охшаган», – дигәне дә бар.

Рәхәт, искиткеч күңелле була икән бу якларда кышын! Һавасы сулап туймаслык, һәрьякта күз карашында киңлек, иркенлек, хозурлык. Урман эче дә яп-якты. Кареллар үзләре ясап кия торган чаңгылар киң һәм авыр, әмма кар өстендә һәйбәт шуа. Кибеттәгеләре бер читтә торсын алары янында.

...Блади абзыйлары беркөнне шундый ике пар чаңгы тотып кергән. Исәнләшкәч, Гафурның әти-әнисенә шатлыклы да, ямансу да яңалык ирештерде. Карел-Фин республикасындагы иң зур шәһәрләренең берсендә аның бик якын туганнары табылган икән. Алар янына күчеп китү мөмкинлеге чынга ашкач, җыену-хәстәрләнүне бик озакка сузмаска булган Блади абзый. Менә хәзер хушлашырга кергән, үзе ясаган аучы чаңгыларын истәлеккә калдырам, ди. Җәйгә һичшиксез бу якка кунакка кайтачакбыз әле, дип тә өстәде. Ызбаларына күз-колак булуларын да үтенде...

Рамазан абзый белән Өммегөлсем апа якты чырайлы кешенең хәлен аңладылар, чын күңелдән кан кардәшләре белән күрешү, бергә тупланып яшәү шатлыгын уртаклаштылар. Әнисе аларның ниятен хуплау йөзеннән: «Үз оясында кош та түлне мул җыя», – дип, хикмәтле сүз әйтеп куйды. Ул гыйбарә Блади абзыйның күңеленә аеруча хуш килде, ахрысы... Тагын бер кат кайтарып сорагач, авыз эченнән генә үзләренчә кабатлап ятлавы булды, күрәсең.

*(Ахыры киләсе санда)*



Таһир
Шәмсуаров

# ҖИР АРЫНГАН ЧАКТА КЫШТАН...

## Нәни ил

Минем өчен җирдә иң якыны,
Аңларсыз дип уйлыйм, атасам.
Кендек каны тамган туган авыл
Һәм әлбәттә мәркәз – син, Казан!

Бу Җир шарын аркылыдан – буйга
Алдый алмыйм, юк, мин гизмәдем.
Күрмәсәм дә әмма үкенмәдем,
Ватан диеп типте йөрәгем!

Урман-таулар, болын һәм чишмәләр –
Гүзәллеге туган ягымның.
Бер тәүлеккә чыккан сәфәремнән
Бер сәгатьтә кайттым, сагындым!

Бишек җыры яши хәтерләрдә,
Ана теле иңгән анадан.
Татарлыкны оныттырмас өчен,
Гасырлардан килгән моң калган!

Илне сөяр булып калыкканбыз,
Малай чакта, Шушма суыннан.
Ә татарлык ата-бабалардан
Бәгырьләрдә гомер буена!

Чал тарихтан изге мирас булып
Тиңсез энҗе-мәрҗән – җыр калган.
Җырсыз халык күптән онытылган,
Җыры барлар исә, сакланган!

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) – *шагыйрь; «Җанлы шәм», «Яратудан тора Җир шары», «Ярату белән» һ.б. китаплар авторы. Лениногорскида яши.*

Яши-яши шуңа инандым мин,
Иң мөһиме менә шуны бел:
Иксез-чиксез илнең таянычы
Без сагынган авыл – нәни ил!

## Татар йөрәгендә ат ята

Кем атлы син, әйтче, замандашым,
Күңел түрләреңдә ни ята?!
Егет солтанының йөрәгендә
Иярләнгән ярсу ат ята...

Болыннарда тайлар уйнакласа,
Үзәннәрдә атлар кешнәсә,
Сикереп мен, әйдә, иярләргә!
Далаларга безне Моң дәшә!

Татар аты кабат кайтты бүген,
Сизәсеңме тояк тавышын?
Күзләренә очкын кунган җайдак
Узган шанлы чорны танысын!

Без тарихка гаярь атта кердек,
Атка менү бизи татарны!
Араннарда Чыңгыз заманыннан
Китмәскә дип кайткан чаптармы?

Татар атлы асыл ир-егетне
Тугры дусты таңда уята.
Ул бүген дә, иртәгә дә шулай
Татар йөрәгендә ат ята!..

## Ана теле

Синең хакта язар өчен
Даһи бер зат булу кирәк.
Мин бу җирдә гади шагыйрь,
Илһамланып тибә йөрәк...

Тукай сыман мәңгелектә
Урын алыр бер җыр язсам,
Туган телне сөюченең
Күңеленә ачкыч тапсам...

Тәвәккәллә, әйдә, каләм!
Таныр мине бәлки чорлар...
Үз дәверен киләчәккә
Илтүчеләр ул – шагыйрьләр!

Әти-әни игезәкләргә
Таһир-Зөһрә исеме кушкан.
Апрель аенда туганбыз,
Җир арынган чакта кыштан.

Гүзәл язда бөреләнгән
Миңа юлдаш шигъри хисләр.
«Шагыйрьмени ул» дисәләр,
Миннән битәр галәм нишләр?!

Тик шулай да тал бишектә
Ана теле миңа иңгән.
Шагыйрь булып яралганнар
Илһам ала туган җирдән.

Хыялымда, Мәҗнүн сыман,
Үз Ләйләмә гашыйк бер җан.
Борынгыдан килгән хисләр
Ургып чыга гармуннардан!

Ана телем! Халкым белән
Төштең тирән шахталарга.
Татар егете моңлы җырын
Ишеттерден җир астында!

Туган телем! Үз илемдә
Аралашам үз телемдә.
Ана телен сөймәгәннәр
Юк, булмады нәселемдә!

Бәхетлемен! Корымаган
Нигеземдә тамырым исән!
Йөзегезгә нур куначак,
«Татар авылы яши», дисәм!

Кайберәүләр аңламаслар,
«Хыялый» дип мине атар.
Гореф-гадәт, дин барында
Киләчәккә атлый татар!

Ватан киткән, тик сөт калган,
Син калгансың – татар теле.
Тел бетә дип уфтанмагыз,
Кояш бит ул – ана теле!

## Бишекләрдә үсми оныклар

Бик еш кына борчу били мине,
Була шундый моңсу минутлар.
Безнең сыман бишек җырын тыңлап,
Бишекләрдә үсми оныклар!

Китап киштәсендә әкиятләр
Сагыналар малай-кызларны.
«Таңбатыр»лар, «Гөлчәчәк»ләр белән
Дуслаштырыйк әле шуларны!

Яз җиттеме, авыл урамнары
Юксынуга никтер таралар.
Хәтфә чирәмнәрдә рәхәтләнеп
Уйнамыйлар нигә балалар?!

Болыннарда тайлар кешнәмиләр,
Кайда калды ярсу байталлар?!
Куе ялларыннан сыйпый алмый,
Атсыз үсә бүген малайлар!

Таң атуга Алсу, Азаматлар
Телефонны кулга алалар.
Сабыйлыкның тиңсез матурлыгын,
Ни кызганыч, күрми калалар!

Бик еш кына бер уй били мине,
Була шундый моңсу минутлар.
Әнисенең бишек җырын тыңлап,
Бишекләрдә үсми оныклар!..

## Өйдә безне әни җылыта

Сәфәр чыга калсак еракларга,
Бер нәрсәне менә онытма.
Суык димә, туган нигез көтә,
Өйдә безне әни җылыта!

Озак торсак, тоткарлансак әгәр,
Кайтмый торсак шактый күп айлар.
Таң атуга тәрәзәдән күзли,
Олы юлдан эзли аналар...

Кайнар чәе берүк суынмасын,
Нурлы йөзен сагыш басмасын!
Юк, саескан түгел, сизгер җаны
Хәбәр итә бала кайтасын.

Исән чакта белик кадерләрен,
Үкенечләр биләп алмасын!
Җирдә беркем әниләрдәй ихлас,
Өзелеп сөйми газиз баласын.

Гомер фасылларын барлаганда
Бер нәрсәне менә онытма!
Тәрәзәдән әни күзәтәдер,
Өйдә безне әни җылыта!

## Ана

Шатлык яше тамды күзләремнән,
Сөенеп, шигыремне язганда.
Гади генә ана нигезеннән
Сәфәр чыга бүген Казанга!

Хәбәр килеп төште төпчегеннән:
«Чакырабыз сине мәркәзгә!
Оныкларың бик тә юксыналар,
Кунакка кил, әни, син безгә!»

Бармыймы соң?! Юлга әзерләнде.
Күчтәнәчләр төяп барасы.
Дүрт сәгатьлек юл гына ич бары
Казан белән авыл арасы!

Җиләк кайнатмасы онытылмасын,
Яңа салган ипи калмасын,
Кипкән мәтрүшкәсен төреп куйды, –
Шундый чәйне эчә баласы...

Кабак бәлеше тели бала күңеле,
Авыл искә төшкән чагында.
Чикләвекләр бик тә уңды быел,
Аерып төйнәп куйды кагын да...

Тиздән менә салкын кышлар җитәр,
Кич утырыйк бүген, әйдәле!
Улы, килененә, өч онықка
Җылы бияләйләр бәйләде...

«Инде менә бар да әзер төсле,
Юл догасын укыйм, балалар!»
Кайтмый торсаң, үзе юлга чыга,
Сагына бит безне аналар!

Шатлык яше тулды күзләремә,
Сөенеп, шигыремне язганда.
Көзге көндә ак күңелле ана
Язлар алып килде Казанга!

## Өмет

Өчпочмаклы хатлар килмәс инде,
Айлар түгел, еллар үтсә дә.
Соңарган хат сузар төсле миңа
Хат ташучы, үтеп киткәндә...

Кыш узуга, язын кабат кайта,
Бөреләнә яңа өметләр.
Өйдәгеләр өзелеп көтте сезне
«Кайтырбыз», – дип киткән егетләр!

Хәбәрсезләр, хәбәр җибәрегез,
Кай туфракта ята кайсыгыз?!
Тол хатыннар сезне күралмады,
Оныклар бар әле, кайтыгыз!

Исемнәрен барлыйк һәйкәлләрдән,
Ялгыш кемдер төшеп калмасын!
Ватан-ана юк, оныта алмый
Яуда башын салган баласын!..

Җиңү алып кайткан батыр ирләр,
Сез – мәңгегә хәтер түрендә!
Каһарманга ничек баш имисең, –
Кояш балкый илем күгендә!

Өчпочмаклы хатлар килми инде,
Айлар түгел, еллар үтсә дә.
Соңарган хат ишек шакыр төсле
Безнең турдан үтеп киткәндә...

## Сүзләр

Тел ачылган көннән бирле,
Һәм шулай ул бүген дә.
Дөньяда иң матур сүзләр
Бары ана телендә!

Сүзләрнең төрлесе була,
Язга тиңе, гүзәле.
Күңеллесен ишеткәннәр
Елмаймыйча түзәме?!

Сүзләр белән ант бирәләр,
Кайберләре була ят.
Яратам дигәнен менә
Әйтегез кабат-кабат!

Әйбәтен күбрәк көтәбез,
Начарын күңел куа.
Барыгыз да килешәдер,
Сүзләрдән җырлар туа.

Сүзләрнең төрлесе була,
Бар татлысы, ачысы.
Әйтче миңа, милләттәшем,
Иң якыны кайсысы?!

Кайбер сүзләр онытылмый,
Ишетүгә ятлана.
Әни, ил, Ватан дигәне
Йөрәгеңдә саклана!

Тел ачылган көннән бирле,
Һәм шулай ул бүген дә.
Дөньяда иң матур сүзләр
Бары ана телендә!..

## Сагышлы таң

Кышкы таңда сагыш басты әле,
Хисләр җанга тулган чагыммы?!
Җитмеш тула тиздән, мин инәйне
Җиде яшьтәгедәй сагындым...

Тал бишектә яткан игезәккә
Кабатланмас исем тапкан ул.
Игез сабый – Таһир-Зөһрәне
Бишек җыры көйләп баккан ул.

Без нигәдер инәй диеп үстек,
Газиз иде безгә шушы сүз.
Инәй кочагына сыенганда
Иң бәхетле бала идек без!

Сине «моңлы җырчы» диләр иде,
Үсә төшкәч моны аңладык.
Сызылып аткан җәйге гүзәл таңда
«Галиябану» җырын тыңладык.

Ә кышкы таң сагыш алып килде,
Нигез эргәсенә сарылдык...
Җитмеш тула тиздән, инәй, сине
Җиде яшьтәгедәй сагындык!..



Наилә Харисова

# МИН КАЙТЫРГА ТИЕШ*

ХИКӘЯ

Милади ел исәбе буенча 1914 елның урталары узган иде инде...

Урылмыйча калган басу окоплар, снаряд чокырлары белән чуарланган. Атлаган саен аякка уралып, ни солдатларга, ни олауларга тиз хәрәкәтләнергә ирек бирмәгән арыш-бодай саламы, әйтерсең үлем төяп килүче дулкынны туктатырга тели. Кагылган саен башагыннан коелган сары бөртекләр, Җирананың күз яше булып, авыр солдат итекләре, дагалы ат тояклары астында калып, көзге пычрак белән буталалар. Туктаусыз яуган яңгырлардан соң төнлә суытып ала. Болай да көйсез бала холкы кебек бертуктамый үзгәрүчән һава торышы окоплардагы солдатларның хәлен түзә алмаслык итә.

Көнчыгыш фронт кайзер гаскәрләре өчен бер дә уңышлы булмады әле. Яулап алган җирләрен русларга калдырып чигенде. Аңа карап, гади рус солдатының да хәле җиңел түгел. Кайсы сугышта гади солдатка җиңел булганы бар инде. Ике яктан да гомергә күз күрмәгән, тик һәрвакыт үзенең өстә бар икәнен искә төшереп торган патша галиҗәнаплары кушуы белән куып китерелгән гавамны, бер-берсенә каршы җибәргәч, алар нишләргә тиеш? Сугышырга, үтерергә! Һәркайсы алданрак өлгерергә тырыша. Үзенә җайлырак, куркынычсызрак урынны табып, дошманына атарга, кылычын айкарга, штыгын дошманының тәненә батырырга тиеш. Син үтермәсәң, сине үтерәчәкләр. Кан исеннән, ничек булса да исән калу теләге белән акылын югалтыр хәлгә килгән кичәге крестьян яки эшче, ни хакына шулай эшләгәнен дә уйлап тормыйча, үзе кебек үк гади бер инсанның Ходай биргән гомерен өзә. Әле төнлә генә бергә тәмәке көйрәтеп, өйдә калган бала-чагалары, эшләнми калган эшләре турында сөйләшеп утырган күршең, якында гына туп төшеп шартлаудан, башта һавага күтәрелә, аннары гәүдәсе әллә ничә кисәккә теткәләнеп, җиргә төшә. Пулемёт куелган олауга

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән әдәби конкурста хикәя номинациясендә өченче урынга лаек булган әсәр.

Наилә ХАРИСОВА (1959) – *язучы; Таҗи Гыйззәт исемендәге премия иясе. «Агымсулар ни сөйли?», «Гомер йомгагын сүтәм», «Бәллүр тозак»* исемле китаплар *авторы. Әгерҗедә яши.*

җигелгән туры ат, өзлексез шартлаган туп тавышыннан өркеп, очасы килгән кош сыман алгы аяклары белән күккә омтыла. Атлар кешнәве, яралыларның ярдәм сорап илерүе, офицерларның окоптан чыгып, артка таба качарга теләгән солдатларга акыруы сугыш канонадасы эченә кереп югала.

Көн буе барган сугыш ике якның да хәлен алган иде. Кичкә таба атышлар тынды. Ике яктан да санитарлар, каршы яктан инде сирәк кенә адашып килгән пуляга юлыкмас өчен, мөмкин кадәр сак кыланып, үз сугышчыларының мәетләрен, яралыларын җыя башладылар.

Санитар гәүдәсен өскә таба әйләндереп салуга, окоп төбендә яткан гөрнәдир сынлы сугышчы ыңгырашып куйды, тик күзен ачмады.

– Исән бугай бу. Әй, сиңа әйтәм! Үзең үрмәли аласыңмы?

Солдат тагын ыңгырашты. Санитар шул чагында гына аның сул җиңенең канга батканын абайлап алды. «Күп кан югалткан, ахры. Мөгаен, үрмәли алмас. Кулы да җәрәхәтле булгач».

– Ярар, мин синең янга носилка белән килермен. Гәүдәң мин генә сөйри торган түгел.

Санитар алга таба китте.

Күп кан югалтудан хәлсезләнгән солдат аңына килгәндә, төн иде инде. Авырлык белән генәниләр булганын исенә төшерергә тырышты. Хәтер төбендә кемнеңдер аңа: «Килермен!» – дип әйтүе калкып чыкты. Тик килүче булмаган, ахрысы.

Контузиядән ни эшләгәнен, кая барганын чамаламаган солдат, уң кулына таянып, окоп төбеннән шуышып китте. Мәетләр аша үрмәләп күпмедер баргач, ул ачыклыкка чыкты. Күрәсең, окопның бу башы түбәнрәк урынга барып тоташадыр. Шуышкан юлы да яңгыр изрәткән туфрак кына түгел, корыган үләнме, егылган ашлык саламымы – нәрсә беләндер катнашкан җир иде. Бары тере җан ияләренә хас үз-үзеңне саклау инстинкты аңа туктамаска, үлем аждаһасы көн буе ут бөркеп торган җирдән ераккарак китәргә куша иде.

Инде көзгә кереп баралар. Ләх җирендә җәйдән башлап барган сугыш беркемне дә кызганып тормый. Шул исәптән җирле халыкны да. Адәм баласы барысына да күнегә, диләр. Хәтта сугышка да. Күнекми кая барасың.

Пан Вуйчек, яше өлкән булу сәбәпле, сугышта бер якка да кушылмыйча, хатыны Бронислава белән кеше күзенә бик чалынмаска тырышып, Варшава губерниясендә яшәп ята. Зур булмаса да, үз җире бар. Малын тота. Рәсәй патшасының ләх җирендәге хикмәтләре белән килешмичә, Пруссиягә күчеп киткән немец Мюллердан юнь генә бәягә алып калган җил тегермәнендә авылдашларына тегермәнче хезмәтен дә күрсәтә. Хезмәте өчен бик кыйммәт алмый. Бергә гомер итәләр бит. Бүген булмаса, иртәгә аларның кирәге чыгар. Аннары хатыны белән икесенә күпме кирәк? Балалары булмады аларның. Туганы Яцекның улы Веславка зур өметләр баглаганнар иде. Ул Варшавага укырга киткәннән бирле аларга бөтенләй кире ягы белән борылды. Пилсудский тарафдарлары йогынтысына бирелеп бетте егет. Ә пан Вуйчек үзе дә, хатыны да яхшылыкны күбрәк Рәсәй патшасыннан өмет итә. Дөрес, моңарчы да Рәсәй кушканча яшәделәр. Мәктәпләрдә дә үз телләрендә укыту барлы-юклы инде. Патша галиҗәнаплары әллә ни рәхәт күрсәтмәсә дә, бөтенләй үк салып та таптамады. Әнә хәзер бу сугышта җиңеп чыкса, ак патша полякларга күп иркенлекләр вәгъдә итә икән. Хәтта автономия дә

бирергә исәпли, имеш. Сугыш башлангач, Рәсәйгә якын провинцияләрдән күпме халык көнчыгышка агылды. Пан Вуйчек кузгалмады. Ишетеп белүенчә, анда да тормыш җиңелләрдән түгел. Ләхне анда да кочак җәеп көтеп тормыйлардыр. Ни күрсәң дә, үз җиреңдә күр инде. Пан шулай уйлый.

Чәчкән ашлыгы бик матур гына шытып чыгып, вакытында буй сикертте. Урып алыр вакыт җитүгә, сугыш дөньяны җир өстендәге җәһәннәмгә әйләндерде. «Бөек сугыш» диләр әле, җитмәсә. «Бөек» булгач, яхшылык китерергә тиештер бит ул. Һәрхәлдә, пан Вуйчек шундый фикердә. Үлем китерүче бу коточкыч галәмәтне ничек «бөек» дип атарга мөмкин? Әнә юньләп урып-сугып алынырга өлгермәгән арпа басуы, кешеләргә рәнҗеп, башын иеп утыра. Сыра ясаучыларга сатып, азрак файдасын күрермен дигән иде пан Вуйчек – булмады инде болай булгач. Башаклары да күптән орлыкларын коеп бетергәндер. Бик азын гына эш итәргә өлгерде. Иген кыры сугыш кырына әйләнгәннән бирле, атышулар тынып торган араларда, ул атын җигеп, басуына килә. Снаряд теткәләгән кишәрлегенә күз яшьләре аша бер карап ала да, аягөсте булганнарын тиз-тиз генә урып, көлтәләрне арбасына ата. Ходай гомер бирсә, яшәр өчен бар да кирәк. Абзарындагы мал кимеде-кимүен. Солдатларны туйдырырга кирәк дип, әле җирле старосталар, әле солдатлар, күзләренә күренгән мал, кош-кортны алып чыгып китәргә күп сорамыйлар. Авыл кем кулына күчүгә карап, тәртипләр дә үзгәрә. Соңгы көннәрдә герман армиясе чигенә әле. Алар бигрәк явыз кылана иде.  Авылга рус гаскәрләре якынлашкач, пан Вуйчек белән пани Бронислава бераз җиңел сулап куйдылар. Төннәрен басуга барып, арбага берничә көлтә булса да салып кайталар.

Бүген дә көн буе аларның басулары ягында ату тавышлары тынып тормады. Вакыт төнгә авышкач кына, пан Вуйчек хатыны белән хуҗалыкларында калган бердәнбер атны җигеп, бодай басуына юл тотты. Салкын яңгыр явып, җирне тәмам изрәткәнче, игеннәрен тагын бераз урып алып кайтырга иде исәпләре.

Дөнья, ни гаҗәп, тын. Көн буе бу якларда туплар шартлаган, йөзләрчә җаннарны кыеп, сугыш узган, димәссең. Туп төшеп яндырган басудыр, урмандыр яки сугыш юлына туры килгән фóльварклардагы[1] йорт, хуҗалык корылмалары пыскудан күтәрелгән төтен генә тулы айдан төшкән  нурларга җиргә кадәр төшеп җитәргә ирек бирми.

Юллары уңды бу юлы. Ир белән хатын арбага бөртекләре коелып бетәргә өлгермәгән башаклы бодай саламын төяп кинәнделәр. Их, дөньялар тынычлансын иде дә бу ашлыкны сугып алып, ризык итәргә язсын иде!

Инде кайтыр юлга борылдылар. Уйсурак урынны узганда, пан Вуйчек туктап калды.

– Тпру! Кемдер ыңгырашамы? Минем колакка гына ишетеләме соң?

Атын туктатып, пан Вуйчек тавыш ишетелгән якка атлады. Бу юлы ыңгырашу тавышын пани Бронислава да ишетте.

– Тукта! Кая барасың? Әллә кем булып куюы бар. Атып егарлар үзеңне.

Пан Вуйчек хатынының сүзләренә игътибар итеп тормыйча, яртылаш ауган иген басуына таба атлавын белде. Пани Бронислава, дилбегәне кысып тоткан килеш, куркудан усак яфрагыдай калтырап, йөк янында калды. Төнлә кем белә бит сугыш барган җирдә ни буласын? Үзләренә зыян

[1] Фóльварк – хутор.

салмаслар дип тә булмый. Атларын куып алып китеп, суеп ашаулары бар. Солдатлардан башка ач качкыннар да җитәрлек.

Пан Вуйчек бераздан әйләнеп килде дә, бер сүз дә әйтеп тормыйча, атын үзе чыккан якка бора башлады.

– Кем бар анда? Нишләмәкче буласың? – диде хатыны. – Нәрсәгә азапланасың инде тагын?

– Бер солдат ята анда. Аңсыз, ахрысы. Үзе ыңгыраша, үзе нидер сөйләнә. Аңлап булмый.

– Булса соң! Алар монда адым саендыр инде. Мәетләрне җыеп алырга да өлгермиләр, ди бит.

– Бу бит мәет түгел, аңгыра баш! Яралы!

Иренең үз сүзен сүз итмичә туктамаячагын белгән пани Бронислава бүтән бәхәсләшеп тормады. Юл читеннән әллә ни ерак түгел иде солдат яткан урын. Киеменә караганда, рус солдаты. Сул җиңе каннан лычма булган.

– Әйдә без аны көлтәләр астына яшерик. Олау өстенә салсак, кеше күрер. Дус бар, дошман бар.

Пан Вуйчек бераз уйланып торды. Хатынының сүзләрендә хаклык бар иде. Күршесе Кох, сиздермәскә тырышса да, герман гаскәрләренең кире кайтуын көтеп яши кебек. Рус солдатын өенә алып кайтканын сизсә, һичшиксез күңеленә салып куячак һәм җай чыгуга (Алла сакласын!), кирәк җиргә барып әйтәчәк. Ай-һай! Нинди болганчык заманнар килде бит!

Көлтәләр астында кайткан яралы солдатны эчке бүлмәдә өченче көн тоталар инде. Һаман аңына килгәне юк. Ир белән хатын аны яткан килеш, булдыра алган кадәр чишендереп, юындырып (алай дияргә яраса), авызына су тидереп торалар. Сул кулы бик нык чәрдәкләнгән. Инде бик каты шешкән. Үзе туктаусыз саташа. Рус солдаты дисәләр дә, теле бер дә рус теленә охшамаган, аңлашылмый. Белоруска та, хохолга да тартмый. Баһадир гәүдәле; яшь, бик яшь кеше әле бу. Аксөяк түгел икәнлеге әллә каян күренеп тора. Калын көчле җилкәләр, тупас эштән сөялләнгән куллар... Кайвакытта берничә мизгелгә генә үзе дә сизмәстән, саташып, күзләрен ача. Шулвакыт аның тирән зәңгәр күзләре өй эчен айкап алалар да тагын озакка йомылалар.

Пани Бронислава, үзе белгәнчә дәвалап та карый: яралының иренենә үлән суларын тидерә, чүпрәк чылатып гөбедәй шешкән беләгенә куя. Кемнедер багасы, кайгыртасы килү кебек теләсә кайсы хатын-кызга хас хисләр аның күңел тирәнлегеннән калкып чыга түгелме соң? Итәк тутырып, бала үстерәсе килсә дә, Ходай аңа бу бәхетне бирмәде. Пани Брониславаның да шушы яшьтәге улы була алыр иде бит. Бәлки берәү генә дә түгел. Ул да шулай кемнеңдер кулына карап ятарга мөмкин иде. Яшь җан кызганыч аңа. Икенче минутта иренә ачуы килә: нәрсә дип алып кайтты инде өйгә? Шушында үлеп китсә?

Пани үзенең шикләрен кич иренә дә җиткерде. Аллам язмасын, аларны кеше үтерүдә гаепләүләре бар! Хәле бер дә алга таба түгел. Яралы кулы эренләп, әллә нинди сасы исләр дә килә сыман. Табиблар кулына эләксә, бәлки, исән калыр.

– Үзем дә уйладым ул хакта. Безгә аны кыр госпиталенә илтергә кирәктер, – диде пан Вуйчек.

Шулай иттеләр дә. Шәһәр читендәге борынгы замокта урнашкан хәрби

госпитальдә егетнең сул кулын кистеләр – гангрена башланган, диделәр. Хатыны: «Хәле ничек микән инде? Аңына килә алды микән?» дип еш искә төшереп торгангамы, Пан Вуйчек солдатны илтеп тапшырса да, хәтереннән сызып ташлый алмады. Өченче көнне, хәлен белеп кайтыйм дип, госпитальгә китте. Формалин һәм төче кан исе аңкып торган госпитальдә яралыларның ыңгырашуы, аларның әле берсенә, әле икенчесенә ярдәмгә ашыгучы шәфкать туташларының тыз-быз килүләреннән баш әйләнерлек иде. Йокысызлыктан аягын чак сөйрәп йөрүче карт хирург аңа:

– Бу солдат сиңа кем була? – дип сорады.

Пан ничек булганын сөйләп бирде.

– Әгәр аңа яхшылык эшләргә телисең икән, алып кит син аны моннан. Ул аңына килде. Организмы яшь. Тиешле тәрбия булганда исән калырга өмет бар. Ә монда... – Доктор башын чайкап уйланып торганнан соң, сүзен дәвам итте. – Күреп торасың бит – ничек күп алар! Җитмәсә, тиф тарала башлады. Хәлсезләнгән бичараларга күпме кирәк? Кырылачаклар инде. Берәр чара күрелмәсә, кырылачаклар. Ә кем күрер ул чараны – белгән юк.

Шулай итеп, пан Вуйчек солдатны, арбасына салып, икенче тапкыр өенә алып кайтты.

...Минһаҗ күзләрен ачты. Беравык кайда икәнен аңлап бетерә алмый торды. Әле генә туган йортында әнисе белән сөйләшә иде бит. Әнисе аны солы коймагы белән сыйлый.

– Аша, улым, аша! Синең ашар чагың. Эшең дә авыр. Бүген, Аллаһ боерса, ерак болындагы печән эшен тәмам итәрсез. Атаң шулай диде. Озакламый урак өсте җитә... Басулар да бик матур утыра, ди. Бик канәгать атаң. Ходай биреп, быел килен дә төшерсәк...

Әнисе серле елмая. Минһаҗ оялып, башын ия дә коймагын ашый бирә. Их, тәмле соң шушы әнкәй кулыннан ашаулары! Әнисе бераз сүзсез тора. Минһаҗ ни әйтер дип көтә бугай. Аннары тагын әйтеп куя:

– Күз салып йөргән кызың бардыр инде, улым?

Минһаҗ һаман дәшми, имеш. Күрше авылда курчак кебек кенә кечкенә буйлы, терекөмеш кебек җитез бер кызга күзе төшкәнен, кичке уенда карашлары очрашканын әйтми, билгеле. Әле сүз дә куша алмады бит. Гармунчы Минһаҗга тальянын тартып, башка егетләрнең кызлар белән парлап биеп-уйнап күңел ачканын карап, кызыгып утырырга кала. Икенче юлы, һичшиксез, гармунын башка егеткә тоттырачак та кыз белән танышу җаен табачак әле ул.

Төш кенә булган икән. Егет тагын күзләрен йомды. Әйтерсең күзләрен йомуга, теге ләззәтле төш дәвам итәчәк тә хәзерге чынбарлык бөтенләйгә аның тормышыннан китеп югалачак. Тик күзләрен йокы алмады. Минһаҗ акрын гына якынлашкан аяк тавышын ишетеп, күзләрен ачты. Карават янындагы урындыкка олы яшьтәге хатын килеп утырды.

– Самопопуче? (Хәлең ничек?) – диде ул егетнең урын-җирен рәтләгәндәй итеп. Авыру эндәшмәде. Сүз әйтелү рәвешеннән генә аннан нидер соравын аңлады. Алар ләх җирендә сугышалар иде. Димәк, хатын полякча сорады. Аның полякча түгел, русчасы да Чаллы-Минзәлә базарларында ишеткәннән артмый бит. Анда әле аның русы-марие үзләре дә теттереп, татарча сөйләшәләр, сатулашалар иде.

Печән ае бетеп килгәндә, «Патша сугыш башлаган!» дип алып киттеләр.

Атасы Шәрәфетдин агай, атын җигеп, улын, тагын берничә егетне Чаллыга кадәр озатып барды. Егетләр юл буе җырлап бардылар. Минһаҗ, эчендәге ярсуын тыярга тырышып, тальян күрүген соңгы чиккәчә сузды.

Биек икән тавыгыз,
Куе икән талыгыз.
Без китәбез, туганнарым,
Бәхилләшеп калыгыз.
Кояш чыга әйләнеп,
Ак болытка бәйләнеп.
Җиңү белән, сау-сәламәт
Кайтсак иде әйләнеп.

– Җиңүләр насыйп булыр микән?

– Их, ичмасам басу эшләрен бетерергә дә ирек бирмәделәр.

– Рамазан ае диген! Борынгылар рамазанда сугышкан җирләреннән дә туктап торганнар.

– Соң, болар мөселман түгел бит. Аларга синең уразаң ни дә, түгел ни!

Атландым атның биленә,
Киттем Герман җиренә.
Герман җире – кара үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.
Без барасы юлларның ла
Ике ягы канаулы.
Без моңаймый, кем моңайсын
Безнең көннәр санаулы.

Тальяны әткәсе кулында елап кайтып китте. Әллә тальян елады, әллә әткәсе...

...– Самопопуче, сэнэк? (Хәлең ничек, улым?)

Минһаҗ күзләрен ачты. Тавышы ягымлы хатынның сүзләрен аңламаса да, үзенә начарлык теләмәвен чамалап, уңай җавап белдергәндәй ияк какты.

Хатын кулындагы зур чынаякны егетнең авызына китереп, нидер әйтте. Ә Минһаҗ нидер эчәргә кирәген аңлап, башын күтәрмәкче булды. Үзенең сул кулының терсәктән югары юк икәнен онытып җибәреп, аңа таянасы итте.

Төзәлеп бетмәгән чи ярага кагылудан бөтен тәненә ут капкандай булды. Егетнең башы кире мендәргә ауды, гәүдәсенең иң тирән урынынынан газаплы иңрәү бәреп чыкты. Хуҗа хатын аңлады аны. Нидер сөйләнә-сөйләнә, тагын бер мендәр алып килде, башын ипләп кенә күтәртеп, мендәргә салды. Аннары сабыр гына Минһаҗга чынаякны кабат сузды. Таныш та, таныш түгел дә иде чынаяктагы чәйнең тәме. Авыл болынында үскән мәтрүшкә чәенә дә тартым, ниндидер ят тәм дә бар кебек. Әле генә көчле авыртудан сыны каткан гәүдәсенә йөгергән шифалы җылылыктан чиксез рәхәтлек кичереп, йотлыгып эчте ул аны. Күпме гомер адәмчә тәгам капмыйча, үлем, кан эчендә йөреп, киеме, гәүдәсе генә түгел, күңеле дә тупаслана, керләнә башлаган кебек иде. Үлән чәе аның тәнен генә түгел, күңелен дә җылытты. Егет шулчак тыныч тормыш, йорт, гаиләдә генә була торган рәхәтлекне тойды. Хатынның куллары әнисенең кулларын хәтерләтте. Ирексездән күзләреннән яшь бәреп чыкты.

Хатын буш чынаякны караватянындагы тумбочкага куйды. Минһаҗның мендәрен тагын җайлагандай итте. Йомшак кына итеп нидер әйтте. Аннары ике кулын яңагына куеп, «йокла» дигәнне аңлатты. Минһаҗ күзләрен йомды.

Киселгән кулының төзәлеп бетмәгән җәрәхәте сызлап, вакыты-вакыты

белән аңын югалтыр хәлгә килә Минһаҗ. Бигрәк тә табигать көйсезләнеп торганда. Ул элек әтисенең: «Аяклар сызлап тора, көн бозылыр, ахры», – дигәнен аңламый иде. Шулай икән. Аның да кисеп ташлаган кулының бармак очларына кадәр сызлый. Ул гынамы? Минһаҗ үзенең кем өендә, нишләп ятканын да аңлый алмый әле. Кемнәр бу? Нигә алар бөтенләй таныш түгел кешене шулай тәрбиялиләр? Башкалар, исән булсалар, окоп төбендә калтырыйдыр. Ә ул җылы, йомшак урын өстендә ята.

Минһаҗ хәтерендәге соңгы көнне өзек-өзек исенә төшерә дә кебек. Көчәнеп уйлый башласа, чигәсеннән кысып, башы авыртырга тотына. Егет кабат һушын югалтудан курка. Аңына килгәннән бирле, әфисәрләрнең «За веру, царя и Отечество!» дип кычкырып, аларны алга барырга дәртләндергәне, үзенең винтовка тотып, окоптан күтәрелгәне хәтеренә килә, солдатларның «Ура!» тавышлары кабат ишетелгәндәй була. Башта шулай дошманга каршы йөгерделәр. Ни гаҗәп, аларга мылтыктан да атмый тордылар. Җиңел генә алга барудан әсәренгән солдатлар, тирә-якта туплар шартлый башлагач кына, моның алдакчы тынлык булганын аңлап алды. Кайсы шунда ук дошман ядрәсе корбаны булды, кайсыдыр үз-үзен белештермичә, артка йөгерә башлады. Җир белән күк тоташты. Солдатлар кире окопларына төшеп ятарга мәҗбүр булдылар. Бераздан туплар тынып калды. Солдатларга кабат һөҗүмгә күтәрелергә боерык булды.  Тагын «Ура!» кычкырып, алга ташландылар. Бу юлы, ни гаҗәп, авыр артиллерия тиз генә тавыш бирмәде. Үлем чәчеп торган пулемёт утыннан котыла алганнар фронт сызыгында дошман белән күзгә-күз очраштылар. Аларны үз окопларында дөмектергәннән соң, рус солдатлары дәртләнеп, тагын алга ыргылды. Шул чакта гына алдагы позициядән кабат туплар телгә килде. Минһаҗны якында гына шартлаган снаряд җиргә алып атты һәм дөнья караңгылыкка чумды.

– Безнең егет ничек анда? – ди пан Вуйчек, кичтән кайтып керүгә. Соңгы вакытта мондый сүзләр алар өендә инде гадәткә керде.

– Әйбәтләнә кебек. Тәненә ит куна башлады. Үзенең дә тик ятасы килми бугай. Кайчан карама – аяк өсте. Бүлмәсендә йөренә.

– Ярый-ярый. Хәрәкәт – әйбәт нәрсә ул. Димәк, кулыннан башка әгъзалары таза, дигән сүз.

– Яшь кеше бит. Күренеп тора: аксөяк түгел.

– Әйеее... Буй-сыны бар, йөзгә дә кызларның төн йокысын качырырлык. Менә шушы яшьтән сыңар кул белән кал инде син, ә!

– Әйтмә инде, кадерлем!

Пан Вуйчек, ашап-эчкәч, Минһаҗ янына кереп утыра. Кергән саен башта «Добры вечур, сэнэк!» – ди. Егет пан Вуйчекның үзенә хәерле кич теләвен, аны «улым» дип атавын хәзер аңлый инде. Хуҗа озак-озак нидер сөйли. Русчага охшаш сүзләреннән Минһаҗ аның сугыш турында сөйләгәнен бераз аңлый. Немецлар чигенә икән. Шулай да рус гаскәрләренең хәлләре әллә ни шәптән түгел. Көннәр салкынайта. Тылдан азык-төлек, корал обозлары китертү авырдан бара, тимер юл тулысынча сугышка хезмәт итсә дә, җитешмиләр икән.

Пан гади халык өчен бу сугышның кирәге юклыгын, аның бары шляхтичлар өчен генә файдалы булуын аңлатырга тырыша. «Сугыш холопның соңгы ыштанын салдыра, шляхтичны баетып калдыра», – ди.

Ят сүзләр күп булса да, Минһаҗ бу сөйләшүләрнең асылына төшенә. Үз илендә булган хәлләрне исенә төшерә...

Чаллы пристаненда аларны, пароходка төяп, Казанга алып киттеләр. Якын-тирәдән сугышка алынучылар арасында Чистай өязеннән да ир-атлар бар иде. Аларны нигәдер башкаларга караганда катырак тәртиптә, сак астында алып бардылар. Сөйләшә торгач, шунысы ачыкланды: алар алпавыт Лебедевның утарын яндыруда катнашучы мобилизацияләнгән крестьяннар икән. Сугышка китүчеләрдән ипиен кызганган алпавыттан крестьяннар бөтен ачуларын алганнар: ачлы-туклы халыкка мобилизациянең бөтен авырлыгын салган хөкүмәт өчен дә, алпавытның абзар тулы дистәләгән атлары булып та, аннан алмыйча, крестьянның соңгы атын алып чыккан өчен дә, бер өй эченнән яше җиткән бар ир затын берьюлы сугышка алган өчен дә... Саран ике тапкыр түли, ди. Алпавыт саранлыгы өчен тагын урман кишәрлекләре, дистәләгән печән кибәне белән дә түләгән. Минһаҗның шулар турында панга сөйлисе килә дә... Тел юк шул. Аңа да, аның әтисенә дә, авылдашларына да сугыш кирәкми. Аның, тырышып эшләгәннең әҗерен күреп, тук тормышта яшисе; өйләнеп, балалар үстерәсе килә; ата-анасына кадер-хөрмәт күрсәтеп, рәхәттә яшәтәсе, картаймыш көнендә үзе дә балаларыннан шуңа ирешәсе килә. Әле кайчан гына Минһаҗның үзе үтергән герман солдатына да бер үче дә юк иде. Ул да яшәсен иде өендә тыныч кына, эшләсен, шатлансын-сөенсен иде. Җир йөзендә бөтен кешегә дә урын җитә югыйсә. Юк бит... Кендеге җиргә береккән Минһаҗ шулай уйлый. Пан Вуйчек та шулай уйлый икән. Теге герман кешесе дә, бәлки, шулай уйлагандыр. Аның белән бергә окопта бет симерткән күршесе дә.

Аларның берничә киче шулай, пан – сөйләп, Минһаҗ тыңлап узды. Бер-берсенә якынайтты.

Вуйчеклар өендә Минһаҗга кыен да, рәхәт тә. Рәхәт, чөнки өзелгән кулының авыртуы акрынлап кимеп, җөйләре төзәлүгә таба бара; ашау-эчү, урын-җир Минһаҗ гомергә күрмәгәнчә. Ризыкның хәләл булмавы гына эчне пошыра. Шуңа күрә иткә кагылмаска тырыша.

Хуҗаларның мөнәсәбәте дә бик әйбәт. Нигә аны шулай кадерләүләрен егет түгел, Вуйчеклар үзләре дә аңлатып бетерә алмаслар иде, мөгаен. Ул хуҗалар өчен солдат булудан күптән туктап, әлегә аларның ярдәменә мохтаҗ бер инсан гына иде. Егет әдәпле, пөхтә. Мөмкин булганча хуҗаларга артык мәшәкать ясамаска тырышуы сизелеп тора. Ашар алдыннан эчтән нидер укып, ашагач яшеренеп кенә амин тотуын күреп, аның мөселман икәнлеген күптән аңладылар инде. Беркөнне пан Вуйчек турыдан-туры сорады:

– Михал (Алар Минһаҗга, үз телләренә җайлаштырып, кайчак шулай дип эндәшә иделәр), син рус түгел бит. Кем син?

– Мин – татар, – диде Минһаҗ.

– Әәә...Татар! Татар-липка! Мин татарларны беләм. Алар бездә дә бар. Тырыш, чиста халык. Батыр халык. Тик телләрен онытканнар.

Минһаҗ бу турыда белми иде.

– Якубович, Адамович, Юзефович... татар?

Минһаҗ туганнарын очраткандай сөенеп куйды.

– Әйе, әйе... Якуп, Адәм, Йосыф...

– Хазбиевич, Измаил, Галий...

– Ә кемнәр ул татар-липка?

– Литва татары.

– Мин липка түгел! Юк, юк... Мин... Казан...

Пан Вуйчек көлеп җибәрде.

– Татар-липка – Урдадан калган татарлар.

«Пан Вуйчек укымышлы кеше икән», дип уйлады Минһаҗ. Авыл мәдрәсәсеннән ерак китә алмаган татар баласына бу хакта сөйләүче булганмыни?!

Алар ул көнне аеруча җылы аралаштылар кебек. Икесе дә вата-сындыра булса да, русча сөйләшергә тырыша. Бер-берсен аңлыйлар тагын.

Минһаҗга монда кыен да. Дөресрәге, кыен түгел, уңайсыз. Ирле-хатынлы Вуйчеклар Минһаҗны үз балалары кебек якын иттеләр. Үз илендә шундый хәлгә юлыкса, Минһаҗ шулай иркәләнеп ята алыр иде микән? Юк, әлбәттә! Ата-анасы теләмәгәннән түгел, аларның мөмкинлекләре булмаганнан. Минһаҗ күрә бит: хуҗалар хәлле кешеләр булганнар. Хәзер дә хәерче түгел.

Беркөнне Пан Вуйчек аңа хуҗалыгын күрсәтеп йөрде. Йортлары түгәрәк күл каршына, таулырак җиргә урнашкан икән.

– Яз көне монда кошлар кайта, – диде пан, кош канат какканны күрсәтеп. Минһаҗ аңлады. Язын туган якларына кайтучы кыр казлары, кыр үрдәкләренең, торналарның җепкә тезелеп, төрле авазлар салып узуларын хәтердән үткәрде. Алар бу вакытта басуда булалар иде. Зәңгәр күкне ярып кычкырып узган кошларга карап, әтисе:

– Сагынып кайталар инде болар үзләренең күлләрен. Туган яклары бит. Кешегә генә түгел, бөтен тереклек затына да газиз шул ул туган җир! – дигән иде. Минһаҗ хәзер генә бу сүзләрнең асылына ныклап төшенде. Авылыннан әллә ни ерак чыгып йөрмәгән әтисенә каян килгән диген мондый фикер! Зирәк кеше шул ул! Сагыну, җирсү хисе Минһаҗның йөрәген чәнчеп алды. Ул да бит хәзерге вакытта туган ягын ташлап китәргә мәҗбүр булган шул кошлар хәлендә. Яз җиткәч, кошлар кире кайтырлар. Ә ул кайта алырмы? Ник килде ул монда?! Нишләп ята ул?!

Хуҗалык юан имән казыкларны бастырып куеп әйләндереп алынган. Вак-төяк карак аның аша үтә торган түгел. Өй каршында юкә агачлары үсеп утыра. Алар шуның кадәр картлар инде: пан Вуйчекның гына түгел, аның ата-бабасының да ыштансыз чабып йөргәнен күргәннәрдер, мөгаен. Ишегалдына керүгә, капкадан башлап, болдырга кадәр чәнечкеле куаклар рәте. «Гөлҗимешкә охшаганнар», – дип уйлады Минһаҗ.

Вуйчекларның өйләре дә ярыйсы иркен. Алгы яктан шунда ук зур гына бүлмәгә килеп керәсең. Ишек өстендә, рам эчендә нindидер рәсемле язулар төшкән сурәт эленеп тора. «Бездәге шәмаил кебек», – дип уйлап куя Минһаҗ. Бүлмәдә диван, диван каршында тәбәнәк өстәл, шакмаклы тукыма белән ябылган урындыклардан башка бернәрсә дә юк. Өстәлдә челтәрләп ясалган кечкенә ашъяулык һәм гөл савыты. Тәрәзәләрдә кисея пәрдәләр. Татар өйләрендә күрергә күнеккән чигүле кашагалар, чәчәкле чыбылдыклар юк иде монда.

Бу бүлмәдән берничә ишек аша йокы бүлмәләренә чыгып була. Минһаҗ яткан бүлмәдә агач карават, карават янында зур булмаган өстәл, урындык. Стенада, баш очында бер хатын сурәте. Хуҗалар аңа карап табыналар.

Соңгы вакытта ул аш бүлмәсендә хуҗалар белән ашый иде. Аш бүлмәсенә керү өчен башта алгы бүлмәгә чыгарга кирәк. Аш бүлмәсе зур. Савыт-саба шкафы, стенада сәгать, озын өстәл тирәли сукно белән тышланган озын эскәмияләр.

Бер артык әйбер юк. Пөхтә итеп җыештырылган. Бар да гади, шул ук вакытта ят иде алар егеткә. Ничектер алардан салкынлык бөрки, дисенме…

Соңгы көннәрдә пан Вуйчекның кәефе китеп тора. Гомерләрен куркыныч астына куеп, кырдан алып кайткан көлтәләр сугылмыйча ята. Шуңа эче поша аның. Яше бар бит инде. Берүзе генә эшли торган эш түгел. Элек хуҗалыкка килеп ялланып эшләүчеләр кайсы кая китеп югалды. Кем полякларга мөстәкыйльлек бирергә өметләндергән Герман ягына чыгып качты, кем бу якта... Хәтта бер өйдән икесе ике якта сугышучылар да бар, диләр. Хатынын авыр эшкә кушу – аңа ят нәрсә. Ә читләрне ярдәмгә чакырырга пан шикләнә: заманасы болгавыр, әллә ни күрүең бар. Шулай да октябрь салкыннары башланган көннәрнең берсендә, тәвәккәлләп ишегалдындагы сараен ачты. Анда озак кына югалып торганнан соң, өйгә керде. Хатыны белән нидер сөйләшкәннән соң, Минһаҗны үзе белән чыгарга чакырды. Егет рәхәтләнеп риза булды. Өйдә ятып күптән туйган. Сөйләгәненең барысын да аңлап бетермәсә дә, ул пан белән ишегалдында, күл тирәләрендә йөрергә ярата. Тик андый чаклар берничә генә булды шул.

Минһаҗга пани Бронислава эш киемнәре бирде. Сәдәпләрен төймәләште. «Әһә, нindидер эшкә чыгасы, ахры», дип уйлады Минһаҗ. Егет монысына аеруча нык сөенде. Аның хәле инде начар дип әйтә торган түгел. Киселгән кул ярасыннан канлы сүл тибеп тора торуын. Анысы гына – вак мәсьәлә. Үтәр әле. Үзен әрәмтамак итеп тоюдан аңа бик оят була башлаган иде инде. Менә бәхет басты: ул да азмы-күпме эшкә яраячак!

Пан Вуйчек аны сарайга алып керде. Сарай зур. Дивар буйлап әллә нинди әкәмәт машиналар тезелеп киткән. Стеналарга ат дирбияләре, төрле кораллар эленгән. Пан бер машина янына килде. Аның бер өлеше өстәлгә охшаган. Өстәл, авышып, тешле-тешле күчәр астына төшеп китә. Бу машина үзе тәгәрмәчтә икән. Минһаҗ аның нәрсә икәнен төшенергә тырышып карап торган арада, пан Вуйчек, ишарәләп, машинаны алып чыгарга булышуын сорады. Минһаҗның исән кулы белән машинаны җиңел генә тартып чыгуын күргәч, панның йөзенә елмаю кунды. Ул йөгереп чыгып, ындырга охшашлы корылманың капкасын ачты. Җирдә сугылмаган көлтәләр өелгән. Хикмәтле машинаны көлтәләр янына урнаштырдылар. Хуҗа өстәл кебек урынга сугылмаган көлтәне салды һәм машинадагы тоткычлы тәгәрмәчне әйләндерергә кушты. Әһә, менә нәрсә икән ул! Ничек Минһаҗның башына алданрак килмәгән?! Күргән әйберсеме...

Алар икәүләп җирдә зур чүмәлә булып өелеп торган ашлыкны кичкә кадәр сугып та бетерделәр. Панның кәефе шәп иде. «Менә шундый улың булсын иде ул! Гомер буе тырышып торгызган хуҗалыгыңны рәхәтләнеп аңа тапшырыр идең дә бер кайгысыз картлыгыңны каршылар идең. Юк шул! Насыйп итмәде...» Егеткә карап, пан шулай уйлады.

Минһаҗ исән кулы белән ашлык тулы капчыкларны җиңел генә келәттәге лар янына ташый. Булышырга теләгән картка елмая, ымлап утырып торырга куша.  Аннары бергәләп ашлыкны ларга бушаталар. Егетнең яратып, теләп

эшләве йөзенә чыккан. Күрәсең, бу эш аңа ят түгел. Җилкенеп эшли. Кайвакыт, ялгышып, яралы кулын бәрсә, йөзен чытып ала да тагын эшли башлый.

Келәт идәненең ике сайгагын алып, берничә капчык ашлыкны баз кебек җиргә төшерделәр. Һич кенә дә яшерен урын бар дип уйламассың! Шундый оста итеп эшләнгән. Пан хәйләкәр генә елмаеп, нидер әйтте. Сүзен аңламаса да, аның кеше күзеннән яшерелгән запас ашлык икәне аңлашыла инде.

...Көнозын баш түбәсендә эленеп торган соры болытлар, болай да юк кәефне бетерәләр. Минһаҗ монда ятуның чиге булырга тиешлеген аңлый. Фронт сызыгы, ул авырып ятканда, авырлык белән булса да, көнбатышкарак күчкән. Ул фронт хәлләреннән хәбәрдар түгел. Бөтен белгәне Вуйчеклардан ишеткәннәр, ишеткәннән аңлаганнар гына. Әле ярасы кансырап, авыртып торса да, ятып торырдай хәлдә түгел. Егерме ике яшьлек таза егет бит ул. Армия хезмәтенә яраксыз икәнен дә чамалый. Сыңар кул белән аны фронтка җибәрмәсләр. Дөресен генә әйткәндә, ул үзе дә ашкынып тормый. Барлы-юклы ике ай эчендә рус армиясенең ни икәнен чамалады инде. Командирларның, берсеннән-берсе уздырып, ахыры ни белән бетәсен уйлап тормыйча, гади солдатны ут эченә кууы, сугыш кирәк-яраклары, коралның вакытында килеп җитмәве аркасында, ничаклы солдатның бер мәгънәсезгә җаннары кыелу, дошманның яхшырак коралланган булуы – гомумән, патша армиясенең сугышка бер әзерлексез керүе гади солдатларга да күптән аңлашылган иде.

Ул үзенә операция ясаган госпитальгә барырга карар кылды. Алга таба нишләргә кирәген аңлатсалар, анда аңлатырлар. Планнарын пан Вуйчекка әйтте. Аларга, аңлата алганча, рәхмәтен белдерде. Карт полякның йөзе аның сүзләреннән нигәдер сүрәнләнде, кәефе төште. Кичке аш вакытында хуҗа:

– Сэнэк, Михал! – дип сөйләп китте. Сүзләренең барысын да аңлап бетермәсә дә, Минһаҗ пан Вуйчек һәм пани Брониславаның аны уллары кебек күрүен, үзләрендә калырга тәкъдим итүен, бөтен байлыкларын калдырырга, яхшы кызга өйләндерергә вәгъдә итүен аңлады. Якын итүләрен Минһаҗ болай да чамалый иде инде. Тик бу кадәресен үк көтмәгән иде. Аның күңеле тулды.

– Без хәзер үк җавап көтмибез. Уйла. Әгәр калырга хәл итсәң, мин сиңа документлар эшләтү артыннан йөри башлармын. Сине Ивангородтагы туганымның улы диярмен. Әгәр инде кайтырга хәл итсәң, госпитальгә алып барырмын, – диде пан Вуйчек.

Бөтенләй чит-ят бу гаилә аның гомерен саклап калды. Тәрбияләделәр. Минһаҗ аларга бик рәхмәтле. Тик Вуйчекларның тук тормышына кызыгып, монда калу, исән килеш ата-анасыннан, туганнарыннан, ахыр килеп, туган җире, туган иленнән баш тарту – егет өчен башка сыймаслык нәрсә. Дөрес, аның үз җирендәге тормышы мондагыдан күпкә кайтыш. Иртәдән кичкә кадәр баш күтәрми эшләсәләр дә, очын-очка көчкә ялгап барган чаклары азмыни? Әмма нинди булса да, аныкы бит ул, газиз бит ул – туган җир!

Икенче көнне егет, булдыра алганча, Вуйчекларга шуны аңлатырга тырышты.

– Мин кайтырга тиеш! – диде.

Аңладылар кебек. Пани Бронислава, сүзгә катнашмыйча гына, алъяпкыч итәгенә күзләрен сөртеп утырды. Пан Вуйчек башын селкеп, күңеленә авыр бу карарны кабул итүен белдерде.

– Синең язмыш, синең тормыш... Ничек хәл итсәң шулай булыр.

Госпитальдә аңа Рәсәйгә кайтып китәргә документлар әзерләделәр. Тик «Ничек кайтып була?» дигән сорауга госпиталь начальнигы башта җилкә сикертеп кенә җавап бирде. Бераздан: «Яралылар белән санитар поезды бер атнадан Петроградка китә. Шунда эләгә алсаң – бәхетең!» – диде.

Күңеле белән инде бүген юлга чыгарга әзер егеткә бер атна күп булып тоелса, Вуйчекларның күңеленә: «Бәлки, кире уйлар», дигән өмет уятты.

Тик атна ахырына пан Вуйчек үзе үк бик дулкынланып кайтып керде.

– Сиңа һич кичекмәстән кайтып китәргә кирәктер, сэнэк. Әле генә Мирослав Тадеушны очраттым. Ул кичә Варшаудан кайткан. Герман гаскәрләре яңадан зур һөҗүмгә җыена икән. Алар монда килеп җитәмеюкмы, бер Ходай кулында, тик шулай да тизрәк китүең хәерлерәк булыр. Иртәгә мин сине станциягә үзем озатып куярмын.

...Ниһаять, ул кайтып җитте. Мең бәла белән яралыларны ташучы санитар поездына эләккән көннән соң ике ай дигәндә. Менә өенә кайтып җитәргә дә әллә ни күп калмады. Минһаҗ кышкы салкын томан аша авылы ягына карап тора. Шәфәкъ кызыллыгы кар диңгезенә ягылып, аны алсу итә. Күбесе җирдән чак калыккан, күп булса дүрт тәрәзәле авыл өйләре, карга төренеп, томан аша күрер күзгә чак шәйләнә. Кайберләренең морҗасыннан төтен күтәрелмәсә, анда кеше яши дип тә уйламассың. Соңгы вакытта биек таш йортларны, ләх җирендәге ныклы тормышлы хуторларны күреп гадәтләнгәнгәме, Рәсәйгә кергәч, күзләре җиргә түнгән салам түбәле йортларга өйрәнә алмый йөдәде. Тик күргәннәре эчен тырнаса да, болар үз иде, анıкы иде.

Исәпләп карасаң, чыгып киткәненә әле ярты елдан чак артык. Минһаҗ ир-атларның: «Кая гына бармый, ниләр күрми ир-егеткәй белән ат башы!» – дип җырлаганын ишеткәне бар иде. Күңеленә нигәдер шул сүзләр килде. Элек җырның сүзләренә игътибар ителмәгән дә. Хәзер менә әлеге сүзләр нәкъ аның турындадыр кебек тоелды. Егерме ике яшьлек сыңар куллы егет, озын юллар үтеп, мең мәртәбә үлем белән күзгә күз очрашып та, гомере бетмәгәч, туган җиренә кайтып җитте менә. Ата йорты кул сузымында гына. Туган җире бүген нинди генә хәлдә булса да, киләчәге имин, матур булыр, Аллаһы боерса! Егет шуңа ышанып кайтты бит. Ул кайткан җирләрдә әле һаман кан коела. Тик ул да мәңгелек булмас. Дөньялар тынычланыр.

Минһаҗ исән калганына сөенеп, гарип булса да, алдагы көне матур буласына өметләнеп кайтып килә. Илләр гизгән кеше күпне күрә. Гыйбрәт алырлыгын да, үрнәк булырдаен күрде. Менә ул да, күргәннәрне истә тотып, туган җирендә тормышын корып җибәрер. Чит җирләрдәге мул тормышка алыштырмады ул аны. «Мин кайттым! Мин исән! – дип кычкырасы килде Минһаҗның.

– Йа Раббым, нинди мәхшәрдә исән калырга насыйп иттең. Моннан да куркынычрак хәлләрнең дөньяда булганы юктыр. Иншаллаһ, сабак алырлык булды. Патшалар тиз көннәрдә, үзара килешеп, бу сугышны туктатсыннар иде кана. Бүтән кан коюларга юл куймасыннар иде. Рәхмәтеңнән ташлама, Раббым! Амин!



*Фәнис Зыялы (1975) Арча районының Өчиле авылында, укытучы Мәрьям белән Фәрхәт Зыятовлар гаиләсендә туа. Мәктәп елларында татар теле һәм әдәбиятыннан Республикакүләм олимпиадаларда катнашып, беренче урыннар яулый. Мәктәпне тәмамлагач, 1992 елда Арча педагогика көллиятенә укырга керә, әмма икенче курста укып йөргән чагында, аңа, Төркиягә китеп, Коньяның Селчук университетына керү форсаты чыга һәм ул районнан бер генә студентка бирелә торган әлеге форсатны кулыннан ычкындырмый. Төркиядә Фәнис хокук өлкәсе буенча белем ала, аспирантурада укый, кандидатлык диссертациясе яклый, Себер татары Мөшфикә-Бану белән гаилә корып, Рәйхан атлы кыз, Туфан атлы ир бала тәрбияли. Бүгенге көндә алар Анталья шәһәрендә гомер кичерә, Фәнис адвокат булып эшли. Шул ук вакытта ул иҗат белән дә актив шөгыльләнә – милләтебезнең бүгенге хәлләре өчен борчылып, ялкынлы шигырьләр яза. Аның шигъриятендә хәзерге төрек поэзиясенә аеруча хас ирекле стиль, фикер белән хиснең шигырь кысаларына сыймыйча, «ярларыннан ташып чыгуы», шулай ук дидактик рух өстенлек итә.*

Фәнис
Зыялы

---

# ЯН СИН, ЯН, ЯРСУ ЙӨРӘГЕМ...

## Яздым йөрәгемә гариза

Галиҗәнап йөрәгемә яздым бүген гариза:
«Бер генә көн булыйм маңкорт, була күр берүк, риза!»
Күтәрелде кан басымым, йөрәк куйды калтырап,
Ышанмады җанда күңел, кинәт калды аптырап.
Авырлык белән хупланды минем тиле гозерем,
«Рәхәт күрсен, әйдә, дидем, бер көнлек бу гомерем».
Сәлам бирә иске дуслар, сораша хәл-әхвәлем,
Тик самимияттән мәхрүм бүген минем күңелем.
Ишетмәдем яшь ананың бүген бишек җырларын,
Тибрәтмәде курай моңы күңелемнең кылларын.
Аңлатмады ак каеннар никтер сөю серләрен,
Назламады чәчләремне иртәнге таң җилләрем.
Юк җаваплылык, шөкер, юк бернинди кайгы-хәсрәт,
Нәфесем азат, тамак тук, хәл дә искиткеч әйбәт.
Янып йөри берәү, әнә, ил бәйсезлеге өчен,
Мәгърифәт, китап өләшә, кызганмый хәләл көчен.
Тукай йорты туздырыла, мәктәпләр бетерелә…
Кушылдым мин залимнәргә: «Кирәк дип бетерергә».
Телләрен җуя сабыйлар, күңелем тыныч, шөкер,
Хафаланмачы, йөрәгем, барчасына да төкер.

Тырышалар гали җаннар сакларга татар телен.
Һич кайгырмыйм, кирәге юк маңкорт өчен ул телнең.
Түзмәде… «Җитте, булды!» – дип кычкырды минем йөрәк, –
«Миңа кирәкми үле җан, миңа искесе кирәк!»
Безгә кирәк туганлык вә мөлаем нурлы күзләр,
Алар мәхрүм бу хисләрдән, аларга ят бу сүзләр.
Ян син, ян, ярсу йөрәгем, бишек көйләрем өчен!
Элеккедәй тип яңадан, күрсеннәр синең көчең!
Миңа кирәк үз йөрәгем, кирәкми буп-буш йөрәк!
Белегез, һәр татарда бар дин өчен типкән йөрәк!
Күрегез, күп татарда бар йөгәнсез, бәйсез йөрәк!

## Йә ватан, йә җан!

Сугыш кыры.
Болын-кырлар кызыл кан.
Ике юл бар:
Йә ватан, йә җан!
Әмма кызганыч,
Калмады сыңар бер ядрә дә.
Әгәр калса әсир төшәр идеме соң
Ничә егет дошман кулына?!
Тик син шуны бел:
Иң газабы исә, нахак сүз!
Мөһерләнде кара мөһер:
«Ватан хаине!»
Иҗат эшләре, сәнгать, җыр,
Шигырьгә мәхәббәт,
Милләт язмышы…
Ике юл бар:
Йә ватан, йә җан!
Юк, юк яшерен берни дә юк!
Юк «качкыннар», бар да табигый.
«Нигә соң бу әрнүләр?» – диде, тик
Ул да диде бары: «Әллүки»!
Тик син шуны бел!
Иң газабы исә – нахак сүз!
Мөһерләнде кара мөһер:
«Халык дошманы!»
Иле өчен, җире өчен,
Халкы өчен, хаклык өчен
Шәһитләр дә әгәр
«Халык дошманы» булса?..
Күлләрен, чишмә суларын,
Болын, урман, кырларын
Яратучылар да әгәр
«Ватан хаине» булса? –
Мине дә алайса мөһерлә!
Ике юл бар:
Йә ватан, йә җан!

## Бала күңеле кайларда?

Күңелгә бик авыр, сызланасың,
Елыйсылар килә кайчакларда.
Ялгышасыз, бала күңеле булмый
Һәрвакытта иркен далаларда.

Безгә кирәкми буш бәйрәмнәр, кичәләр.
Күңелләрдә бозлар эреде,
Җаныбызга Ислам, Милләт, Ватан өчен
Якты иман нуры өрелде.

Безгә кирәкми куркаклар, маңкортлар,
Кирәкми комсыз акча кортлары,
Безгә кирәк ирек, бәйсезлек һәм милли
Үзаң, кирәк инсан хаклары.

Кирәкми безгә намусын, җанын сатканнар,
Кирәкми урам этләре,

Кирәкми ялган тарихчылар, кирәкми
Кан имүче урман бетләре...

Хас түгел татарга кул кушырып утыру
Вә эшсез өйдә тик яту.
Коелмасын кан. Вәхши түгел без, тик кирәк
Акыл белән атып калу.

Аллаһ саулык бирсен, дога кылыйк, булсын
Дәүләт теле – туган телебез,
Белем-тәрбия, сәнгать һәм изгелек
белән үтсен безнең һәр көнебез!

Күңел боларда булмаса, булса башка далада,
Димәк, ул – черек күңел.
Дин, Милләт, Ватан өчен янып-көймәгәннәр
Безгә һич кирәк түгел!

## Шөкер ит

Шөкер ит, якташ, тормышыңа:
Бар икмәгең, эчәргә суың.
Алсаң башканың насыйбын,
Хәрам булыр хәләл ризыгың.

Шөкер ит, якташ, тормышыңа:
Бар, шөкер, эшең, җылы өең.
Утырсаң башка бер арбага,
Һәрчак көйләрсең аның көен.

Шөкер ит, якташ, тормышыңа:
Бар гаиләң, бар якыннарың.
Үрелсәң ятимнең хаккына,
Йөз чөерер барлык туганнарың.

Шөкер ит, якташ, тормышыңа:
Сау-сәламәт аягың, кулың.
Итагатьле кызың үсеп килә,
Дөреслеккә омтыла улың.

Шөкер ит, якташ, тормышыңа,
Тәүбәгә кил, борыл кыйблага!
– Гафу кыл, гөнаһларымны, – дип,
Сәҗдәгә кит, ялвар Аллага!

## Үрнәк сыйфатлар

Сабыр булыйк, чыдам булыйк, дөрес һәм тугры булыйк!
Хаталардан, ялгыш юлдан, зинадан ерак торыйк!
Яхшы кешедән үрнәк алыйк, начарыннан гыйбрәт!
Тирләтер мәхшәр көнендә ялган әйтү һәм гайбәт!
Әти-әни, өлкәннәргә итагать, хөрмәт итик!
Яшь буын тәрбиясенә берүк игътибар итик!
Әхлак, гыйлем, игелеккә өндәү – безнең эшебез,
Дин вә телне саклыйк, бердәм булыр безнең көчебез!
Ерак торыйк кяфер, мөшрик, мөнафыйкъ ишеләрдән,
Ырымнарга ышанучы, мәкерле кешеләрдән!
«Харут-Марут»ның кыйссасын дөрес өйрәник, белик,
Сихер, күрәзә, багуның гөнаһ икәнен белик!
Хәрәм ризык, кеше хакы – бигрәк нечкә мәсьәлә.
Киң күңеллелек белән тик чишелә бу мәсьәлә.
Изгелек, юмартлык – рәсүлемнең үрнәк сыйфаты.
Тәкәббер, саран булуның җәзасы, ай-һай, каты.
Хакыйкатькә тугры булыйк, гыйбадәткә омтылыйк,
Җыен юк-бар сафсатадан, дусларым, ерак торыйк!



Лилия
Фәттахова

# ГАЯРЬНЕКЕЛӘР

хикәя

Габбас икенче көн инде үз-үзенә урын таба алмый. Тумыштан тыныч, салмак, уен җиде кат уйлап кына сүзгә төрә торган, ашыкканнан акыл сорама дип санаучы ирнең күңеле айкала. Үз улы бит, үз улы! Үз каны. Җанының әллә кай төшләренә берегә бит ул бала кисәге. Күпме әйтте, күпме кисәтте: тыңламады бит. Адвокатлык хезмәтендә какланып, чиләнеп, каешланып беткән атасын тыңламады. Имеш, башкача булдыра алмый. Имеш, безнең бүтән җиребез юк, син дә күз йом, мин дә күз йомыйм, аннары балаларыбызның күзенә ничек карарбыз? Гаярь Гайнан дип ат алган бабасының кайнар каны ага шул бәдәнендә, бер дә бүтән түгел.

Габбас ишекле-түрле йөргән җирдән туктап калды. Карчыгы кайтты бугай, ишекләре «шаярма алай» дип, тавыш бирде дә тынды. Майлыйсы бар – кул тими.

– Гайшәбикә җаным-ахирәт кайттымы? Гайбәт төяп җибәрделәрме, гыйбрәтме, беләмче карчыгым? – дигән булды ир, җиңел сөякле хатынына таба атлап.

– Менә инде, гайбәт ташып йөрер яшьтәме соң инде без? Зәкия апаның хәлен белеп кайтышым, картым, – дип куйды Гайшә, акъяулыгының кырыеннан бүселеп чыгарга иткән тыңлаусыз чәчләрен рәтли-рәтли. – Бер-бер хәл булмагандыр бит? Иртәләгәнсең бүген.

Моннан кырык еллар элек зәңгәр күзләренең төбенә батырып, бөдрә чәчләренең исеннән исертеп гашыйк иткән зифа буйлы кызыкай бүген аңа тормышның ачысын-төчесен иңгә-иң куеп күтәргән ханым-солтаным булып карый. Хәер, Габбас гомер-гомергә йөкнең авырын үз иңенә алырга тырышты: хатынының җан тынычлыгын бозасы килмәде. Бар нәрсәне йөрәк аша үткәрә торган хисчән хатыны болай да саулыкка туймый иде.

– Юк, сине сагындым, җимеш, – дип, кочагына алды аны ир, күңелдәге давылын басарга тырышып.

Икесе дә алтмышның уртасына таба барган ир белән хатын бераз берберләренә сыенып, тын гына басып тордылар. Яшьлектән калган гадәт иде бу – бер-береңнең сулышын тою, йөрәк тибешен ишетү. Җиңел чакта да, кыен чакта да бер-беребезгә сыеныйк дип уйнап-көлеп башлаганнар иде, тәмам бер ритуалга әйләнде ул алар өчен. Шуннан соң гына чәйгә утыралар, шуннан соң гына тормыш-көнкүреш хәлләрен сөйләшә башлыйлар иде. «Тик үзем әйтмәсәм, ни булды дип сорама, җаным», – дигән иде Габбас. «Ә син, мин берни сөйләргә теләмәсәм дә, төбенә төшми туктама, яме, җаным», – дигән иде Гайшә. Менә ничә еллар инде язылмаган канун сыман үтиләр алар сүзләрен.

– Ул-бу юк алайса, – дип сынап карады Гайшә иренә, күзләрен кыса төшебрәк, тик төпченеп тормады.

– Һаман да шул бер балык башы инде бездә. Эчәләр дә сугышалар; эчәләр дә урлашалар. Тормышның кояшсыз ягы.

– И-и-и, нигә бар кеше дә кешечә яшәмидер инде.

– Һәркем үзе белгәнчә яши.

– Яки белмәгәнчә.

– Белмәгәнен белмичә.

Алар шулай бераз сүз уйнатып алдылар. Гайшә аңлый: ире эш турында барыбер сөйләмәячәк. Кирәк тә түгел инде ул аңа. Әшәке адәмнәрдән, яман бәндәләрдән Аллам үзе сакласын; балаларны, оныкларны Үзе сакласын. Гайшә ялга чыкканнан бирле дин-шәригать юлында; инде үзенең дә мәҗлесләрдә Коръән укуын сорый башладылар. Габбас ул якка бик тартылмый әле. Дөрес, елга бер корбанын чалдыра, зәкят-садакаларын кызганмый. Ләкин Гайшә комганнарын тотып, тәһарәт алып йөргәндә, намаз укыганда, ул тыныч кына гәҗит-журнал укып утыра; эш буенча кәгазьләрен караштыра. Ир сүзеннән чыгарга гадәтләнмәгән Гайшә «әллә син дә намазга басасыңмы минем белән» диебрәк бер генә сүз катып караган иде, «әйдә, җаным, син моны минем үземә хәл итәргә калдыр инде, яме» дигәч, башка сүз үстереп тормады. Диндә көчләү юк, диләр бит; кемнең күңеленә кайчан сала орлыкны Аллаһ Тәгалә. Күңел дигәннән, бая сыенып басып торганда, ир канатының күңеле борчулы кебек тойды ул. Йөрәге дә әллә ничек дулабрак тибәме шунда? Хәерлегә булсын.

Шамил турында әйтми дөрес эшләдем, дип уйлап куйды ир, эш кабинетына кереп утыргач. Кеп-кечкенә Гайшәнең кеп-кечкенә йөрәгенә сыймас ул, әнә әле дә йөрәге уйнап торганга охшаган, үзе сиздермәскә тырышса да, сизде аны Габбас.

«Бераз эшләп аласым бар» дип кереп китсә дә, башында эш кайгысы юк иде. Телефонына дус-иш җибәргән хәбәрләргә тагын бер күз салып алды да улының номерын җыйды. Кичәдән бирле – «абонент җавап бирми». Күңелендә соңгы сөйләшүләрен яңартты.

– Улым, хәзер андый юллар белән эш итү куркыныч. Сез бүре авызыннан бәрәнне тартып алырга җыенасыз. Сез тартышкан саен очлы тешләрен ныграк батырачак ул корбанына – бәрән исән калачакмы соң? Каш ясыйм дип, күз чыгару булачак бу.

– Ә нишләргә тиеш соң без, әти? Бүреләр азынганын тыныч кына карап торыйкмы? Аннары көтүләре белән сарыкларга һөҗүм итсеннәрме?

– Соң, улым, хәзер дә шул ук хәл бит инде. Син дә, без дә системага каршы барып, берни дә кыра алмыйбыз. Система көчле, ул үзенә кирәкле кешене куя, кирәксезен ала. Никадәр пар чыгарып йөрсәгез дә, ахыр чиктә үзегезгә зыян гына салачаксыз.

– Бакча артында ук җиреңнең маен сыгып алсыннар, коенып үскән күлләреңне киптереп бетерсеннәр, ә син шуларны күрмәмешкә салыш. Шулаймы, эти? Без бит бу җирдә килмешәк түгел! Килмешәк булсак, ник чукынып китмисана җирегез дияр идек!

– Кызган баштан түгел, уйлап эшләргә кирәк, улым. Бүренең авызыннан бәрәнне алу өчен аны башка нәрсәләр белән кызыктырырга кирәк, алдатырга, вәгъдәләр бирергә. Зирәк кеше шул юлны сайлый. Урамга чыгып, көч күрсәтү заманы түгел хәзер.

– Тешсез икәнлегеңне сизгән саен отыры котыра бит алар. Үзең күреп торасың, бабайлар авылында урманга бару юлларын да томалап сөрдерделәр; елга буйларын кемнәргәдер сатып җибәргәннәр ди әнә. Көтү көтәргә болын калмады бит инде авылда! Киләләр дә, талыйлар да китәләр! Файдасы юк, дисең. Зәңгәр күлне саклап калдык бит узган ел. Егетләр белән бергәләшеп каршы тормасак, интернетта шау-шу куптармасак, аны да пыран-заран китереп аткан булырлар иде.

– Ул чигенүләр вакытлыча гына ул, адвокат борыным шулай сизә.

– Димәк, син безне хупламыйсың?

– Хупламыйм. Кылыч өстеннән йөрисез. Әнкәңне уйла, хатыныңны, балаларыңны уйла.

– Аларны уйлаганга йөрим бит инде, эти. Әллә маема чыдаша алмаганнан йөримме? Кайвакыт балаларны көннәр буе күрмим. Ярый ла, бәхетемә Сөмбел аңлый. Ә син аңламыйсың, эти. Бер-бер хәл булса, якламассың да әле.

– Мин сәяси эшләргә алынмыйм бит, беләсең. Тыныч кына пенсиягә чыгасым килә, исемемне тапламыйча. Син дә уйла.

– Их эти!

Ата белән ул арасындагы бу каршылык берничә ел бара иде инде. Габбас – карт төлке; заманында үзе дә гаделлек дип сикеренеп караган иде, төрмә белән имин тормышның аермасын тиз аңлаттылар. Иренен чәйнәп, кешедән яшеренеп, ярсый-ярсый елаган чаклары аз булдымы яшьрәк чакта? Башың белән күпме генә төй син ул диварны, маңгаең күбәчәк, тик дөнья үзгәрмәячәк. Киребеткән улына да шуны аңлатырга азаплана да соң...

– Мин җилләнеп кайтам әле.

Габбас бүлмәдә китап укып утырган хатынына шулай диде дә, сораумазар биреп туктатмасын тагын дигәндәй, ашыга-ашыга чыгып та китте. Исәбе – сәгать ярымлык кына арадагы туган авылыннан әйләнеп килү иде. «Шаярма алай» дип озатып калды күпне күргән авыр ишек.

Машинага утыруга, җыр кушып куйды. «Үз илемдә» дип җырлый иде берәү. Юлларда йөргәндә, күп вакыт җыр тыңлап барса да, җырчыларын аермый диярлек. Аңа Илһам белән Әлфия бар да, Хәйдәр бар, Зөһрә бар... Нигәдер хәзергеләргә атасы шикелле «гөмбәләр» диясе килеп тора.

Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да, –

дип җырлый иде атасы да.

Бар да мулдан иде аңарда. Күкрәктән чыккан тавыш та, күрше-күлән ипи-тозга дип керсә, кулы да мулдан иде. Ачуы чыкса, ачуы да мулдан иде, гайрәтләнсә – гайрәте-гаярьлеге дә. Озын буйлы, нык бәдәнле иде ул. Гомере генә озын булмады: карап торышка типсә, тимер өзәрдәй агай, җитмешен дә тутырмый китте дә барды. Яныл-пешеп, печән чабып кайтты да салкын әйрән эчеп торган җиреннән капыл гына күзләрен йомды. Шулай да була икән. Әллә шуңа инде улында атасының холкын күреп куркып куя Габбас; ул да бабасы шикелле янып яши; аңа да үз дөньясы гына җитми.

Габбас авылга җитәрәк машинасын Олы тауга таба борды. Гомер бакый шул тау итәгеннән печән чапты алар, әниләре исә апа-сеңелләре белән җиләк, мәтрүшкә җыйды. Тау астындагы чишмәнең тешләрне сындырырлык салкын суын бәлзәм урынына тотарлык, ди иде мәрхүм әтиләре. Кушкаен аланы дип аталган үз аланнары бар биредә. Бер-беренә сыенып үскән карт каеннар инде алар хәзер, ә яшьрәк чакта, Гайшәсе – Зәңгәр күзе белән танышканда, алар кебек үк яшь иде әле. Малайчак юләрлеге белән «Габбас» дип, исемен каезлап язган чакта алар әле җир йөзендә усал куллы адәмнәр дә барлыгын белми дә иде. «Маңгаеңа язасың калган!» Атасы, бил каешына тотынган җиреннән кире уйлап, сүз белән каезлады аны бу шуклыгы өчен. Һәм бер риваять сөйләде.

Бик борынгы заманнарда кешеләр яхшылык турында оныта башлаганнар. Бер-берләрен алдыйлар икән, башларында кара уйлар, ди, күңелләренә көнчелек белән явызлык хуҗа булып алган, ди. Мондый хәлне күреп Җир-ана хәлсезләнгән, көчсезлеген сизеп ыңгырашкан; тәне ялган һәм көнчелек кабыгы белән капланган. Һәм бервакыт аның ыңгырашуын Күк кызы ишеткән, ди. Караган да Җиргә – коты очкан: кешеләрнең кара уйлары Җирне буар елан шикелле чорнап алган, Җир акрын гына үлеп ята икән. Җирнең әрнүе Күк кызының йөрәген дә яралаган – ул чыдамаган, меңнәрчә кисәккә таралган да Җиргә чәчелгән. Кешегә эләксә, кешенең җаны чистарган, ди. Агачка тисә – агачлар агарган, ди. Менә шулай ак каеннар барлыкка килгән бу җирдә.

Гомеренә җитәрлек сабак алды Габбас. Шуннан соң яр буйларына, Кушкаен аланына әтиләре белән нәни агачлар утыртып йөрде. «Агачларга тимәскә!» дип, хәтта такта кисәге дә элеп куйган иде.

Уйларына бирелеп, Кушкаен аланына якынлашты ир. Аның өчен «көч җыю урыны» иде ул. Кемдер Аркаимга бара, кемдер Валаамга, кемдер үзебездәге Зөя утравына. Гайнанныкылар өчен Кушкаен аланыннан да зуррак көч бирә торган урын юк иде. Җирнең бик күп почмакларын күргән олпат ир буларак әйтә ул моны хәзер.

Габбас капыл туктады. Риваятьтәге Күк кызы сыман хис итте ул үзен: йөрәге парә-парә килде. Аның Кушкаен аланы ыңгырашып ята иде. Аның Кушкаен аланы куш каеннарсыз иде. Ул урында караеп, ике төп тора. Якындагы яшьрәк каеннар да ботарланган: берничә әрҗәлек бүрәнә булып, әрдәнәгә өеп куелган. Өем-өем ботак-сатак. Аланның

мәтрүшкәле хуш исле печәне зур машина тәгәрмәчләре астында калып изелгән, сытылган.

Габбасның беренче уе тау астында урнашкан авылларына барып, бу вәхшилекне кем эшләвен ачыклау иде. Аннары кире уйлады: хәзер берни үзгәртеп булмый бит инде. Машинасын кабызды да килгән юлына ашыкты. Башында гөжләгән уйларын, йөрәгенә утырган авырлыкны басар өчен җыр кушып карады.

Нигә белмәдем җирдә син барын...
Бер кызны күрдем дә яраттым...
Яшьлегемдә калган мәхәббәт...

Җырларның берсеннән икенчесенә сикерде – күңеле сораганын таба алмады. Илсөя Бәдретдинова дискын куйды.

Ачы тауда көтеп алдым
Сызылып таңнар атканын.
Күңел җырлый, сайрый тургай –
Талмасын канатлары.

Машинасын туктатып, озак үкседе ул. Җаны үкседе. Күзеннән сытылып чыккан сыңар бөртек яше кырынган шома битеннән тәгәрәп төшүен дә сизмәде. Эчендә нидер өзелгән иде бүген. Ниндидер бик якын, бик кадерле нәрсә иде ул. Гомере буе кырыс хезмәттә булган ир, беркайчан да күз яшьләренә ирек бирмәгән ир аны сүз белән аңлатып та бетерә алмый иде.

Үзләренә туры кайтмады: шәһәрнең икенче башында яшәгән улының йортына китте. Фатирда аны килене Сөмбел каршы алды. Мөслимәләрчә киенгән киленнәренең күзләре кызарган. Ул, каенатасына туры карамаска тырышып, пышылдап кына аш бүлмәсенә чакырды:

– Әткәй, балаларны йоклаткан идем. Әйдәгез, чәй куям.

– Тамак кайгысы түгел әле, кызым.

Киленнәре өченче балага түгәрәкләнеп килә. Аны ничек тә булса азрак борчырга дип уйласа да, монда инде хәлләр әдәп саклаудан узган иде. Габбас соравын турыдан бирде:

– Шамил кайда утыра?

Сөмбел әле һаман да күзен күтәрми генә адресны әйтте.

– Сез борчылмагыз, дуслары яклаячак аны. Озакламый кайтачак ул, иншалла.

Габбас беркатлы хатын-кызга киресен раслап утыруны кирәк санамады. Азрак белүләре яхшырак.

– Акчагыз бармы?

– Бар. Дуслары ярдәм җыюны да оештырган.

– Кешедән өметләнеп утырмагыз. Без булганда, – дип өстәде Габбас. Кесәсеннән портмонесын алып, булган кәгазь акчасын өстәл читенә куйды. – Ни кирәк булса да, иң беренче үземә шалтырат.

Шамилнең ата-анасыннан акча алуга катгый каршы булуын белгәнгә шулай диде.

– Ярар, китим мин. Шамил белән сөйләшәсе бар.

– Кертерләр микән?

– Мине кертерләр.

– Сез... сез... аны якларга булдыгызмы?

Габбас икеләнеп басып торган килененә карады.

– Атасы якламый кем якласын аны? Ата аркасы авыр чакта кирәк.

– Соң сез бит... Каршы идегез.

– Мин әле дә каршы. Анысы аның башка мәсьәлә. Алга таба ничек яшисен соңрак уйлашырбыз.

«Әйткәнем дөрескә чыкты бит, үзең күрәсең. Өч бала белән утырып калырга мөмкинсең. Ә аны рәшәткә артына илтеп тыгарлар. Ишетүемчә, әшәке статьялар әзерлиләр», – димәде ир, кыз-кыркынга ул сүз артык иде. Габбас улына карата соңгы вакытта кычкырып әйтергә дә куркыныч сүзне кулланырга җыенуларыннан хәбәрдар иде инде.

– Их, киленкәем! – диде ул, ачынып. – Нигә тыймадың соң, ә? Әни кеше буларак диюем.

– Аның ничек җаны әрнүен белеп торам бит, әткәй. Һәркем җаны кушканча яшәргә тиеш, ди ул. Ни булса да, Аллаһтан узган эш булмас.

– «Ак бүре» оешмасында таныштыгыз бугай шул, – дип кул селтәде Габбас, икәү бер сүз сөйләгән килене белән улын уйлап. Берни эшләр хәл юк, ир бала үз юлын үзе сайлый. Парын да уйлары белән күңеленә якынын сайлады, баштан ук аңлашылган иде.

Бер чынаяк чәй генә эчте дә кузгалды Габбас.

– Әниегезгә әйтә күрмәгез. Күпме соңрак ишетә, шулкадәр яхшырак. Аңа кадәр, бәлки, ни дә булса майтарып булыр. Үзеңне сакла. Балаларны да.

Каенатасы ничек көтмәгәндә, кинәт килеп кергән булса, шулай тиз генә җыенып чыгып та китте.

– Әнкәй белә шул инде, – дип, килененең пышылдап кына әйткән сүзләрен ишетмәде ул.

Шәһәрнең икенче башында исә нәфел намазына утырган хатыны имани сабырлык белән теләкләрен тели иде: «Аллаһы Тәгаләм, балаларымны һәр төрле явызлыктан һәм начарлыктан, пычрак нәрсәләрдән, яман кешеләрдән сакла. Фәрештәләреңне аларга юлдаш кыл. Тормышларының ахырына кадәр әманәттә имин кыл.

Йа Раббым! Балаларым өчен сөенү шатлыгы бир. Аларны картлыгымда таянычларым ит, кадер-хөрмәтләрен күрергә насыйп ит. Кыямәт көненә кадәр имин нәсел булып яшәргә акыл, зиһен, күркәм холык бир. Йа Раббым...»



*Дмитрий Моисеев 1986 елның 7 октябрендә Чабаксарда туган. И.Н. Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаган. Башта «Çамрăксен хаçачĕ» («Яшьләр газетасы») корреспонденты булып эшли, аннан соң шул ук басманың мөхәррире була. 2016 елдан алып «Хыпар» Нәшрият йорты»ның баш мөхәррир урынбасары. Хәзерге вакытта шушы ук медиахолдингның директоры-баш мөхәррире вазифаларын башкара.*

*Дмитрий Моисеев Россия Журналистлар берлеге, Чувашия Язучылар берлеге, Төрки дөнья яшь язучылар берлеге (Баку, Азәрбайҗан) әгъзасы. Ике тапкыр Чувашия Президенты стипендиаты, Чувашстанның Дәүләт яшьләр премиясе лауреаты һәм башка бүләкләр иясе.*

*2022 елда аның «Ют пахчари хăмла çырли» («Кеше бакчасыннан өзгән кура җиләге») дигән китабы басылып чыга, ул шул ук елның иң яхшы балалар китабы булып таныла. Әдәби әсәрләр язу белән бергә ул популяр авторларның әдәби әсәрләрен чуваш теленә тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә.*

Дмитрий
Моисеев

# КЕШЕ БАКЧАСЫННАН ӨЗГӘН КУРА ҖИЛӘГЕ

хикәя

– Син кем булдың соң әле минем белән болай сөйләшергә? Нәрсә, синең атаң инженермы, анаң врачмы, югары урыннарда утыраламы әллә? Үзең соң, үскәч, кем булырсың икән? Карак, угрымы? Күреп тор, әйткән иде диярсең менә, башың төрмәдә черичәк синең!

Татьяна Сергеевна төкерек чәчә-чәчә ачуланганда, Артёмның йөрәге табан астына ук төшеп тибә башлады, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Кем-кем, сеңлесенең укытучысы эт итеп сүгә бит!

Бу сөйләшүне Артём белән бергә кеше бакчасына төшкән малайлар да ишетә ала иде, әмма алар күз ачып йомганчы койма ярыгыннан шуып кына үттеләр дә елгага таба чаптылар. Артём әллә куркуыннан, әллә укытучы апасыннан оялудан кысылып калды – ни алга, ни артка чыга алмый. Әллә койма ярыгы бәләкәйрәк, әллә малай тазарак булды шунда...

– Качарга өлгергән малайлар кемнәр иде? Әйт, тиз бул, – дип, аның саен кызды бакча хуҗабикәсе.

Артём нишләргә дә белмәде: җәйге каникулга әби-бабайларына кунакка

кайткан шәһәр малайларының исемнәрен әйтсәң, сатлык буласың; укытучы апаның соравына җавап бирмәсәң дә, яхшы түгел... Артёмның бите ут капкандай яна башлады, кычыткан белән өтәләгәннәр, диярсең. Ул башын аска иеп, бер сүз дә әйтмичә басып торуында булды.

Малайдан җавап ала алмагач, Татьяна Сергеевна сөйләнә-сөйләнә китеп барды: «Үзләренең бакчасындагы җиләкне шәһәргә алып барып саталар, ашарга кеше бакчасына төшәләр...»

«Оят, бигрәкләр дә оят! – дип, җанын талкыды Артём да. – Бер җиләк өзеп алган өчен карак исеме күтәреп йөр инде!..» Дөресен генә әйткәндә, аның шәһәрдән кайткан дуслары белән барасы да килмәгән иде, тегеләр әйдә дә әйдә дип ялынгач ризалашты. Ике-өч җиләк өзеп каба алдылармы икән, «җиләк карак»ларының эзенә төштеләр...

Татьяна Сергеевнаның туры юлга күндерүне күздә тоткан нәфрәте яуганда, Артём авыз эченнән генә үз-үзен акларга маташып торды әле:

– Мин бер генә җиләк ашадым... Берне генә...

Менә хәзер үзе генә калгач, ул Татьяна Сергеевна әйткән сүзләрне каткат исенә төшерде: «Карак! Башың төрмәдә чериячәк!» Бер җиләк өчен шундый куркыныч сүзләр әйтәләр, димени? Болай килеп чыгасын белсәме, ул иптәшләренә иярер идеме? Нәрсәгә кирәк иде инде аңа кура җиләге? Үзләренең бакчаларында тулып ята... Татьяна Сергеевнаны урамда яки мәктәптә очратканда, ничек итеп күзләренә карар? Үз-үзен ничек тотар... Артёмның җавапсыз сораулардан башы тубалдай булды.

Шушы көнгә кадәр Артёмның сыер савучы булып эшләгән әнисе белән тракторчы әтисеннән оялу турындагы уй башына да кереп чыкмаган иде. Хәзер исә ул әти-әнисенең югары вазифаларда эшләмәвенә, аларның хәзергечә әйтсәк, «кәттә» түгеллегенә чын мәгънәсендә эче пошып, үкенеп куйды. Шунда ул мәктәптә 8 Мартка язган иншасын исенә төшерде. Әнисенең иркәләп елмаюы, аның җиңел-җиңел генә атлап йөрүе турында ничек яратып язган иде ул!.. Әнисе барысына да өлгерә, иртән иртүк тора, сеңлесе белән аңа ботка пешерә, мәктәпкә барысы да әзерме дип, бер барлап ала да фермага йөгерә. Сыерларына ул яратып, кушаматлары белән генә дәшә, тегеләре дә аны шатланып мөгрәп каршы ала. Авырып китсәләр, сабырлык белән карый...

Әнисе савып алган сөтне шәһәргә алып китәләр, аннары ул сөтне камыр изгәндә кушып, тәмле ризыклар пешерәләр яки шәһәр кешеләренә сатуга куялар. Артёмга әнисе бик кирәкле, файдалы эш башкара кебек тоела иде. Ул иншасына да шулай дип язды.

Әтисе дә чәчү вакытында да, печән чорында да, урып-җыюда да намус белән хезмәт куя, кайчагында куна-төнә эшләргә дә туры килә иде. Бервакыт «Тантӑш» (Яшьтәш) газетасы журналисты Артём янына мәктәпкә үк килгән иде. Аның әтисе турында очерк язарга. «Күз алдына китерәсезме, бите дә, куллары да кап-кара, киеме дә солярка белән тузанга баткан, ә аңа барыбер: эшен ярата ул! Ул тракторын сеңлем белән мине яраткан кебек яратадыр сыман тоела, кайчакта күбрәк тә әле. Әмма без аңа үпкәләмибез, ул бит безнең өчен тырыша, акча эшли! Ә акчасыз бүген яшәп булмый», дип, өлкәннәрчә фикер йөртә Артём газетада басылып чыккан «Улы да әтисенә охшап, тракторчы булырга хыяллана» дигән мәкаләдә...

Әйе, Артём, чыннан да, мәктәпне тәмамлагач, механизатор булырга җыена иде, ә хәзер менә аңлады: тракторчы һөнәре мактаулы түгел икән...

Күпләр, бала кеше җитди итеп уйлана белми, дип саный. Ничек кенә уйлыйлар әле! Менә Артём да башта – укытучы, аннан соң бәлки директор да булырмын әле дип хәл иткәнчегә кадәр йоклап китә алмады. Фермада әнисенә дә булышасы килми башлады, әтисенә дә печән-салам ташырга ярдәм итәсе килмәс инде...

Артёмның күңелен икенче бер борчу ныграк тырный әле: «карак» исеменнән ничек котылырга соң?.. Һәм ул, үзе уйлаганча, дөрес карарга килде. Әйе, ул 1 сентябрьдә мәктәпкә килү белән линейка вакытында ук үзенең гаепле икәнен таныячак, шунда аны барысы да ачулансыннар, оялтсыннар, ә ул барысыннан да, беренче чиратта, Татьяна Сергеевнадан гафу сорар. Гәрчә апасының сүзләрен гадел дип санамаса да. Шул ук вакытта Артёмның укытучы апаны аклыйсы да килә: бәлки, аның, шундый авыр сүзләр әйтеп, малайны кисәтүе булгандыр, алга таба караклык эзенә басмасын, авылның сукбае, мәңге айнымас Петяга охшамасын, аның кебек шешәдер, тимер-томыр җыеп сату көненә калмасын яки кибеттә урлашып тотылган өчен ел ярым утырып кайткан Михаил кебек булмасын, диюедер. Артём әбисе белән күрше әбиләренең аларны адәм актыклары итеп сөйләгәнен бер генә ишетмәде... Малайның бер генә дә аларга охшыйсы килми иде...

– Артём, тор, улым, кура җиләге җыярга кирәк. Җыеп, суыткычка тутырып куйыйк, кышка витамин булыр. Салкын тисә, кура җиләге белән чәй эчәсең дә, шундук терeләсең! Күбрәк җыйсаң, базарга илтеп сатарга да булыр, – дип иркәләп кенә уятты аны әнисе.

Әнисенең сүзләре Артёмның ярасына тоз сипкәндәй тәэсир итте. Ул хәтта яңа гына боздан арчылган салкын сулы Иделгә чумдырып алган кебек куырылып куйды. Тамара Витальевна да улының үз-үзен тотышында үзгәрешне сизми калмады: авырып китмәгәнме тагын? Маңгаен тотып карады. «Хәлең ничек?» – дип сорады. Артём: «Барысы да яхшы», – дип мыгырдады да киенеп кура җиләге җыярга чыгып китте...

Киртә буйлап үсеп утырган куакларда эре-эре булып кура җиләкләре асылынып тора. Иртәнге кояш нурларында алар тагын да эрерәк күренә, мине өз дә мине өз дип ымсындырып торалар иде, әмма Артёмның аларның берсенә дә кагыласы килмәде: күз алдында Татьяна Сергеевнаның образы калка да, колакта аның нәфрәт тулы сүзләре яңгырап ишетелә. Укытучы гүя митингта чыгыш ясый иде...

Атна буена авыр уйларына чумып йөргәч, ниһаять, Артём алга таба ничек яшәргә дигән бер план корды: аңа хәзер бик яхшы укырга да бик зур, кирәкле кеше булып үсәргә кирәк. Шул ук көнне ул авыл китапханәсенә барып, бер өем китаплар алып кайтты, буш вакытында йотлыгып-йотлыгып, шуларны укыды. Көндәлек яза башлады, анда көннәренең ничек узуын, нинди китаплар укуын, кайсы китапның герое ничек тәэсир иткәнен – теркәп барырга ияләште... Классиканы гына түгел, заманча авторларны да укыды. Китапханәче максатчан үсмерне тагын да дәртләндерер өчен үз хисабына яздырып алдырган журналларын да биреп җибәрә иде. Артём алар аша чит ил, аерым алганда, Америка язучыларының психологик

романнары белән танышты, журналларның яңа саннарын түземсезлек белән көтеп ала иде.

Бер үк вакытта ул үзенең физик әзерлеген дә ныгытты. Әтисе үзенә турник ясап биргәнче, Артём иртән дә, кичен дә мәктәп стадионына барып, турникта тартыла иде. Үсмернең ихтыяри рәвештә үз-үзен җәфалавын күреп, мәктәпнең каравылчы бабае мыек астыннан гына көлеп тә йөрде әле: алтынчыда гына укыса да, кияү егете булырга әзерләнә. Хәзерге балалар иртә өлгерә, янәсе...

Шулай итеп, өч ел узып та китте. Шушы вакыт эчендә Артём районда ике олимпиадада җиңү яулады – математика белән әдәбияттан. Әдәбият белән аңлашыла инде: ул бик күп язучыларның иҗатын белә, ярата, чуваш язучылары Ильбәк Мигулайны да, Леонид Агаковны да, башкаларны да. Кайчак алар турында сөйли башлый, әле гадәттәгечә итеп түгел, үзенчә, хәтта туктатып булмый, сөйли дә сөйли. Артём әдәбияттан теләсә кайсы сорауга җавап бирә ала, ә менә математикадан олимпиадада җиңүенә ул үзе дә гаҗәпләнде: математиканы алай ук яратмаса да, тырышып укый иде. «Булмас! – диде ул, мәктәп линейкасында аның фамилиясен әйткәч. – Мөгаен, олимпиадада катнашучыларның эшләрен тикшерүчеләр ялгышкандыр...» Шулай да рәхәт иде аңа: сыйныфташлары, мәктәбе алдында йөзе ак!

Артём карашы белән генә Татьяна Сергеевнаны эзләде, әмма ул үзе җитәкләгән сыйныф укучылары арасында юк иде. Артёмның уңышы турында беренче булып, төпсез кесәләрендә яраткан оныкларына бетмәс-төкәнмәс конфетларын әзерләп торган әбисе дә, хәтта әтисе белән әнисе дә түгел, ә нәкъ менә аның ишетүен теләгән иде. Йә, ярар, Татьяна Сергеевна линейкада булса, барыбер бу яңалыкны ишетми калмагандыр. Кызганыч, бүген Артём аның күзләренә карый алмады...

Соңрак Артём тагын җиңүләр яулады, бик күп булды алар. Мәктәп укучылары аларны үзешчән мәктәп оешмасының җитәкчесе итеп сайладылар; ул «Сеспель учагы» фестивалендә катнашты, Чабаксарда сәнгатьле укучылар конкурсында җиңде... Һәм линейкада аның уңышлары турында сөйләгәндә, Татьяна Сергеевна беркайчан да янәшәсендә туры килми иде. Ә аның укытучы апасының күзләренә туры карыйсы килә иде...

Унбиш ел узгач, көннәрдән бер көнне Артём Михайловичның Мәскәүдәге фатирында телефон шалтырады. Артём белән ун ел дәвамында бер парта артында утырып үскән дусты Николай булып чыкты. Мәктәпне тәмамлап чыгуларының унбиш еллыгына чакырып шалтыратуы. Артём очрашуга кайтырга булды һәм җомга көнне кул астындагы хезмәткәрләренә хәбәр итте:

– Дүшәмбе генә киләм. Эш режимын шулай ук дәвам итәбез. Мин килгәнче, барысы да тәртиптә булыр дип өметләнәм.

Өйгә кайта торган юл шактый озын – алты йөз чакрымнан артыграк. Озын юл, кагыйдә буларак, уйларны да еракларга алып китә. Менә хәзер дә Артём Михайлович бизнесын алга таба ничек үстерү, төбәкләрдәге кулдашлары белән элемтәләрне ничек урнаштыру һәм башкалар турында уйлана... Шунда гына исенә төште: әтисе Түбән Новгородка кереп,

комбайнына кирәкле запчасть алып кайтырга сораган иде бит! Әнисе дә, күрәсең, иреннән калышмаска теләптерме, бакча җиләгенең яңа сорты белән кызыксынып киткән. Итальяннар чыгарган сорт, ди. Ярый әле, шәһәрдән чыгып җиткәнче исенә төште монысы да. Шулай да кире борылырга туры килде, заказларны, кирәкле запчастьны эзләп тапканчы шактый вакыт узарга мөмкин. Ләкин берни эшләр хәл юк – әтисе белән әнисе фермерлык белән мавыгып киттеләр дә хуҗалыкларында нәрсә генә үстермиләр хәзер! Гектар-гектар иген чәчәләр, дистәләрчә сутый җирдә җиләк үстерәләр...

Җәй көне караңгы соң төшә, һәм Артём Михайлович Сура елгасы күперен чыкканда, якты иде әле. Туган җирләргә якынайган саен йөрәге катырак тибә, ә кайчагында, киресенчә, туктап калгандай итә. Сыйныфташлары белән булачак очрашу да күңелен җилкендерә.

...Ул инде туган авылына таба борылган иде, юл читендә таякка таянып, әкрен генә атлаган карчыкны күреп алды. «Безнең авылныкы булырга тиеш», дип уйлады ул һәм туктап, карчыкны утыртты.

Алгы утыргычка кереп утыргач, тегесе чал чәчләрен кызыл яулыгы астына пөхтәләп кертеп бетерде дә:

– Рәхмәт инде сиңа, улым, мине хөрмәтләп утырткан өчен, – диде арыган тавыш белән. – Бөтенләй хәлсезләндем, югыйсә болай иртә картаермын дип уйламаган идем...

– Сез әле алай карт түгел, – дип тынычландырырга тырышты аны Артём Михайлович. Һәм шунда ук ник әйткәненә үкенеп куйды: карчык тамырлары беленеп торган чандыр куллары белән битен каплап елап җибәрде... Ул машинасын туктатты, ә әби бераз тынычлангач, сөйләп китте:

– Белсәң иде, улым, мин бит гомерем буена балалар укыттым, ә үземнекеләргә җитәрлек итеп тәрбия биреп бетермәгәнмен. Берсе зиратта инде, икенчесе кирпеч саный... Шуның яныннан кайтышым, чәй, шикәр илттем. – Аның тавышы элеккечә калтырап чыга иде. Шунда ул машина йөртүчегә таба борылды. Һәм аларның карашлары очрашты...

Татьяна Сергеевнаның күзләре егерме ел элекке кебек үк якты иде. Ә менә башкасы... Йөзен тирән җыерчыклар каплаган, иягендә, маңгаенда картлык таплары чуарлана...

– Бигрәк иртә картайдым шул, иртәрәк, – дип ачыклык кертәсе итте ул, Артёмның игътибар белән үзенә карап торуын күреп. – Ирем эчте, ничек теләсә, шулай йөрде, балаларга әйләнеп тә карамады, кая анда тәрбияләү. Айлар буена югалып тора иде, кайткан арада әле берсен, әле икенчесен кыйнап китә... Берьялгызым үстердем мин аларны, инде икесен дә бер үк төрле итеп ашатырга-эчерергә тырыштым, киендердем, ә икесе ике төрле булып үстеләр, туганнар кебек тә түгел. Берсе икенчесен кешечә яшәгән өчен яратмады: өйләнде, йорт салып чыкты, тегесе-монысы... Ә кечесе әтисе кебек теләсә ничек йөрде... Берсендә табын артында утырганда эчтеләр дә сүзгә килделәр. Кечесе абыйсының эченә типте. Шундый итеп типкән, табиблар да коткарып кала алмады... Үзем судка кадәр барып җитмәс идем, килен тырышты – кече улымны утырттылар. Хәзер менә аның аркасында хөрмәтле укытучы түгел мин, үтерүче анасы исемен күтәреп йөрим...

Машина һаман да кузгалып китмәгән иде әле. Артём Михайлович Татьяна Сергеевнаның кулын учына салды да игътибар белән аның йөзенә

карады. Кайчандыр карак дип кычкырган малайны танымады, ахры, ул. «Монда кемнедер гаепләп торуның мәгънәсе дә юк инде хәзер. Табибмы син, укытучымы, һәркемнең тормышында үз-үзен тыеп кала алмаган мизгелләр була. Барыбыз да кеше бит», дип уйлады Артём Михайлович. Татьяна Сергеевна да ул вакытта әйткәннәрен оныткандыр, кеше авызыннан чыккан һәрбер сүзне исендә тотып бетерә алмый. Һәм ул укытучының күңелен күтәрергә теләп:

– Сез бит, Татьяна Сергеевна, миннән кеше ясадыгыз, – диде, елмаеп. – алтынчы сыйныфларда укыганда, мин сезнең бакчага кура җиләгенә төшкән идем. Шунда сез мине ачуланган идегез. Шул көннән соң беркайчан да чит кеше әйберенә кагылганым булмады, максатларыма үз көчем белән ирешергә тырыштым. Сез миңа бик яхшы сабак бирдегез ул вакытта, Татьяна Сергеевна! Бик зур рәхмәт сезгә!

Их, теленә тилчә чыккыры, нигә дип элеккеләрне искә төшерергә кирәк иде аңа?.. Болай да бәхетсез хатынга!

Татьяна Сергеевна тагын да ныграк каушап төште.

– Артём, синме бу? – ул күзләрен кысып, юлдашына текәлде. – Танымадым, бай булырсың, – диде һәм машина йөртүченең яңагыннан сыйпап куйды. – Мин инде сине очратудан өметемне өзгән идем. Гафу үтенеп кала алмам дип курыктым... Ул вакытта сиңа әйткән усал сүзләремне әле дә хәтерлим. Шайтан котырткандырмы, әллә инде исерек килеш кайтып кереп, кыйнарга килгән иремә ачуданмы... Ул вакытта качып, бакчага чыгып бара идем... Гөнаһ шомлыгына, анда син туры килдең... – Бераз гына дәшмичә утыргач, ул тагын өстәп куйды: – Сиңа әйткән ул сүзләр үземнең улыма төшкән, күрәсең.... Кыенлык килгән саен искә төшәләр иде... Кичерә алсаң, кичер син мине, юк икән...

Юл кырыенда туктап торган машина кузгалып китте дә караңгы төшеп килгән авыл эченә кереп, күздән югалды.

**Ландыш ӘБҮДӘРОВА** ***тәрҗемәсе***

# «БУ БИТ БЕЗНЕҢ СУКМАК!..»

Әдәбият мәйданына яшьли аяк атлап та, иҗат җимешләрен татар укучысына бераз соңрак, тыйнак һәм сак кына тәкъдим иткән әдипләребез шактый. Лирик якты-моңсу әсәрләр тупланган «Ялантауга ай кунган» (рус телендә «Ялантау»), «Сихәтләнү» җыентыклары, «Карт шомырт хатирәсе» (рус телендә «Воспоминания черёмухи») исемле китабы, балалар өчен язылган берничә жыентыгы белән тыйнак кына, ләкин шактый ныклы адымнар белән әдәбият мәйданында үз сукмагын булдырган Равилә Шәйдуллина-Мурат иҗаты – бүгенге көндә үз укучысын тапкан иҗат.

Хәзерге татар прозасының лирик-экзистенциаль канатын Равилә Шәйдуллина-Мурат «Ялантауга ай кунган» дип исемләнгән җыентыкта урын алган гаҗәеп якты, эчке тирән сагышлы повестьлары, «Карт шомырт хатирәсе» сагасы һәм «Тау башында бүре бар» романы белән баетты. Әдәбият мәйданына шигъри бәйләмнәре белән килеп кергән язучыбызның прозасы милли мәдәният традицияләрен баета, үстерә. Әдибә иҗатындагы лирик-эмоциональ башлангыч, моңсу-экзистенциаль бәян язма-басма сүзнең төп сурәтләү объекты – кешенең эчке дөньясы, кальбе, рухы дигән фикерне ныгыта.

Игътибарны Равилә Шәйдуллина-Муратның «Ялантауга ай кунган» (2016) исемле җыентыгындагы укучы хөкеменә тәкъдим ителгән ике повестена юнәлтик. Бу әсәрләрдә урын алган төп мотивлар әдибәнең соңгы елларда дөнья күргән романнарында үстерелә, баетыла.

Беренче – «Ялантауга ай кунган» әсәрен язучы үзе бәян жанрына нисбәтли. XX-XXI йөз татар әдәбиятын концептуаль якын килеп өйрәнүче әдәбият галиме Д.Заһидуллина карашынча, соңгы еллар татар прозасында повестьларны бәян дип билгеләү психологик анализ алымнарына, полифонизмга киңрәк мөрәҗәгать итү, текстларның композицион ачыклыгы белән бәйле, «татар әдәбиятындагы күчеш дәверендәге күренешләр».

Повестьның төп сюжет сызыгы – Зәйтүнә-Сәет мөнәсәбәтләре романтик яссылыкта тәкъдим ителә. Ятим үсмер егет Сәетнең кунак кызы Зәйтүнә белән Ялантауга менеп, айга сокланулары, тәүге кичерешләр матурлыгы, илаһилыгы әсәрдә кайма хасил итә. Романтик-сентименталь пафос повестьны романтик юнәлешкә якынайта, ләкин әсәрдә урын һәм вакыт төгәллеге вакыйгаларны детерминацияләргә мөмкинлек бирә: аларның сәбәпләре заманда, җәмгыятьтә икәнлеге ачык әйтелә. Шул рәвешле, М.Мәһдиевләрдән килгән стильне дәвам итеп, реализмны романтизмга хас алымнар белән баетып, Р.Шәйдуллина-Мурат совет һәм постсовет чоры җәмгыятенең бердәм моделен тудыра.

Повестьның төп герое «хыялый Сәет» образы лирик-экзистенциаль рухта укучыны үз артыннан вакыйгалар дөньясына алып кереп китә. Хисләргә бай, омтылышлары якты егет баянда уйный, җырлый, табигать һәм тормыш матурлыгын күрә. Повесть дәвамында аның хис-кичерешләренә анализ бирелә. Иртә ятим калган бала гомере буе әнисенең «салкын кулларын һәм йөрәк тибешен, әнисен күтәреп, мәңгелеккә зиратка илткәндә, аның өстенә ябылган кызыл җәймәнең бер почмагы яралы кош канаты кебек

җилдә җилфердәп баруын» гына хәтерли. Саф вөҗданлы, иманлы, чиста күңелле Зариф бабасы Сәеткә гомерлек гыйлем калдыра, тормышның катлаулы борылышларында ул берөзлексез бабасының сүзләрен искә ала. Сәет дискурсы, беренче чиратта, егетнең эш-гамәлләрендә чагылыш таба. Үзәк герой авырлыклар алдында баш имичә, алга атлавы белән игътибарга лаек. Язмыш алдан иманына тугры үсмерне үзе кебек нечкә күңелле, якты кичерешле Зәйтүнәне очратып сыный. Беренче кавышу кичennән соң, авыл үсмерләре хәерче, яклаучысыз Сәетнең башын каты яралап, аның тормыш тәгәрмәчен үзгә якка боралар. Озак дәвалану вакытында Сәет Зәйтүнәгә хәбәр салмый, кызны бәхетсез итүдән курка. Зәйтүнәнең хаста әнисен карап, шактый гаҗиз хәлдә кияүгә чыкканын белгәч, иркә Мәрьямгә өйләнгән Сәет ялгышканын аңлый. Үзен кечкенәдән яратып йөргән Хәниянең намусына тап төшергәннән соң, хатыныннан китәргә карар кылса да, Мәрьям белән балалары булачагын белгәч, ниятеннән кире кайта. Әлеге вакыйгалар Сәетне яңа рухи үсеш баскычына – намаз укуга әзерли. Сәет гомере буе Зәйтүнгөлен эзли, айга карап, сөйгәненә эндәшә. Асылда, автор акыллы, эшлекле, диниятле, хыянәтсез татар егетенең үз асылын җуймыйча, озын-озак юллар үтеп, бәхеткә ирешү тарихын бәян итә. Мәрьям белән күз тегеп көткән кызлары, яшьли үлгән әнисенең дәвамы Хәятнең алдан үзенең бертуганына (Хәниянең улы Искәндәргә) гашыйк булып, аннары рус егете Константинга барып, динен алыштыруын – Анастасиягә әверелүен күтәрә алмыйча, хаста булган Сәет иманыннан ваз кичми, баласыннан баш тарта, ләкин Хәятнең улы Яковны Якуб дип тәрбияләргә карар кыла. Хәниянең улында үзенең яшьлеген танып үкенсә дә, улы барлыгы, аның зыялы ата белән үсүе аны тынычландыргандай итә.

Экзистенциальлек Зәйтүнә тарихында тагын да көчәйтелә. Сәеттән аермалы буларак, кыз авырлыклар алдында югалып кала. Әтисе шахтёр Әхмәт үлгәннән соң, әнисе акылыннан яза, Ялантауда руска мәңге бармаячакмын, дип вәгъдә биргән Зәйтүнә гаҗизлектән үзен яратып йөргән Василийга, ярдәм итәр дип ышанып, кияүгә чыга. Васыйл-Василий, әнисе белән бергәләп, Зәйтүнәнең газиз балаларын чиркәүдә чукындыралар, фатирда тәре элеп куялар, әмма хатын көчсез, дәгъва белдерсә дә, язмышына риза була. Әнисен, ирен, улын югалтканнан соң озак еллар үткәч, Алансу зиратында Сәет белән очрашып, Ялантауга менәр алдыннан Зәйтүнә: «Соңрак очраштык, соңга калдык», – ди. Автор намазны Сәеттән дә, Зәйтүнәдән дә укыттыра, алар күңеленә илаһи көч турында фикер сала. Димәк, автор кешене иманга башкаларга карата ачу хисен җуйганнан соң, авыр хәлләрдән үз көченә, сабырлыгына таянып чыгарга өйрәнгәннән соң китерә. Кеше үзендәге илаһилыкны тормыш сынауларын дөрес үтсә генә таба, ди язучы. Әгәр сынаулар аша үтеп, үзенә тиешле тәрбия кыла алмаса, кеше илаһилыкка килә алмый, сына, юкка чыга.

Шул рәвешле, лирик-экзистенциаль пафослы Зәйтүнә-Сәет сызыгында автор позициясе ачык билгеләнә. Кешене бу дөньяда иманга, хәтергә, үз асылыңа тугрылык кына бәхетле итә, ди Р.Шәйдуллина-Мурат. Ялантау – кешеләрнең җирдәге алтын айлы мәчете. Бабасы коткарып калган изге ай, иманнарына кайткан авылдашлар, ефәк шәл уранган Зәйтүнә – Сәетне бәхетле иткән чынбарлык шушы. Димәк, Р.Шәйдуллина-Мурат повестенда, Ә.Еникидәгечә, якты сагыш белән өретелгән экзистенциаль башлам – өметсезлек өметләр кайту белән алышына.

Совет һәм постсовет җәмгыятенә бәя ярдәмче сюжет сызыкларында бәян ителә. Сәетнең әтисе Инсаф язмышы – мәчет манарасын кискән атасы Шәрәфинең юлын дәвам итеп, колхоз рәисе булып, авылдашларын рәнҗетеп, хатынын үлем түшәгенә яткырган, үз улыннан баш тарткан имансыз, денсез, вәхши кешенең иманга кайту – улын үлемнән коткарып, кылган гөнаһлары өчен тәүбә итеп, картлык көнендә бәхеткә ирешкән татар ире тарихы ул. Инсаф язмышы аша үз асылыңа кайту шулай ук иманга кайту белән янәшә куела. Иң авыр вакытларда да иманын сатмаган изге күңелле Габделхәйләргә, аксакал архетибына якын торган Зариф картларга каршы бирелгән

Инсаф гомеренең икенче яртысында туры юлга баса, төзәлә. Әдибә таяныч ноктасы кешенең үзендә, үз әхлагы белән билгеләнгән булырга тиеш, ди.

Повестьның уңышы фәлсәфи мотивларның алга куелуына дә бәйле. Әсәр Хәятнең үлеме һәм аннан соң яшәү, Каракай әби, Фатыйма-Инсаф, Мәйсәрә тормышы һәм үлеме арасында, экзистенциаль чикләрдә тирбәлә. Чор, дәвер проблемаларын гомумкешелек проблемалары белән тоташтыру омтылышы ясала. «Яшәү мәгънәсе – иманлы-хыянәтсез булуда, гафу итә белүдә» дип кабатлый автор. Кичерешләрнең тирәнлеген, хисләрнең үткенлеген күз яшьләре мотивы белдерә. Шәрәфи үзе үләр алдыннан ясин чыгарга кайчандыр үзе төрмәгә озаттыра язган иманга тугрылыклы җиде бала атасы Габделхәйне чакыра. Ул вакытта авыл кешеләренә коткарып калганнары өчен күз яшьләрен яшерә-яшерә рәхмәт укыган Габделхәй, еллар үткәч, үз кулында үлгән Шәрәфинең күзендәге бер бөртек яшен күрә. Әсәрнең буеннан-буена моң, бәхиллек мотивы экзистенциаль катламны көчәйтеп калкытыла. Автор язмышны кылган гамәлләрнең нәтиҗәсе кебек аңлата, асылда һәркемнең үз тормышы өчен җаваплы булырга тиешлеге турындагы хакыйкатьне алга чыгара. Болар – әдибәнең матур табышы, уңышы да.

Әсәрдә милли яшәеш тәртипләре, моделе тәкъдим ителә. Ә.Еники, М.Юнысларны дәвам итеп, автор Мәйсәрә, Фатыйма, Хәят, укытучы Нурания кебек татар хатын-кызларын олылый, алардагы Акъәбиләр миһербанлылыгын, тән һәм җан пакьлеген, гадел, сабыр, рәхмәтле була белүне, ирне олылау, балага хөрмәт кебек сыйфатларны калкытып куя.

Алда әйтелгәннәргә өстәп, әсәрдә әдәби алымнардан күптавышлылык, психологизмга мөрәҗәгать итү, лирик чигенешләр, кайма, тормыш мәгънәсен эзләүче герой тәкъдим итү бәянне хәзерге татар прозасында лирик-эмоциональ канатның иң күркәм үрнәкләренең берсе, метафизик прозага якын торган әсәр итеп танырга мөмкинлек бирә.

Һәр ике повестьның сентименталь пафосы үзәк герой бирелеше белән бәйле. Әдибәнең «Үксезләр» повесте – хәзерге татар прозасындагы метафизик канатка мөнәсәбәтле иң гүзәл әсәрләрдән. Д.Заһидуллина карашынча, Ә.Еники, Ә.Баяннардан башланган күренеш – аң төпкелендә барган процессларга игътибар юнәлтү хәзерге татар прозасында киң таралган. Ятим баланың эчке халәтен тасвирлаганда, Р.Шәйдуллина-Мурат күренешләрнең асылына төшеп җитәргә омтыла. Хис һәм фикерләр туу, үзгәрү процессы сиземләнә торган күңел хәрәкәтләре аша бирелә.

«Үксезләр» повестенда төп героиня ятим калган кыз Айзадәнең газаплы кичерешләре бәян ителә. Кызның төшләре, саташулары – бу кырыс чынбарлыкта җылы, якты караш эзләүче кешенең сызланулары лирик-экзистенциаль сюжет сызыгын тетрәндергеч, тәэсирле итә. Әнисен төшләрендә көтеп сызланучы җиде яшьлек Айзадәнең үги әнисе кырыслыгына түзә алмыйча әрнүләре, эт көчеге Аппакны үз итүе тарихы аллегория булып тора. Метафизик прозаның төп героинясына хас булганча, Айзадә үзен-үзе белештермәс хәлендә эзләнә. Чынлыкта, кырыс хатыны ташлап киткән Таһир да, хатыны үлгәч, алданып өйләнгән Мансур да, баласыз гомер сөрүче Хәят тә – эчтән сызланып, ялгыз газап кичереп яшәүчеләр. Алар һәммәсе җылы сүз, игътибар эзли. Автор ялгыз, чарасыз кешене ятим бала белән чагыштыра, матди кыйммәтләрне өстен иткән җәмгыятьтә һәркем үзен шулай тоя, дип сызлана; саташулар-төшләр, аң агышы ярдәмендә экзистенциаль мотивны тагын да көчәйтә. Асия, Хәят, Галихан, Сәйдә кебек үзара ярдәмләшеп яши белү генә тормышны мәгънәле итә, ди автор.

Эстетик яктан камил, тәэсирле, романтик пафос белән сугарылган, шартлы сурәтне иркен кулланучы әлеге повестьлар татар әдәбиятына яңа сулыш өргән каләм остасы килгәнлекне хәбәр итәләр.

Равилә Шәйдуллина-Муратның соңгы елларда дөнья күргән үз нәселе тарихын

гәүдәләндергән «Карт шомырт хатирәсе» (2021) һәм «Тау башында бүре бар» (2023) романнары әдибәнең иҗатына мөкиббән аудиторияне бермә-бер арттырды. Хикмәт язучының үз нәселе тарихын яки шәхси тормыш юлын тасвирлавында гына түгел. Беренчедән, автобиографик нигезле әсәрләр татар әдәбиятында күп, бу романнар – шуларның дәвамы. Ләкин, аермалы буларак, «Карт шомырт хатирәсе» – сага жанрындагы тәүге татар романы. Икенчедән, Р.Шәйдуллина-Муратның әлеге романнарының төп темасы – югалган җылыны эзләп тилмергән буынның шәхси фаҗигане, эчтән тырнап торган әрнү-сызлануларны үтеп, кеше булып калып, мөмкин булмаган шартларда үз көче белән яңа үрләр яулап, мул тормышлы, укымышлы нәсел данын кайтаруы. Әдибә иманлы, укымышлы, нык тормышлы татар нәселе темасын күтәрүе белән һәр татарның аң төпкелендәге затлылыкка, зыялылыкка, булдыклылыкка омтылышын өскә калкыта. XX йөзнең утызынчы елларыннан башлап, ике гасыр чигенә кадәрге вазгыятьне тасвирлаган соңгы егерме-утыз елда дөнья күргән күпсанлы романнар арасында Р.Шәйдуллина-Мурат үз нәселе, шәхси тарихы мисалында башка сыймаслык фаҗигаләр үтеп тә, уңышлы һәм бәрәкәтле тормыш кору максатын куйган очракта, армый-талмый, алны-ялны белми хезмәт куеп, гыйлем алып, һәрдаим иман һәм игелек юлында гамәлләр кылып, шанлы нәсел куәтен кайтарып була һәм кирәк, дигән мотивны алга куюы белән укучының игътибарын җәлеп итә. Сүз дә юк, бу романнар – әдибәнең лирик-экзистенциаль иҗатының бәрәкәтле дәвамы. Укучы бу әсәрләрне фаҗига үткәндә сынмаган гади кешеләр – көчле шәхесләр, куәтле нәсел турындагы трагик башлангычлы, романтик һәм экзистенциаль катламлы романнар буларак үз итә. Һәр ике әсәрдә татарның үзаңын билгеләгән гыйлемле, иманлы, мул һәм бәрәкәтле булу омтылышы, аеруча буыннарга үзеңнән соң җылы калдыру теләге укучының йөрәген кузгатырлык төп мотивлар буларак аерып куела. Әдибә кешенең фани дөньяга кыска аралыкка килеп китүен иманга, хәтергә, үз асылыңа тугрылык – мәгънәле, фаҗигале чынлыкны үтә белү, сынмау, горур-тыйнак һәм омтылышлы-тырыш булу тормышны бәрәкәтле, дәвамлы итә дигән фикерләрне калкытып, татар кешесенең йөрәгенә үтеп керә, аны гамәл кылырга, максат куеп, нәселне көчәйтү, ишәйтү хакына хезмәт итәргә өнди. Үзендә шул омтылышларны сизеп тә, чынга ашыру юлын һәм мадәтен эзләүче укучы бу романнарны көтеп ала, йотлыгып укый.

Хәзерге татар прозасының лирик-экзистенциаль канатын әнә шундый гаҗәеп тирән кичерешле, яшәеш мәгънәсе турында уйланып, әрнеп-сызланып язган повесть-романнары белән баеткан Р.Шәйдулина-Мурат иҗаты татар укучысын энҗе-сәйләндәй шигърияте белән дә сөендерә.

«Сихәтләнү» (Казан, 2016) дип исемләнгән җыентыкта урын алган шигырьләр белән танышып чykканнан соң, чынлап та, рухи чистарыну, сихәтләнү сизәсең. Әдибәнең шигырьләре дә, аларның Сүрәя Гайнуллина тарафыннан русчага тәрҗемәсе дә гаҗәеп тирән, лирик, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә.

«Яшьлекне эзләү» шигырендә лирик героиня – парлы яшьләргә сокланып та, моңаеп та карап калучы өлкән ханым болай ди:

*«Бәхетлеләр уза янәшәмнән*
*Ел фасылы тими парлыга...*
*«Бу бит безнең сукмак!» – диеп,*
*Эчтән генә дәшәм аларга».*

«Мәхәббәтен саклап басып торучы ханым» «ялгызлыкның тәүге төненә кереп барганга» әрни, сызлана кебек, ләкин, ни гаҗәп, аның сагышы якты, илаһи бер моң, кайтаваз:

*«Әле әлегә... Җанда кайтавазмы,*
*Китеп барган кошлар өнеме?!*
*Алар – көнгә, ә мин төнгә керәм –*
*Ялгызлыкның тәүге төненә...»*

Ялгызлыкның тәүге төнендә никадәр әрнү бар, сагыш, газап бар, әмма лирик героиня зарланмый лабаса, бары кабул итә, эчке моң һәм илаһи бер сабырлык белән риза була, сабырлык исә җылылык уятырга сәләтле:

*«Куеныма алдым, җылытырмын:*
*Ялгыз күшекмәсен хыялым.*
*Кара төнне икәү кичәрбез без*
*Төн артында көтә уяну».*

«Гомер көзе» шигырендә «югалган җылыны эзләп» тилмергән лирик героиняның өметләре сүнгән, сүрелгән. Автор көз, салкын образларын кабатлап, аларны яңгыр, чәчәкләр, кырпак кар, ак томан образлары белән янәшә куя. Яңгырлы көз кышка әзерләнә («кыш өчен җылытыйм җанымны»). Өметләр өзелгән мәлдә дә кеше башкаларга җылы өләшүдән туктамаска тиеш, туктамый булдыра ала бит, ди кебек автор. Чәчәкләргә иелеп чәчәк җанына лирик героиня шулай дәшә. Һәркем башка берәүнең зарын үзенекедәй итеп кабул итә, тоя ала, кешедә җылылык җитәрлек ләбаса:

*Көз. Салкын. Ак томан.*
*Кышларга кергәндә, кемдә дә*
*Куерган сагышлар бар сыман.*

Димәк, кеше юатуны көзләрдән түгел, үзеннән, башкаларга өләшер җылыдан эзләсә иде, ди әдибә.

«Югалган өмет» шигырендә авторның табышы – ялгыз каз сагышы. Ә.Еникидән килгән ялгыз каз мотивы гаҗәеп тирәнлек белән, табигый моң, әрнү катыш чарасызлык белән өретелә:

*«Кыз-киленнәр бүген каз йолкыйлар,*
*Җырларына җырлар ялгана...*
*Җан авазы белән иңри ялгыз*
*Өметләре кисек каз гына».*

Бер караганда, каз өмәсе – гаҗәеп муллык бәйрәме дә соң, икенче яктан, ялгыз каз балаларын җуйган ананы хәтерләтә, мондый борылыш тетрәндерә, тормышка карашны үзгәртеп, саграк булырга чакыра кебек:

*«Каз каурые ятты сукмакларга,*
*Каурыйларда ап-ак теләкләр.*
*«Балалардан мәхрүм итмә!» – диеп,*
*Тибә бүген безнең йөрәкләр...»*

Әдибәнең лирикасында затлылык, сүз-сурәт белән сак эш итү ярылып ята.

«Әниемә чемле җиләк» шигыре күздән яшьләрне китереп, моңсу уйга сала, җанны әрнетә торган тагын бер гаҗәеп шигъри сүз:

*«Һавалардан баллар тамган чак бу,*
*Пәрәвезләр чыңлый тынлыкта.*
*Чемләп җиләк җыйдым, әни, сиңа –*
*Ышанасым килми син юкка».*

Кеше күңелен гомер буе тырнап килә торган хәсрәтләрнең иң олысы – әнине югалту хәсрәте. Р.Шәйдуллина-Мурат әни һәм җиләк образларын янәшә куеп, ананың җан җылысы, тиңсез яратуы матурлыгын илаһилаштыра:

*Печән җыеп кайткач, кулларыңда*
*Булыр иде һәрчак чемле җиләк:*
*«Сиңа җыйдым кызылларын сайлап,*
*Балланыплар пешкән, кызым, бигрәк.*
*Болыннардан сиңа бүләк!» – диеп*
*Салыр идең нәни учыма».*

Образларның сайланышында никадәр зәвык, затлылык:

*«Тасма-тасма хәтер сукмаклары*
*Җиләкле болынга ашкына.*
*Җиләкләрем чем-чем сиңа дигән*
*Туган йортка таба кайтып киләм».*

Җәйләр исе сеңгән мөлдерәмә җиләк, алсуланган таң – әниле чакның бәхете, сүз белән аңлатып бетерә алмаслык рәхәте сурәте:

*«Кышкылыкта чемле җиләкләрне*
*Синең кебек киптерергә эләм»...*

Р.Шәйдуллина-Муратның шагыйрә буларак үзенчәлеге – фәлсәфилеккә омтылу. Анага булган хис сүнми дә, сүрелми дә, Җир-әнкәбез бездән әнә шул хис кайнарлыгын көтә, ди автор:

*«Нигезеңне ташлама...» – дип,*
*Пышылдады Җир-әнкә.*

«Кем урлаган» шигырендә автор гомер агышы турында якты бер моңсулык белән яза:

*«Бер энәсен тартып алдым*
*Ай нурының.*
*Бер сапламын өзеп алдым*
*Тожымнарның».*

«Сөйгәненә чиккән кулъяулыгы югалган, толымнардан чәчүргече төшеп калган» лирик героиня узган гомерне «кар суларына» тиңли:

*«Бу гомерләр кар сулары*
*Булган икән,*
*Аккан эзен яңа язлар*
*Җуйган икән».*

Күңел лирикасының фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылышы гомер соңы турындагы «Китеп кенә торам» шигырендә иң көчле яңгыраш ала. Автор татар кешесенең эчке тирән сызлануын, хәсрәтле уйларын йота белүен, Ә.Еникиләрдәгечә нечкә һәм затлы итеп бирә.

Лирик героиня үлем турында уйлана:

*«Гомер үтә, кеше үлә, имеш...*
*Ә мин никтер бер дә үлмәм кебек.*
*Посып калырмын күк оныкларның*
*Күңеленә, җаннарына кереп».*

Яшәү матурлыгы ак томаннар, гөлләр тамыры, һәр көнгә зекер әйтә белү, дип кабатлаган лирик героиня кешенең үлеменең асылын әйтеп бирә.

Димәк, кешенең бу дөньяда яшәве үзеннән соң җылы калдыру өчен кирәк. Үзеннән гөлләр, хәер-дога калдырган кеше үлми, «мин әлегә китеп кенә торам», – ди.

«Сихәтләнү» исемле җыентыкка тупланган шигырьләр арасында «Бичураның бәби туе» шигыре игътибарны аеруча җәлеп итә. Туксан яшьлек әби, Ә.Еникичә әйтсәк, «үлемгә күптән кул селтәгән» карчык (әдибә образны үз әнисеннән алып яза) соңгы чәен эчәр өчен нигезгә юл тота. Иң соңгы ахирәтен озатып кайткан көнне әбинең уйлары үлем турында:

*«Яшьтәшләрдән калды инде*
*Бүген менә үзе генә...*
*Ишек шакый гомеренең*
*Туксанынчы көзе менә.*
*«Оныттыңмы әллә, әҗәл?*
*Әллә үлем булдымы җәл?*
*Җир йөзендә яшәсен дип,*

*Калдырдыңмы әллә мине*
*Тере тарих итеп?!»*

Әби үлем киләсен көтә, аның бу гасабилы, аңлашылмый торган чынбарлыктан, әхлаксызлыктан ничек тә котыласы килә кебек, сызланулары шул хакта:

*«Китәр вакыт җитсен тизрәк:*
*Җаным елый, сызлап тибә йөрәк».*
*Җиргә килде әллә нинди*
*Яңа буын,*
*Ямьсез буын,*
*Гамьсез буын.*
*Аңлап булмый теләкләрен,*
*Ниятләрен, телен, уен.*

Ана Акъәбиләр өнен – васыятьнең әйтелә алмаячагын инде таныган, чарасыз сызланучы кебек тәкъдим ителә:

*«Акча, байлык өчен җанын сатып,*
*Ясый алар һәр төн саен*
*Бичураның бәби туен».*

Бичура образын кертеп җибәреп, әдибә татар әдәбиятында киң таралган мифлаштыру күренешенә мөрәҗәгать итә. Шул рәвешле, әдибә фикерләрен әни ул – туган йорт – туган нигез аңланылышына бора:

*«Туган нигез ясин көтә...*
*Булмый кереп.*
*Явыз эте, сары эте,*
*Бикләп куйган бүре кебек,*
*Туган димәс, чәйнәп өзәр,*
*Килмә якын.*
*Болар күптән оныткannар*
*Туган хакын,*
*Алла хакын...»*

Әдибәне иң борчыганы – борынгыдан килгән яшәеш әдәбе югалу, намус, кешелеклелек кебек сыйфатларның җуелуы. Карт шомырт образы шул мәгънәне – буыннарны тоташтырып торучы әхлак, әдәп кануннары, яшәеш тәртибен аңлатып символлаштырыла:

*«Капка-койма затлы үзе,*
*Ләкин биек.*
*Кермәк булып, җилләр улый,*
*Җилләр чаба,*
*Һәм карт шомырт бертуктаусыз,*
*Башын иеп, тәрәз кага.*
*– Кем бар анда?»*

Ләкин төп нигезгә бичура – кара көч ияләшкән, җен ияләшкән җирдә якты теләк белән килгән карчыкка урын юк:

*– Әй, бичура!*
*– Тәрәзәң ач.*
*«Төп нигезгә туксан яшьлек*
*Кызың килгән.*
*Соңгы тапкыр*
*Ясин чыгу ниятеннән.*
*Ишегеңнән керә алмый,*
*Этең усал».*

Явызлык – кеше күңелендә, усал эт – татарның үз асылын җуйган бүгенге рәвеше дә, рәвешсезлеге дә.

Нәтиҗәдә Акъәбиләр дәвамчысы – Ана –

*«Туксан яшькә җиткән карчык*
*Аксый-туксый*
*Мәңгелеккә китеп бара».*

Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыяте»ндәге төп мотив шигъри юлларда болай кабатлана:

*«Мизгел саен ерагая*
*Сезнең ара.*
*Ә кара шомырт,*
*Өметләнеп, әле һаман*
*Тәрәз кага.*
*Ишетмиләр...*
*Төп нигездә бичураның*
*Оныгының туе бара».*

Димәк, буыннар арасындагы бәйләнеш җуела бара, әдәп югала, алай гынамы соң, «төп нигезгә бичура төпләнеп оя корган».


Әдибәнең лирик-экзистенциаль иҗатының колачына күз салганнан соң, аның балалар турында олылар өчен, балаларның үзләре өчен язылган шигырьләрен укып таң каласың. Күптән түгел генә басылып чыккан «Елан кызы Акбану» китабы да – әдибәнең нәниләргә бүләге. Аларда якты балачак идиллиясе – бәхетнең үзе ташып тора. Шагыйрәнең иренә, балаларына, оныкларына багышлап язылган шигъри тезмәләрен өйрәнеп, бәяләп укучыга тәкъдим итү әле – киләчәк эше.

Сүзне әдибәнең «Ялантауга ай кунган» повестеннан өзек белән тәмамлыйсы килә: «Килдегезме, мин сезнең киләсегезне белдем. Язлар килгән саен, кар сулары гөрләвекләр булып агып китеп, болыннар шау чәчәккә күмелеп, табигать уянуга, һәр ел саен көттем мин сезне. Бераз үзгәргәнсез. Ә мин һаман яшь, җырлый-җырлый агам да агам. Сезгә кадәр дә, сездән соң да миңа бик күпләр серләрен сөйләделәр, минем янымда мәхәббәтләрен аңлаттылар. Ә мин аларның серләрен беркемгә дә сөйләмәдем, чөнки мин сер саклый беләм». Бу сүзләр әдибәнең укучысына әйтер сере дә, буыннарны тоташтыру турындагы җан әрнүе дә, ышанычы-өмете кебек тә яңгырый.

Шул рәвешле, татар шигъриятенә һәм прозасына татарча тыйнак, сабыр-салмак, ләкин ышанычлы адымнар белән атлап кереп, үз сукмагын тапкан әдибә татар укучысына милли хисләрне үтә дә нечкә, сак кына уятырлык әсәрләр бүләк итеп килә. Татар әдәбиятының Ә.Еникиләрдән килгән затлылык белән өретелгән бите әнә шулай бүген дә дәвам итә.

**Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,**
*КФУ доценты.*

# ТОРМЫШТАН ЯМЬ ТАБЫП ЯШӘДЕ



Узган елның август ахырлары иде. Кызып кына эшләп утырган мәлемдә телефоным шалтырады. Экранда «Рашат Низамиев» дигән язу чыкты.

– Тыңлыйм, Рашат абый, – мин әйтәм.

– Исәнме, Рафис! Матур гына романың чыгып бара. Минем дә «Сәйдәшнең соңгы елы» дигән кыйссам бар бит. Сиңа китабын язып биргән идем бугай, – ди.

Минем «Казан утлары»нда Салих Сәйдәшев турында «Артык кешеләр» дигән роман-эссем чыгып бара иде. Шул уңайдан шалтыратуы икән Рашат абыйның.

– Әйе, – мин әйтәм, – ул китабың мин роман язганда өстәл өстемдә булды.

– Әйдә, романың басылып беткәч, Өбрәгә кайтып, халык белән очрашып киләбез.

– Бик әйбәт булыр. Сентябрь саны чыксын да, Сәйдәш музеена алып кайтырга бер бүләгебез булыр, – дидем.

– Мин әле бакчада ятам. Сентябрь башларында шалтыратырсың. Аннары шул: мин беркөнне редакциягездә шигырьләр калдырып киттем. Шуларның басылып чыкканын да күрәсе иде, – диде Рашат абый.

Сентябрьнең бересе көне иде. Язучылар берлегеннән шалтыраталар: «Рашат Низамиев вафат».

Аяк астым убылып киткәндәй булды.

Рашат абый белән 1972 елдан бирле аралашып, дуслар булып яшәдек. Шул елны ул Казан дәүләт университетын тәмамлап, мин укыган Биектау районының Олы Битаман урта мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшкә килде. Ике ел үзе оештырып җибәргән әдәби түгәрәккә йөргән күпме бала күңеленә игелек орлыклары салып, туган телгә, әдәбиятка, китапка мәхәббәт тәрбияләп калдырды ул. 1974 елда без аның белән икебез бергә Казанга чыгып киттек. Мин – Казан дәүләт университетына, ул авиация заводының күптиражлы «Алга» гәзитәсе редакциясенә барып керде. Аннан соң «Татарстан яшьләре», «Ялкын», «Идел», «Казан утлары» редакцияләрендә әдәбиятка хезмәт итте.

Әйе, бөтен гомере буе игелекле хезмәттә булды: иҗат белән шөгыльләнде, шигырьләр, хикәяләр, повестьлар язды. Шул эшеннән ямь һәм тәм табып яшәде.

Журналыбызның бу санында без аның шул вакытта калдырып киткән соңгы шигырьләрен укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык. Алар әдәбият сөючеләр күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз.

**Рафис КОРБАН**

Рашат
Низами

# ЫШАНАСЫ КИЛӘ...

## Ватан тойгысы

Мин фәлсәфә ташын эзләп киләм.
Ул тирәндә ята, тирәндә.
Ак уйларым ташый күбекләнеп,
Очар кошлар сайрый тирәмдә.

Челтер-челтер ага чишмә суы,
Пышын-пышын үлән чайкала.
Сәлам биреп байый кызыл кояш,
Кичен күктә сердәш ай кала.

Җирдә булган барлык матурлыкка
Томырылып, сөеп күз атам.
Төннең кочагына чалкан ятып,
Йолдыз агышларын күзәтәм.

Татлы һава – тормыш нигезедер,
Туган телем – чиксез хәзинә.
Канатлансам, Тукай катламына
Җитми кала күңелем әз генә.

Тәнемдәге күзәнәкләр саен
Кайный җанда Ватан тойгысы.
Мин сүзләрдән асыл мәрҗән үрәм,
Бу шигырем – булмас соңгысы!
Мин фәлсәфә ташын эзләп киләм...

## Пушкин Казанда

*Әйтерләр: Пушкин бар, Пушкин бар...*
Сибгат Хәким

И-и, хәзрәти Пушкин! Нигә әле
Казаннарның юлын сайладың?
Чөнки Казан бер дә яратмаган
Уй-фикернең түбән, сай чагын.

Әби патша мәгәр белде микән
Шагыйрь ничек атта җилдергән...
Каретаның тәгәрмәчләренә,
Уралышып,
Кыпчак даласында җил йөргән.

Патшалардан, канлы державадан
Синең җаның, рухың өстәрәк, –
Каурый каләм, ак кәгазең белән
Хакыйкатьне бардың өстерәп.

Иң катлаулы, кискен чорларда да
Декабристлар яклы булдың син.
«Аксөякләр» дигән исемлекне
Халыкчанлык якка бордың син.

Халык нәрсә? Сәнәк тотса гына,
Хакыйкатькә таба юл ачык.
Шуңа да бит тарих эргәсендә
Калкып чыккан фетнә Пугачёв.

Пугачёвның эзе чакыргандыр,
Ил картларын эзләп килгәнсең.
Казанның син шагыйрьләр каласы
Икәнлеген, шиксез, белгәнсең.

Ашыгып кына килгән сентябрьнең
Гәрәбәгә баткан чаклары.
Ярты Рәсәйне чорнап алган
Пугачёвның яугир сафлары.

Татар полковниклары да – шунда,
«Бунтовщик»ны алар яклаган.
Алар, алар, бердәм сафка басып,
Азатлыкка таба атлаган.

Күз яшьләре һәм алсу кан белән
Сугарылган илнең яртысы.
Рәсәй киңлегендә дуэль барган:
Яхшы белән яман тартышы.

Печән базарына таба карый
Фукс яшәгән йортның тәрәзе.
(Пушкин кебек, шушы йортка килеп,
Иман яңартырга кем әзер?)

Акыл тәпәнендә ми урынына
Коры кибәк булса, мондыйлар –
Хакимият вә хаким каршысында,
Күмәкләшеп, койрык болгыйлар.

Хатынына хатлар яза Пушкин:
«Юкка йөрмәдем мин Казанда, –
Пугачёвның кайнар эзләреннән
Азык таптым үземә, язарга...»*

## Әй, табигать

Табигатьнең хали хаталарын
төзәтергә
Сәләтлеме Адәм баласы?
Кая бакма – җирдә сызылып ята
Мәгыйшәтнең утлы ярасы...

Тетри диңгез! Гарасатлар куба,
Ил кадәрле илне су баса.
Зыр әйләнә язмыш тегермәне,
Әйтерсең лә дөнья – куласа.

Уяна да вулкан-динозавр,
Ташлар чөеп «уйный» янартау.
Кайнар лава юган болыннарны
Мөмкин түгел инде яңарту.

Җир тетрәсә, кыелып кына төшә
Аягүрә баскан шәһәрләр.
Тимер-бетон плитә асларында
Өзелеп кала күпме бәгырьләр!

Яшәү дәвам итә. Киләчәккә
Барасы да безгә, барасы...
Табигатьне көйләп төзәтергә
Сәләтлеме Адәм баласы?

## 24 сәгать

*(уены-чыны бергә)*

Тәүлектә бар – егерме дүрт сәгать...
Вакытны без ничек «туздырабыз»?
Гырлап яки төсле төшләр күреп,
Өчтән берен йоклап уздырабыз.

Итекче дә, министр да йоклый,
Кем яратмас икән йокыларны!
(Депутатлар хәтта утырышта
Йоклап-йоклап ала кайчакларны).

Җәмгыять бит шулай калыплашкан –
Җан тырмаша, хезмәт куя кеше:
Ярты юлда төртелә дә кала,
Яки гөрләп кенә бара эше.

Берәүләре әнә корыч коя,
Хан сарае сала икенчеләр.
Урак өсте! Төнгә кадәр эшли,
Кырдан кайтып керми игенчеләр.

Хөрәсән һәм ялкау бәндәләргә
Кагылмыйдыр вакыт тойгылары, –
Киек казлар кебек тезелешеп
Көн арты көн узып китсен бары!..

Егерме дүрт сәгать кочагында
Адәм баласына ял да кирәк.
Вакыт – алтын! Моны дөрес итеп
Файдалана белүчеләр сирәк:

«Эврика!»га таба юллар яра,
«Энҗе» эзли уйлап табучылар.
Төн утырып ак кәгазьгә бата
Шагыйрьләр һәм әһле язучылар.

Егерме дүрт сәгать вакыт җитми
Дәрманлы һәм гамьле замандашка.
Максудыңа барып җитәр өчен
Эзне, сүзне кирәк югалтмаска!

Вакыт җитми, дуслар, вакыт җитми,
Күпме гамәл алда көтеп тора!
Дөньялыкта гаять ир-егетләр,
Атлант кебек, Җирне тотып тора.

Тәүлегенә егерме дүрт сәгать,
Үзгәртергә кирәк вазгыятьне, –
Гамәлебез күбрәк булсын өчен,
Егерме биш сәгать озынлыкка
Куып кертү кирәк җәмгыятьне!

Ут-Кояш тирәли әйләнә Җир,
Төяп безне еллар кочагына.
Озайта белсәк тәүлек сәгатьләрен –
Фида җаннар өчен файда гына...

---

* Пушкин, Казанны гизеп кайтканнан соң, «История Пугачёва» дигән хезмәтен яза.

## Ышанасы килә!..

*Тукайга ияреп*

Ышанасы килә: Шәймиевнең
Аякөсте һаман каласын, –
Ул бит инде алгарышка этте
Татарларны, татар каласын.

Ышанасы килә: Кремльнең
Һаман көтәм, көтәм ясканып, –
Милләтләрнең хокукларын танып,
Федератив юлга басканын.

Ышанасы килә: чиновниклар
Яңачарак мәлдә калкына, –
Күп-күп кенә мәнфәгатьне алар
Кайтарачак үзенең халкына.

Ышанасы килә: бу болганчык
Һәм вируслы фани дөньяда, –
Шундый сәгать сугар!
Үзгәрербез,
Тормышыбыз булыр өр-яңа...
Юкса, без бит тумаганбыз юкка!..

Ышанасы килә: шовинистлар
Акылга һәм аңга килерләр, –
Үзләрендә тыныч яшәп яткан,
Мәскәү казнасына акча керткән
Милләтләрнең кадерен белерләр.

Ышанасы килә: НАТОның да
Аек бер фикергә килүен, –
Безнең бик тә күрәсебез булсын
Коралдану дәрте кимүен.

Ышанасы килә: сугышларсыз
Яшәр әле, яшәр кешелек, –
Әнә шундый өмет-ышанычлар
Өстебезгә килә ишелеп.

Бер тамчы да артка чигенмәмен,
Ышанасы килә яхшылыкка, –
Җир шарына һәм бу дөньялыкка
Таҗ кидертү өчен туганбыз ла,

## Премияләр турында

Яшьләр кыю, яшьләр үткен хәзер,
Шигырь канатында җиләләр.
Тукай, Җәлил премияләренә
Олы кашык тотып киләләр.

## Тәүфикъ Әйдигә

Ватанына дошман күсәк орса,
Батырларын биргән һәр заман.
Милләт өчен җанын фида кылды
Тәүфикъ Әйди дигән әйдаман.

## Ркаил Зәйдуллага

Депутат һәм рәис мөнбәренә
Саллы гәүдәң белән үрлисең.
Туган телем һәм татарым, диеп
Янар учак кебек дөрлисең!

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ РАУШАН КӨЗГЕСЕ

Тукай – безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән зур бүләк, раушан көзгебез. Ул калдырган рухи мирас ниндидер вакыт кысаларына гына сыймый. Аның үлчәме – мәңгелек.

Аңа милли хис белән сугарылган искиткеч зур талант иңдерелгән. Һәм ул үзенең кыска гына гомерен чәчми-түкми милләтенә хезмәт итүгә багышлаган. Гомеренең беренче көненнән башлап, соңгысына кадәр халык белән яшәгән, аның авыр язмышын үз язмышы рәвешендә кичергән.

Шагыйрнең һәрбер әсәре милли хис һәм рух белән сугарылган. Җанына һәм тәненә, милләтебез язмышы, тарихы сеңгән. Аның әсәрләрен укыганда, үзеңне тарихыбыз эченә чумгандай хис итәсең, аның белән бергә милләтебез язмышын тасвирлыйсың сыман.

Моның шулай икәнлеге аның «Милли моңнар»ында бигрәк тә ачык чагыла. Берәү, бу берәү дигәне – «Болгар» номерларындагы күршесе, аның дусты шагыйрь Сәгыйт Рәмиев җырлый, ә шагыйрьнең күз алдына чал тарих килеп баса.

Җыр аның күңелендә бөек чорыбызның һәм коллык упкынына төшкән мескен булып торган өч йөз ел арасындагы контраст картинаны тудыра. Күз алдына Агыйдел, дөньяга мисали һөнәрчелеге, сууткәргечләре, кәрван юллары белән тоташкан Болгар килеп баса. Дустының җырлавы аңарда үткәнебезне сагыну хисләре тудыра. Әйтерсең лә аның үз күңеленнән дә «сызылып-сызылып», милли хисләр сугарылган әнә шул җыр чыга. Гүя ул җырчыга кушылып җырлый, халкыбыз тарихын күз яшьләре белән диярлек барлый, җырчы белән бергә үзе дә «өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә татар күңелениләр сизгәнен».

Чыннан да, ул татар күңеле ниләр сизгәнен һәрвакыт барлап, үз йөрәге аша уздырып, халкының үткәнен һәм үзе яшәгән бүгенгесен барлый, аңа үз бәясен бирә килгән. Ул чыннан да, үзе әйткәнчә, коеп куйган шагыйрь генә түгел, сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә. Шагыйрьнең бу сыйфатларын күп әсәрләреннән тоемлап була.

Без аның «Шүрәле»сен тик бер авыл егете Былтырның урман җене белән булган мавыктыргыч маҗаралары итеп кенә карарга күнеккән. Ә бит монда шагыйрьнең күпләребез игътибар итмәгән үткән тарихыбызга карашы чагылган. Шагыйрь Чыңгыз гаскәре төшенчәсен урмандагы биниһая, бихисап агачлар белән чагыштыру өчен генә кулланмый. Аның күз алдына кылт итеп, борынгы бабаларның батырлыклары, дәүләтләре килеп баса, тарихның пәрдәсе ачылган кебек була, аңарда уфтану хисләрен уята: «Аһ, – дисең, без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе!».

Ник без болай соң яки зәгыйфь? Без кемнән ким? Кая безнең дәүләтләребез, кайда ул нам? Боларның берсе дә юк, алар «бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады», дип яза ул. (Халык әдәбияты. Т.2, 262.). Әйе, без кемнән ким?

Тукай милләтенең мескен, кол рәвешендә булуына борчыла, аны тизрәк уятасы килә. Бөеклегебезгә кайту хыялы белән яна. «Кайчан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың (язың), Кайчан китәр кичең, килер нәһарың (көндезең). Килерме әллә кабергә мин сөрелгәч, Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?» дип, милләтенең, бигрәк тә яшьләрнең акрын уянуына борчыла. «Бара милләт зәгыйфь абыныр-абынмас, Сүнә яшьләрдә ут кабыныр-кабынмас».

Шагыйрь 1905 ел революциясенә зур өметләр баглый. «Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән». Аның бу сүзләре шул ук вакытта XIX–XX гасыр чикләрендәге татар алгарышына өмет баглавы. Чыннан да, шушы елларда татарларның меңләгән тираж белән чыга торган китаплары, 30дан артык газета-журналлары, берсеннән-

берсе сәләтле язучылары, журналистлары, театр, музыка сәнгате барлыкка килә. Халкыбызның милли горурлыгы уяна, ул бер газета язганча, гүреннән торып, өстеннән кабер туфрагын кагып төшерә һәм горур рәвештә янә тарих мәйданына чыга. Милләт абынудан туктый, яшьләрдә сүнмәс дәрт туа. Татар, Тукай язганча, үлмәгән дә, йокламаган да, тик һушы гына киткән була. Ул 1552 елда башланган, Габделбарый Баттал сүзләре белән әйткәндә, рус җәһәннәменнән, мескенлектән чыга башлый. Аны милли хисләр биләп ала.

Шушы яңарыш дулкынында милләтебезнең тарихи хәтере хәрәкәткә килә, үз тарихы белән кызыксынуы беренче урынга чыга. Иж-Буби шәкертләре әйтүенчә, «бер нәрсәне дә яшермәстән, үткәнебезне һәм бүгенебезне ачыкларга» вакыт җитә. Шушы ачыклау эшен Шиһаб Мәрҗани башлап җибәрә. Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәров, Газиз Гобәйдуллин кебек тарихчылар аны дәвам итәләр. Аларның хезмәтләре халкыбызның милли горурлыгын уята.

Тукай тарихчыларыбызның эшчәнлеген күзәтеп тора. Бигрәк тә Шиһаб Мәрҗанине олылый. Ул да тарихыбызны барлый, ләкин профессионал тарихчылардан аермалы буларак, үткәнебезне халык иҗаты аша төсмерли. Аңа, ди ул, «туплар да атмаган, уклар да кадамаган». Шуның өчен ул аны тутыкмас көзгегә тиңли, халыкның тарихи хәтерен уяту чыганагы итеп күрә.

Шагыйрь тарихыбызны халык иҗатының җәүһәре булган җыр-моң аша да төсмерли. Ул аларга гашыйк. Аларны тыңлаганда, «аркадан каннар йөгерә», ди ул, һәм моңыбызның «алтынын коймаска» өнди. Бала чагында урман буенда ат көткән вакытларында Сәйфетдин вә Гайнетдиннәрнең учак кырыенда «җырлаган җырлары һәм дә моңлы күңелләреннән чыккан хиссият утлары минем йөрәгемә тәэсир итәләр иде», бу «җырлаулар» минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар», дип язган Тукай.

«Мин кечкенәдән җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем». «Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәгемнән миндә туган телебезгә сөю туды. Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!» Күренә ки, монда җыр аша туган телебезгә мәхәббәт ярылып ята. Тукай шушы мәхәббәтне җыр-моң аша яшь буынга сеңдерүне беренче урынга чыгарган. Кешенең балалык чорына махсус игътибар биргән, чын татар булуны баланың дөньяга килүе белән үк башларга кирәклеген аңлап эш иткән. Шагыйрьнең балаларга багышланган шигырьләрендә, әйтерсең лә җыр, моң, туган тел бер җепкә тезелгәннәр.

Тукай иҗатында юкка гына бишек җырларына махсус игътибар бирелмәгән. Җыр, аның көе, теле татар кешесенең гомерлек юлдашы. «Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән, аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән». Ана кеше моң аша баласының Аллаһы Тәгалә биргән туган телен ача. Ә әбисе мавыктыргыч экиятләр белән аны баланың күңелендә ныгыта, анда аны камил рәвештә урнаштыра. Тукайның «Бишек җыруы»нда «Әлли-бәлли көйләрем, хикәяләр сөйләрем, сиңа теләк теләрем, бәхетле бул диярем» дигән сүзләр язылган. Монда ананың моң һәм тел аша, Аллаһы Тәгаләдән бала өчен изге теләкләр теләү нияте.

Тукайның «Ана догасы»нда бу бигрәк тә матур чагылыш таба. Авыл киче, тирә-як тып-тын, халык йокыга талган, хәтта этләр дә өрми. Күктә нурлы ай калкып, тирә-якка нур чәчә. Тик бер өйдә генә ут сүнмәгән. Анда бер ана намазлык өстендә Аллаһыдан баласына теләк тели. «Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән газиз улым!» Күзләреннән тамчы-тамчы яшь тама. «Карагыз, – ди шагыйрь, – шул догамы инде тәңре каршына бармас?»

Ул, гомумән, баланың итагатьле, мәрхәмәтле, эшсөяр булып зур дөньяга чыгуын беренче урынга куя. Баланың үзенә мөрәҗәгать итеп, ул «тынма, эшлә, и сабый! Бел тәңредән эшләргә көн; эшләп аргачтан бирелгәндер тыныч йокыга төн» дип, аны кояштан үрнәк алырга чакыра. Кояшның иртә торып, таң аттырып, көнозын күктә йөзеп, дөньяны яктыртып арганнан соң «иренеп кенә тауга батуын» тасвирлый. «Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһат итсәң һаман, күк арасында кояш күк ялтырарсың бер

заман», – дип, аны якты киләчәккә чакыра. Искиткеч төсмерле, мавыктыргыч рәвештә язылган «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең исеме үк шагыйрьнең бала күңеленә хезмәткә ихтирамын арттыруга багышланган. Балаларга багышланган дистәләгән әсәрләрендә ул аларга милли хисләр сеңдерүне, аңа татарлык оеткысын салуны беренче урынга куйган. Һәм бигрәк тә җыр-моң, халык иҗаты аша.

Ул татар җырларына аларның нечкә кылларына тукынулары өчен генә түгел, телебезнең сакчысы булганлыгы өчен дә гашыйк. «Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк дип, кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була. Аннан башка кайдан табасың?» Әйе, кайдан табасың?

*«Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен».*
(Т.2, 38 б.)

Бу, әлбәттә, яшәештә уен-көлкегә урын булмаска тиеш дигән сүз түгел. Тукай иҗатында аларга да шактый урын бирелгән. Тик менә шагыйрь һәрвакыт диярлек халык күңелләрен кузгата, аның нечкә кылларын тибрәтә торган көйләргә өстенлек бирә килгән. Аларны ул милли рухыбызны ныгыту чыганагы итеп күргән. Тукайга, күрәсең, моңыбызның эченә үтеп керердәй сәләт иңдерелгән, аның сихри көчен аңлардай мөмкинлекләр бирелгән.

Тукай халык иҗатының бертуктаусыз байый торуына да игътибар иткән. Ул үзе ишеткән төрле вариантлардан мисаллар китерә, шуның белән халыкның үзендә җырга нигез салучылар була торганлыгына ишарә ясый.

Шагыйрь үзенең «Халык әдәбияты» рисаләсен юкка гына туган тел шигыре белән тәмамламый. Һәм шулай ук бу шигырь дә юкка гына милли гимныбызга да әверелмәгән.

Тукайның «Җырлар дәфтәре»ндә 28 җыр тупланган. Шикләнмим, әгәр дә ул шушы халык җәүһәрләрен тупламаган булса, аларның күбесе инде онытылган да булыр иде. Нинди генә җырлар юк монда! Аларның барысында да халык язмышы. «Озын эрбет», «Сәгать чылбыры», «Җырчы Фәхри» кебек җырлар үзләре генә дә ни тора! Болар – халык җәүһәрләре.

Бу зур эшне яшь шагыйрь Уральскида вакытта ук башлап җибәргән һәм гомере буе аны дәвам иткән. Шушы шәһәрдәге бер әдәби-музыкаль кичәгә багышланган мәкаләсендә ул «Тәфкилев», «Әллүки», «Сакмар суы» кебек җырларны «карт аталарыбызның чын йөрәгеннән чыккан» «туган һәм туачак балаларыбызның күңеленә яңа-яңа милләт хисләре... саба җиле шикелле рух өрәчәктер», дип язган. (Т.3, 107 б.)

«Без татарларның шигырь сөйли торган бәхерләре (үлчәүләре – И.Т.) гаять гүзәлдер. Бер татар шигырен әллә ничә төрле көйләргә җырларга мөмкиндер» һәм хәтта татарлар җырлый торган көйгә рус шагыйрьләренең шигырьләре дә килеп торадыр, дип язган ул. Бу, әлбәттә, рус җырларында да татар көйләре чагылганлыгына ишарә. Бу турыда язарга яратмыйлар. Чөнки ничек инде ул бөек рус халкының җырларында татар көйләре чагылсын? Бу мөмкин түгел сыман.

Ә менә күренекле рус этнографы мәрхүм Евгений Прокофьевич Бусыгин бу турыда сөйләргә оялмый иде. Ул бик күп рус җырларының татар көйләре белән сугарылганлыгын ассызыклый килде. Шаляпинның җырларында да татар элементлары барлыгы турында язып чыгучылар булды.

Татар моңы – ул борынгы төркиләр моңы. Ул киң далаларда яшәгән борынгы бабаларыбызның эчке хисләрен сеңдергән. Юкка гына аны кытайлар да үз итмәгән, алай гына да түгел, аны Ерак Көнчыгышка таратканнар, хәтта япон утрауларына кадәр илтеп җиткергәннәр. Нишләп әле аны татарлар белән йөзләгән ел янәшә яшәгән руслар үзләштермәсен икән? Юк, мин һич кенә дә рус музыкаль культурасын шик астына

куймыйм. Әмма борынгы рус халык җырларының татар моңнары белән аваздашлыгына шикләнмим. Ә Тукай моны бик яхшы тойган. Нәкъ шунлыктан Пушкинның бер шигырен татар көе белән җырлау мисалын китергән.

«Еду, еду в чистом поле, («Җизнәкәй» (ике кәррә))

Колокольчик динь-динь-динь («Балдызым, ялгызым» (бер кәррә)). Боларны язган вакытта аның алдында русларның «Народные песни» китабы булган. (Т.3, 143-144 бб.).

Бездә әлегәчә шушы уртаклыкка багышланган фәнни хезмәтләр юк. Мәсәлән, кышкы суык далада өшеп үлгән ямчы (ямщик) турындагы бөтен эчтәлеге белән бер-берсенә туры килгән җырның татар һәм рус вариантлары бар. Аның татарча вариантының язмасы Германиядә Беренче бөтендөнья сугышы вакытында әсирлеккә төшкән татар солдатлары башкаруында сакланган.

Җырның төп нөсхәсе татарныкымы, әллә русныкымы икәнлеген әйтү кыен. «Ямь», «ямчы» хезмәте илнең бер почмагыннан икенчесенә уңайлы гына барып җитә алу максатыннан Алтын Урда заманында ук барлыкка килгән. Ә Мәскәү дәүләте аякка баскач, аны руслар да дәвам иткәннәр. Моның шулай икәнлеген революциягә кадәрге рус галиме В.Сергеевич үзенең өч томлык «Древности русского права» исемендәге хезмәтендә исбатлаган. Шулай булгач, минемчә, бу җыр баштарак барлык моң-зары белән татарларда барлыкка килгән.

Тукай халкын, аның иҗатын җаны-тәне белән сөйгәнгә күрә үзенең кыскадан-кыска гомеренең шактый өлешен моң һәм халык әдәбиятын барлау һәм җыйнауга багышлый. 1910 елны Шәрык клубында укыган лекциясендә аларның берсен ачкыч, икенчесен йозак рәвешендә бәяли. Ачкыч белән яки моң аша, халык күңеленә үтеп кереп була, йозак белән яки халыкның бертуктаусыз байый торган җор шигъри теле белән, аны югалмастай дәрәҗәдә саклап була. Чыннан да, тик гасырлар буе буыннан-буынга күчеп, үзенә үткән бай вә фаҗигале тарихыбызны сеңдерә барган моң һәм әдәби мирас ачкыч һәм йозак рәвешендә яши алалар. Болар ниндидер рәвештә игезәкләрне хәтерләтәләр.

Тукайның шушы искиткеч чагыштырмасын, бүгенге иҗат кешеләре дә үзләренә күрсәтмә итеп кабул итсәләр, бәлки милли моңнарыбызны, җырларыбызны каплап, томалап бара торган бүгенге булыр-булмас сүзләргә көйләнгән мәнсез җырларга киртә булыр иде. Ә киртә кирәк, чөнки тел һәм милли моң – милләт сакчылары.

Тукай юкка гына шактый җырларның тарихын тикшереп, аларны төрле яктан анализламаган. Ул аларның бабаларыбыз тарафыннан калдырылган «иң кадерле вә бәһале бер мирас» икәнлеген аңлап эш иткән. Болгар шәһәре, авыллары «беттеләр, эзләре дә калмады», әмма алар «халкыбыз күңелендә «һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф раушан көзгеседер», дип язган шагыйребез. Ул конкрет мисаллар белән халык җырларының яшәү көзгесе икәнлеген күрсәтә алган. Аларны укыганда, Тукайның рухи дөньясы халыкчанлык хисе белән сугарылуына тагын бер кат инанасың.

Тукай шактый күп җырларны җыеп, туплап кына калмый, аларның тарихы турында да мәгълүмат бирә. Мәсәлән, «Тәфкилев» көе мөфти Тәфкилев кызының француз егетенә булган бәхетсез мәхәббәтенә багышланган. Шагыйрь бәхетсез мәхәббәтнең тамырлары шактый тирән икәнлеген аңлап эш иткән булса кирәк. Аның «Җырлар дәфтәре»ндә «Хан кызы көе» дә булган. Тик ул аннан ертып алынган. Кем белә, бәлки ул Алтын Урда ханы Туктамыш кызының бәхетсез мәхәббәтенә багышланган җырның берәр варианты булгандыр. Әйтүе кыен, ләкин шулай булуы бик тә ихтимал.

Туктамыш ханның кызы Нәнекәйҗан караим егетенә гашыйк була. Хан, әлбәттә, башка диндә булган егеткә кызын бирергә теләми. Кайгысыннан кыз текә кыядан сикереп, үзен үлемгә дучар итә. Шушы җырны ишеткән Зәки Вәлиди аның көе «Тәфтиләүне» хәтерләтә иде дип язып калдырган. Димәк, җырның көе, әлбәттә, инде ниндидер үзгәрешләр белән саклана килгән, ә сүзләре һәрвакыт диярлек заман фаҗигасенә җайлаштырыла килгән булып чыга.

Тукай аша без «Ашказар» көен дә шундый ук бәхетсез мәхәббәт тудырган икәнлеген

беләбез. Бу һәм аның тарафыннан тупланган, тикшерелгән башка җырларның сүзләре һәм моңнары да ачкыч белән йозак мөнәсәбәтендә яшәгәнлекләренә дәлил булып тора.

Шул ук вакытта Тукай халык иҗатының бертуктаусыз байый торуына да игътибар иткән. Ул аларның үзе ишеткән төрле вариантларыннан мисаллар китереп, шуның белән халыкның үзендә җырга нигез салучыларның туа торуына ишарә ясаган. Шуның белән халкыбызның бөеклеген, аның бетмәс-төкәнмәс иҗат чишмәсе икәнлеген раслаган.

Тукай – халык җырчысы. Аның шигырьләре, барлык язмалары моң булып яңгырый. Аңа халык шагыйре исемен бернинди указ белән дә бирмәгәннәр. Милләт биргән исем ул. «Мине әгәр синеке дип исәпләсәләр, мин бәхетле», дип язган шагыйрь. Ул милләт хыялын барлык хыяллардан да татлырак, дип санаган. «Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем».

Теләге кабул була. Халык аның үлеме турындагы хәбәрне гомум кайгыдай кабул итә. Бу көнне барлык татарлар да елый, алар үзләренең бөек сүз патшасын югалттылар, дип язган «Кояш» газетасы. Шул көндә чыккан газеталар, шагыйрь үзе калдырган 500 сум акчага, Тукай фондын булдыру максатыннан «Тәрҗеман» газетасы үзеннән 100 сум өстәде һәм башкаларны да шушы башлангычка кушылырга чакырды, дип язганнар.

Һәммә җирдә, Кытайның Көлҗә шәһәреннән башлап Петербургка, Әстерханга кадәр булган барлык җирләрдә дә диярлек Тукай җәмгыятьләре барлыкка килә. Шагыйрьгә багышланган кичәләр үткәрелә. Казандагы Тукай җәмгыяте үзенең төп максаты итеп, мохтаҗ язучыларга ярдәм итүне билгеләи.

Әстерханда бу җәмгыятьне күренекле азәрбайҗан җәмәгать эшлеклесе Нәриман Нәриманов җитәкли.

Моңа каршы төшүче көчләр дә табылмый түгел. Мәсәлән, Оренбургта һәм Читада ике студентның Тукай иҗатына багышланган лекцияләре тыела. Казанда шушы эшләрне башкарырга тырышкан ике укытучыны урыннарыннан алалар. Ләкин төрки һәм ислам дөньясында шагыйрьнең даны шулкадәр киң таралган була ки, халык хәрәкәтен берничек тә туктатып булмый.

Бакуда рус телендә чыга торган «Каспий» газетасында Дагестани имзасы белән «Мөселман язмалары» исемле язма басыла. Ул тулысы белән Тукайга багышланган. Автор сүз белән мөселман йөрәкләрен яндырган шагыйрь турындагы хатирәләр һәркем өчен дә кадерле», дип язган. Минем, ун еллык иҗтимагый эшчәнлек дәверемдә беренче мәртәбә мөселман йөрәкләрен яндырган шагыйрьгә карата шушы кадәр кайнар мөнәсәбәтне күргәнем юк иде, дигән ул.

Бу кеше халыктан аерылган интеллигентларга карата ризасызлык белдереп, болай дип яза: «Шуның өчен дә шул Сабир һәм Тукай кебек талантларны югалту, андый зыялыларны түгел, күбрәк халыкны борчый».

Тукай яшәгән җирләрдән читтә яшәгән кавказлы шагыйрьнең никадәр халык йөрәгенә үтеп керә алуын билгеләи алган. Тукайны төркиләр генә түгел, барлык башка мөселман халыклары да яраткан, аны үз иткән. Күренекле таҗик язучысы Садретдин Әйнидән, революциягә кадәр Пушкин белән Лермонтовны белә идеңме, дип сораганнар. Ул моңа «әйе, белә идем, Тукай аша», дип җавап биргән.

Чыннан да, халыкны үзеннән ерак торган интеллигентлар түгел, ә аның үзе, аның кайгысы һәм шатлыгы белән яшәгән, аның ихтыяҗларын чагылдырган язучы һәм шагыйрьләр язмышы борчыган.


Тукай – халыкны, ә халык Тукайны яраткан. «Барлык уем кичен дә, көндезен дә сезнең турыда, милләтем. Синең саулыгың – минем саулыгым. Синең авыруың – минем авыруым». Ул шушы рәвештә яшәгән һәм шушы милли хисләр белән якты дөньядан киткән. Ләкин ул халык күңеленә раушан көзгеседәй мәңгегә сеңгән.

**Индус ТАҺИРОВ,**
*тарихчы, җәмәгать эшлеклесе.*

# ШӘХСИ АРХИВ СЕРЛӘРЕН МИЛЛӘТЕБЕЗГӘ АЧЫП...

## («Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат», төзүче Зөфәр Мөхәммәтшин)

2023 елда Бакый Урманченың шәхси архивы фондында сакланып калган искиткеч олы кыйммәтле мәдәни хәзинә аерым китап булып дөнья күрде. Басманы төзүче дә, гарәп шрифтындагы текстларны кириллицага күчерүче дә – Зөфәр Мөхәммәтшин. «Шәхси архив – серле дөнья» дип аталган кереш сүзендә китапны төзүче: «Татар сынлы сәнгате классигы Б.Урманченың уйма һәм рәсем сәнгате шактый дәрәҗәдә тикшерелсә дә, өйрәнүчеләр игътибарыннан язма мирасы читтә кала килде», дип искәртә һәм басмага төрле елларда татар вакытлы матбугатында дөнья күргән яки кулъязма рәвешендә шәхси архивта сакланган материалларны тәкъдим итә.




Татар сынлы сәнгатенә нигез салучыларның берсе, рәссам, сынчы, график, каллиграф, Татарстан АССР һәм РСФСР-ның халык рәссамы, Казакъстан ССРның атказанган рәссамы, ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Бакый Урманче (Габделбакый Идрис улы Урманчиев, 23.02.1897–06.08.1990) эшчәнлеге әлеге китапта икенче яктан, кайбер очракта бөтенләй көтелмәгәнчә ачыла.

Китап «Мәкаләләр һәм бәяләмәләр», «Хатирәләр», «Көндәлекләр», «Шигырьләр», «Хатлар», «Документлар» дип аталган бүлекләрдән тора. Шәхсән үзем әлеге зур форматтагы, саллы, Бакый аганың төрле елларда ясалган фотосурәтләре белән тулыландырылган 464 битлек әлеге китап белән танышуны «Дәрдемәнднең вафаты уңаеннан» (41 бит) дип аталган язмасыннан башладым.

Шагыйрьнең мәгълүм «Бүзләрем маналмадым» шигыре юлларын эпиграф итеп алган әлеге язма беренче юлларыннан ук нәкышлап, детальләп язылган картина кебек укучының дикъкатен үзенә бәйли дә, тәмам булып, соңгы ноктасы куелганга кадәр бер сулышта, хәтта ки сулыш алырга да оныткан бер хәлдә укып чыгыла: «Авыруның хәле бик яман (начар) булса да, аның авыр сулавын тыңлаганда, авыр күз кабакларының көчкә-көчкә күтәрелеп, гасырлар моңы тулган, тирән сагышлар чагылдырыр күк күзкәйләренең аз гына күренеп китүе, күкрәгенең иң тирән почмагыннан азап белән эндәшкән зәгыйфь тавышы, заманында гаҗәп матур булган, ләкин корышып саргайган бармакларының хәрәкәткә килеп тибрәнүе әле бу авыр чирнең чигенүенә, авыруның могҗиза буларак терелеп, уңалып китүенә бер өмид бирәләр иде. Ләкин бу дәмдә бу өметләр сүнде. Ятакка сузылган гәүдә бөтен галәмнең һавасын суларлык итеп күкрәген киерде, якты дөньяның сурәтен бер карауда йотып алырлык итеп, моңлы күзләрен киң ачты да хаят белән видаглашты. Өмидләр өзелде...» Котсыз 1921 елның сурәте, мәрхүмне кадерләп, кабергә иңдерерлек кәфенлек тә булмавы,

Дәрдемәндне соңгы юлга озатучылардан 15 кеше булып, ундүрте – туганнары булуы турында язылган юллар бәгырьләргә үтеп, гаҗизлектән тамак төбенә утырган юшкынны йотып җибәрә алмаслык бер халәткә китерә...

Мәкаләләр темаларының төрлелеге һәм авторның үзе күтәргән һәр мәсьәләдә ачык мөнәсәбәте белән игътибарны җәлеп итә. «Коръән» (38 бит) дип аталган язма авторның тирән уйланулары, масштаблы фикер йөртүе белән аерылып тора. Мәкаләдә Кыпчак Коръәненең үзендә саклану тарихына, аның сыйфатына мөнәсәбәтле аерым фактлар китерелгән. «...Минем кулга каләм алуымның бер сәбәбе – Мисырда хөкем сөргән мәмлүк-кыпчаклар, ягъни татарлар хөкем сөргән заманда татарча шәрехләнгән, татарча тәрҗемә ителгән Коръәннең бер җөзьэи кулымда булуы. ...Безнең тарихчыларның зур вазифасы шушы дәверне тирән вә киң рәвештә, Мисырның, Каһирәнең үзенә барып, изге Нил дәрьясы ягасында татарларның ничек хөкем сөрүләрен, олуг мәдәни хәрәкәтендә боларның һәм онытылмас эз калдыруларын аңлатудыр. Масштаб кирәк, кардәшләрем. Ильминский, Ашмарин кебек миссионердан азган «төрек угыллары»н гына татарчага шәрехләп чыгару оят безгә...» Шул рәвешле һәр язма детальләп сурәтләнгән, төгәл, авторның вакыйга яки хәлгә мөнәсәбәтен ачык чагылдырган булуы белән сыйфатлана.

Язмалар арасында 1919 елда ук «Кызыл Армия» газетасында басылып чыккан «Казан гарнизонындагы кызыл солдатларга. Митинг», «Бетсен монархистлар» кебек тарихи-сәяси вакыйгаларга мөнәсәбәтлеләре дә, «Безнең юл» журналында дөнья күргән «Казан сәнгать техникумы» (1926) (Б.Урманче – әлеге уку йортында белем алган татарлардан беренче кеше), татар рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, архитектура, скульптура тарихы, үсеше, бу өлкәдә танылган шәхесләр турында мәгълүмати мәкаләләреннән «Сурәтчелек» (кульязма), «Ислам дине һәм сәнгать» кебек язмалары милли сәнгать өлкәсенә аяк басучылар өчен аеруча әһәмиятле дип уйлыйбыз. «Төркестан милли архитектурасын яңартуда бер тәҗрибә» мәкаләсе («Безнең юл», 1926, 10 нчы сан) тәнкыйди рухы белән аерылып тора. «Карт татар скульпторы Мирзаҗан ага Байкиев» мәкаләсе («Безнең юл», 1929,10 нчы сан) исә Ленинградта, Эрмитажда эшләп танылган Пенза татары, оста сынчы булып җитлеккән шәхес Мирзаҗан Байкиев (1868–1942) турында сокланып, катлаулы тормыш юлы узып та, татар кешесенең сәнгать өлкәсендә зур осталыкка ирешкән булуына шаккатып та язылган. «Мирзаҗан аганың эше аны татар иҗтимагый тормышыннан байтак читтә яшәргә мәҗбүр итсә дә, аның табигатендә үк иҗтимагый сизгерлек булу аны рухан һәрвакытта татарның иҗтимагый тормышы белән бәйләнештә тота. Тукай, Исмәгыйль Гаспринский, Мулланур Вахитов кебек татарның мәдәни-иҗтимагый сималарын ясавы – моның өчен зур дәлилдер. ...Эрмитажда эшләү – һәрбер скульптор-реставратор өчен идеал дәрәҗәсендә. Әлбәттә, бу максатка ирешер өчен күп казгану, күп осталык кирәк. Менә бу эше, бу профессиональ казанышлары өчен без Мирзаҗан аганы икенче тапкыр тирән самимият белән тәбрик итәбез». Урманченың кулга алыну сәбәбенең дә нигездә имла мәсьәләсе икәнен хәтерләгән укучыга аның «Безнең хәрефләрнең реформасы» («Безнең юл», 1926, 10 нчы сан) мәкаләсе кызыксыну тудырачак. Әлеге мәкаләдә гарәп язуының матурлыгы-нәфислеге, типография мөмкинлекләре, хәрефләрнең укырга кулайлыгы, күзнең физиологик күрү сәләтенең үзенчәлекләре турында да кызыклы мәгълүмат бирелә.

Китапның шактый зур өлешен (45–139 нчы битләр) хатирәләр тәшкил итә. Бүлектә исеме телгә алынган дистәләрчә татар җанлы шәхесләрнең үзенчәлекле образы тудырыла. Алма-Ата университетында славян телләре кафедрасы мөдире татар телен «фанатизмга тиң» яратучы, олуг масштаблы галим Хәйрулла Хәбибулла улы Мәхмүдов; «го-

мердәше», филолог, фольклорчы галимә Флора (Айгөл) Урманче; Мәскәүдә белем алган, татар җанлы, татар зыялылары белән аралашып, шактый истәлекләр калдырган танылган табиб Гыйниятулла Нигъмәтулла углы Терегулов; бер заманнарда Соловкида тоткынлык чоры кичергән «намус, сәдакать иясе», галим Исмәгыйль Ситдыйк улы Хантимер; әдәбият галиме «гаҗәеп мөлаем, нәҗип (зыялы), сабыр табигатьле, сөйкемле кеше» Җамал Вәлиди; гарәп теле һәм әдәбияты белгече, лексикограф-галим, Б.Урманче язганча «гаять нәҗип, сабыр, акыллы галим, нәзакәт иясе» Таһир Ильяси; төзген, архитектор, «иҗат шәүкы белән яшәүче, намуслы сәнгать остасы һәм остаз» Исмәгыйль Гайнетдинов; «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесе, «олуг галим, җәмәгать хәдиме, акыл иясе...» дамелла Галимҗан хәзрәт Баруди; «мәркәзи мөселман хәрби коллегиясендә Шамил Усмановның урынбасары» Юныс Вәлидев; «бик прогрессив казый, сәнгать сөюче» Хәсәнгата хәзрәт Габәши, аның улы «татар музыкасына хезмәт иткән затларның иң мәгърифәтлесе» Солтан Габәши, «татарның бер галиме, Европага барып, Льеж университетында хәтме котеб кылган математик, Казан университеты профессоры, горбәттә дөньялыктан киткән» шәхес Гаяз Максудов; Акчуриннар, Алмаевлар, Максудилар, Шакир Мөхәммәдьяров, Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан Ибраһимов, Мирсәет Солтангалиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Гадел Кутуй, Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һ.б. әдәбият-сәнгать, фән өлкәсендә танылган, татар халкының йөзек кашы булырлык, ләкин күбесе режим тарафыннан юк ителгән, яки татарның үзе тарафыннан бәяләп бетерелмәгән, кыйммәте ачылмаган шәхесләр галереясы... Татарның асыл инсаннары хакында ихлас җылылык, олы хөрмәт, үкенеч, сызлану белән язылган хатирәләре – укучыга XX гасыр татар зыялылары хакында ифрат бай мәгълүмат бирә.

Китапның «Көндәлекләр» өлеше Б.Урманче тарафыннан теркәп барылган 1951 елдан башлап 1990 елга кадәр булган көндәлек язмалардан тора (140–255 бит). Язмалар сәнгать әһеленең Казан, төрле сәбәпләр аркасында Ташкент, Алма-Ата, Балхаш, Тирасполь (Молдовия), Татарстанның район һәм авыллары, Уфа, Җаек, Кара диңгез, Кырым һ.б. якларда күргән-кичергәннәре, шул уңайдан тел, әдәбият, сәнгать, тарих, аерым шәхесләр, вакыйгалар хакында фикерләре, уйланулары бирелгән. Болар укучыга гаҗәеп гыйбрәтле дөнья ача.

Китапның шактый саллы өлешен (150 биттән артык) сәнгать остасы язган шигырьләр тәшкил итә. Б.Урманче, үзе язганча, «шагыйрь булмакны дауламаса да», хәтта аның сынлы һәм уйма сәнгате турында да «шигърият рухы сеңгән, төсләр гармониясе тудырылган» дип бәяләргә мөмкин.

Р.Фәйзуллинга мөнәсәбәтле «Равил Фәйзуллин кичәсе» (41 бит) дип аталган кульъязмасында, рәссам, мәдәният, тел турында кайбер фикерләрен терки дә, көтмәгәнчә, үзенең гомер буе шигырь язуы, аларны беркемгә дә күрсәтмичә саклавы хакында яза. Шулай да кайбер шигырьләрен Һ.Такташка күрсәткән, аның белән исә 1921 елда Ташкентта танышуы турында хәбәр итә. «1923 елда булса кирәк, Казан отелендә (кунак бүлмәсе) күрше бүлмәләрдә берничә көн уздырырга туры килде. Шулвакыт мин Такташка берничә шигыремне укып күрсәткән идем. Бик яман бәя алдым. «Бу шигырь түгел» дигән сыман бер уе хәтеремдә калган. Күңелем буйсынды. Артык берәүгә укырга бирмәдем. Ләкин шигырь язудан туктамадым...»

«Рәссамның шигырьләрендә җан сыкравы, җәмгыятьтә барган гаделсезлекләргә җавабы, эчке халәт белән тышкы халәт арасындагы каршылыклары, күңеле күрергә теләгән дөньясы, борчу-мәшәкатьләре, гүзәллек, табигать матурлыгы, лирик-фәлсәфи карашлары чагылыш тапкан», диюе белән китапны төзүче хаклы, безнеңчә.

Б.Урманченың йөзләрчә шигыре арасыннан аерым берләрен сайлап алу шактый катлаулы эш булса да, алар-

ның асылын, рухын укучыда күзаллау тудыру өчен берничә шигырь юлын китерәбез:

***

*Идел, Хәзәр буйларында әллә кайчан*
*Чәчәкләрдер.*
*Әмма монда*
*Көртләр арасында кәфенле гүрләнгән*
*«Атауның» гранит ярлары.*
*Күңелемдә, күңелемдә һаман*
*Алмагач чәчәкләренә күмелгән Идел ярлары.*
*Сандугачлар сайравыннан шәгәрап,*
*Хуш исләр аңкыр Идел баглары.*
*Аһ, күңелемдә*
*Иңрәү, көрсенүләр һаман,*
*Сабыйлык чакларымның моңлы сазлары*
(1930, Соловки, 257 нче бит).

***

*Каракошның колачлар канатларын,*
*Кырыксалар аргамакның аякларын,*
*Богауга салсалар асы канны,*
*Булуыннан аларның файда бармы?!*
(1935, 259 нчы бит)

***

*Мин чынлап шашынган идем анда*
*Илләр өстендә туачак таңга.*
*Аһ, сабыйлык!*
*Ал хыяллар, нурлы өмидләр багбостаны,*
*Үсеп акыл, күреп талаш.*
*Күп канның туфрак белән юылганын.*
*Алдашу, хыянәттән калып таңга,*
*Узды өмид,*
*Үлде хыял,*
*Аералмадым ни дошманны, ни дустларны.*
(1948, 269 нчы бит)

***

*Менә Хан мәсҗеде!*
*Менә Казан!*
*Кайчандыр шул манарадан*
*Кодрәтле аваз белән әйткән азан.*
*Аһ, Казан!*
*Йөрәге халкымның сызлаган.*
(1953, 275 нче бит)

***

*Империя юк, таралды инде.*
*Аның урынына бер «партия» килде.*
*Нинди милләт инде ул,*
*Әгәр булса*
*Ермак бандит – милли герое*
(409 нчы бит).

Китапның ахыргы өлешендә Б.Урманче язган, аңа атап язылган хатлар, аның белән бәйле төрле документлар тәкъдим ителгән.

Китапны төзүче З.Мөхәммәтшин Б.Урманченың Мәскәүдә укыган елларда фарсы теле буенча белемен арттыруын, инглиз, немец телләрен үзлегеннән үзләштерүен; аның төрки, рус һәм славян халыкларының шәхесләре белән аралаша, фикер алыша алырлык киңкырлы белем иясе булуын сокланып та, горурлану хисе белән дә яза. Рәссамлык һәм сынчылык белән шөгыльләнүдән тыш, татар гуманитар фәне, музыкасы, этнографиясе белән дә кызыксынган талантлы татар улының архивында сакланган кулъязмаларын туплаган әлеге китап, һичшиксез, сәнгать-әдәбият белән кызыксынучылар, күңелендә милли горурлыгы булган һәркем өчен Бакый Урманче шәхесен ачу, XX гасыр барышы, сәнгать үсеше, замана, тарих, милләт язмышында үз эзен калдырган дистәләрчә вә дистәләрчә шәхесләр турында киң мәгълүмат бирә торган чыганак.

**Флёра СӘЙФУЛЛИНА**,
*филология фәннәре докторы.*

# ХӘЙРИЯЧЕЛЕКНЕ ЯКЫННАРЫҢНАН БАШЛАРГА КИРӘК

*«Ханский дом» төзелеш компаниясен оештыручы Ильяс Гыймадовны күпләр «Меценаты» бизнес-берләшмәсе рәисе, «Честный бизнес» юридик компаниясенә нигез салучыларның берсе, Яшел Үзән шәһәр советы депутаты буларак та белә. Күпкырлы һәм киң күңелле шәхес белән әңгәмәне укучыларга тәкъдим итәбез.*



*Хәйрияче Ильяс Гыймадов.*

**– Эшкуарлык һәм хәйриячелек эшен башлап җибәрүгә нәрсә этәргеч ясады?**

– Эшкуарлык белән мин күптәннән шөгыльләнәм. Казанга килгәч, көндезге бүлеккә укырга кирәргә балларым җитмәде, шул сәбәпле документларны читтән торып уку бүлегенә тапшырдым. Укыган вакытта нәрсә дә булса эшләргә кирәк иде һәм мин 17 яшемдә видеосъёмкалар белән шөгыльләнә, балалар бакчаларында бәйрәмнәр, туйлар, юбилейлар төшерә башладым. Бизнестагы иң беренче акчамны шунда эшләдем. Уйнап кына башлаган идем, ләкин әлеге юнәлештәге эшчәнлек бүген дә дәвам итә. Соңрак салоннар челтәрендә, телефоннар сату өлкәсендә эшләдем. Хәйриячелек белән шөгыльләнү иң беренче тәрбиядән һәм диннән килә, мөгаен. Фәкыйрьләргә, мохтаҗларга, ятимнәргә ярдәм итүнең нинди зур мөмкинлек һәм саваплы эш икәнлеген аңлау шушы эшкә китергәндер. Беренче хәйрия эшемне әнидән башладым дип әйтергә мөмкин. 2008 нче еллар булгандыр... Әнинең бик нык хаҗга барасы килә иде һәм мин аның шушы теләген чынга ашырырга булдым. Беренче эшләгән бөтен акчамны җыеп, әнигә тапшырдым. Шуннан соң күңелдә рәхәт, ләкин шул ук вакытта ниндидер бер үкенечле хис барлыкка килгән иде. Үзең эшләгән акча бит... Тиенен кадәр биреп, бернәрсәсез калдым кебек тоелган иде. Ләкин сиздем: әни хаҗга барган елны минем эшләрем алга китте. Кыска вакыт эчендә хәйран гына акча эшләргә өлгердем, бик күп заказлар килә башлады. Бераз соңрак белдем: хәйриячелекне, башкаларга ярдәм итүне иң беренче якыннарыңнан башларга кирәк икән. Кайвакыт без кемгә ярдәм итәргә икән дип, баш ватабыз. Баксаң, якында гына кемнеңдер дәү әнисе, дәү әтисе даруларга акча җиткерә алмаска мөмкин. Бәлки, кемнеңдер күршесенә ярдәм кирәктер. Шуңа күрә әти-әнигә, якын кешеләреңә игътибардан башларга кирәк. Әлбәттә, бар кешегә дә ярдәм итеп булмый, һәркем үзенең кулыннан килгәнчә тырышырга тиеш. Бизнес өлкәсендә төрле хәлләр була. Барысы да шома бармаска мөмкин, ләкин без гадәттә яхшы якны гына күрсәтәбез. Социаль челтәрләрдән карап торганда, эшмәкәрләрнең барысы да әйбәт, акчада коеналар, ял итеп кенә йөриләр, дигән фикер туарга мөмкин. Ләкин эшмәкәр гаиләсе өчен генә түгел, хезмәткәрләре өчен дә үз өстенә бик зур җаваплылык ала.

**– Сез «Тап-татарча бизнес» дигән китап та язарга өлгергәнсез...**

– Ул күбрәк минем тормыш юлым турында. Бәлки, кемгәдер минем тәҗрибәм файдалы булыр, дигән фикер белән язылды. Китапта, әлбәттә, бизнес өлкәсе һәм тормыш кыйммәтләрем турында сөйләнә. Хәзерге җәмгыятьтә, безгә үтеп кергән күп кенә китапларда көнбатыш кыйммәтләре пропагандалана. Күбесендә беренче урынга акча куела. Бүген нәрсәгә дә булса ирешү өчен, «зур абзыең» ярдәм итеп җибәрергә тиеш, дигән фикер яши. Шул ялгыш фикер аркасында мәктәптә укучы балалар, яшүсмерләр үзләренә киртә куймасыннар иде. Мәсәлән, мин – гап-гади авыл малае. Әлбәттә, нинди дер зур дәрәҗәләргә ирешкәнем юк, әлегә зур максатларга таба юлда гына. Бу – үземнең тәҗрибәмнән чыгып, кызык вакыйгаларны искә төшереп, киләчәк буынга атап язылган мотивацион бизнес жанрындагы татарча беренче китап. Кызганыч, бүгенге көндә татар теле кулланышта аз, укучылар да кимеп бара. Китап татар телендә басылып, кайдадыр тузан җыеп ятмасын өчен аны ике телдә – татарча-русча итеп эшләдек. Рус кешесе әлеге китапны кулына алса, авторы татар икәнен аңлаячак. Кайберәүләр өчен татар телен камилләштерергә яки исенә төшерергә дә мөмкинлек була.

**– Финанслау өчен проектларны сайлаганда, нинди төп принципларга таянасыз?**

– Нинди дер критерий юк. Бөтенесе – йөрәктән. «Приют человека» проектын мисалга алыйк. Әйе, «ялкауларны арттырасыз, кешеләр эшләми, ашап кына йөри» диючеләр бар. Ләкин шунысы билгеле: безгә килүчеләрнең 95 проценты – әбиләр. Аларның пенсияләре бар, тик бүгенге көндә дарулар бик кыйммәт. Безнең максат – мохтаҗларны кайнар ризык белән тукландыру. Моңа өстәп, проект безне берләштерә: бу эштә эшмәкәрләр дә, дәүләт тә катнаша. Мин башта үзем хәйрияче булсам, соңрак оештыручыларның берсенә әйләндем. Яхшы эш үзенең йогынтысы белән күбрәк кешеләрне җәлеп итәргә тиеш, дигән фикер белән без бизнес-берләшмә ясадык. Бүгенге көндә 250 эшмәкәр бар. Алар үзара аралаша: кемдер сата, кемдер партнёрлар таба, нинди дер тәҗрибә ала. Биредә мин күбрәк оештыручы, ярдәм итәргә теләүчеләр белән мохтаҗлар арасында арадашчы ролен башкарам. Тамчыдан күл җыела дип, башкаларга ярдәм итеп киләбез. Әгәр проектларны күрсәтәбез икән, моны мактану яки пиар өчен түгел, ә бу эш тагын да үссен, кешеләргә тагын да файдалы булсын өчен эшлибез.

**– Эшкуарлык эшчәнлеген хәйриячелек белән бергә алып баруның нинди өстенлекле яклары бар?**

– Әгәр бизнесның җәмгыятькә файда китерү кебек югары максаты булмаса һәм ул акча китерү инструменты ролен генә үтәсә, күпмедер вакыттан соң аның тәме югала. Чөнки кешегә күп нәрсә кирәкми. Ул машина, фатир кебек төп ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен көне-төне эшләргә мөмкин. Ә төп максатларга ирешелсә, кешенең акчаны исраф итү юлына басуы бар. Әгәр эшмәкәр хәйриячелекнең тәмен бер тапкыр татып карый икән, аның кабат шул юлга кайтасы киләчәк. Чын күңелдән нинди дер эштә катнашсаң, кемгәдер ярдәм итсәң, дөньяда бушка яшәмәвеңне, җәмгыятькә нинди дер файдаң барлыгын тоясың. Бу хис соңыннан да күбрәк эшләргә, күбрәк ярдәм итәргә көч бирә.

**– Үзегезгә иң зур йогынты ясаган проект кайсы булды?**

– Бу очракта иң истә калганы дип әйтү дөрес булыр. Иң истә калганнары – иң беренче проектлар, мөгаен. Мәчет төзү эшендә катнашканымны, ничек янып йөргәнемне хәтерлим. Хәзер дә әлеге мәчеткә бәйле бары тик матур вакыйгалар гына хәтергә килә. Бүгенге көндә үзебезнең «Ханская усадьба» бистәсендә (Олы Ключи авылы) эшлибез. Милли үзенчәлекләрне һәм традицион кыйммәтләрне нигез итеп алып, бистәне формалаштырабыз. Һәр урам дәүләтебез тарихына зур өлеш


керткән шәхесләр исеме белән аталган. Биредә яшәүчеләр күрсен, белсен өчен һәр урамда ул шәхесләр турында кыскача мәгълүмат урнаштырылган. Шулай ук бистәдә мәчет салынды. Без аңа Әхмәт бай Хөсәенов исемен бирдек, чөнки ул үз вакытында бик зур эшмәкәр булган, чит илләр белән хезмәттәшлек иткән. Белем өлкәсенә дә үзеннән бик зур өлеш керткән, китаплар һәм укытучыларга хезмәт хакы белән ярдәм күрсәткән. Казан губернасында гына да 20 дән артык мәчет торгызуда катнашкан. Без, интернеттан күреп, чит ил кешеләрен кумир итеп сайлыйбыз, ә үзебезнең милләт тарихында тирән эз калдырган шәхесләребезне белеп бетермибез. Шуңа күрә мәчеткә исемне дә киләчәк буынга үрнәк булсын дип сайладык. Безнең бистәдә шулай ук умарталык, алмагач бакчалары бар. Элек авылда бер-беребезгә кунакка йөрешә идек, хәзер кеше күбрәк интернетта аралаша, күршеләр белән аралашу да сирәгәйде. Безнең максат – үзебезнең бистәдә элеккеге җылы атмосфераны тудыру. Анда атна саен чаралар оештырабыз, шушы җылы мохитне булдыру, үзебезнең кыйммәтләрне саклауны да күз уңында тотабыз. «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер», дигән татар халык әйтеме бар. Бу эшләр кайдадыр сөйләп, мактанып йөрү өчен эшләнми. Иң беренче чиратта, халык ризалыгы өчен эшлибез, чөнки бу дөньяда беребез дә мәңгелек түгел. Ходай күпме гомер биргәнен беркем дә белми, шуңа күрә һәр яңа көнне яхшы гамәл белән үткәрәсе килә. Син үзеңнең белемең, тәҗрибәң, оештыру эшләрең белән дә башкаларга ярдәм итә аласың. «Башта үземә йорт төзим, машина алам да соңыннан башкаларга булышам» дигән фикерне дә ишеткән бар. Ләкин тәрбияле чын кеше, күпме акча эшләвенә карамастан, башкаларга ярдәм итү юлын табачак.

**– Хәйриячелек эшчәнлегегез кысаларында нинди оешмалар яки төркемнәр белән хезмәттәшлек итәсез?**

– Күбрәк эшмәкәрләр, үзебезнең партнёрлар, дуслар ярдәм итә, бик күп фондлар белән дә эшлибез. Мин үзем генә бу проектларның берсен дә алып бара алмас идем. Бергә җыелып эшләгәч, ниндидер бәрәкәт барлыкка килә, эшнең күләме күзгә күренеп арта. Билгеле бер тармак экспертлары һәм башка меценатлар белән тәҗрибә уртаклашу өчен, Татарстанда үзебез мөмкинлекләр тудырдык. «Меценатлар» бизнес-берләшмәсе мәйданчыгында атна саен очрашулар үткәрелә. Анда эшмәкәрлек, хәйриячелек буенча фикер алышабыз. Айга бер тапкыр, бөтенебез бергә җыелып, тормышка ашырылган эшләргә нәтиҗә ясыйбыз, киләсе айга яңа максатлар билгелибез. Эш барышында төрле каршылыклар очрый. Иң зур кыенлык – ул кешеләрнең «хәзер үземнән бүлеп бирәм һәм миндә кими» дип уйлавыдыр. Әлбәттә, әгәр проектка алынасың икән, аны ахырына кадәр җиткерү өчен көч тә, дәрт тә, сабырлык та кирәк.

*Әңгәмәдәш* – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА**

# ӘДИП ХАТЛАРЫ



*Шәхси архивымны барлап утырам.*

*Олы шәхес, әдип, минем остазым, дустым, башкорт һәм татар халкының бөек шагыйре Нажар ага Нәҗми хатлары. Без аның белән, ул бакыйлыкка күчкәнче, хатлар алыштык. Вакыт үтү белән кешене тирәнрәк аңлыйсың, яңача ачасың икән. Ул көчле, каләмдәшләре иҗатына, язмышларына игътибарлы, гаиләсен өзелеп яраткан, заман, халык, туган тел турында янып яшәгән шәхес тә, шул ук вакытта капма-каршы фикерләр, икеләнү, эзләнүләр, борчылу, хәтта кайсы вакытта рухи ярдәмгә мохтаҗ булган гап-гади кеше булып та күз алдына баса. Шуңа да каршылыклары белән бергә олы шәхесләрнең язмышлары, гамәлләре кешелек өчен кызыклы, фәһемле булып кала.*

*Нажар ага Нәҗми хатларының беразын укучыларга да тәкъдим итәргә булдым.*

**Халисә МӨДӘРРИСОВА,**
*Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Һади Такташ исемендәге әдәби премия иясе.*

*2 октябрь, 1987 ел.*

Халисә сеңлем!

Хатыңны алдым. Аны алмасам да, язарга җыена идем. Яңа гына язның карлы-яңгырлы чагы иде, хәзер инде көзнең карлы яңгыры яварга тора.

Минем гомер гел урмандагы йортта үтә, хәзер авылдан да болайрак, ут юк, керосин лампасы белән яшим, ә бу хатны Уфада язам.

Синең «Отып та булмый, онытып та булмый» дигән табышың белән саташып йөрим. Ниһаять, үзең дә язгансың икән. Әмма ул:

*«Отып та булмый,*
*Онытып та булмый*
*Син җыр шикелле»*

«Син җыр шикелле»не икенчәрәк итеп әйтеп булмыйммы?

Һәр җырны отып та була, онытып та була. Ә отып та булмаган, онытып та булмаган җыр гади түгел. Монда, уйлавымча:

*«Отып та булмый,*
*Онытып та булмый,*
*Әллә нинди серле (сихри) җыр булдың»,*

уңышлырак булыр иде дип уйлыйм. Хәер, үзең беләсең, син шагыйрә, күңелең ни куша.

Үземнең хәлем күңелле түгел.

Шигырь язылмый, язылганнары күңелсез. Менә берсе:

*Мин үлгәч тә зур югалту, диеп*
*Язылыр бәлки, бәлки язарлар.*
*Язылганның соңын төрле*
*дәрәҗәле*
*Фамилияләр урап алырлар.*
*Зур югалту… Әйтерсең мин әле*
*Югалмаган, гел күз алдында.*

*Көймә, күңел! Бу дөньяда әзме*
*Югалганнар тере чагында?*
*Тере хис һәм уйлар өчен әмма*
*Изге туфрак – халык күңеле.*
*Корымасын шушы туфрак кына,*
*Шул туфракта шагыйрь гомере!*

Миңа озакламый 70 яшь. Нәшрият хәтта китап чыгармый. Яшәве «рәхәтләнә» бара.

Көтмим, бары тик дөньяда үзең булып калырга кирәк. Яза башласаң хатка, борчыган әйберләр күп. Болар бәлки картлык мыжыклыгыдыр.

Хатың бик эчтәлекле, уйлануларың чын шагыйрьләрчә. Тумыштан шагыйрь булу билгесе дә шулдыр.

Гаиләңә сәламәтлек телим.

*Нажар абыең.*

***

*30 октябрь, 1987 ел.*

Халисә сеңлем!

Хатыңны укып чыгуга өч минут, ә дүртенче минутта шушы сүзләрне язам. Белмим нинди хәбәр тизрәк йөридер: бәхетлелек хакындамы, бәхетсезлек хакындамы?

Минем аяк хакындагы хәбәр сезгә дә барып җиткәч, шатланыбрак та куйдым. Димәк, хәбәр ишеттерүчеләр өчен дә, аны алучылар өчен дә минем барлыгым сизелә икән. Аягымны җиргә тидерә башладым – ни әйтсәң дә, үз сөягең бит, гәүдәне айлар буена өйдә яткырасы килмидер. Әлбәттә, бик сызландым, шул көйгә сызлану шигырьләре яздым, уртачалар – сынган күңелдән сынык нәрсәләр туар инде.

Миндә әллә нинди күңел сизгерлеге бар кебек:

1. Кичәле-бүгенле «Хәлисә минем хатны алдымы икән?» дип уйланган идем, синнән – хат.

2.1983 елда (12 нче ай) минем племянницаның ирен үтерделәр.

Үтерүчене аклар өчен нык көч салдылар. Акладылар. Шул хакта Мәскәүгә хат яздым, әмма Мостайның: «Бер өч ел вакытың юкка үтәчәк», –дигән сүзен дөрес табып тукталдым. Перестройкалар башлангач, шул хакта уйландым да кул селтәдем. Кичә-бүген тагы шул хакта уйланып яттым. Менә күптән түгел (бер сәгать элек) «Ленинчы» газетасыннан бер егет шул хакта сүз башлады. Туры килүме бу?

Шигырьләрең белән килеп чыксаң иде.

Язуны туктата күрмә. 70 яшьлек карт аягы сынганда да язганда, мәшәкать дип аклануны кабул итә алмыйм.

*Ихтирам белән, Нажар абыең.*

***

*11 декабрь, 1987 ел.*

Халисә сеңлем!

Хатың чын шагыйрь күңеле белән язылган. Син уйлаган әйберләрнең кайсы бер почмаклары минем яңа, аяк сындырып сызланып ятканда язган шигырьләрдә чагыла. Үзем яздым, язганнарымнан үземнең күңел кайта барды, чөнки басылмый торган шигырьләр күбәйделәр. Моннан берничә көн элек «Кызыл таң» егетләренә укыган идем, алар: «Бу шигырь түгел, ә крик души», – диделәр. Шуннан соң күңел үсеп китте. Аларны сиңа укысам, сиңа да ошар иде дип уйлап утырам. Шуларның икесен бер татар егетенә русча тәрҗемә итәргә бирдем, чөнки руслар тәрҗемә итмәячәкләр.

Безнең күңелләр унисон. Соңгы хәлләр турында башланып ташланган шигырем дә бар, һәм җавап итеп, кайберәүләргә «элек кайда булдыгыз, хәзер молчали бы» дигәнрәк шигырь дә язарга йөрим.

Син «гомер үтеп бара», дисең, ә мин «үтте» димен. Җил-давыллы күңелеңне аңлыйм, андый күңел белән яшәү авыр да, хәтта кызганыч та.

Бу хатны мин иртән язам, сәгать 4 тә. Өйдә Флорида апаң чирли, әби чирли (кәйнә), кызым больницада (роддомда).

Икенче малае бар. Оныгым Ансаф кына, күз тимәсен, хәзергә чирләми. Ике сәгатьтән соң аны уятам да балалар бакчасына илтеп куям. Кич белән кызым янына барам. Шуларга карамастан язам, чөнки язылганда язу – дәва. Син дә үз-үзеңне кайчак камчылап куш.

Бездә иҗади кичәләр күбәеп китте. Кичәләр бар, иҗат, шигырьләр юк. Йөрим, аяк та сынык, күңел дә сынык.

*Сәлам белән, Нажәр карт Нәҗми.*

***

*7 декабрь, 1988 ел.*
*«Янгантау» шифаханәсе*

Халисә!

Ниһаять, хатың кулга килеп эләкте. Минем хатны да алгансыңдыр инде. Казаннан хат 3 көн йөри, ә сездән 6 көн. Чуваш әйтмешли, «какой клуш» (глушь). Шаяртам. Съезддан калган күңелсезлекләрне язган идем, бәлки эмоция күбрәктер дә, тик чыны да шунда.

Бераз язам. Менә бер өзек:

*О! Яшәүнең яме калмас иде,*
*Һәр сорауга җавап табылса,*

– дигән юлларга, сантый адәм шикелле үзем сокланам.

Өч көн җанымны кая куярга белми йөрдем. Ни башта, ни йөрәктә шигырь юк. Уйлана торгач, Рәшит Нигъмәти турында истәлек яза башладым. Уйлап карасаң, аның хакында беркем бернәрсә язмаган, ә замандашлары үлеп беттеләр, күреп белүчеләр биш-алты кеше генә калдык.

Әйткәнемчә, мин моннан 8 нче декабрьдә китәм. Синнән хат алып өлгерермен кебек.

*Сәлам белән, Нажәр абыең.*

***

*14 октябрь,1993 ел.*
*«Янгантау» шифаханәсе*

Халисә сеңлем!

Хатыңа дүрт көнгә соңлап җавап язам. Хатыңны алган көннәрдә шундыйрак шигъри юллар белән саташып йөри идем:

*Шулдыр инде, шул үзедер инде*
*Үкенечле гомер азагы.*
*Авыр икән (ничектер ул үлем)*
*Әкренләп тә сүнү газабы.*

Үткән хатым битәрләү булып тоелса, монысы ничек булып барып җитәр. Бу юлларда һич кылану юк, бу көннәрне бик авыр кичерәм һәм аны табигый дип уйлыйм. Кулым эшкә бармый, җитмәсә ялгызлыктан китеп, ялгызлыкка кайтып керәсе бар. Моннан иртәгә китәм, тау җимерердәй булып килгән идем, күңелсез хатлар язудан баш чыкмады.

Монда өч җирдә очрашу булды. Китапларым күп иде, сатып алып бетерделәр. Казанда чыкканын сиңа җибәрәм дип тоттым, аны да якташ, колхоз председателе алып чыгып киткән.

Бер карасаң, ихтирам да бар, сәлам бирүчеләр, туктап сөйләшүчеләр туп-тулы. Безнең халык күп. Минем монда икәнне барысы да белде, тик йөрәктә нәрсә кайнаганны берсе дә белми. Колхоз председателе «язылмый» дигәч, «язылганы җитәр» дип кенә куйды. Бәлки аның сүзендә резон бардыр.

Ой, синең хәлеңне аңлыйм, Халисә! Мин дә оныкларымны бик сагындым. Китәм инде. Минем тәрәзәдән сызылып таң атканы күренә. Ул да кала. Таң нурында тау сыртлары сызылып-сызылып күренеп тора. Хәтта Кавказны хәтерләтә. Моннан бер ничә ел элек Ессентуки санаторие тәрәзәсеннән шулай Машук һәм Биштау күренә иде. Маяклар монда. Барыбер китәсе килә, ләкин кая барырга?

Ярый, Халисә, сау  бул.

*Наҗар абыең Нәҗми.*

***

*15 октябрь, 1993 ел*

Халисә сеңлем!

Хатың өчен рәхмәт, борчуларың зур шагыйрьләр януына тиң. Менә әле дачада япа-ялгызмын (кара әле, ялгызлык хат яздыра), төнге сәгать 3.

Көн буе мыштырдап, кич белән ашарга әзерләп, үзем эшләгән шәраб белән кичке ашны ашап, ятып торган идем, оеп киткәнмен дә сәгать 2 дә уяндым. Җитмәсә, мичкә күп якканмын да, өй эсселәнеп киткән, ишекне шыр ачып, аны суытып маташтым. Ни өчен боларның барысын да язам? Кызык бит, тормыш. Яңадан йоклап китүем икеле булгач, өстәл артына утырдым.

Яңа язылган шигырьләрне карап утырдым. Өченче көн биюче Нуриев турындагы шигырьне тирәнәйтүемә шатланып куйдым. Минем «Тагын татар» дигән шәлкем бар.Ул өч шигырьдән тора. Май аенда ук «Шәһри Казан»га тәкъдим итмәкче идем, һаман сузыла.

Син телефон аша сөйләшкәндә, һәрвакыт: «Шигырь язасызмы?» – дип сорыйсың, ә мин ык-мык итеп кенә җавап бирәм. Әкрен генә языла икән. «Көтәм», «Таяк», «Каенымны кистем» дигән яңа шигырьләрем бар. Июнь аенда пароходта йөргәндә, күпләргә дүртьюллык бер шигыремне укып йөрдем. Менә ул:

*Бер яшьлектә, бер картлыкта икән дә шул,*
*Күңелемдә буран, ап-ак, җылы буран*
*Картлыгымнан яшеренеп, куркып кына*
*Очрашырга килүчене көтеп торам.*

Ул уйлап табылган шигырь түгел, хәят һәм халәт җимеше. Башта тагын «Яшьлек белән картлык» дигән бер шигырь йөри. Менә тәүге строфасыннан соңгы өч юлы (язылган өлеше):

*Яшьлек белән картлык*
*Һаман ярсып, ярсып,*
*Пар ат кебек җилә йөрәктә.*

Хатыңны алгач та, хат язмавымның сәбәбе шул: «Сөембикә»дә шигырьләреңне укыйсым килгән иде.

Укыдым, котлыйм. Үземә шундый ачыш ясадым: шәкелең һәм рәсемең гармония булып күз алдына басты. Шундый ук гармонияне мин Татарстандагы Таңчулпанда да күрәм. Мин аны күреп белмим, әмма шигырьләре, синеке шикелле талантлы, самими, эчке драмалы.

Хатны тәмамлыйм да ятып карыйм, бәлки йоклап китәрмен.

Дачада берүзем – бөтен авылда берүзем. Караңгылык, тынлык, ялгызлык. Тынлыктан, ялгызлыктан күп сәлам сиңа.

*Наҗар абыең Нәҗми.*

**P.S**. Римне күрдем, әйтте, котлыйм!!!

***

*1 декабрь,1993 ел*

Халисә!

Вакытында җавап яза алмадым.

Чөнки «Йоматау»да конверт та, маркалар да юк. Иртәгә соңга Уфага барып килмәкчемен, шул чакта хатны салырмын дип язып утырам. Кичә Флорида апаң Уфага кайтып китте (без аның белән бергә ял итәбез), ул киткәч, шигырьләрне, поэмаларның кайсы бер урыннарын төзәтеп утырам. Минем 10 табаклык җыентык чыга. 10 табаклык хезмәт җилгә оча дигән сүз... «Татар каны» исемле поэманың азагын үзгәртәм. Вакытында язылганның ялган икәнен күреп, үртәлеп тә, үкенеп тә утырам.

Бер атна вакытым «Коточкыч хәл» («Фаҗига» дигән баш астында чыкты) дигән мәкалә язу белән үтте. Кирәктерме, кирәк түгелдерме, яздым инде.

Монда 12 һәм 8 юллы ике шигырь яздым. Усаллыклары белән үземә дә ошап куйды.

13 нче ноябрьдә Миңештедә – минем туган авылымда синең исемең кабатланды. Мин колхоз бәйрәменә кайткан идем, Фидан белән Нурия концерт куйдылар. Концерттан соң, гадәттәгечә була торган өстәл артында Нурия мине синең аркылы күбрәк белгәнлеге, синең минем хакта нинди фикерләр әйткәнеңне сөйләде. Шул чакта сиңа рәхмәтләнеп утырдым. Казанны тыңлыйм. Бу арада нигәдер синең «Балан»ны тапшырмыйлар. Бәлки тапшыралардыр да, хатлар буенча төзелгән концертлар бер төрле булганлыктан җиләтте, тыңламыйм.

Үзем өчен өченче көн үземне гафу итә алмаслык ачыш ясадым әле. «Күңелемдә бер кош канатларын җилпеп хушлаша» дигән җырның сүзләренә соклана идем, ул Диләнеке икән. Кайткач шалтыратып әйтим әле. Ул да артык читкә тибелгән булып чыкты бит әле. Читләтүнең дә чиге булырга тиеш бит инде. Кайчагында фикерләр дә соңлап килә шул.

Хуш иттек, Халисә! Картлык мыжыклыгы сиңа кагылмасын.

*Наҗар абыең.*

**P.S.** Бүген 8.12. Бөтенләйгә кайттым, хатны да бер атна соңлап җибәрәм.

***

*2 июль, 1994 ел.*

Халисә сеңлем!

Ниһаять, синнән хат! Ике хатка өч ай буенча язылган җавап. Битәрлим, озак җавап яздың. Хатларың уйландыра, күңелгә җылылык бирә, бигрәк тә дәваханәдә яткан кешегә. Сиңа хат язганда, Республика больницасының 8 нче катында идем. Ни өчен ничәнче кат икәнен күрсәтәм? Шул йортның тәрәзәсеннән Уфа йортлары тау-таш өемен хәтерләтә! Күпме йорт салынган, шунда күпме кеше яши, ә минем балаларыма шунда адәмчә яшәргә шарт юк. Аларга шарт булмагач, миңа да шарт юк дигән сүз, чөнки бергә гомер итәбез бит.

Көннәрне, айларны санавымның сәбәбе тагын шул: сиңа хат язганда, чирем берәү иде, икенчесен таптылар – инфаркт. Шуны тапкач, «Зелёная роща» санаториендагы реабилитация бүлегенә җибәреп, 24 көн яткырдылар. Бүген шуннан чыктым, ә хатыңны кичә алдым.

«Бөек» дигән сүзне ишетү рәхәт, ләкин колакны яра. Ул сүзне әйтүче син беренче түгел, ә иң соңгы ишетүем 16 апрельдә Габдулла Байбурин авызыннан булды. «Әгәр дә мин синнән соң үлсәм, – диде ул, – табутың янында арабыздан бөек кеше китте, дип әйтәчәкмен». 7 сәгатьтән соң үзе үлгән иде инде. Аның белән без икәү генә дачада идек.

Инфаркт – минем өчен яңа күренеш, башта бик тәэсир иткән иде, хәзер инде күнегә барам. Больницада һәм санаторийда өч мәкалә (репликага җавап белән дүрт), «Әниемә», «Татар генераллары» дигән 2 шигырь һәм өч дүртьюллык яздым. Аның берсен үзара гына укырга мөмкин.

Синең авыруың мине бик көендерә. Яшь көенә шундый кан басымы. Минеке 130/80, кайчагында бераз күтәрелгәли. Минем хатыным да шуның белән этләнә.

Бүген синең сүзләргә Батыркаева язган җырны тыңладым, оригинально! «Балан» – классик әсәр! Вәт бит: бер җыр белән барыбызны да бәреп ектың, киләчәктә дә уңышлар сиңа! Уңышларың белән котлыйм. Хәзер иң эшләр чагың, әмма вакытың бигрәк тар. Эш, бала-чага, ир-тормыш. Гаиләндә бәхетле булу – бәхет, билгеле.

Кайда инде безгә Анна Ахматова, Жорж Сандлар шарты… Әле дә язабыз әле. Хәтта пенсиягә чыккач та.

Минем соңгы китап чыгып килә.

Үзем канәгать түгел. Төрле яклап битарафмын. Була икән шундый тойгылар да.

Ярый хатны бетерим инде, озынлыгы белән синекеннән калышмады шикелле.

*Хөрмәт белән, Наҗар абыең.*

***

*11 август, 1994 ел.*

Халисә!

Кичә кич хатыңны алдым.

Мин пыр тузып мәкаләләр, истәлекләр яза-яза, кардиология диспансерында ятам. «Скорая помощь» белән китереп ташладылар, мондый почёт сезнең берегезгә дә эләкми, так что кемнән хат алганыңны белеп укы.

Дачада ухылдап йөргәндә, март аенда язылган бер шигырьне яңадан эшләдем. Яттан беләм, чөнки склероздан да дару бирәләр.

*Бу минутлар онытырлык түгел,*
*Алар синдәй илаһ затыннан.*
*Күңелемдә кояш чыга кебек*
*Күкрәп үткән яңгыр артыннан.*

*Бу минутлар онытырлык түгел,*
*Соңгы минутларга кадәре.*
*Җаным әйтә шулар өчен дә бит*
*Яшисе бар икән, бар әле.*

*Бу минутлар онытырлык түгел,*
*Бар булмышың илаһ затыннан.*
*Кояш чыга кабат яшьлек дигән,*
*Сөю дигән таулар артыннан.*

Күп язарга тырышам, язып калырга кирәк. Ишек шакый төсле теге «абзый».

Атнабай турында яздым, Марат турында башладым, Сәйфи ага Кудаш турында яздым, Шәриф Бикколга яздым, Гыйлемдар Рамазановка яздым, Шәрәф Әхмәмәткә яздым. Монда килгәч, «Ярату – мәхәббәт чыганагы» дигән мәкалә яздым. Бу минутларда узган ел августта язылган мәкаләне сипләп утырам. Монысын яратмыйм, татарларны башкортлаштыруга каршы.

«Кызыл таң»га, «Башкортостан»га шәлкемнәр бирдем.

«Якынаю» китабы чыкты булса кирәк, күрәсем килми.

Менә сиңа буталчык фикерләр.

Үлгәнче, бер бик шәп шигырь язып булса иде.

*Наҗар абыең.*
*15 август, 1994 ел.*

***

Халисә сеңлем!

Эшләрем бетте дә, берни эшлисем килми, сиңа хат язам.

«Рәйхан»ны карадым. «Кызыл таң»га «Шәл һәм орчык, мич һәм җыр» дигән отзыв яздым. Бу кичәге повтор икән . Мин шәл өлешен карадым да, мич чыгаручыга җиткәч, телевизорны сүндердем, әй, белгән булсам. Синең өлешең дә бик ошады.

Сиңа җибәргән шигыремне Диләгә дә укыдым, ул яныма килде, китаплар китергән иде, аңа да бик ошады. Дилә киткән иде, Әмирхан Еники килде. «Шәрык» кино эшли,

безнең очрашуны төшереп алдылар. Озак кына сөйләшеп утырдык. Аннан сеңелкәш килде. Дәвалаучы врачка да «Рәйхан» хакында сөйләдем. Караган икән, врачларча реагировать итте.

Менә хат та язылып бетте.

Палатада берүзем, көн кичкә авыша. Дилә китергән китаплар белән калам, ошасалар ярар иде.

*Наҗар абыең.*

***

*8 сентябрь, 1994 ел.*

Халисә сеңлем!

Хатыңа җавап яздым да җибәрергә уңайсызландым. «Наҗар абый бирешкән, мин аны көчле кешегә саный идем» диярсең дип уйладым. Нишлисең, авырганда башка әллә нинди уйлар керә.

Дачада берүзем. Иртәнге сәгать 4.

«Шәл һәм орчык, мич һәм җыр»ны «Кызыл таң»да укыдыңмы икән? Синең хакта әзрәк җылылык җитмәгәнен гәзиттә чыккач кына сиздем. Больницада язылды бит, бәлки шул мохит тәэсир иткәндер. Кызык: больницада Шәриф Биккол, Шәрәф Әхмәмәтов, Зәкәрия Акназаров турында, «Ярату – матурлык чыганагы» дигән мәкаләләр яздым. Узган елгы «Милли тойгы һәм милли чир» дигән мәкаләне яңадан язып чыктым. Вот тебе больной!

Синең больницада ятып чыгуыңа каршымын, андый җиргә минем яшьтә генә керәләр. Бу хатны Наҗар абый җавап та язмады дип әйтмәс өчен генә язам. Көн дә Уфага кайтып йөрим. Румыниягә китү мәшәкате белән йөрим. Арыйм.

Вакытың булса хат яз. Мин киткәнче килеп өлгермәс тә инде.  Авырма. Менә шул.

*Сәлам белән, Наҗар абыең.*

***

*24 ноябрь, 1999 ел*

Халисә сеңлем!

Яңа йортка, яңа адрес буенча килгән беренче хат – синнән! Күңелгә бик тә рәхәт булып китте. Телефон аша да беренче булып синнән хәбәр алган идем.

Хәйдәр Бигичев хакындагы истәлекне бүген иртән язып бетердем, дөресрәге, акка күчердем.

Ярыйсы булып чыкты, формасы белән кызык тоела, ә исеме «Әйтелми калган тост». 5 нче мартта Әмирхан ага Еникинең юбилей кичәсе. Фәридә Кудашева белән икебезне чакыра. Авыр булса да, бармый булдыра алмыйм, ул мине бик тә якын күрә бит!

Дүртөйледән туры Казанга «Волга»да китмәкчебез. Истәлекне дә үзем белән алып барырмындыр, бер үк көнне барып керербездер.

Ул истәлек мәсьәләсе ничек итеп Нуриманга барып чыкты соң? Рифат Фәттаховка бәйлеме? Кызганычка каршы, мин ул егетне белмим.

Йорт һәм аның урыны, туган җирем булгангамы, бик соклангыч кебек. Килгәч күрерсең әле. Ике шигырь яздым. Беренчесе – «Егет сүзе», икенчесе «Берәү» дип атала.

Хәзергә үземне «Миништинский пленник» дип атадым. Телевизорга тышкы антенна куелмаган. Бүген телефон куйдылар. Номеры: 66-632, бу вакытлыча бугай. Авыл һәм район арасында бәйләнеш өчен ярап тора. Район үзәгендә һәм авылда мөнәсәбәтләр бик яхшы. Йортта 5 ноябрьдә 81 яшь тулган көнне яшәтә башладылар. И гомер! Әле генә 80 иде бит!

Вакытың булса, язгалап тор, ни әйтсәң дә, мин башка чыккан кеше бит әле. (Шаяртам). Киләчәктә планнар зур.

*Сәлам белән, Наҗар абыең.*



*Каләм ияләре «Казан утлары» редакциясендә (сулдан уңга): Равил Фәйзуллин, Самат Шакир (аның тууына бу айда 100 ел тула), Шәүкәт Галиев, Марс Шабаев, Нәби Дәүли, Зәки Нури. 1964 ел.*



*Бу айда озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире булып эшләгән журналист, публицист, тарих фәннәре кандидаты Шәмси Хамматовның (сулдан беренче) тууына 105 ел тула.*

*«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә. Сулдан уңга: газетаның партоешма секретаре Марат Әмирханов, «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы мөхәррире Ибраһим Үзбәков, сәркатип Сәкинә Алтынбаева, баш редактор Шәмси Хамматов.*





*Шагыйрә Бикә Рәхимова (1939-2011).*



*Бикә Рәхимова һәм Равил Фәйзуллин Новосибирск шәһәрендә армия хезмәтендәге уллары Алмаз янында. 1987 ел.*




*Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсеннән соң. Беренче рәттә (сулдан уңга): Гариф Ахунов, Шәһидә Максудова, Сара Садыйкова, Сибгат Хәким, Фәхри Насретдинов, Нәҗия Теркулова, Фатих Хөсни. Икенче рәттә: Миңгол Галиев, Ренат Таҗетдинов, Вафирә Гыйззәтуллина, Айрат Арсланов, Разия Гайнуллина, Заһид Хәбибуллин, Фасил Әхмәтов, Дания Нуруллина, Бикә Рәхимова, Николай Беляев, Равил Фәйзуллин, Эльс Гаделев, Марсель Галиев. Казан. Төзүчеләр мәдәният сарае. 1976 ел.*

*Фотолар Равил Фәйзуллин һәм Габделбәр Ризвановның шәхси архивларыннан алынды.*

*Самат Шакирның тууына – 100 ел*

# БАТЫРЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК ҖЫРЧЫСЫ



Күренекле эзтабар язучы, шагыйрь, педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында дистәләгән документаль әсәр авторы Самат Шакирның (1924–1988) тууына 100 ел тулды.

Журнал укучылар игътибарына хәзер инде «тарихи» дип тамгалана торган бер язма тәкъдим ителә. Моннан төп-төгәл 10 ел элек, Татарстан Язучылар берлегенең Габдулла Тукай исемендәге клубында язучының тууына 90 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узган иде. Сез менә кичәнең беркадәр кыскартылган язмасын тыңларсыз. Нәкъ менә шушы тапшыруга мөрәҗәгать итүебез юкка гына түгел, чөнки анда Самат Шакирның иҗаты да, тормыш юлы да шактый тулы итеп күрсәтелә.

Кичәне Фәнис Җиһанша алып бара, язучы һәм галим, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин кыска гына вакыт эчендә язучының иҗатына гаҗәеп тирән анализ ясый. Әлеге язманың «Газиз тавышлар» рубрикасына ятышып торуы тагын шунда: кичәдә мәрхүм Искәндәр Биктаһиров та катнашкан булган һәм ул Самат Шакир шигырьләренә иҗат ителгән җырлар башкарган.

Сүз уңында әйтик, Татарстан радиосы фондында аның 12 җыры саклана. Үз вакытында аның шигырьләренә халкыбызның иң олпат композиторлары еш мөрәҗәгать иткән, «Медалемне алып уйга калдым» (Мәсгуть Латыйпов музыкасы), «Яраннар чәчәк аткан» (Фасил Әхмәтов), «Төнбоеклы күл буенда» (Әнвәр Бакиров), «Балтачым – туган ягым», «Болыннарда икәү йөргән идек» (Сара Садыйкова) кебек җырлар озак еллар дәвамында популяр булып килделәр.

Кичәдә шулай ук язучының якташлары катнашкан, туган авылы Күәм мәктәбе укучылары башкаруында аның шигырьләре язылып калган. Хәзер инде бу укучылар үзләре дә зур кешеләрдер, моннан ун ел элек ясалган язма аларны да битараф калдырмас, дип уйлыйбыз.

...Һәм менә без тапшыруның иң кызыклы урынына җитәбез – Самат Шакирның үз тавышы ишетелә. Хәтердә, әлеге язманы кичәне оештыручылар бездән – Татарстан радиосыннан сорап алганнар иде.

Шагыйрьнең шигырьләре Татарстанның халык артисткасы Луара Шакирҗан укуында да яңгырый. Кичә күренекле җырчыбыз мәрхүм Рафаэль Сәхәбиев башкаруында «Өч нарат» (Фәрит Хатыйпов музыкасы) дигән җыр белән тәмамлана.

Самат Шакирның кем булуын, иҗатының әһәмиятен, мирасының зурлыгын аңларга-тоемларга теләгән кеше бу тапшыруга битараф калмас. Әйдәгез, якты рухын искә алып тыңлыйк.

*Бикә Рәхимованың тууына – 85 ел*

# ОНЫКЛАРЫМ БЕЛӘН БЕРГӘ ЯЗАМ



Шагыйрә, балаларның яраткан язучысы, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, галимә һәм педагог Бикә Рәхимованың тууына 85 ел тулды.

«Татар энциклопедиясе»ндә әдибә турында менә мондый төп мәгълүматлар бирелгән: Бикә Рәхимова (Фәйзуллина Миңнебикә Рәхмәтулла кызы) 1939 елның 10 апрелендә, Әлки районы Чуаш Кичүе авылында дөньяга килә. 1963 елда Казан университетын тәмамлаганнан соң, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1973 елдан Казан мәктәпләрендә татар теле укыта. 1980–1994 елларда Татарстан китап нәшриятында әдәби басмалар мөхәррире.

«Сәрвиназ» (1986 ел), «Ачыл, күңел!» (1989 ел), «Иделләр казанында» (1999 ел), «Мәрхәмәт» (2005 ел), балалар өчен «Кырмыскалар өендә» (1991 ел), «Урман радиосы» (1995 ел), «Җайдак малай» (2007 ел) шигырь җыентыклары, «Бакый сагыш» (2009 ел) публицистика китабы авторы Б.Рәхимованың иҗаты фәлсәфи мотивларга, халыкның яшәеше турында лирик уйлануларга бай.

2011 елның 9 мартында Казанда вафат була, туган авылында җирләнә.

Татарстан радиосы ел саен апрельдә – шигърият аенда Бикә Рәхимованың туган көнен билгеләп үтә. Быел да аның тууына 85 ел тулу уңаеннан әдәби тапшырулар циклы әзерләнде. Әйтик, шагыйрәнең китабы исеме белән аталган «Ачыл, күңел» дигән әдәби-музыкаль композициядә шигырьләре һәм аларга язылган җырлар урын алды. Язучының «Әткәй миче» хикәясе Луара Шакирҗан укуында эфирга чыга.

Журнал укучылар игътибарына без Бикә Рәхимованың үз тавышы кергән бер язма тәкъдим итәбез. 2010 ел ахырларына радионың балалар һәм яшүсмерләр редакциясе мөхәррире Дания Гайнетдинова шагыйрәне «Язучылар – балаларга» дигән тапшыруга чакыра. Аңлашыладыр ки, ул биредә балалар язучысы буларак катнаша, балалар өчен язылган шигырьләрен укый, аның сүзләренә иҗат ителгән җырлар яңгырый. Әдибә биредә балалар әдәбиятына кагылышлы фикерләре белән дә уртаклаша. Бу өлкәдәге катлаулы мәсьәләләрне гади генә, җайлы гына итеп аңлата да бирә. Мисалга әңгәмәдән менә бу сүзләрен китерик:

«Мин соңгы 2-3 елда үземнең оныкларны багарга булышам бит. Алар миңа шигырь язарга да ярдәм итә. Аларның хәтта аерым юллары шигырьгә кереп китә, үзләреннән-үзләре шигырь сөйлиләр кебек. Мин оныкларым Чулпан һәм Ильяс белән бергә иҗат итәм...»


Инде әйдәгез, QR-код ярдәмендә сайтыбызга кереп, шушы язманы тыңлыйк.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# ӘДӘБИ СКАНВОРД

Хәбир Ибраһимнең тәхәллүсе

Язучы Әхәт ...



Язучы ... Мөхәммәтшин

Гаяз Исхакый повесте

Моторлы яки җилкәнле судно

Фәхрелислам ... (балалар язучысы)

Лев Толстой титулы

Шагыйрь ... Гыйләҗев

... Жароков (казакъ шагыйре)

Зиннур Хөснияр романдилогиясе

Ягулык та, ашлама да

Рус химигы

Байрак, флаг

Язучы ... Хафизова

Образ, характер

Әмирхан ...

Шәймиев фатихасы белән ачылган мәктәпләр

... Барбюс

Мәңге яшел куак, лавр

... Бажов (рус язучысы)

... Исәнбәт

... Батыршина

Архитектура стиле

... Кари (балалар шагыйре)

Хуҗа Әхмәт ...

Шагыйрь ... Вәлиуллин

... Кристи

... Зәйдулла

Шагыйрь Харрас ...

Җәй ае

... Челидзе (грузин шагыйре)



Көннең читен чигеп бизәк төшерү

Россиядәге өлкә үзәге

Кинофильм кадрындагы язма

Актёр ... Пачино

... Лиснянская (рус шагыйре)

... Сойер

... Гарипов (башкорт шагыйре)

**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Ихсанова, Аппакова, Гәрәй, Дефо, карел, Савва, Гек, муел, «Ника», Литва, Лилия, «Яз», «Тозак», Фаил, Юныс, «Рәшә», авар, кое, Рид, Лас, Ги, Лев.* ***Өстән аска:*** *ифтар, Есенин, Вил, Факил, Ирада, Имамов, «Кияүләр», Аяз, каз, Вәкил, абага, лото, Кәрими, Юзеев, Оноре, Утыз, Вәлиев, Ары, Абай, лаек.*

# İctimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ

15, 16, 17 мартта Россия Президентын сайлаулар булды. Республикада тавыш бирү өчен 65 территориаль, 2722 участок сайлау комиссиясе эшләде. Аларның эшен 22 мең кеше тәэмин итте. Сайлау участокларында 16 меңнән артык күзәтүче (шул исәптән чит илләрдән) эшләде. Татарстанда сайлаучыларның 84,61 проценты тавыш бирде. «Гаилә белән сайлыйбыз» марафонында өч Lada Vesta автомобиле уйнатылды. Марафонда 71 мең сайлаучы катнашты. Республикада Владимир Путин – 88,74, Николай Харитонов (КПРФ) – 4,83, Леонид Слуцкий (ЛДПР) – 3,93, Владислав Даванков («Яңа кешеләр») 1,53 процент тавыш җыйды. Татарстанда хокук бозу очраклары теркәлмәде, сайлау нәтиҗәләренә йогынты ясый торган шикаятьләр килмәде.

## ОЧРАШУ

Татарстан Язучылар берлегендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов урта буын татар язучылары белән очрашты. Очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, язучылар Рүзәл Мөхәммәтшин, Рифат Сәлах, Гөлүсә Батталова, Айсылу Имамиева, Эльмира Җәлилова, Булат Ибраһимов, Дания Нәгыйм, Лилия Гыйбадуллина, Ландыш Әбүдәрова, Илгиз Зәйниев, Резеда Гобәева катнашты. Очрашуда сүз гаиләдә, шулай ук балалар бакчаларында, мәктәпләрдә милли тәрбия бирү турында барды. Балаларны һәм яшүсмерләрне җәлеп итәрлек әдәби әсәрләргә ихтыяҗ турында да сөйләштеләр. Киләчәктә «Мәктәп сәхнәсе» дигән җыентык нәшер итәргә килештеләр. Очрашу ахырында Марат Әхмәтов язучыларга иҗат уңышлары теләде. Чарада ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов катнашты.

## ЧАЛЛЫДА ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Чаллы шәһәре иллегә якын кунак кабул итте. Болар – язучылар, журналистлар, мәдәният хезмәткәрләре. Алар каланың мәктәп, гимназияләрендә укучылар алдында чыгыш ясады. Укучылар да җавапсыз калмады, шигырьләр сөйләде, җырлар җырлады. Әдәбият бәйрәменең төп тантанасы Чаллының А.Гыйләҗев исемендәге татар дәүләт драма театрында булды. Монда шагыйрь, прозаик, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Факил Сафинга 70 яшь тулуны билгеләп үттеләр. Юбилярны Чаллы шәһәре мэры Наил Мәһдиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТРның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Мөслим муниципаль районы башлыгы Альберт Хуҗин, әдипнең каләмдәшләре, якташлары котлады. Кичәдә Факил Сафинның шигырьләрен, әсәрләреннән өзекләр укыдылар, җырларын җырладылар.

## ӘНГАМ АТНАБАЕВКА ҺӘЙКӘЛ

Башкортстанның Тәтешле районында Башкортстанның халык шагыйре, драматург, публицист Әнгам Атнабаевка һәйкәл ачылды. Ул Ленин урамындагы үзәк китапханә каршына куелган. Аны ачу тантанасында Казаннан кунаклар – «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин катнашты.

## ТҮБӘН КАМАДА «ЧИЧӘННӘР ҖЫРЫ»

Түбән Каманың Т.Миңнуллин исемендәге татар дәүләт драма театрында «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсенең быелгы беренче кичәсе шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин иҗатына багышлап үткәрелде. «Чичәннәр җыры» дип аталган әлеге чараның төп кунагы үз шигырьләрен сөйләде. Кичәне алып баручыларның сорауларына җаваплар бирде. Бәйрәмдә Түбән Кама татар

дәүләт драма театрының баш режиссёры Рөстәм Галиев, шагыйрьнең каләмдәшләре: Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, язучы Рөстәм Галиуллин, шагыйрьләр Ләбиб Лерон, Йолдыз Миңнуллина, Фәнил Гыйләҗев, Дания Нәгыйм, журналист Рузилә Мөхәммәтова, шәһәрнең Фатих Кәрим музеена килгән делегация вәкилләре, шул исәптән каһарман-шагыйрьнең оныгы Артём Кәримов, музей белгече Флёра Дәминова, Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылыннан (Ф.Кәримнең туган авылы) килгән кунаклар һ.б. катнашты. Марат Фәйрушин, Руслан Хәсәнов җырлары, театр артистларының, әдипнең Кукмарадан килгән якташларының чыгышлары бәйрәмне тагын да ямьләде. Сәхнәдә Рүзәлнең улы Идел дә чыгыш ясады.

## НИЯЗ АКМАЛНЫ ИСКӘ АЛУ

Чаллы үзәк китапханәсендә шагыйрь, прозаик, журналист Нияз Акмалның тууына 70 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, Башкортстаннан шагыйрә Фәния Габидуллина, автор-башкаручы Риф Гатауллин, Г.Камал театры артисты Фәридә Сафина, композитор Айдар Тимербаев, җырчы Гөлдания Хәйруллина, Ниязның бертуган апасы Энҗе ханым белән бертуган энесе журналист Нәсим Акмал һ.б. чыгыш ясады.

## ЮБИЛЕЙ

Теләче районы Мәдәният йортында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, шагыйрә Равилә Шәйдуллина-Муратның юбилей кичәсе булды. Юбилярны гомер бәйрәме белән район башлыгы Нәҗип Хаҗипов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, татар-төрек язучысы, тәрҗемәче Фатих Кутлу, кинорежиссёр Нурания Җамали һ.б. котлады. Кичәдә Равилә Шәйдуллина-Муратның шигырьләрен, әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

## «БЕРӘҮ» ПОВЕСТЕ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиянең Анкара каласындагы «Һәҗә» нәшриятында татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗевның 1959 елда иҗат иткән «Берәү» повесте төрек телендә басылып чыкты. Әсәрне каләмдәшебез Фатих Кутлу тәрҗемә итте.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышы булды. Аны берлек рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды. Аның урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Факил Сафин ике утырыш арасында башкарылган эшләргә хисап ясадылар. Аннары Татарстан Язучылар берлегенең 90 еллык юбилеен уздыру турында сөйләштеләр. Бәйрәмне май аенда «Корстон»да үткәрү күздә тотыла. Идарә әгъзалары  Ульяновск җәмәгатьчелегенең үзләрендә Татарстан Язучылар берлегенең бүлекчәсен ачу турындагы хатүтенечен тыңлады һәм бертавыштан хуплады. Утырышта шагыйрә, прозаик, драматург, тәрҗемәче Рауза Хуҗәхмәтова белән шагыйрә, популяр җырлар авторы Гөлчәчәк Садретдинова Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

## ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Кәеф» медиалабораториясендә «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе һәм «Интертат» сайты баш мөхәррире Рәмис Латыйповның «Атмый калган таң» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә чыгарылган егерме бишенче китап. Чарада «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, китапның мөхәррире, язучы Вакыйф Нуриев чыгыш ясады. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Фәнис Җиһанша әлеге басмага кертелгән «Салдат мәхәббәте» хикәясеннән өзек укыды. Салих Сәйдәшев музееның өлкән фәнни хезмәткәре Раушания Җиһангәрәева «Солдатлар» (Роберт Әхмәтҗанов сүзләре, Фәтхерахман Әхмәдиев көе) җырын башкарды. Китап бәйрәменә килгән КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе студентлары яңа китапка багышланган викторинада катнашты. Кичәне «Татар-информ» һәм «Интертат» сайтларының SMM белгече Милена Новикова алып барды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХАКИМА «Таинственная монета», повесть И.ДИНДАРОВА «Чёрные дни белых ночей», рассказ Н.ХАРИСОВОЙ «Я должен вернуться»;*
*поэма Г.БАТТАЛОВОЙ, стихи Р.ХАРИСА, Т.ШАМСУАРОВА.*
*«Новые имена»: стихи Ф.ЗЫЯЛЫ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Л.ФАТТАХОВОЙ «Род Гаяра».*
*«Литература родственных народов»: рассказ Д.МОИСЕЕВА «Малина с чужого сада» в переводе Л.АБУДАРОВОЙ.*
*«Литературная критика»: статья Г.ГАЙНУЛЛИНОЙ.*
*«Литературное наследие»: стихи Р.НИЗАМИ с предисловием Р.КУРБАНА.*
*«Драгоценности души»: статья И.ТАГИРОВА.*
*«Обзор книги»: статья Ф.САФИУЛЛИНОЙ.*
*«Соплеменник»: интервью А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с меценатом И.ГИМАДОВЫМ.*
*«Памятные письма»: письма Н.Наджми к Х.Мударрисовой.*
*Фотоархив журнала.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 100-летию С.Шакира и 85-летию Б.Рахимовой.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: мост Миллениум г. Казани. Фото И. АБРАМОВОЙ;*
*доктор филологических наук Ф.САЙФУЛЛИНА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by Z.KHAKIM «The Mysterious Coin», story by I.DINDAROV «Black Days of White Nights», story by N.KHARISOVA «I Must Return»;*
*poem by G.BATTALOVA, poems by R.KHARIS, T.SHAMSUAROV.*
*«New names»: poems by F.ZYYALI.*
*Literary competition «Morals of the Father's House...»: story by L.FATTAKHOVA «The Gayar Family».*
*«Literature of kindred peoples»: story by D.MOISEEV «Raspberries from the other man's garden» translated by L.ABUDAROVA.*
*«Literary critics»: article by G.GAYNULLINA.*
*«Literary Heritage»: poems by R.NIZAMI with preface by R.KURBAN.*
*«Pearl of the Soul»: article by I.TAGIROV.*
*«Book review»: article by F.SAFIULLINA.*
*«Tribesman»: interview by A.KHABIBULLINA with philanthropist I.GIMADOV.*
*«Memorable letters»: letters from N.Najmi to Kh.Mudarrisova.*
*Photo archive of the magazine.*
*«Priceless voices»: articles for the 100th anniversary of S.Shakir and the 85th anniversary of B.Rakhimova.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the Millennium Bridge in Kazan. Photo by I.ABRAMOVA;*
*Doctor of Philology F.SAYFULLINA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Миллениум күпере.
*И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* әдәбият галиме Флёра СӘЙФУЛЛИНА.